# Казан утлары

2
ФЕВРАЛЬ-1971

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

2

ФЕВРАЛЬ
1971

## Бу санда:

### РОМАН, ПЬЕСА, ШИГЫРЬЛӘР:

С. РАФИКОВ. Тын елга буенда. Роман . . . . 3
И. ЮЗЕЕВ. Юк, мин яши алмыйм алай... Хушыгыз! Мин китәм еракка!.. Бәрәңге чәчәге. Үз-үзеңне эзләп табыйм диеп... Аннан бирле күпме печән үсте... Заман агышыннан калуларын... Яшьтәшләре бар да яуга киткән... Йокыга талды арып кайткан... Балалыкка кире кайтыйм әле... Йөзек кашы. Мин сине нигә яратам!.. Шигырьләр . . 51
Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Карт. Хикәя . . . . . . . . 56
Р. ЗАКИРОВ. Яшим әле... Буразналар сызам... Дуслык. Чалт аяз булса да бүген көн... Ялга кайткач. Һаман көтәсең... Шахтерлар сүзе. Мәхәббәт турында җыр. Кошлар юлы. Кайвакыт төн буе поездда... Манара. Инде вакыт... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 62
К. СИБГАТУЛЛИН. Туу. Юл башы. Әманәт. Заман кәтә. Йөз дусың юкта... Мәҗнүн. Киткәндә. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 66
А. ГЫЙЛӘҖЕВ, А. ЯХИН. Шамил Усманов. Драма . 69

### БЕЗДӘ КУНАКТА

Бай да, бөек тә, тирән дә . . . . . . . . . . 109
М. ТУРСУНЗОДА. Кояш белән хатын-кыз. Шигырь. 110
М. МИРШАКАР. Беркет. Шигырь . . . . . . . 111
А. КАХХОРИ. Елмаю. Шигырь . . . . . . . . 112
Ф. АНСОРИ. Юлда. Шигырь . . . . . . . . . 113
М. КАНОАТ. Разлив. Шигырь . . . . . . . . 113
У. РАҖАБ. Сукмак. Шигырь . . . . . . . . . 114
М. ХӘКИМОВА. Энҗе бөртеге. Шигырь . . . . 115
Л. ШЕРАЛИ. Соңгы җыр. Шигырь . . . . . . 116
Х. ФАЙЗУЛЛО. Җилгә әйтә агач. Шигырь . . . 116
Б. ГАНИ. Изге эш. Хикәя . . . . . . . . . . 117
СОРБОН. Төш. Хикәя . . . . . . . . . . . . 119
У. КУКЗОД. Дөя кайдан килеп чыккан. Хикәя . . 121
Ф. МӨХӘММӘДИЕВ. Мәгърифәт урыны. Хикәя . 122

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

И. НАДИРОВ. Хөрлеккә өндәүче моңнар . . . . 123

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ПУБЛИЦИСТИКА

**А. АЙНЕТДИНОВ.** Ватан сугышы һәм язучылар . 131

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**һ. МӘХМҮТОВ.** Сәет Шәкүров драмалары . . . 139

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

**Р. МОСТАФИН.** «Оҗмах»ка сәяхәт. Юл язмалары. 145

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**Ә. НӘҖИП.** Уртак хәзинә . . . . . . . . . . . 173

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Х. МӘХМҮТОВ.** Җәүһәрләр сандыгы . . . . . . 178

Безнең сафка . . . . . . . . . . . . . . . 183

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

**Ф. ШӘФИГУЛЛИН.** Хөкем. Идея. Анекдот һәвәскәре. Кышкы иртәдә. Диалоглар . . . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63, Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Техник редакторы Р. Набиуллина. Корректоры Р. Сулейманова.

Производствога бирелде 2/XI-1970 ел. Басарга кул куелды 25/XII-1970 ел. ПФ 09142. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 17,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 80846 экз. Заказ С-597. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды, Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1971 ел.

Сөббух Рафиков

# ТЫН ЕЛГА БУЕНДА

РОМАН[1]

## I

Тагы шулай яз килде...

Бер уйласаң бик гаҗәп шул — хисапсыз күп эреле-ваклы мамык мендәрләр сыман күперәп торган ап-ак кар диңгезе өстеннән мәһабәт рәвештә шуып бара һава кошы. Артта ни хәтле кар чокырлары кала. Һичбер төрле сикәлтә, салулар сизелми. Кинәт каршыда ниндидер зур ак тау үсеп чыга. Менә, менә барып бәрелерләр дә шунда инде коточкыч хәл булыр сыман тоела. Колакларда мотор тавышы бер көчәя, бер тоныклана. Ул да булмый, күз алдында зәңгәрлек ачыла. Монысы инде хәвефле кар тауларыннан һич көтмәгәндә диңгезгә килеп чыгуны хәтерләтә. Юк, диңгез түгел! Аста әллә нинди шәкелләргә охшап, каралып, урманнар, авыллар күренә. Кечкенә тәрәзәләрдән төшкән кояш нурлары самолет эчен яктыртып җибәрә. Бары шунда гына ул самолет тәрәзәсеннән карашын ала. Һәр ике як стена буйлап тезелгән, ак җәймә корылган креслоларның барсына да кешеләр утырган. Халык чуар — ирләр дә, хатын-кызлар да бар, балачага да күренә.

Бераз онытылып барганнан соң, ул тагы карашын тәрәзәгә салды. Инде болытларның сирәгәюе сизелә, аста җир тормышы ачыграк күренә, сыртлары карала башлаган ак дулкыннар берсен икенчесе алмаштыралар. Киң кырлардагы салам эскертләре ак койрыкларын сөйрәп йөгергән ниндидер борынгы заман хайваннарын хәтерләтәләр. Ә чокырлардагы агачлар кышкы салкыннардан куркып яшеренгәннәр дә, яз кояшы карый башлагач, гүя башларын калкытканнар. Бер карасаң, әле чын кыш, бер карасаң... Мәгәр, моннан ике генә көн элек җир өсте

---

[1] Беркадәр кыскартып басыла.

ярым чуарланып килә иде кебек. Ә бүген... Күрәсең, төнен кар яуган да, аяк астын чиратып, җиргә ертык ак җәймә капланган. Ни хәтле генә карама — барыбер күреп туярлык түгел...

— Васил Закирович, килеп тә җитәбез,— дигән тавышка Сафин сискәнеп китте. Инде эчне пошыра башлаган самолеттагы бер төрлелек тагы аны чеметеп алгандай булды. Каршыдагы креслода утырган Зиннур Гафиятуллинга теләр-теләмәс кенә күз төшерде.

— Шулай шул, әнә Сөембикә манарасы да артта калды.

— Бу соңгы елларда Казанда булганым юк иде, аны бөтенләй танырлык түгел. Яңа кварталлар, нихәтле дәү-дәү йортлар! — дип тантаналы төстә сөйләнеп барды Зиннур.

Юлдашы Васил Сафин да аны җавапсыз калдырмады:

— Бәхәссез зур үзгәрешләр монда. Үсеш...

Зиннур кайчандыр яшьлек елларында беренче мәртәбә аяк баскан, күңелгә якын бу шәһәргә соклануыннан тиз генә туктамады.

Озакламый алар утырган самолет, җилләр уйнатып, зур аэропортка килеп төште. Самолеттан чыгуга Сафинның җиңелчә генә башы әйләнеп китте. Берничә минуттан соң инде алар, нәкъ базардагы шикелле, ыгы-зыгы, шау-шу белән кайнашып торган аэровокзалның киң залына, халык арасына кереп югалдылар.

Зиннур да Сафин артыннан калмады. Алар юлга җиңел чыкканнар, кулларында берәр чемоданнан башка әйбер юк иде. Чемоданнарын почмаккарак илтеп куйдылар да, әйберләр янында Зиннур калып, Сафин белешергә китеп барды. Монда һәркем каядыр ашыга, зур пыяла ишекләр бер ачыла, бер ябыла, кешеләр хәрәкәте һич тә тукталып тормый. Сафин шул кайнашып торган ыгы-зыгы эчендә залның урта бер җирендәге будкага, белешмәләр бюросы каршына чиратка басты. Дежурный телефоннан сөйләшкәнлектән һәм кайберәүләр чиратсыз кергәнлектән, ул тәрәзәгә җиткәнче байтак вакыт үтте. Будкада утыручы тулы гәүдәле, болай төскә-биткә ярыйсы гына күренгән, урта яшьләргә якынлашып килгән хатынга сорау биреп, аның җавабын ишеткәч, Сафин, бер мәлгә югалып калгандай, аптырап торды. Чөнки алар барасы урынга, бу язгы былчыраклар башланыр алдыннан, самолетлар очудан туктаган икән. Сафин сораулы кыяфәттә Зиннур янына әйләнеп килде.

— Инде нишлибез?

— Тимер юл белән китсәк,— диде Зиннур.

— Алай да бик мәшәкатьле, шайтан алгыры...

Тәмәке төтене белән зәңгәрләнгән, төрле истән тынчулангаң залда башкача түзеп торырлык әмәл калмагач, чемоданнарын күтәреп һавага чыктылар. Җиләс саф һава шундук сулышларына рәхәт итты. Аэропорт бинасы алдындагы аркалы эскәмиягә килеп утырдылар. Зиннур кесәсеннән папирос чыгарды, көйрәтеп җибәрде. Бу ләззәтле һавада папирос тарту да ничектер күңелле иде. Бераздан инде ул пальтосының изүләрен чишеп җибәрде. Аннары, Сафинга ара-тирә күз кушып, тирә-якны күзәтергә кереште. Көннен чырае төксе булса да, сыек болытлар арасыннан кояш күренгәли, ул җиргә нурларын мул итеп коеп калырга ашыга иде. Бер арада Зиннур:

— Нindirәk җир икән ул? — дип сорады.

— Наратлыны әйтәсеңме?

— Юк, Яңа Наратлыны.

— Аның искесен, яңасын кем белә инде, баргач күрербез,— диде Сафин.

— Минем ул тирәләрдән бәләкәй чакларда гына үткәнем бар. Иске Наратлы олы авыл иде. Яңасы да шуннан ерак булмаска тиеш.

Зиннурның да күңеле тынгысыз иде. Чигәләренә нечкә генә итеп бакенбард үстергән, куе кара кашлы, туткылрак озынча битле, урта

гәүдәле бу тулы яшь иргә күн пальто, яхшылап чистартылган күн итек нечектер бик килешә. Аның да күңеле юлдашыныкы кебек үк тынгысыз иде. Зиннур папиросын, тартып бетермәгән килеш, якындагы чүп савытына ташлады да янә икенчесен алып кабызды. Һавага зәңгәрсу төтен мамыклары чыгара-чыгара, дәвам итте:

— Алда тагы күчү мәшәкатьләре! Квартира артыннан йөрисе, семьяны чакыртасы, тегесе-монысы...

Куйбышев төзелешен барлыкка китерүдә катнашкан бу ике кеше, төрле-төрле участокларда эшләгәнлектән, бер-берсен ныклап белмиләр, берсе икенчесенең гаилә хәлләре белән дә таныш түгел иде. Шуңлыктан, ахры, әле Зиннур сүзгә керешкәч, Васил сорый куйды:

— Сезнең балаларыгыз ничәү соң?

— Икәү.

— Зур түгеллэрдер әле?

— Малай беренчедә укый. Кызыбыз детсадка йөри.

— Хатыныгыз?

— Арматурачы иде. Менә өченче ай инде болытларга үрмәли.

— Кранчымы?

— Әйе.— Зиннур эскәмиянең икенче башына шуышыбрак утырды, бер карчыкның күгәрченнәр туйдыруын кызыксынып карарга кереште.

Сафин тигез итеп киселгән куаклыкларга күзен төшерде. Карасу-кызгылт ботаклардагы бөреләр, көздән бүртеп калсалар да, нигәдер әле генә борын төртеп чыккан сыман күренәләр. Табигать язга таба борылган саен, алар җанланалар, яз сулышын, кояш җылысын тоеп, яктырып ачыла баралар. Зур шатлык кичергән шикелле чыр-чыр сайрашып, куаклар өстенә бер төркем чыпчык килеп кунды. Кышкы салкыннарны газапланып үткәргән бу әрсез кошчыклар җилпенә-кагына томшыклары белән канат асларын тазарталар, чистарыналар иде. Алардан берничәсе аерылып, куак төпләрендәге юеш карга төшеп, коенырга тотындылар. «Яз. Җанлылык арта. Йомычкалар кузгалыр чаклар җитә...» — Сафинның башыннан шундый уй йөгереп үтте. Ләкин тирә-яктагы күренешләр һәм яз галәмәтләре аның күңелен озак биләп тора алмады. Аның борчылырлык уйлары бар иде.

...Чыннан да әллә ул хаклымы? Кайчан соң алар утрак тормышта яши башларлар, башкалар кебек вакытында эштән кайтып, вакытында ял итеп иркенрәк гомер кичерерләр? Китәр алдыннан хатыны Нурзилә белән булган кискен сөйләшү әледән-әле аның хәтер капчыгыннан калкып чыга торды. Нигә болай кирегә сукалый соң бу Нурзилә?

...Васил Сафин, төзүче инженерлар институтын бетергәннән соң, берничә ел ерак Норильск якларында йөреп, янадан Идел буйларына әйләнеп кайтты. Егет атаклы Куйбышев гидротөзелешендә эшли башлады. Заман романтикасы белән тирәнтен рухланган иде ул. Зәһәр салкыннар, томанлы котып төннәре, әледән-әле кабатланып торган күз ачкысыз бураннар һәм барыннан да элек тынгысыз хезмәт эчендә үткән өч ел шактый чыныктырды аны. Ул үзе дә, иптәшләре дә моны ачык сизделәр.

Идел буендагы төзелештә, әле прораб чагында, гомерендә беренче мәртәбә Нурзиләне очратты. Бик салкын январь көннәренең берсендә, Васил төзелеш йомышларын юллап йөрде дә, юлаучы машинага утырып, өч километр читтәге изма үзәлына китте. Тегесе артыннан, монысы артыннан чаба-йөгерә, хәтсез генә вакытның авышканын сизми дә калды. Ул бары тик хезмәт көне бетәр алдыннан гына йомышларын юллады, гидротөзүчеләр поселогына кайтырга чыкты. Кайтасы дигәч тә, әле анысының да мәшәкате юк түгел иде. Вакытлыча юка такталардан гына укмаштырып куелган автобус тукталышындагы каралты янында нихәтле көтеп торсалар да, машина килмәде. Сабырлары төкәнә башлаган кешеләр ары йөренделәр, бире йөренделәр, җитмәсә алар-

га яңалар өстәлә торды. Вакыт кичегә иде. Васил кешеләр белән машина көтеп, гасабиланып йөренгәндә, кышка хас җылы киенгән, урта гәүдәле бер кызга күзе төште. Ул башкалар кебек өзлексез «җир үлчәми», күбесенчә, бер урындарак таптанып, үкчәсен үкчәсенә кагып тора иде. Төньяктан искән салкын җил торган саен үзенең зәһәрлеген арттыра барды. Теге кыз да җилгә аркан борылды. Ләкин кешеләр нихәтле көтсәләр дә, автобус күренмәде. Җир өстенә караңгылык пәрдәсе сарыла башлаганда, өметсезләнгән юлчыларның төрлесе төрле якка таралуын карады, әле берәмләп, әле төркемләшеп поселокка таба атладылар. Васил күзе төшкән кыз икеләнә иде, ахрысы, ул контора ягына карап-карап ала иде. Хәтта кыз бер тапкыр шул якка китмәкче булып берничә адым да атлады, аннары тукталышка борылып килде. Бу чыннан да китеп бармагае дигән кебек, Васил аңа саклык белән генә сүз катты:

— Болай торганчы җәяүләп киту артыграк булмасмы?

Кыз бераз көттереп җавап бирде:

— Минемчә дә шулай. Ләкин өшеп-туңып бетмәсәк?

— Анысына гына бирешмәбез,— диде Васил.

Алар бергәләп киттеләр. Битләрне чеметеп искән җилгә каршы баруы кыен иде. Кыз беркадәр җир Васил белән янәшә барганнан соң арткарак калды. Васил түзмәде, артына әйләнеп карады. Кыз интегәтартыша җилгә аркан бара иде. Бу хәлгә сәерсенгән егет аны туктап көтеп алмакчы булды. Бер арада чыр-чу иткән аваз ишетелде. Караса, ни күзе белән күрсен: кыз нәрсәгәдер сөртенеп егылган лабаса. Ул үзе торырга өлгергәнче, Васил йөгереп барып аңа кулын сузды. Янәдән бергәләшеп бара башладылар. Кызның ияк һәм бит алмалары бик туңган, ахрысы, ул әледән-әле битен куллары белән каплый, бәсләнгән чәчләре маңгаена төшеп уңайсызлый, үзенең артка каласы да килми, шул ук вакытта аңа Васил белән янәшә атлап баруы да кыен иде. Васил да ничектер уңайсызлана калды. Бу халәтне тойган шикелле, аны кыз үзе култыклап алды. Әче җилгә кыю каршы барган Василга сыенып атлау һәм егетнең салкынга бер дә исе китмәве гүя аны куандыра иде. Пальто якасын күтәрмәгән, бүрегенең колакчыннарын төшермәгән Василга кыз юл буе гаҗәпләнеп барды. Ахырында әйтмичә түзмәде:

— Сез котыпта да бирешмәс идегез.

— Монда андагы салкыннарның баласы гына.

— Сез төньякта булдыгызмыни?

Шундый сүз кузгалгач, Василга төньякта булуы турында ирексездән сөйләп бирергә туры килде. Шулай ара-тирә сүз алышкалап кайткангадыр инде, юл артык озын тоелмады. Бер-берсенең исемнәрен дә, кайда эшләүләрен дә белделәр. Васил Нурзиләне кызлар тулай торагы ишегеннән кертеп җибәрде дә үзе ашханәгә таба юнәлде. Әле күптән түгел генә салынган инженер-техниклар йортына, үз бүлмәсенә кайтып яткач та, башка вакыттагы кебек кулына китап аласы килмәде, күзләренә тиз генә йокы үрләмәде аның.

Бер көн үтте, ике көн, өч көн... Ләкин салкын төндә үзе белән бергә кайткан ягымлы кызны ул оныта алмады. Аннары түзмәде, телефон аша шалтыратып сөйләште. Шул ук көнне кич кызлар тулай торагына тагы шалтыратты. Нурзиләнең матур җырдай саф тавышы, маңгаена куе чәчләре чыгып торган ягымлы чырае, бераз гына моңсу, әмма тере күз карашлары, оялчан елмаюы, күгәрчендәй вак-вак атлап йөрүләре — берсе дә Василның күз алдыннан китмәде. Һәм әлеге кайнар эздән, суытмыйча, ул кичен кызлар торагына юл тотты. Бәхете икән — Нурзилә аны ачык чырай белән каршы алды. Алар ул көнне беренче тапкыр икәүләп киногa бардылар.

Моннан соң инде очрашулар, буш вакытларны бергә уздыру, озак-озак урамнарда йөрү, бер-берсе янына барулар гадәткә кереп китте.

[Н]урзилә танцы-бию дигәндә жанын да жәлләмәүчеләрдән иде. Басилга
[к]илса, ул бию һәм танцылар белән артык дус түгел, аның аяклары да
[к]ечектер авыррак йөри иде шикелле. Әмма яшьләр кичәләрендә күбә-
[л]әк кебек очынып йөргән Нурзиләнең күңеле кителмәсен өчен, аннан
[д]а бигрәк башкаларның аның мәгъшукасы белән әйләнүен жене сөй-
[м]әгәнгә, Василга еш кына түгәрәк уртасына чыгып, кызның нечкә би-
[л]еннән тотып тулганырга туры килә иде. Сонра ул мондый биюләрне
[ө]тәп ала торган булды. Тора-бара алар бер-берсеннән башка тора
[а]лмас хәлгә килделәр. Һәм тормышларын бергә бәйләргә ашыктылар.
[Л]әкин квартир яклары бик кыен иде. Загска барып язылышкач та, әллә
[н]ичә айлар аеры-чаеры яшәргә туры килде. Мондый халәт әйтеп бетер-
[г]ысез уңайсыз иде, билгеле. Ләкин беркадәр вакытлар көткәннән сон,
[м]онысы да юлга салынды. Яңа урамга беренче булып салынган дүрт
[к]атлы таш бинада аларга да квартир бирделәр.

Шулай итеп атналар үтә, айлар тәгәри һәм әкренләп еллар да
[у]зыша торды. Васил белән Нурзиләнең уртак мәхәббәте булып дөньяга
[б]еренче кеше — кечкенә Ринат туды. Хәзер ул дүртенче яше белән бара
[и]де инде. Малайны ясле-бакчага урнаштырып, шунда тәрбияләделәр.
[А]ларга хезмәтләренә йөрү өчен дә жайлы иде. Жылы, уңайлы квартир,
[ш]әһәргә хас әйбәт тормыш... Тормыш дигәннән, аның көзгедәй шома,
[т]үл өсте шикелле тын чаклары сирәк була бит. Василларның тормыш-
[л]ары да һәр яктан тыныч бармаса да, әле бу чаклы күңелсез булганы
[ю]к иде. Бу бигрәк тә һәм башлыча Василны икенче эшкә күчәргә тәкъ-
[д]им ясалгач килеп чыкты. Нурзилә бу күченүгә башы-аягы белән кар-
[ш]ы торды. Василның хәтеренә соңгы сөйләшү килеп басты.

— Күчәргә туры килә,— диде ул хатынына.

Нурзиләнең күзләрендә очкыннар кабынды:

— Кая, шушындый рәхәттән?

— Татарстандагы яңа төзелешкә.

— Күчмә кошлар кебек яшисем килми минем.

— Кошлар алар үзләре безнең арттан йөриләр,— дип, мәгънәле
[г]енә итеп әйтеп куйды Васил. Ләкин Нурзилә бер карыш та чигенергә
[у]йламады, һаман үзенекен итте:

— Бармыйм дигәч бармыйм.

— Бәлки соңыннанрак?

Монысына инде җавап та кайтармыйча, Нурзилә яшьле күзләре
белән мендәргә капланды. Шуннан соң, әле күптән түгел генә көләч-
лек һәм шатлык чәчеп йөргән яшь хатынның чыраена күңелсезлең
утырып калды. Хәтта Васил киткәндә дә Нурзилә аны озатырга бар-
мады...

Васил, барыннан да арынырга теләп, кинәт күтәрелеп карады. Зин-
нур урынында юк иде. Менә тагы, кая киткән булыр ул? Тик якындагы
баягы карчык белән аның күгәрченнәр туйдырып торуын күргәч кенә,
ул тынычлана төште. Сизмәстән үзе дә шулар янына барып басты. Лә-
кин борчылулары таралмады, күгәрченнәр булып күгәрченнәр дә аның
күңелен озак билән тора алмады.

Шулай инде бу тормыш дигәнең, аның жәбе килсә, ибе килми, ибе
килсә, жәбе килми, дип уй йөртте ул.

Тиздән алар, очраган беренче таксига утырып, тимер юл вокзалына
юл тоттылар.

## 2

Көньяктан искән җилләр жылылык алып килә.

Якын-тирәдәге басу, калкулыкларда кыш бабай япкан ак тун ачылып,
байтак урыннарда каралып жир чыккан булса да, Тын елга буеның
уйсу болынлыклары ак төсләрен алай ашыгып алмаштырмыйлар иде

әле. Мәгәр монда да кар астына су төшә башлаган иде инде. Уйсу җирләрдә җыелып торган кар сулары кояш нурлары астында күзләрне чагылдырып җемелдиләр, әйтерсең лә, яналар иде.

Үзенең сайрар кошлары, чылтырап аккан гөрләвекләре, ярларын күмеп ашкынган ташулары, әле яңа гына оядан чыккан каз бәбкәләре төсле чибәр бөреләре белән җирне иңләп килгән яз кешеләрнең дәртдәрманнарын үстереп җибәрә. Басу һәм урманнарның саф һавасын алып килә, сулышларны киңәйтә, тәннәрне җиңеләйтә торган шушы язгы җилләр кеше күңелендә нинди генә ашкынулар, нинди генә күтәренке хисләр уятмый! Беренче кич Яңа Наратлыда куныл, иртәгесен башлыклар янына барганда Васил Сафинның да күңелен әлеге шул язгы хисләр талпындырды. Аның күз алдында, барысыннан тирәрәк һәм җанлырак булып, төзелеш күренешләре, тормыш картиналары ачыла барды. Бу ничек әле болай? Санап бетергесез чокырлар, кабыргаланып яткан сыртлыклар, беркадәр өлеше төзелеп тә, ярым ташландык хәлдә яткан корылышлар? Хәер, яңа төзелеш барган урыннарда шулайрак була инде ул. Асылда мондый күренешләр аңа таныш иде. Тик аермашул — гадәттә төзелешләр тирәсендә яки алардан бер читтәрәк шәһәр була. Аның зур йортлары күренеп тора. Ә монда? Тирә-яктан төрле тарафлардан авыллар, авыллар гына, чокырга поскан шикелле, башларын калкытып утыралар.

Васил Сафин ике катлы ак йорт янына килеп җитәр алдыннан адымнарын әкренәйтте. Тирә-юньне тагын бер тапкыр күзеннән кичерде. Кояш чыгышында калкулык, кырлар, аннан да ары күксел урман, ә төньякта, төзелештән җиде-сигез километрлар ераклыкта, тау өстендә Иске Наратлы авылы. Зур авыл. Хәер, ул район үзәге булса да, аны бу тирәдә Читән шәһәре дип йөртәләр икән. Шушы урыннарда яшәргә, үзенең көннәрен төрле кичерешләр белән шушы җирләрдә уздырырга тиеш булачак Васил. Күпкәме, азгамы — анысын тормыш үзе күрсәтер.

Тар гына баскычтан өске катка күтәрелгәч, Васил беркадәр икеләнебрәк торды: «Кайсына керергә?» Баш инженерның кабинеты бикле иде. Васил төзелеш башлыгы кабинетына атлады. Ул, уң як битендә миңе булган, зур зәңгәр күзле секретарь-машинистка белән баш кагып сәламләшергә өлгермәде, тегесе ашыгып әйтә куйды:

— Сез Андрей Акимовичкамы?

— Әйе.

— Ул кабул итә алмый, занят.

— Ярый алайса, көтеп торырмын.

Секретарь дәшмәде. Аның кашларын җыеруыннан, ниндидер кәгазьне караган атлы булып өстәл тартмасын шакылдатып ачуыннан, үз юлыңны кара, иптәшкәй, дигәнрәк мәгънә аңлашыла иде. Шундый хәлне сизенгән Васил сабырлык саклап ишек катындагы диванга утырды. Минутлар үтә торды, Василның үз уйлары үзенә җитәрлек иде. Ул инде кире борылып чыгып китәргә дә исәпли башлаган иде, шул чакта кабинетның ишеге ачылды. Куыш иякле Андрей Акимович Никитинның карашы иң беренче булып Василга төште:

— Сез мине көтәсезме?

— Әйе...

— Рәхим итегез!

Алар кабинетка керделәр. Олы җитәкчегә хас булганча зур гына кабинет. Иң беренче булып күзгә ташланганнары: «Т» хәрефе рәвешендәге өстәл, өстәл каршында ак җәймә каплаган креслолар, бер як стена буенда яңа диван, калган стена кырыйларында ярым йомшак урындыклар. Васил тагы даниләр барын күзләргә керешә алмады, Никитин сүз башлады:

— Сез... кем, безнең чакыру буенчамы?

Васил аңа документның сүзды. Никитин, тиз генә танышкач, доку-
энтны янадан иясенә кайтарып бирде.

Аннары ул ничектер җанланып китте:

— Мин инде, Юлдашев сөйләве буенча, сезне беркадәр беләм. Мон-
ә күпләребез яңа кеше. Ул да, мин дә... Сезне әлеге шул Зариф Сали-
эвич тәкъдиме буенча чакырттык. Эшләрбез бергә-бергә.

— Теләк шундый инде,— диде Васил Сафин.— Аннары хәтерендә
Элдашев калкып чыкты. Ул кайчандыр аларны укыткан иде. Юлдашев
ернигә ел буе төзүче инженерлар институтында кафедра мөдире
улып эшләде. Аннан соң ничектер аны Казандагы бер төзелеш тресты-
а җитәкче итеп билгеләделәр. Башка шәһәрләргә китеп тә эшләп йөр-
е бугай...

Биредәге төзелешнең хәзерге баш инженеры Зариф Салихович
Элдашев турында Васил Сафин шуннан артык белми иде. Ә менә ни-
ектер ул Василны онытмаган, исенә төшергән.

Никитин, баш инженерның өч-дүрт көннән кайтып җитәчәген әйтеп,
Засилга төзелештәге хәлләрне сөйләргә керешә:

— Ике СМУ, берсе электростанция кору белән шөгыльләнә, икенче-
е торак объектлары төзи. Ярдәмче предприятиеләр, субподряд оешма-
лар... Саный китсәң, байтак алар. Безнең беренче номерлы бурыч...

Никитин дистәдән артык мөһим эшне санап чыкты. Аныңча, алар-
ның һәркайсы «беренче номерлы» бурычлар рәтенә керә иде. Ул тагы
да сүзен дәвам итеп, әлеге дә баягы «беренче номер»ны гел кабатлый
торгангa, Васил җиңелчә елмаеп куйды, «Икенче чираттагы бурычлар
бер дә юк, ахрысы, монда»,— дип уйлады.

Никитин болай озын гәүдәле кеше булса да, терсәкле урындыкка
күмелеп утыргач, ничектер кечерәеп калган сыман булды. Куыш иякле
булуы өстенә, саргылт кашларының да тоташып торуы аны беркадәр
көлкерәк кыяфәтле итеп күрсәтә иде. Бу калын тавышлы кеше аз гына
вакыт эчендә Василны төзелештәге эшләрнең торышы, кадрларның
ниндирәк хәлдә булулары белән таныштырып чыгарга да өлгерде. Ан-
нары Никитинга кемдер телефоннан шалтыратты. Бу сөйләшүдән так-
та-агач материалларына төзелештә кытлык булуын абайлап алды
Васил. Никитин сөйләшкән арада ул стенадагы төрле схемаларга
карап утырды. Чыннан да бик зур булачак икән бу электр станциясе.
Зур-зур төп корпус биналары, өч мәһабәт труба. Схема-рәсемдә инде
алар чын шикелле мәгърур басып торалар.

— Телеграмма текстын мина китерегез. Чарасын күрергә кирәк,—
дип, төзелеш начальнигы телефон трубкасын куйды.

— Бу гаять перспективалы як. Якындагы елларда танымаслык бу-
лачак. Мондагы корылмалар өчен проектлар төзелә. Бездә шикәр заво-
ды, холодильник һәм алардан башка да корылышлар булачак. Әлегә
боларын калдырып торыйк. Безнең беренче номерлы бурыч — электро-
станция төзү. Дөрес, монда безгә хәтле дә эшкә керешкән булганнар.
Ләкин...

Тын елга буендагы зур электр станциясе төзү эше Куйбышев гидро-
төзелеше коллективына тапшырылгач, яңа елдан соң төзелешкә яңа
җитәкчеләр килеп, искеләр бик аз калган иде. Эре промышленность
үзәкләреннән еракта, моңарчы болынлык һәм кырлары белән тыныч
кына утырган бу урында күз күрмәгән, колак ишетмәгән яңа тормыш
кайнарга тиеш иде. Ләкин монда адым саен кыенлыклар... Шуларны
күздә тотып, Никитин сүзен дәвам иттерде:

— Биредә эшләү майлы ботка ашау түгел. Авырлыкларны ерып
чыгу безгә дә җиңел булмаячак. Ну, шулай да бөгелеп төшмәбез дип
уйлыйм. Барлык кнопкаларга тигез басканда гына...

Төзелеш начальнигы иске җитәкчелекнең электр станциясе салуда
тәҗрибәсе җитмәү, квалификацияле эшчеләрнең азлыгы һәм барыннан

да элек промбазаның булмавы яки бик йомшак булуы эшкә тоткарлык ясавы турында шактый озак сөйләде. Василга аны тыңлау күңелле дә һәм, йөрәгенә тынгысызлык салып, аны уйландыра да иде. Никитин, аның бу халәтен сизгәндәй, кулларын болгый-болгый, ара-тирә стенадагы схемаларга күрсәтеп сөйли бирде:

— Элек монда барлык җитәкчелек төзү районына буйсынган булган. Эшнең төренә карап төрле-төрле участоклар булган. Без яңа система булдырдык, сыналган система.— Аннары ул СМУларның өстенлеге турында сөйләп китте.

Васил Сафин төзелеш начальнигының әйткәннәренә каршы килмәсә дә, аның төп теләгенә төшенеп җитә алмады, киңәш итепме яки үз кичерешләрен уртаклашып сөйли идеме ул аңа, яки эш белән таныштыра идеме? Моның һәр икесе дә булырга мөмкин икәнлеген уйлады соныннан. Икенче яктан китереп, ул башлык кешенең төзелеш хәлләре турында болай сөйләнүенә гаҗәпләнерлек урын да тапмый. Тик менә ни өчен соң әле Василның нинди урында, кем булып эшләячәге турында ләм-мим әйтми ул? Васил шуны ишетергә теләсә дә, Никитин бу тиклесен һаман читләтеп үтә бирде. Бер кызып, бер сүрелеп дигәндәй, «йомгак җебен» сүтә торды. Гадәтенчә ул сүз арасында калын тавыш белән тамак кырып та ала иде. Васил бу кешенең тагы бер ягын искәрде, ул папиросны үзенә генә хас бер ләззәт белән суырып, яңакларында тирән чокырлар чыгарып тарта. Әмма ярым-ярты тарткач, көл савытына ташлый да яңасын кабыза. Ул гасабиланып сөйләгәнгәме, бәлки гадәте шулаймы — бик еш тарта сыман күренде. «Ярый әле, форточка ачык, кара мунча булыр иде монда»,— дип уйлады Васил. Аңа тагы шунысы мәзәгрәк тоелды: начальник гел юктан гына, дөресрәге, үз сүзеннән үзе ниндидер бер эчке канәгатьләнү белән көлеп тә куя.

Никитин кинәт кенә урыныннан торды. Китәргә вакыт дигән шикелле, Васил да кузгала башлаган иде, теге тагы килеп утыргач, ул да яңадан йомшак креслога чүкте. Сүз барышында башлык кешенең шулай урыныннан кузгалып, торып сөйләү гадәте барлыгын да белеп алды ул.

— Ә хәзергә таныша торыгыз,— диде Никитин.

Васил аны аңлап җиткермәде җиткерүен, алай да Никитин белән бергә кабинеттан чыкты. Аңа хәзер кая барырга, ничек танышырга, ниһаять, ул бу төзелештә кем булып эшләргә тиеш? Шундый билгесезлек алдында уйга калып, ике катлы ак йорт янында торганда, Никитин гүя аңа ярдәм кулын сузды:

— Әйдә, утырыгыз!

Яңа «газик» аларны чокыр-чакырлы юллардан алып китте.

Төзү-монтаж идарәсе контораларында һәм кайбер субподряд оешмаларында булганнан соң, алар иң зур һөҗүм алып барылырга тиешле урынга, булачак төп корпус бинасы мәйданына килеп чыктылар. Бу киң мәйданда кешеләр корт иле кебек кайнашып торалардыр дип уй йөрткән иде Васил. Ләкин анда-санда гына эшләп йөрүчеләрне күргәч, ничектер күңеленә авыр тойгы килеп сугылды. Шулай да йөри торгач, төрле галереяләрдә, котлованнарда байтак кына эшчеләрнең әвәрә килеп эшләүләрен күрде. Салыначак төп корпус бинасы урыны үзенең шактый аста булуы һәм билгәән мәйданының зурлыгы белән игътибарны җәлеп итеп тора иде. Анда инде бетон салалар. Бу авыр хезмәт кыш буе алып барылган булса кирәк, байтак урында каплап куелган салам һәм камыш чипталарга карап Васил шулай чамалады. Никитин аңа иң мөһим эшләрнең берсе булган дренаж системасының инде төгәлләнүен әйтте. Соңгы насос станциясендә монтажлау эшләрен тәмамлау алдында торалар икән. Бетон салуны да кыш буе кул хезмәте — тачкалар, носилкалар ярдәмендә башкарып килгәннәр. Трубалар буенча бетон

жибәрү әле юлга салынып кына килә икән. Күренеп тора — кышкы дәвернең кул белән башкарылган эше үрчемле бармаган. Кешеләр тик тормаганнар. Бары шул гына... Васил моңа охшашлы хәлләр белән гомер килешәчәк түгел...

Кайбер урыннарда бетон ташучы үзбушаткычларның, бара алмыйча, тәгәрмәчләр гел бер урында әйләнүдән резин исе чыгарып, тик торуларын күрделәр. Әле бу кар эри генә башлаган, җир туңы бетмәгән чакта шулай. Ә соңрак, көннәр җылыта башлагач, балчык изрәгәч, хәл нинди төс алыр? Васил, барыннан да элек, әнә шул турыда баш ватты:

— Монда бер дә юллар каралмаган икән,— диде ул, тирән сулап.

Никитин аның бу сүзен күтәреп алды:

— Бөтен бәла дә менә шунда шул, туган.

— Ә нишләргә?

— Шул турыда баш ватабыз. Җир-су кибү белән әчке юлларны тәртипкә китерә башларга кирәк булыр.

— Ә анарчы нишләргә?

Василның соңгы әйткәненә Никитин җавап кайтармады, бары тик иңбашларын гына сикертеп куйды.

Инде китәргә генә җыенганда, Никитин төп корпус бинасы мәйданыннан хәтсез еракта кечкенә тауны хәтерләткән балчык өеменә таба атлады. Васил да аның артыннан иярде. Таучыкның бер ягыннан әйләнеп үттеләр. Төнлә шартлатып балчык әзерләнгән яхшы ук киң котлованнан экскаватор кубометр сыешлы чүмече белән җир алып, аны бер-бер артлы килеп торган машиналарга төйи иде. Әлеге пәһлеван экскаватор янында беразга тукталып калдылар.

— Монда идарә итү пульты бинасы булачак,— диде Никитин.

Мәйданга килгәнче үк төрле сызым-схемаларны күргән Васил өчен бу таныш иде инде. Никитин да, шуны сизенгән шикелле, янадан бу хакта сүз куертмыйча, Василга ым какты да икәүләп экскаватор янына килделәр. Никитин кул хәрәкәте белән машинистны чакырды. Машинист, рычагны басып, кабинадан чыкты. Бу — өстенә брезент куртка кигән Зиннур иде. Ул Василга карап елмайды.

— Эшләр ничек бара? — дип сорады Никитин.

— Мактанырлык түгел,— диде Зиннур.

— Нишләп? — Шунда ук төзелеш башлыгы үз соравына үзе җавап кайтарырга ашыкты: — Машиналар җитешмиме?

Зиннур киң басмадан җиргә сикереп төште:

— Әйе, иптәш начальник, өч кенә самосвал йөри. Тагы да шуның хәтле булса, хәзерге кебек буш торулар булмас иде.

Никитин, Василга карап, иңбашларын сикертеп алды:

— Күрәсез, һәркайда кыенлык очрый. Автохуҗалык аксап-туксап эшли. Машиналар...

— Машиналар азмы? — дип сорады Васил.

— Анысы бер хәл. Автомашиналарның күбесе ел ярым-ике ел эчендә теге дөньяга киткән... Бердән, атай малы — катай, икенчедән, юллар...

Алар шулай гәпләшеп торганда, борылмалы чокырлыктан чыгып үзбушаткыч килеп туктады һәм Зиннур кабинага сикереп менде. Василнең Зиннур янынннан тиз генә китәсе килмәгән иде. Мәгәр, Никитинның икенче участокка ашыгуын күреп, Зиннурның да сөйләшеп торырга вакыты булмавын тоеп, башлык артыннан атлады.

Аерылганда Никитин Василның кулын кысты һәм азрак җибәрмичә торды:

— Менә хәзер инде сезгә мондагы хәл азмы-күпме таныш. Болай каушап калмагансыздыр бит?

— Юк, иртәгә мин кая чыгарга тиеш?

Василның бу соравына Никитин елмаеп, аннары иреннәрен тешләбрәк җавап бирде:

— Иртәгә иртүк килерсез, сөйләшербез. Кайгырмагыз, әле эштән туеп бетәрсез, ял итәргә туры килмәс тә.

3

Күп йөрүдән Василның аяклары кызыша иде. Ул гостиницага кайтып җитәр алдыннан гына аякларына күз төшерде. Аның кирза итекләре кызыл балчыкка буялып, бөтенләй икенче төскә кергән иде. Ничек игътибар итмәгән соң ул моңарга? Хәзер инде юллар һәм сукмаклар юеш, урыны-урыны белән былчырак булганга, монда шәһәрдәге шикелле туфли киеп йөреп булмый. Иң кулае кирза яки резин итек. Васил, өсте каралып торган кар көртенә барып, аякларын чистартты.

Гостиница дигәне вакытлыча булып, зур баракның яртысын били тора. Тар гына коридор, як-якта тар гына ишекләр. Ә баракның икенче яртысында торак коммуналь хуҗалыгы конторасы һәм почта бүлеге. Үзе килеп урнашкан бүлмәгә керим дигәндә генә ниндидер бәхәсле, үгетләүле тавышлар ишетеп, Васил тукталып калды. Кемнәр булыр икән, бу нинди хәл? Ул ишек тоткасына сузган кулын кире алды. Эчтә сүз дәвам итте:

— Беләсегез килсә, кеше ул баш хәрефләр белән языла. Максим Горький сүзләрен бер дә ишеткәнегез юкмыни сезнең? Дорфа сез, иптәшләр, игътибарлык җитми. Сезгә киләчәктә махсус лекцияләр сөйләргә яки курслар ачып укытырга туры килер, мөгаен. Менә бит ничек килеп чыга...

Бу тавышка кемдер каршы төште:

— Урын җәю, я булмаса идән себерү өчен нинди курс кирәк булсын тагы? Мунчала юк, чүпрәк күбрәк бирегез. Баскыч төбенә аяк кыргычлар куясы бар. Менә шуны эшләтегез сез, Вазих Вафич.

Баягы тавыш тагы колакка сугылды:

— Җаваплылык хисе җитми сезгә. Нигә консерваторларча сөйләнәсез? Беләсегез килсә, мин сезгә теләкләремне боерык рәвешендә дә җиткерә алам. Сез яна кешеләр әле бездә. Бездә электән эшләүчеләр моны бик яхшы аңлыйлар.

Кемнәрдер җиңел генә көлешеп алдылар. Боеручан тавыш сүрелә барган кебек тоелды:

— Тәк, тәк, менә шулай. Әйе, бу караватны чыгарасыз. Васил Закирович — безнең төзелешкә килгән җаваплы иптәш. Аның караватын әнә шул иркен почмакка... Урынын пөхтәләп җыеп куегыз. Карагыз аны, патша караватыннан ким булмасын!

Ул да булмады, ике хатын бер караватны җилтерәтеп бүлмәдән алып чыктылар һәм коридор буенча алып киттеләр. Караватның бер башын коридорда торучы Василга чак бәрдермәделәр алар. Васил бүлмәгә керде. Бер хатын почмактагы караватны җентекләп, бөртекләп җәеп маташа, шул җыештыручының һәр хәрәкәтен күзәтеп торучы кечкенә гәүдәле, очлы борынлы, очлы иякле, зур кубанка бүрек астыннан кечкенә күзләре ялтыраган берәү Василга таба борылды. Һәм очланып торган кулларын сузды:

— Танышу булыйк, Гәрәев, Вазих Вафич... Сез иптәш Сафин бит әле, ялгышмасам, Васил Закирович?

— Әйе. Саумы сез.

Теге, сүзен өзмичә, кукле-яшелле тавыш белән тезеп китте:

— Бик яхшы иткәнсез безнең төзелешкә килеп. Без сезнең кебек иптәшләрне бик хуплап каршы алабыз. Гафу итегез, кадерле Васил Закирович, мин биредәге торак хуҗалыгы начальнигы булам.— Аннары ул, беразга туктап торып, дәвам итте: — Безнең бурыч билгеле инде:

кешеләргә нормаль тормыш шартлары тудыру. Әле менә күрәсез... Тукта, мин әйтәм, Васил Закировичны ничегрәк каршы алдылар икән безнең гостиницада? Шулай, һәркайсына житешергә тырышабыз.

Васил нидер әйтергә җыенып авызын гына ачкан иде, Вазих Вафич тагы пулеметтан сиптергән шикелле сүз йөгертте:

— Без инде гостиницабызны кулдан килгәнчә тәртипле тотарга тырышабыз. Иптәш Никитин да килгәч тә шушында торды. Безнең контора теге башта гына. Минем гадәт шулай инде, гостиницада да, тулай торакларда да көн дә обход ясамасам — ашаганым тамагымнан үтми. Сезгә монда начар булмас дип уйлыйм. Безнең бурыч...

Гәрәевнең сүзләрен ишетү күңелсез һәм әчпошыргыч булса да, аны тыңларга туры килде. Василның яңакларына кызыллык йөгерде. Ул, ни әйтергә белмичә уйланыбрак торганнан соң, әкрен генә дәште:

— Илтифатыгыз өчен рәхмәт, Гәрәев иптәш.

Тегенең авызы колагына житәрлек булып ерылды, кубанкасын маңгаенарак күтәрде, күзләрендә ниндидер хәйләкәр очкыннар уйный башлады.

— Кая әле безгә рәхмәт әйтергә? Иртәрәк әле, хезмәт иямәренә уңай шартлар тудыру ул...— Гәрәев сүзне икенчегә борды: — Сез, баш инженерның беренче урынбасары буларак, безгә ярдәм итәрсез дип ышанам, Васил Закирович. Безнең ни... тегесе, монысы, ремонт дигәндәй... һәркайсын яхшы сыйфатлы итеп ерып чыгасыбыз килә. Сезнең ярдәм... эһ... эһ....

Ни сөйли бу кеше? Сүзләрен бик әдәпле итеп әйтсә дә, аны ягымлы да, бер үк вакытта ялагай дип әйтү дә кыен. Бәлки ул бер хәйлә капчыгыдыр. Ә менә Василның әлегә үзе дә белмәгәннәрне бу кеше кайдан белә икән? «Баш инженерның беренче урынбасары...» Ул аны кемнән булса да ишеткән булырга тиеш. Ә Васил үзе белми, бу ничегрәк килеп чыга соң әле? Төзелеш начальнигы Никитин кайда, кем булып эшләячәге турында аңа бер сүз дә әйтмәде ич әле. Бәлки ул монда килгәнче төзелеш идарәсендә аның кем булып эшләячәге турында башлыклар арасында сүз булгандыр. Гәрәев тә шуннан ишеткәндер. Ничек кенә булмасын, Васил өчен ниндидер сер бар иде бу сүзләрдә.

Гәрәев озак юанмады, тагы берничә җылы һәм төче сүз әйтте дә, ниндидер канәгатьләнү хисләре белән, артына карый-карый, бүлмәдән чыкты. Әле урамда да аның төсендәге елмаю яктылыгы сүнмәгән иде. Тик менә арттырыбрак җибәрде түгелме иптәш Гәрәев, «беренче урынбасар» түгел, «урынбасар» дип кенә ишеткән иде бит ул югыйсә. «Беренче» сүзен өстәү ник кирәк булды әле аңа? Берничә адым атлауга инде Гәрәев монысына да кул селтәде: «Әйдә, гел шулай була бирсен, ни хәтле май салсаң да ботканың тәме китми аның»,— дип юатты ул үз-үзен.

Дүрт кешелек бүлмәдә өч кенә караваг калгач, бүлмә иркенәеп киткән иде. Әкренләп Василның барысына да күзләре төшми калмады: урындыкларны да алмаштырганнар, тумбочкалар өстәгәннәр, репродуктор да яңа, идәнгә каяндыр келәм дә китереп җәйгәннәр, салфетка, эскәтерләр дә кар кебек ак. Бүлмәдәге бу алмашынулар чыннан да аның кәефенә ошады. Васил белән Зиннур килеп төшкәндә бүлмәнең күренеше башкачарак иде. «Күрәсең, Гәрәев мундирга карап эш итә»,— дип уйлады Васил.

## 4

Төзелеш башлыгы Никитин белән баш инженер Юлдашев икесе ике төрлерәк уй йөртәләр иде. Дөрес, Васил Сафинны баш инженер азмы-күпме белә. Аны төп чакыртучы да ул үзе булды. Никитин аңа каршы килмәде. Алар арасында Василны чакыртып телеграмма сук-

кач кына бәхәс кузгалды. Юлдашев Васил Сафинны үзенең урынбасары итеп кую ягында, чөнки, аныңча, моңа табигый җирлек тә бар иде. Аның исәбе хәзерге урынбасары Брагинскийны тәэминат бүлеге начальнигы итеп күчерүдә иде. Ә Никитинның исәбе башкачарак иде. Шуңарга күрә төзелеш башлыгы, Васил үзе килеп күрешкәч тә, кайда кем булып эшләргә тиешлеген өзеп әйтә алмады. Ул Юлдашевның кайтуын көтте. Ә Юлдашев һаман кайтмады да кайтмады.

Никитин ялыга башлады. Эш сәгате күптән беткән булса да, ул кабинетыннан тиз генә китәргә ашыкмады. Төрле кәгазьләрне карады, аларны калдырып, ишекле-түрле йөренде, стенага ябыштырылган схемалар өстендә күз йөртте. Берсе дә аның күңелен озак биләп тота алмады. Кабинетта тын, тыштагы төн караңгылыгы, әйтерсең лә, бу тынлыкны көчәйтә, куерта иде. Аңа ничектер куркыныч сыман тоела башлады. Кешеләр белән кайнашып торган коридор да тын, күрше бүлмәләр дә һәммәсе тын... Кинәт, тышта җил уйнап, ахры, шап итеп форточка ябылуга, Никитин сискәнеп китте. Яңагына алма сыярлык чокырлар хасил булуын сизмичә, тирән-тирән суырып папирос тартуын белде. Форточканы барып япты, анысы җилләнеп тагы ачылды. Никитин, кашларын җыерып, йөренде дә йөренде. Монда күченеп килгәнче аның көннәре тыныч үтә торган иде. Ничек соң әле киргәннән артык гасабилана башлады ул? Бәлки ял итәргә кирәктер, бәлки төп авырлыкны яшьрәкләргә йөкләп, аңа күзәтчелек итеп кенә торырга кирәктер? Бу исәпне тагы башкалары алмаштырды. Нигә кайтмый, нигә күренми бу Юлдашев та, кая китеп югалды? Гадәттә ул эштән соң да идарәгә килеп чыга торган иде. Кайтып җитмәгәндер, күрәсең. Беркадәр вакыт узгач, ул баш инженерның квартирына шалтыратып карады. Өметсезләнеп телефон трубкасын куйды. Нигәдер вакыт, үч иткән шикелле, әкрен уза.

Кинәт кенә телефон шалтырауга Никитин шатланып китте. Телефонда Роза Павловнаның ягымлы тавышы ишетелде:

— Андрей Акимович, сүз куешканны онытты́ң түгелме? Мин инде көтә-көтә зарыгып беттем димәсәм...

Никитин, аңын-исен югалткандай, башта ни әйтергә белмичәрәк торды. Аннары гафу үтенергә кереште:

— Шулай туры килде, Розочка. Бүгенгә барып булмый инде. Әле һаман көтәм.

— Зариф Салихович кайтмадымыни?

— Юк шул. Билгеле, ул анда кунарга калмас кебек.

Роза Павловнаның үпкә сүзләре Андрей Акимовичны тетрәтеп җибәргәндәй булды:

— Синең эштән бушаячагың юк инде. Бер җиргә барып булмый. Кешеләр...

Роза Павловнаның якты зәңгәр күзләре бу минутта моңсуланып киткәндер, тамарга торган чиядәй иреннәре гаять килешле булып бөрешкәндер, кыйгач кашларыннан дулкыннар йөгереп үткәндер. Андрей Якимович аны тынычландырырга тырышты:

— Бәлки бүген үзең генә барырсың. Ә иртәгә таш яуса да бармый калмыйбыз. Кстати, киногa түгел...— Никитин берничә секунд зиһене таралган хәлдә торды да янә сүз катты: — Иртәгә эстрада артистлары килә. Әйе, Казаннан. Әлбәттә.

Телефон трубкасын куюга, ул ике учы белән башын тотты...

Бер уйласаң, ни хәтле гомер артта калган. Аның Ерак Көнчыгышта эшләгән еллары әле кичә генә булган кебек. Ул вакытта Роза Павловна да, ул үзе дә яшь иде. Аннары Иркутскига күченеп китүләре... Мәшәкатьле көннәр. Әмма яшьлек берсенә дә бирешми икән. Ә хәзер? Яшь гомерләр ерак, ерак калган сыман тоела. Алай гынамы соң? Никитинның күңелен әллә нинди ят һәм шикләндергеч тойгылар тырный.

Бәлки ул тагын да күңелсезрәк исәпләр кичерә башлар иде, кемдер җиңел генә ишек шакыды да килеп тә керде.

— Хәерле кич, Андрей Акимович!

— Сезгә дә шулай ук, Зариф Салихович!

«Я, сезне тыңлап карыйк» дигән сыман, Никитин житез адымнар белән өстәл артына барып утырды. Гәүдәсе төзелеш начальнигыннан кайтышрак, алай да шактый озын, какчарак буйлы Юлдашев өстәл каршындагы йомшак креслога килеп утырды. Һәрвакыттагыча ул аяклэре күгәргәнче пөхтәләп кырынган, хушбуй сөртеп йөргәнлектән, үзеннән сафлык аңкый, юлда булуына карамастан, күлмәк якалары да әле яңа гына үтүкләп кигән шикелле ап-ак, күзләре тере иде. Ара-тирә, бигрәк тә ашыкканда һәм каушаган минутларында тотлыгып куючан Юлдашев сүзен салмак кына башлап җибәрде:

— Актау заводын айкап чыктым, Андрей Акимович. Кирпечне һаман шул чамадан арттыра алмыйлар. Кызыл балчыкның үзлелеге җитеп бетми, үзләре дә ул турыдан борчылалар. Аннары, яндырганда төгәл режим сакланмый. Кирпеч яки кирәгеннән артык яна, яки янып җитмичә чыгарыла. Нәтиҗәдә ныклыгы ким була, я тиз уала. Зарланучылар бер без генә түгел икән.

Никитин, сүзнең ахырын ашыгып көткән сыман, Юлдашевны бүлдерде:

— Нинди чаралар күрергә җыеналар соң?

— Чаралар дип, алар авторитетлы комиссия төзеп, барлык технологик процессларны тикшерергә булдылар. Аңа хәтле дә кирпечнең сыйфаты яхшыра төшәр дигән өмет бар. Тагы төп бәлаләрнең берсе кирпечнең бик нык уалуына кайтып кала бит әле. Бу юнәлештә инде безнең үзебезгә кайгыртырга туры килә. Кирпечне контейнерлар белән кайтартмый булмас. Контейнерларны ясау артык мәшәкатьле эш түгел.

— Бу кадәресе ярый. Ә таш мәсьәләсендә эш ничек тора?

— Кыен.

— Ул кадәресе миңа мәгълүм. Бергәләп баш ватарга кирәк.

— Һичшиксез. Саный китсәң, монда бик тиз очына барып чыгарлык түгел. Бигрәк тә шәрә җиргә корырга тиеш тапканнар электростанцияне.

Никитин гаҗәпләнүдән кулларын җәеп салды. Юлдашевка күзен очландырып карап алды һәм үз-үзенә нык ышанган шикелле итеп әйтте:

— Шәрә җирнең шәрәлеген бетерүдән гыйбарәт бурыч та. Барысы да эшләнгән булса, бирелә безнең кирәгебез дә калмас иде. Миңа ошый бу яклар.

— Хәзер бернинди дә чигенешкә юл куймаслар, хет шартлап ярыл, ярты юлда туктап калырга рөхсәт итмәсләр,— диде Юлдашев, Никитинга карамыйча гына.

Никитин дәшмәде. Ул кесәсенә папирос алырга тыгылды, ләкин тартманы бармаклары белән кармалады да папирос чыгармады. Юлдашев исә уң кулының бармаклары арасында кызыл карандаш уйнатып тора иде. Берәр минут чамасы икесе дә тынып утырдылар. Иң башлап Никитин сүз ачты.

— Сафин килде.

— Кайчан?

— Моннан дүрт көн элек.

— Сез инде аны билгеләп тә өлгердегезме, Андрей Акимович?

Никитин, бер күзен кыса төшеп, хәйләкәр генә көлеп куйды.

— Әле приказга кул куелмаган, сезнең кайтуыгызны көттем.

Юлдашевның төсендә куера башлаган төкселек сыгаеп китте. Ул кызыл карандашны бер куйды, аннары тагы кулына алып, ни өчендер

әйләндерә-әйләндерә караган итте. Юлдашев Васил Сафинның язмышы турында, дөресрәге, аның төзелештә нинди урын алырга тиешлеге турында юлда кайтканда да хәтеренә китергән иде. Шундый энергияле яшь белгеч уң кулың булганда эшләрне тәгәрәтү ул кадәр авыр булмаячак, дип уй йөртте ул.

Никитин аңа мөмкин кадәре туры карарга тырышып сорап куйды.

— Сезнең караш үзгәрмәдеме?

— Ничек әйтергә?.. Аның баш конторада эшләве шәбрәк булыр кебек.

Никитинның баштагы уеннан кайтырга чигенергә нияте юк иде.

— Минемчә, безнең шартларда иң авыр эш СМУ да хәзер. Анда нык куллы, таләпчән җитәкче кирәк. Баш инженер урынбасары мәсьәләсенә килгәндә, минем караш сезгә билгеле.

— Брагинский тәэминат эшләренә кулайрак булыр иде.

— Юк, ул хәзерге эшендә дә ярыйсы. Тазалыгы да шәп.

Юлдашевның тын утыруын күргәч, Никитин тавышына яңа көч өстәп дәвам итте:

— Безнең системада, Зариф Салихович, авырлык СМУлар өстенә төшә. Ничек әле, кошларның канатлары очкан чакта ныгый диләрме? Шулай булгач... Хәер, мин Сафинны әлегә аз белсәм дә, эшли-эшли чыныгыр ул.

Юлдашев кинәт йомшарды, шулай, әле бергәләп эшли башлауның тәүге айларында ук үзара ризасызлыклар булуын теләми иде ул. Мондый чакларда мин-минлекне арткы планга куеп торырга туры килә. Никитин салмак кына итеп сүзен төйнәде:

— Булмаса, әйдә, болай итик: чакыртыйк Сафинның үзен. Аннан хәл кылырбыз.— Ул телефон трубкасына үрелде.

## 5

Төннең яртысы авышканы сизелми дә калган, бәхәс һәм киңәш эчендә ни хәтле утырылган. Төзелеш конторасыннан поселокка кадәр бергә кайттылар да өчесе өч якка юнәлделәр. Никитин сулга борылды, Юлдашев уңга каерды. Сафин каралтылар арасыннан гостиницага таба атлады. Төн караңгы, йолдызлар күз кысмый иде. Васил, ялгыз гына калгач, адымнарын әкренәйтте, нигәдер шунда йортка керәсе дә, кайтып ятасы да килмәде аның. Урамда һава иснәп йөрсә нишләр? Васил үзенең уендагы бу сорауга җавап кайтарырга өлгергәнче, арттан аяк тавышлары ишетелде. Ул сагая калды. Ләкин мондый тойгы озакка бармады, таныш тавыш колагына килеп сугылды:

— Минә тагы очраштык, Васил Закирович.

— Әле сезнең дә кайтып кына килүме, Зиннур?

— Ике сменаны әйләндереп салдым. Җитәр бер көнгә.

— Нишләп ике?

— Моңарчы бер генә смена эшләгәннәр. Никитин-башлык кыздырган, ди. Ләкин мине алмаштырырга тиешле машинист чирләп тора икән. Шулай итеп, миңа калырга туры килде.

— Әйе, сез бик кызу тотындыгыз.— Васил «сез» белән «син»не бутавын да сизмәде.

— Мондый чакта санашып торып булмый инде.

— Машиналар ничек йөрде соң, тоткарламадылармы?

— Төрлечә булды. Дөрес, баштарак яхшы иде, соңга таба бер машина бөтенләй юкка чыкты.

— Нишләп?

— Баллоны шартлаган диделәр.

— Бик ардырмадымы?

— Арыганны мин урынга яткач кына беләм.

Алар сөйләшә-сөйләшә гостиницага җиттеләр. Поселок тирән йокыга талган, барлык өйләр, йортлардагы кебек, гостиница тәрәзәләрендә дә утлар күренми иде инде. Алар кешеләрне уятмаска тырышып әкрен генә баса-баса эчкә үттеләр. Зиннур Василның кем булып эшләргә керешүе турында сорарга исәп итеп куйган булса да, нигәдер сүз кузгатмады. Кичкенә өстәл каршында җәйләп утырган, йокыга талган вахтер хатын шыпырт кына баскан аяк тавышларыннан куркып уянды, күрәсең, урындыгыннан егылып төшә язды. Соңга калган кешеләрне җене сөймәгән вахтер бу икенең әле берсенә, әле икенчесенә кырын күз салып алды да әйтә куйды:

— Болай соңга калганчы, куныл кына кайтырга кирәк иде.

Васил тегенең чеметтерүен аңламаганга салышып сорады:

— Ни булган, апа?

— Берни дә булмаган. Җанкайларның чибәрләрен тапкансыз, ахры. Тиз. Гаҗәп хәзерге заман кешесе... Бер карашып алалар да култыклашып китеп тә баралар.

— Сез һәр соңга калган кешене дә шулай каршы аласызмы? — дип көлемсерәде Зиннур.

Яулык астыннан тузынып чыгып торган чәчләрен рәтләгәндәй итеп, вахтер гүя аны ишетмәгән дә төслерәк дәвам итте:

— Безнең Яңа Наратлы кызлары магнитлы алар. Яшь ир-атны үзләренә сразы тартып алалар...

Васил, безнең бакчага таш атуыгыз дөрес түгел, дип әйтәсе килсә дә, юан апа белән сүз көрәштерергә теләге юк иде, авызын ачмады. Зиннур эш киемнәрен салырга кухняга кереп китте. Васил да, сак кына адымнар белән барып, үзе урнашкан иң түрдәге бүлмәнең ишеген ачты. Бүлмәгә кергәч тә, электр тоташтыргычына кагылмастан, бер генә шырпы сызып, урын-җирне барлагач, караңгыда өс-башын чишенеп йокларга ятты. Төзелеш идарәсендә сөйләшү, тарткалашулар һәм, ниһаять, моңарчы дәвам иткән билгесезлекнең ачыклануы аны бер яктан куандырса, икенче яктан борчый башлады. Моңа тикле бит әле ул бары өлкән прораб һәм ярты елга якын участок начальнигы гына булып эшләгән кеше. Ә монда... Төзелеш житәкчеләре аның белән әңгәмә алып барганда, экономик базаның йомшак булуы белән бергә, кадрларның һич тә җитмәвен, булганнарының да квалификация ягыннан ике аяклап аксауларын басым ясап әйттеләр. Зур коллектив, моңа якын кеше... Василның башында кайнаган бер уйны икенчесе алмаштыра торды. Ул бер яктан икенче якка әйләнеп ятып карады, йөзтүбән ятып карады, аннары чалкан борылды, ләкин ни генә кыланмасын, барыбер күзләренә йокы әсәре кермәде, керфекләре йомылмады. Әйтерсең лә, уйлар түгел, бер нәрсәдән дә курыкмый торган черкиләр сырып алган иде аны. Ахырында Васил урыныннан торып папирос көйрәтергә коридорга чыкты. Тышкы ишек бикле, баягы вахтер апа да, кухнядагы әскәмиягә бишмәтен салып, борынын сызгырта-сызгырта йоклый иде. Тынгысыз уйларга күмелгән Васил, тубалдай авыр башын көч-хәл белән күтәреп, яңадан бүлмәгә керде.

Бу табигатьнең шаяруларына һич төшенерлек түгел. Әле кичә генә язга, чын язга тартым җепшек көн иде. Ә бүген... Бик соңга калып кына ватылып йокыга талган Васил бүлмәдәге башка кешеләргә карaганда иртәрәк уянды. Үзе дә сизмәгән ниндидер җилкенү, ниндидер ашкыну хисләре кулларыннан сөйри кебек иде аны. Ул тиз генә урыныннан торды, гадәттәгечә физзарядка да ясап матәшмастан, урын-җирен җыеп куйгач, аннан-моннан гына юынды да урамга чыкты. Якындагы тулай торaклардан төркем-төркем булып ашханәгә баручы яшьләр күренде. Ул да шулар артыннан китте. Ул барып кергәндә ашханәдә

халык шыгрым тулы иде инде. Житмәсә чираты да ишек катыннан ук койрыкланып киткән. Ничектер шунда стаканнардагы төссез чәйне күргәч, ул Нурзилә хәзерли торган куе, хуш исле, арыган башларга ял бирә торган тәмле чәйне хәтерләде. Ул чиратка басты, әкренләп минутлар минутларны куа торды. Алай да чират якынаймады. Чөнки анарга калса, бердән, ашны бик әкрен бирәләр, аннары чиратсыз керүчеләр әледән-әле күренеп тора иде. «Монда болай тора-тора эшкә соңга калуыңны көт тә тор»,— дигән исәп менеп утырды аның башына. Кулын селтәде дә китеп барды.

Янадан урамга чыккач, ниндидер шифалы җил искән шикелле, Василның бөтен тәне, бөтен гәүдәсе җиңеләеп китте. Хәер, әле ул бу поселокта яңа, бөтенләй яңа кеше. Әле ул моңарга хәтле буш һәм тын урамнарны, тын тыкрыкларны гына күрә һәм бу авылга хас тынлык аның шәһәр шау-шуына күнеккән күңеленә ят тоела иде. Ә бүген! Якындагы баракларның ишекләре бер генә минутка да ябылып тормый. Гади эш киемендәге кешеләр җәяүләп тә, өсләренә көймәләнеп брезент ябылган автомашиналарга утырып та, мотоцикл һәм моторлы велосипедлар белән дә эшкә, бары да эшкә ашыгалар. Уен-көлке, чырчу, һаваны яңгыраткан яшь авазлар, чын мәгънәсендә тормыш авазлары! Бу хезмәт иртәсе, бу кешеләр ташкыны, бу иртәнге саф җил, бу җанлылык аның рухына тулысынча тап килә иде. Егетләр кызлар белән шаярышып та алалар. Әнә бер егет таеп егылган бер кызны култыклап торгызды да шаян сүзләр әйтә-әйтә бара. Тегесе чапалана: «Җибәр, җибәр,— ди.— Җибәрмәсәң авызыңа утыртам»,— ди. Үзе бер дә сукмый, бары тик шарык-шорык көлүен генә белә. Әнә кайсылардыр юеш кар атышып уйнап баралар. Урта һәм өлкән яшьтәге кешеләр сирәк күренә. Яшьләр... Яшьләр...

Чү! Болары кемнәр тагы? Күбесе өсләренә сырма, кыска бишмәт һәм нәкъ ирләрчә чалбар кигән, төрле төстәге яулык яки шәлләрен якаларына кыстырган һәм, бер-берсеннән аерылырга теләмәгән шикелле, гел бергәләшеп атлаган хатын-кызларны куып җитеп, шулар арасында бара башлады Васил. «Билгеле инде, боларның күбесе кызлар, араларында яшь киленнәр дә юк түгелдер әле»,— дип уйлады. Ул үзе дә дәртләнеп барган шушы кешеләрдән әллә ни аерылмый иде. Аның өстендә итәге бөрелеп куелышлы сырма пиджак, җылы чалбар һәм аякларында кирза итек, башында кара мех бүрек, кулларында каешланып беткән гади перчатка. Яшь ягыннан да ул алардан әллә ни аерылып тормый кебек. Үзләреннән артка да калмаучы, узып та китмәүче бу кешегә бара-бара хатын-кызлар күз салмый калмадылар. Ләкин берсе дә башлап дәшмәде. Ят кеше ич, яңа кеше. Сүзне Василның үзенә башлап җибәрергә туры килде:

— Сез кайда эшлисез, кызлар?

— Кайда җиңелрәк — шунда,— диде берсе, шаяртып.

— Без авырыннан да тайчана торганнар түгел,— дип өстәде икенчесе.

— Әллә безнең бригадада эшләргә исәбегез бармы, абый? — диде кайсыдыр.

Кызларның бу рәвешчә шаяртуыннан соң Васил каушап калмады, сүз кушмыйча гына елмайды, күзләрен кыскалап алды. Аннары әйтте:

— Мин дә сезнең белән бергәләп эшләрмен, дип уйлыйм.

— Кем булып?

Аңа җавап бирергә туры килмәде, бер такылдыгы иреннәрен бөрештереп әйтергә ашыкты:

— Бу абый берәр нәчәлник кисәгедер әле. Алай бик авызыгызны ермагыз, малакайларым. Соңыннан җыларга туры килмәсен.— Шунда ул әйткәннәренә өстәп тә куйды: — Наряд-мазар язуга кагылышлы эштә булып, артык лыгырдаган өчен кисеп куймасын тагы. Мондый

абыйлар янында итәк-жиңенне жыеп йөрү лутчырак. Бу дөньяның хәлен белмәссең...

Шулай сөйләшә-шаяра бара торгач, Васил бу хатын-кызларның төзелә торган электр станциясенең төп корпусында эшләүчеләр икәнен белде. Проммәйданга килеп житәр алдыннан, тимер юлны чыккач, ул сулга борылды һәм төркемнән аерылып, бер катлы таш йортка керде.

Күрәсең, аның монда эшләячәге турында конторага хәбәр ителгән булырга тиеш, яшь кенә секретарь-машинистка Василны оялчан гына елмаеп каршы алды һәм аңа кабинетның ачкычын бирде. Уртача зурлыктагы кабинетта инде, аңа калса, һәммәсе дә үз урынында кебек: стена буенда урындыклар... диван, өстәл, телефон... Васил өстәл артына барып, урындыкка утырырга да өлгермәде, бер кәгазьгә күзе төште. Бу аны төзү-монтаж идарәсе начальнигы итеп билгеләү турында төзелеш башлыгының приказы иде. Баштарак Василга биредә һәр нәрсә ят сыманрак күренсә һәм ниндидер юксыну хисе күңелен тырнап торса, кешеләр, эшләр белән таныша башлагач, мондый тойгы тиз сүрелде.

Ул житәкчелек итәчәк төзү идарәсенең прораблык участоклары контора бинасында булмыйча, төрлесе төрле жирләрдәге вагон һәм вакытлыча такталардан кагып-сугып укмаштырылган кечкенә өйләргә урнашкан иде. Ул иң элек бүлек мөдирләре һәм хезмәткәрләре белән танышып чыкты. Шулай итеп төшкә кадәр булган вакытның ничек узганы сизелми дә калды. Инде эш кайный торган участокларга чыгып китәргә ниятләп кенә торганда, ишектән песи кебек сак кына басып керәү керде. Тукта әле, аңа таныш түгелме соң бу кеше, аны кайда күргәне бар иде соң әле? Әй, бу хәтер дигәнең, бөтенләй икенче кешегә ошатты бит әле ул аны... Өч-дүрт секунд вакыт үткәндерме, юкмы, Васил инде бу плащлы кешене танып та өлгерде һәм кулларын сузып, өстәл артыннан чыкты:

— Игнат!

— Бәй, үзебезнең егет булып чыкты бит әле бу.

— Әйе, мин.

— Котлыйм, чын күңелдән котлыйм безнең якларга килүегез унае белән. Сафин да Сафин диләр, туктале мин әйтәм, безнең институтта укыган Васил Сафин түгелме бу? Тәки сизенгәнмен икән! — дип, Игнат яктырып көлеп жибәрде.

— Син монда күптәнме, Игнат?

— Икенче ел.

— Няләнеп беткәнсеңдер инде алайса?

— Мин үзем шушы якныкы, безнең авыл моннан ерак түгел.

— Алайса берге-берге тәгәрәтәбез инде ташны.

— Мин дә шулай дип торам.

— Син бер дә үзгәрмәгәнсең, Игнат, һаман шул көенчә.

— Ни, теге, бераз бардыр инде, гомер үтә бит, Васил Закирович.

— Бирешмәскә кирәк!

— Барысы да безнең ихтыярда булса, гел артка китәсе килми дә югыйсә.

— Менә ничек килеп чыкты, һич көтелмәгәндә күрешү,— дип куйды Васил.

Алар арасында башланган сүз тиз генә туктамады. Сүз арасында Игнатның: «Васил Закирович» — дип еш ара кабатлый башлавы Василга ничектер уңайсыз тоелды һәм аны туйдыра да башлады. Чөнки ул әтисе исемен дә кушып эндәшүгә башта да бик авыр күнекте. Аныңча, аны исеме яки фамилиясе белән генә атап йөртсәләр, шул житкән иде кебек. Ләкин бар төштә дә шулай канунлашкан булгач, теләсә-теләмәсә дә аңа да бу хәл белән килешергә туры килде. Шулай да үзе белән бергә институтта укыган иптәшеннән «Закирович» дип ишетәсе килми иде.

Институт... Игнат Данилов аннан өч курс түбән укый иде. Бер тулай торакта тордылар. Хәтта бер елны бүлмәдәш тә булырга туры килде аларга. Игнат Данилов үзенең чамадан тыш тыйнаклыгы һәм тып-тын йөрүе, йомыклыгы белән башка бик күпләрдән аерылып тора иде. Аның җыелышларда бер мәртәбә дә чыгып сөйләгәне булмагач, бер тапкыр кызык иткәннәр иде. Профсоюз җыелышындамы, комсомол җыелышындамы шунда кайсыдыр, шаяртып, Игнатның сөйләргә теләвен записка язып председательлек итүчегә тапшыра. Председатель, кирәк кайчан булмасын, залның һаман бер почмагындарак утыручы Игнат Даниловка сүз бирә. Нишләсен? Баштарак карулашып маташа теге. Кат-кат әйтеп кыстый торгач авыр гына бер рәвештә урыныннан күтәрелә. Халыкка карап, нидер эзләнгән сыман хәрәкәтләр ясый да кычкырып әйтеп салмасынмы: «Мин барлык иптәшләрнең сөйләгәннәре белән риза, берсенә дә каршы килмим»,— ди. Шуннан соң тып-тын урынына утыра. Залда шаулашып көләләр. Әлеге дә баягы шул чакларны исенә төшергәч, Васил чак-чак кына көлеп җибәрмәде. Ләкин бара-тора студент Данилов белән прораб Данилов арасындагы аерма беренче күрешүдә үк сизелгәнен уена китерде. Алар икесе дә тынып калган арада, кемнәрдер кабинетка кереп, йомышларын әйттеләр. Данилов, тагы ярты сәгатьләр чамасы утыргач, үз эше белән китеп барды. Васил кабинеттан тиз генә чыгып китәргә форсат тапмыйча интегеп бетте. Чөнки әле берсе, әле икенчесе кереп кенә торды, кешеләр саеккан арада телефон шалтырап аңа уйларын җыеп алырга мөмкинлек бирмәде. Бер арада ул җәһәт кенә кабинеттан чыкты.

## 6

Ял көне.

Зур төзелештәге хезмәт шау-шуы тынып, яшь авазлар урамнарга, өйләргә һәм баракларга күчте. Васил гадәтенчә иртә торды. Ул бит-кул юып йөргәндә, бүлмәдәгеләр оеп йоклыйлар иде әле. Васил кешеләрне борчымаска тырышты, аяк очларына сак кына басып йөрде. Дөрес, бүлмәдәгеләргә карап аның үзенең дә күзләренә йокы үрмәләргә әзер торган шикелле иде. Инде бер урыныннан кузгалгач, кире ятмауны артыграк санады. Нигәдер шунда, әле ул бәләкәй чакларда әнисенең еш-еш әйтергә ярата торган сүзләре хәтерендә калкып чыкты: «Иртә белән озак йоклаган — бәхетен йоклаган. Иртә торган бәхетле була, бай була»,— ди торган иде әнисе. Бала чактан ук колагына кергән әнисе сүзләре кирәк чагында шулай баш калкытып куялар иде.

Бәй, нинди хикмәт бу, ниякләренә нинди төкләр үскән? Аның көннәре бер дә сизелмичә үтте бу араларда, үзенең кыяфәт-рәвешен тәртипкә китерергә дә оныткан лабаса. Шулай булмый хәле дә юк. Кырык көймәнең койрыгын тотарга йөри бит ул, инде тәртәгә үзең риза булып җигелгәнсең икән, сөйрәми хәлең түгел! Бу араларда аның көзгедән дә караганы юк иде бугай. Әлегә парикмахерга барып тормады инде, әйдә, икенче берәр чакта житешер әле. Васил коридорга чыгып, стенадагы зур көзге алдында кырынды да, ял көненә тәңгәлрәк китереп, чиста киенгән хәлдә, ашханәгә барырга җыенды. Тик аның ялгыз гына чыгып китәсе килмәде, Зиннурлар бүлмәсенең ишеген саклык белән генә ачты. Караса — тегесе киенеп ята икән.

— Кая болай иртүк?

— Буыннарны ныгытып алырга кирәк,— диде Васил.

— Бара торыгыз. Мин космически корабль тизлегендә сезне куып житәрмен...

Бүген тирә-юньнән, башка көннәрдәге кебек, ашханәдә койрыкланып чират тезелмәгән, буш урындыклар да җитәрлек иде. Васил бер өстәл артына барып утыруга Зиннур да килеп житте.

— Хәзер кая барабыз? — дип сорады Зиннур.
— Ә синеңчә?
— Киногა керсәк.
— Анысын кичке якка калдырсак лутчырак булыр шикелле.
— Миңа барыбер,— диде Зиннур.

Гостиницага яңадан әйләнеп кайтуларына, юанлыгы мичкәдән аз кайтыш, бер көн аларны үчекләп каршы алган вахтер хатын Зиннур алдына килеп басты. Ул, бер кулын артка куйган көе, шаяртып әйтә алды:

— Сез Гафиятуллин буласыз бит әле?
— Әйе, мин булам ул кеше.

Хатын артка яшергән кулын кинәт алга чыгарды.

— Бие, сиңа хат бар!

Зиннурның һич шаярасы килмәсә дә, авызын ерып торган вахтер хатын, барыбер бер-ике биеп-әйләнеп күрсәтмичә, аңа хатны бирмәде. Зиннур коридорның түренә куелган диванга барып утырды һәм конвертны ачты. Ул укыганда Васил арлы-бирле коридорда йөренде. Зиннурны озак көтәргә туры килмәде. Ул җиңел генә урынынннан торды да, чыраен балкытып, Васил янына килде. Тегенең сорау-сорамавын уйлап тормастан, ниндидер бер җиңеллек белән әйтте:

— Ашыктыра минем Хәмидә. Балалар сине бик сагыналар, дигән. Тиздән безне кайтып ал, алмасаң, үзебез төянеп юлга чыгарга күп сорашмабыз, дигән. Бергә-бергә торуларга ни җитә, айры-чайры торулар ай читен лә, дигән.— Бераз тыныш ясап, Зиннур әйтеп бетерергә ашыкты: — Минем Хәмидәнең чәче, аллага шөкер, кыска түгел, ә менә акылы житеп бетми бугай. Кил, көтеп торалар сине, коймак пешереп көтеп торалар... Тозлап-борычлап хат язарга туры килер. Менә аны, тилене, квартир чутларыннан мин киткәндә үзем әйтеп язарга булдым ич аңа. Ул безнең шулайрак инде, иртән чәй эчкәнен кич оныта. Тәртәне зиректән каерырга ярата.

Тыштан шулай каударланыбрак сөйләгән Зиннур, хатынының фигыль-холкын энәсеннән җебенә кадәр белгәнгә күрә, эчтән алай бик көяләнми иде. Чөнки ул аның тупаслык ясамавына чын күңеленнән ышана иде.

Васил, килгәч, үзенең хәл-әхвәлләрен, кичерешләрен әйтеп хатынына тәфсилле рәвештә хат язып салган иде инде. Ул әлегәчә җавап көтә, кайчан килер?

Алар гостиницадан чыктылар. Василның исәбе поселок урамнарын бер урап кайтуда иде. Ул шул хакта юлдашына әйтергә уйлап кына торганда, аларга каршы Игнат Данилов килгәне күренде. Чапаев урамы почмагында тукталып калдылар. Исәнлек-саулык турында кыска гына сүз алышкач, Игнат бер Василга, бер Зиннурга карап торды да (ул инде Зиннурны да белә иде) сүз ачты:

— Ярый әле, чыгып китмәгәнсез икән, койрыгыгызны тоттым тәки. Әйдәгез, киттек, минем тормышларны да күреп чыгарсыз...

Ничектер шунда Васил читенсенгән сыман күренде.

— Мәшәкатьләп йөрү килешер микән соң? — диде ул.
— Нинди мәшәкать? Берәр тустыган чәй эчеп чыгарсыз. Аңа карап айның бер чите кителмәс...

Өчәүләп Яңа Наратлының көнчыгыш ягына таба юнәлделәр. Менә бер урам үттеләр, ике урам, ниһаять, өченче урамга барып керделәр. Бу нинди хикмәт: һаман бараклар да бараклар... Мондый типтагы биналар, бердән, һәр яктан уңайлы торак шартларын булдыру өчен җайсыз булсалар, икенчедән, аларның «яшәү гомерләре» дә озын түгел, барыбер ун-унбиш ел үткәч, сүтәргә туры киләчәк андый йортларны. Васил шул турыда баш ватып бара торгач, авызыннан сүз ычкынып киткәнен дә сизмәде:

— Нигә бу хәтле күп салганнар боларны? — Башкаларның тын баруларын күреп, башлаган сүзен дәвам иттерде: — Юк, дускайлар, хәзер инде бараклар заманы үтте. Монда кемнеңдер башы эшләп җиткермәгән булырга кирәк. Алга карап, киләчәкне күздә тотып эш итмәгәннәр барак салучылар, минемчә. Бүгенге көн белән генә яшәп булмый бит...

Ул тагы да нидер әйтмәкче булган иде дә, Игнат каршы төште:

— Алар да кирәк, бараклардан башка да булмый. Капиталь йортларны салырга ни кирпече, ни башка материалы җитешми аның. Шәһәрдән ерак мондый җирләрдә.

— Ничек кенә булмасын, үзен аклый торган эш түгел бу, Игнат.

Тирә-яктагы күренешләргә карый-карый берничә минут тын баргач, поселокның урталарына килеп җиттеләр. Биредә инде хәл башкачарак иде. Киң урам, бер калыпка сугып эшләнгән шикелле, берсеннән икенчесен аеруы мөмкин булмаган ике катлы йортлар. Төньяктан көньякка таба калкып барган бу урамның һәр ике ягында яңа йортлар салынып ята иде. Биредә алар адымнарын салмакландырдылар. Әлегәчә ике инженерның сөйләшүен тыңлап барган Зиннур да сүзгә кушылды:

— Бу тирәләр инде шәһәргә охшый.

Игнат, аны ишетмәгәндәй, Васил куертканнар турында әйләнде:

— Хәзер инде бараклар салмыйлар. Киләчәктә дүртәр-бишәр катлы йортлар салу проектлаштырыла. Әлбәттә, бараклар салу белән кемдер, син әйтмешли, артыграк бөгеп җибәргән булырга кирәк.

— Бу урамның исеме ничек, бер җирдә дә язуы күренми.

Василның бу соравына каршы Игнат ашыкмый гына җавап кайтарды:

— Ленин урамы була бу безнең.

— Аннан өстәгесе?

— Анда әлегә, күрәсез, ике йортка нигез генә казылган. Энергетиклар урамы булачак. Электр станциясе эшчеләре өчен күп катлы зур йортлар салырга планлаштырылган анда.

— Бу «урам»ның күп урыны әле һаман да басу бугай? — дип сорады Зиннур.

— Узган ел анда бәрәңге утырттылар. Бу поселок урынында моннан өч-дүрт ел элек чыннан да басу һәм әрәмәлекләр иде. Солыларны урып алгач, беренче баракларга нигез салганда үзем дә катнаштым,— диде Игнат.

Бер карасаң, гаҗәп матур, гаҗәп күңелле урын: төньяктагы калкулыкта, нәкъ тау өстендә шикелле, Иске Наратлы, ә поселокның кояш чыгыш һәм кояш батыш якларыннан сузылган күксел урманнар көньягында бергә килеп тоташалар да гүя кешеләрне үзләренә таба чакырып торалар. Васил күптән укыган бер китапны хәтеренә китерде. Пугачев явы турында язарга материал җыйганда кайчандыр бу тирәләрдән бөек рус шагыйре Александр Пушкин узган. Аның тарафыннан язылган «Пугачев бунты» китабының бик иске басмаларыннан берсендә бу яклардан Пугачев явы үткәндә хәзерге Иске Наратлы тирәләрендә таш крепость булуы турында да телгә алына. «Менә нинди җирләр,— дип уйлады Васил.— Пугачев эзләре, Пушкин эзләре...» Кинәт кенә ул Игнатка таба башын борды да революциягә кадәр бу урыннарда кемнәр хуҗалык итүен сорады.

— Бәлки ишеткәнең бардыр, син үзең шушы якныкы булгач,— дип өстәде.

Игнат бу якның тарихын ул кадәр яхшы белмәсә дә, бөтенләй хәбәрсез түгел иде. Өлкәннәрдән, авылдашларыннан ишеткәне бар иде аның.

— Монда дегет кебек кара туфраклы җирләр. Элек Стахеев диган бик бай алпавыт хуҗа булган бу басуларга. Ул үзе Алабугада торган.

Бу тирәләрдә аның управляющие баш булып йөргән. Стахеевның Камада үз пароходлары, баржалары булган. Минем әни бик нык белә ул хакларда. Сорасагыз, һәммәсен дә әйтеп бирер.

Тиздән поселокның зур йортлы урамнары артта калды. Алар әйтерсең, шәһәрдән чыгып авылга керделәр. Игнат урамдагы һәркем үзе салган таныш өйләргә игътибар бирмичә, алдына туры караган килеш тыныч кына бара бирде. Васил белән Зиннур исә төзек каралтылы, күбесе алты почмаклы өйләрдән тезелгән урамның әле бер ягына, әле икенче ягына күз салгалап бардылар. Ара-тирә әллә ни шәп булмаган иске өйләр дә күзгә чалынып китә иде. Күрәсең, якын-тирә авыллардан төзелешкә өйләре — хуҗалыклары белән күченеп килүчеләр иде болар. Аларда инде нәкъ авылның үз төсе, үз рәвеше сакланган, өйләрнең капкаларына калайдан кисеп ясалган әтәчләр дә менеп утырырга житешкән иде. Байтак ихаталар турыннан үткәндә сыер мөнгерәгән, сарык бәрәннәре кычкырган авазлар да ишетелеп кала, тавыклар җырлаша. Игнатларның өйләре эрәмәгә якын гына икән. Яңа коймалар, алты почмаклы яңа өй, төзек кенә каралты-кура. Васил аның гаилә хәләте турында сораштырмаган иде. Өйгә кергәч, авылча киенгән карт анасыннан башка кеше күренмәде.

— Васил, Васил дип улымның авыз сулары корый. Васил шушы буламыни инде? — дип, кулын биреп күреште карчык. Шунда бер рәттән Зиннурга да бармак очларын сузган итте. Карчык үзе бәйләгән ак оекбашларын киеп, бик килешле һәм тере генә йөри иде өендә. Озаклямый ул табын хәзерләде, тирән тәлинкә тутырып коймак куйды, зур ак самоварны колакларыннан җилтерәтеп тотып өстәлгә китереп утыртты. Карчык үзе табынга утырмаса да, әле монысын, әле тегесен өстәлгә өсти-өсти, юмарт һәм ачык чырай белән кыстый торды:

— Әйе, менә куе итеп сөт салып эчегез. Кәҗә сөте. Бер көн кәлиндәрдән укуларын ишеттем. Кәҗә сөтен анда дөньядагы иң файдалы сөт дип язганнар.

Васил өйгә керешли лапас янында уйнап-сикереп йөргән кәҗә бәтиләрен күргән иде. Әле хәзер карчык кәҗә сөте турында сүз кузгаткач, сорамый түзмәде:

— Кәҗә асрыйсыңмыни, апа?

Карчык, өзлексез рәвештә күз кабакларының тартылып торуына эче пошкан шикелле, күз читләрен сөртеп алды да тезеп китте:

— Кәҗә дигәндәй, югыйсә аның үзен татар дуңгызы дип, бер дә белми әйтмәгәннәр әйтүен. Карап тормасаң, бер корткыч инде юньсез, дуңгыз инде чынын әйткәндә. Дуңгыз дигәндәй, ул каты борынны да асрыйбыз инде без. Һәркайсы үз урынында ярап тора шунда. Бер дә мал-туарсыз булмый. Улымның бер жалунҗы акчасына гына ышанып ятып торсаң...

Кергәннән артык сүз тегермәне тарта дигән сыманрак бер төстә әнисенә маңгай астыннан гына карап-карап алды Игнат. Карчык улының киресе, бик сүзчән булып чыкты. Бер сүзне бетермәстән, икенчесен ялгап җибәрде:

— Шулай менә төпчек улым белән тормыш көтеп яткан көнебез инде. Тормыш дигәннән тормышлар иркенгә китте казер бик. Тик менә бу көннәрне Гөргери дәдәгез генә күрә алмады. Туган ил өчен башын салды дәдәгез.— Карчык күз төпләрен алъяпкыч итәгенең очы белән сөртеп алды да тагы дәвам итте: — Башта ышанмадым, көтә-көтә чыраема әллисун сарылары чыкты. Кайтмады. Тик сандык төбендә әлекке налук кәпитәнсәләре арасында аның үлүе турында килгән язу гына ята. Аның сөякләре кай илләрдә ята торгандыр инде? Сөяк дигәннән, барыбызны да үз куенына тартып алачак инде бу җир. Үзе тудыра, үзе күмеп тә куя дигәндәй. Тик менә үз үлеме белән үлгән булса, бу тикле йөрәк ашалмас, бу тикле бәгырь телепмәс иде.— Карчык зурай-

тып стенага рам эченә куелган карточкага карады да бер сүз дә дәшмәстән кече якка кереп китте. Бераздан олы якка да чыгып, үз шөгыльләре артыннан йөри бирде.

— Ул елларны әйтәсе дә юк инде, минем дә бер туган абыем сугышта үлде,— диде Васил.

Карчык улы иярткеп кайткан кунакларның үзе белән кызыксынып сүз катуларына куана калды һәм янә тел тибрәтергә тотынды:

— Гөргери дәдәгез әйтер ие, Барбара дияр ие, шушы Гнатымны кеше итсәм, шушы күәс кырынтысын бер аякка бастыра алсам, диер ие, үлсәм дә үкенмәс идем, диер ие. Әнә, күреп торасыз, кодайның рәхмәте белән алтын багана булып житте улым Гнат.

Бу ягымлы карчык Зиннурга да бик кешелекле, бик сөйкемле күренде. Ул чырае яктырган хәлдә тыңлап кына калмады, үзе дә сүзгә кушылды:

— Бүтән балаларыгыз юкмыни, апа?

— Үз гомеремдә дүрт кыз китердем. Кодай тәгалә кушмагач дигәндәй, Гнаттан башка малай тумады.

— Кызларыгыз кайларда соң?

— Кызлар дигәннән, күптән инде башлы-күзле булып беттеләр. Кыз баланың ни аның, канатлары бер үсеп житкәч, синең ихатаңда тормый инде ул, очып китә.

Үз авыллары, төп йортлары, бу якларның танымаслык булып үзгәрә барулары, тагы әллә ниләр турында жанланып, еш кына «дигәндәй»не кушып авыз суларын корытып сөйләде Варвара карчык. Василның хәтеренә сөйләгәндә санап бетергесез «значит» кыстыручан бер танышы килеп баскандай булды һәм көлеп жибәрде. Билгеле, ул Варвара карчыкның туган авылында «Дигәндәй Варвара» кушаматы белән атап йөртелүен белми иде. Урыннан кузгалгач, Василның карашы кече якка төште: почмакта икон, аның алдында чылбырлы шәмдәле дә бар. Күрәсең, кунакның күзе өйдәге әйберләргә төшсә, хужаның күзләре кунакта иде. Варвара карчык, тик торганда жырлый башлаган тавыкны хәтерләтеп, сүз йөгертте:

— Безнең ни, керәшеннең, татардан тел алган, урыстан дин алган дигәндәй, пурмы өчен генә ул почмактагы нәмәстәкәй. Картлардан калган гадәт инде шунда...— Карчыкның бу сүзләренә каршы килеп тә яки башкача да кайтарып сүз әйтүче булмады. Варвара карчык ул арада аралыктан әйләнеп килде, аның кулында кечкенә капчык иде. Шуннан учлап-учлап көнбагыш алды да яшьләрнең кесәләренә тутыра башлады:

— Үзем үстергән айбагыр, рәхәтләнеп чиертеп йөрерсез. Юлларны кыскарта, барасы жиреңә тиз аппара ул айбагыр дигән затлы ризык. Шулай килгәләп торыгыз, Данилыплар капкасы кай якка ачылганны белдегез инде казер. Якты чырай, такта чәй, дигәндәй...

Кунаклар бөтен хужалыкны Варвара карчыкның үз кулында тотуын һәм әле Игнатның шушы көнгәчә өйләнмәгән икәнен дә абайлап алдылар. Васил Игнатның институтта укыган елларда йомшак табигатьле булуын, башкалар кебек, кызлар белән дә йөрмәвен исенә төшерде. Өченче дистәне куып килгән кешенең гаилә хәле, аңа калса, ничектер аңлашылып житми кебек иде.

Василның менә шушы минутларда каядыр ераграк чыгып китәсе килә иде. СМУның шактый таушалган газигы бар, бәлки шуңа утырып бер сәфәр йөреп кайтырга кирәктер? Юк, жәяү йөрү артыграк булыр. Поселоктан ерак булмаган урманга барып кайтсалар нишләр? Бәлки ул үзен борчыган хисләрнең кайберләренә жаваплар табар? Васил үзенең теләген иптәшләренә әйтте, тегеләр каршы килмәделәр. Биш-алты минут үтүгә инде, Кармалка дип аталган кечкенә инеш куперчегеннән

чыгып, ат тизәкләре һәм коелдык саламнар белән чуарланган тар гына юлдан урманга таба киттеләр.

Яз сулышы!

Табигатьнең янару һәм терелү чаклары!

Яр буендагы таллыклар салмак кына тирбәләләр...

Ерак юллар үтеп, әле күптән түгел безнең бу тарафларга сагынып кайткан кара каргалар шул таллыклар өстеннән көтү-көтү булып, җирне котлагандай кычкыра-кычкыра очалар, бу яклардагы үзгәрешләрне күреп, беркадәр ятсыналар да шикелле. Зиннур куанычлы төстә әйтеп куйды:

— Сабанчы кошлар да килгән.

Кара каргалар юл читләренә төшә башладылар. Алар, үз шәүләләреннән үзләре курыккан кебек, елт-елт караналар, гәүдәләре озынча, юка, өсләре дә кара-кучкылланып ялтырап тормый, юл килеп ябыкканнар, күрәсең.

Тиздән урманга килеп керделәр. Биредә әле кыш кышлыгын итә, агач төпләрендә ап-ак карлар шикәрдәй агарып ята, тар урман юлы да нәкъ кышка хас карлы һәм ачык кырлардагы шикелле каралмаган, шадраланмаган иде. Ә агачларга карасаң, аларның кышкы тирән йокыдан уянган булулары сизелеп тора, бигрәк тә тал һәм тирәкләр яшь бөреләрен бүртереп, якты, җылы нурлар эчеп утыралар. Урман урман инде, аның саф һавасы, үзенә генә хас тынлыгы, тәннәргә рәхәт җиңеллек салуы һәм сулышларны рәхәт киңәйтүе аларның рухын күтәрде. Урман юлы тар, күңелле, биредә хисләр нечкәрә. Авылга килеп кергәч эт өреп якн этәч кычкырып каршы алган кебек, урманда берен-че булып тукраннар күренде. Әллә нинди кызыл түшле, берсеннән-бер-се матур кошлар гел очрый тордылар. Тар гына әлеге юл аларны шактый ерак алып китте. Биредә инде карангырак һәм дымлырак та иде. Ике километрлар чамасы эчкә кергәч, көчле гүләгән мотор тавышлары аларның игътибарын үзенә тартты. Шуннан соң күп тә үтмәде, авыр гәүдәле бульдозер күренде. Эшнең нидә икәнен бер кадәр чамалаган Васил ашыгып сорый куйды:

— Монда ни эшлиләр, Игнат?

— Күрәсең, агач аударалар.

— Ә нигә?

— Мачталарга юл ачалар.

— Әһә, бу төштән югары вольтлы линия үтәчәк...

— Әйе.

— Харап итәләр...

— Нигә? — дип сорады Игнат.

Васильның кашлары җыерылган, чыраенда һәм күзләрендә борчылу сизелә иде. Ул инде сукрангнны хәтерләтеп әйтте:

— Бу бит урман, нинди шәп агачларны әрәм итәләр. Чытырманлы әрәмә-мазар булганда бер хәл. Ә монда... Васильның хәтеренә мәсәлче Крыловның мәшһүр сүзләре килеп төште. Дуга бөгәм дип нихәтле агачны кырып, сындырып бетергән аю... һәм тиресе ертылып үзе дә танымаслык хәлгә калган...

— Әйдәгез әле, шунда барыйк.

Зиннур белән Игнат Василга карашып алдылар да аның артыннан бульдозер эшләгән якка борылдылар.

Киң алымлы, куәтле бульдозер агачларны кырыпмы-кыра иде. Күрәсең, агач аудару берничә көн дәвам иткән булса кирәк, ачылган киң юлдан киң булып зәп-зәңгәр күк йөзе күренеп тора, агачлардан чистартылган участок читләрендә каралып өемнәр ята. Васил кулларын болгап бульдозерчыга мөрәҗәгать итте, агачларны гарипләндермәскә тырышып, саграк аударырга кирәклеген әйтте. Бульдозерчы, аның хак-

лы икәнен аңлап, риза булган төстә ияк какты һәм бу эшне үзенең дә йөрәге жылап кына башкаруын әйтте:

— Начальниклар шулай кушалар. Мин нишли алам,— диде.

Васил, эченнән әрнеп, өемнәргә тагы бер кат карап куйды да, сүз катмыйча гына, килгән сукмакларыннан кире борылды. Сукмак тар булганлыктан, алар бер-бер артлы атладылар. Урманда алардан башка да саф һава иснәп, күңелле генә сөйләшеп йөрүче парлылар очрый торды. Песиле тал ботакларын чәчәк букеты сыман кадерләп кенә кулларына тотып кайтучы кызчыклар да, малайлар да күренде. Васил кайчандыр үзенең дә шулар кебек гамьсез чакларын, яз көннәрендә пыяла банкада тал үстерүләрен һәм беренче Май бәйрәме демонстрациясенә яшел нәфис яфраклар ярган тал ботаклары арасына кәгазьдән ясалган ак чәчәкләр куеп чыккан чакларын исенә төшерде... Мәгәр боларның берсенә дә карамастан, аның күңеле борчулы, йөрәге урынында түгел иде.

## 7

Матур гына башланган кояшлы көн кинәт куе кара болытлар чыгып, өермәләнеп бозылып киткән сыман, Васил өчен кичкә таба бүгенге ял көне дә шундыйрак бер төс алды.

Саф һава иснәп, ләкин күңелгә тынгысыз яңа уйлар, яңа исәпләр салып урманнан чыкканнан соң, юлдашлары Игнат борылмалы тыкрык буенча үз өйләренә китеп барды. Васил белән Зиннур барак-гостиницага кайтып керделәр. Ләкин ни күзләре белән күрсеннәр: баскыч төпләре, коридор тулы халык. Баракның икенче башындагы торак хужалыгы конторасында да шундый ук хәл. Шуларны күрүгә Васил пошына калды. Килүчеләр арасында кызлар да бар иде. Яшьләр белән сөйләшкәннән соң, ул аларның күбесен бетончы, ташчы, штукатурчылар икәнен белде. Төзелештән кайчандыр биргән заявка буенча аларны Казан шәһәреннән оешкан төстә җибәргәннәр икән. Ул кешеләр киләчәге турында моңарга кадәр дә ишеткән, ләкин аларны бүген яки иртәгә килерләр дип уйламаган иде. Билгеле, килүче эшчеләрнең күбесе ул житәкче итеп билгеләнгән СМУ оешмасында эшләргә тиеш булачаклар. Ял көне, беркем юк диярлек. Нишләргә?

Васил торак коммуналь хужалык конторасына юнәлде. Анда бер тулай торакның коменданты, ачулы төстә, чыраен җимереп утыра иде. Кешеләрне тизрәк урнаштырырга кирәклеген әйткәч, утыз биш яшьләр тирәсендәге, озын борынлы, очлы иякле хатын зәһәр күз карашларын чагылдырып, ризасыз төстә җавап кайтарды:

— Тапканнар ял көнне килергә! Бар икән, бер минутка да жан тынычлыгы юк шушы ЖКОда. Йөрисең инде шунда эт котүчесе кебек...

Комендант хатын ризасызлыкларын бәлки тагы да мулрак сибәр иде дә, аны мөмкин кадәр тыныч һәм ягымлы булырга тырышкандай, әкрен тавыш белән Васил бүлдерде:

— Ничек кенә булмасын, урнаштырырга кирәк безгә кешеләрне.

— Урын юк,— диде хатын, күтәрелеп карамыйча гына: — Боларның үзләренә генә дә бер барак кирәк.

— Сезнең общежитиедә, мәсәлән, ничә урын бар?

— Күп булса, дүрт-биш карават буш.

— Билгеле, кыенрак. Сыйган кадәр урнаштыра торыгыз.

— Булмый, иптәш Сафин.

— Нигә булмый?

— Вазих Вафич резолюциясеннән башка кеше кабул итмибез без. Бездә тәртип шулай.

— Ул соңыннан рөхсәт итәр. Әлегә кереп урнаша торсыннар. Килгән кешеләрне урамда тотып булмый бит инде.

— Юк инде, закон боза алмыйбыз без. Бездә катгый тәртип бар, ны һичкем бозарга тиеш түгел...

— Урнаштырыгыз, монда нинди тәртип бозу булсын, ди, аңлашылмый бу.

— Приказ бирергә минем үз начальнигым бар. Кешеләр белән эш тү бик нечкә, бик четерекле эш ул, иптәш Сафин. Тегесе-монысы, сәймәсе яки матрацы аяклана башлый. Аннан соң эзләп йөр...

Васил бу комендант хатынны да, кай ягы беләндер, төзелешкә киүенен икенче көнендә үк очраган Гәрәевкә охшатты. Күрәсең, Гәрәев тәрбиясе» тирән тамыр җәйгән булса кирәк, дип уйлады. Ул хатынын бу кыланышыннан көләргә дә, ачуланырга да аптырабрак калды. Ахырда комендантка тиз арада начальник Гәрәевне эзләп табарга кирәклеген әйтте.

— Начальнигыгызның өендә телефоны бардыр ич?

— Бар.

— Алайса шалтыратыгыз, килсен.

— Аңа шалтырату файдасыз, иптәш Сафин. Өйдә юк, дип кенә җавап аласың. Ышанмасагыз, үзегез шалтыратып карагыз.

Комендант хатын әйткәннәр чынга чыкты, Гәрәев квартирасыннан: «Өйдә юк», дип җавап кайтардылар. Ахырында комендант хатын начальникны эзләп китте һәм берәр ярты сәгатьтән генә кире әйләнеп кайтты. Ярый әле, тегесе озак көттермәде. Комендант кайтып бераз торгач, бәйрәмчә яхшы киенгән, пөхтәләп кырынган, төсе гадәти көнләргә караганда кызгылтрак күренгән Гәрәев килеп тә житте. Ул бүген башыннан сирәк төшә торган кубанка бүрек урынына яшькелт эшләпә кигән иде. Васил белән кычкырып, көр тавыш белән күрешкәннән соң, тар һәм озынча кабинетының бер почмагына барып утырды. Ни өчендер ул кабинеты кебек үк озынча өстәле артында башын коймага салган карт үгез сыман кыйгаебрак торган терсәкле урындыгына күзагы белән генә карап алды. Аңа инде эшнең нәрсәгә тәрәлеп калуы көн кебек ачык иде. Уйланып торган шикелле, иреннәрен бөрештереп алды, аннары Василга карады.

— Һе, мәсьәлә шулайрак килеп чыкты алайса. Сезнең положениене аңлыйм мин, Васил Закирович.

— Кешеләрне урнаштырырга кирәк,— диде Васил түземлеген сакларга тырышып, аның инде каны кыза башлаган иде.

Гәрәев елмаеп куйды да әйтте:

— Төзүчеләрнең планы булган кебек, минем дә үз планнарым бар, Васил Закирович. Минем дә сводкаларым бар. Һәр көнне нинди тулай торакта нинди үзгәреш яки хәрәкәт — һәммәсе турында да мәгълүматлар биреп торалар миңа.— Ул өстәлендә яткан калын тышлы алфавитлы кенәгәсен ачып карады, аннары янә дәвам итте: — Урыннар аз шул, нишлик икән соң?

— Ничек тә әмәлен табарга кирәк, Вазих Вафич.

Тулай торак комендантларыннан тагы берничә кешене чакырттылар. Тарткалаша-бәхәсләшә, килгән халыкның яртысын урнаштырсалар да, чемоданнарына утырып яки басып торучылар белән нишләргә белми аптырап беттеләр. Гәрәев көчле җил вакытында бер ярдан икенче ярга ташланган бүрәнә кебек бөтерелде:

— Урта мәктәпнең берәр бүлмәсен сорасак вакытлыча гына?

Васил кашларын җыерып, кулларын селтәде, кискен рәвештә башын какты.

— Вакытлыча гына клубка урнаштырсак,— диде Гәрәев.

— Сез булдырып булмаганны сөйлисез. Башка мөмкинлекләр табарга кирәк,— диде Васил.

— Сез әйтсәгез югыйсә каршы килмәсләр иде,— дип тә карады Гәрәев.

Васил җавап кайтармады. Баш вата торгач, гостиница урнашкан баракка, урыннарны тыгызлау хисабына, берничә кешене урнаштырдылар. Ниһаять, Васил тулай торакларга юл тотты. Ахырында, узара киңәшә-тартыша, вакытлыча берничә кухняны биләргә туры килде, ике тулай торактагы кызыл почмакка да вакытлыча кешеләр кертергә туры килде.

Ләкин бу тиклесе эшләнсә дә, әле моның белән генә эш бетми, кешеләр һаман килә торачаклар бит. Аның өстенә төзелешкә кирәк булган квалификацияле эшчеләрне теге яки бу объектның өлгерүенә карап чакырта тору шулай ук котылгысыз хәл иде. Васил бу уңайдан иртәгесен Никитинның үзенә шалтыратты. Төзелеш начальнигы аңа бик теләктәшлек күрсәткән төстә андый хәлләрнең алда да очраячагын ирештерде:

— Мәскәү дә бер көндә төзелмәгән,— диде.

...Тын елга буйларында Василның танышлары һаман арта торды. Аларның һәр кайсыннан азмы-күпме яңалык, җылылык сирпелеп торган сыман тоелды аңа. Баштарак аңа ят итеп, мәзәгрәк караган кешеләр дә эш барышында ничектер торган саен ныграк ышаныч бәян итәләр кебек.

Участокларның төрлесе төрле төштә, кешеләр дә җитәрлек, йөреп кенә җитеш! Телисеңме, теләмисеңме, эш көненнең шактый өлешен бер катлы ак йортта, аннары башлыклар утырган кабинетларда уздырырга туры килә. Ул кайчандыр үзе прораб булып эшләгәндә күбрәк вакытын хезмәтнең иң кайнаган җирендә, эшчеләр арасында уздыра иде. Инде хәзер идарә начальнигы булгач, андый ук мөмкинлекләре чикләнсә дә, барыбер дөньясын онытып кабинетта гына утыра алмады. Проммәйданга чыга, конкрет рәвештә эшләрнең барышы белән танышып йөрү өчен аның йөрәге ясканып тора. Кешеләргә прораблар яки мастерлар, бригадирлар аша задание бирү генә җитми әле. Үтәлешне тикшерергә, башкарылган эшнең сыйфатын һәм күләмен белгеләргә кирәк. Саный китсәң...

Объектларны карый-карый Тын елга буена ук килеп җитте Васил. Бригадалар гадәттәгечә басылып кына эшлиләр: кайсы арматура җайланмаларын урнаштыра, кайсы аларга тышламалар ясый, кайсылары күздән бетонлап калган, ләкин өсләренә чыпта япкан галерея тирәсендәге юеш карларны тазарталар иде. Ул кешеләр белән сөйләште, карады, тикшерде, һәммәсенә төшенергә тырышты. Монда барысы да яшьләр иде. Хәтта биредә ир уртасы яшенә якынлашып килгән кешеләрне дә абзый дип йөртәләр. Хәер, андыйлар бик аз. Шундыйларның берсе Фиргали Гатин иде. Васил бу бригада янында башкаларга караганда озаграк тукталды. Ничектер шунда эшләре дә укмашыбрак, тигезрәк бара, кешеләрнең һөнәрләре дә әйбәт булса кирәк. Бригадир үзе шушы Тын елга буйларындагы авылларның берсеннән икән. Ул үзе дә туктаусыз хәрәкәттә кайнашып эшләп йөри. Яшьләр аңа бик еш кына мөрәҗәгать итәләр:

— Фиргали абзый, бу «челтәр»не кайсы башы белән урнаштырыйк?

— Фиргали абзый, арматура китерәләр.

— Фиргали абзый, вибратор әллә нишләде, чыгымчылый.

— Фиргали абзый, рулетканы бир әле, монда почмак туры килеп бетми, үлчәп карыйк әле.

Фиргали Гатин эшчеләрнең берсен дә кире какмый, берсен дә җавапсыз калдырмый. Васил бу кешегә сокланагандай, тирән кызыксыну белән карап, күзәтеп торды. Васил бригада егетләренең бер һөнәр белән генә чикләнмичә, бер үк вакытта арматура эшен дә яхшы белүләрен, бетон салуны да үзләре башкаруын, изоляцияләү эшендә дә аларга читтән ярдәм кирәк булмаганын шунда эш барышында чамалап алды. «Әх, шушындый бригадалар күбрәк булса икән»,— дип уйлады.

Бригада кешеләре шаукымына ияреп, югыйсә һич кенә дә теле бармаса да, бригадирга «абзый» дип әйтергә туры килде:

— Фиргали абзый, сез күптәнме Яңа Наратлыда?

— Күптән. Без килгәч тә Иске Наратлыда тордык.

— Элек кайларда эшләгән идегез?

— Саный китсәң...— Брезент бияләен салып, бармакларын бөгеп сөйләргә кереште ул: — Уфа, аннан Чиләбе, Салават электростанцияләрен төзүдә катнаштым. Аннан үзебезнең якларга кайттым. Хәзер инде шушында тепләнеп каласым килә. Яшь чаклар узып китте, минем кебекләргә төп оя корырга вакыт җиткәндер дип уйлыйм.

— Алайса сез авылдан бик күптән киткән кеше?

— Мең ел дисәм, арттыру булыр, йөз ел дисәм, азрак булыр. Менә шулай бот буе чагымнан ук авылдан чыгып киттем мин.

— Авылда кардәш-ыругларыгыз бармы соң?

— Бар дисәң — бар, юк дисәң — юк, чыбык очлары гына. Болай бәйләнешне өзеп бетергән юк югын. Кесәңдә булса, бик якты чырай белән каршы алалар...

Эш, яз, якындагы бурычлар турында кайта-кайта сөйләшә торгач, Гатин бригадасы кешеләре белән тагын да ныграк танышты Васил. Җиргә нык басып йөрүчән, урта гәүдәле, Василга калса, куллары озынрак күренгән һәм нечкә генә кара мыеклы, куе кашлы, очлырак борынлы бу кеше белән сөйләшү ничектер күңелле сыман тоелды.

— Мин сезне хәзер таныйм инде, онытмам,— диде Васил.

Фиргали авызын киң ерып тешләрен агартты:

— Мине берәү белән дә бутамассыз, Васил Закирович, мин бит... тамгалы агач димәсәм.

Ул мыек очларын бөтереп алды, күзләрендә тере очкыннар чагылды:

— Төзелештә бүтән мыеклы берәүне дә күрмәгәндерсез ич?

— Хәтерләмим,— диде Васил.

— Шадра кеше дә ул гына,— дип шаяртты кайсыдыр.

Фиргали аңа ачуланмады, башкалар белән бергә кычкырып көлде һәм тегенең авызына сылап та куйды:

— Беләсең килсә: шадра йөрәк яндыра ул, энем.

Фиргалиләр белән янәшә эшләүче Петр Кузнецов бригадасына да тукталды Васил. Гомуми эш, теге-бу турыда сораштырды.

— Юл өзеклегендә эшчеләргә түләү ничек булыр? — дип сорады Кузнецов. Бу сорауга каршы ачык итеп өзеп бер сүз дә әйтә алмады Васил. Тик:

— Быел юл өзеклеге булмас,— диде. Кешеләр бу сүздән бер нәрсә дә аңламадылар һәм аның артыннан ни әйтергә белмичә, аптыраган рәвештәрәк карап калдылар. Васил да үз әйткәненә үзе төшенеп җитмәде кебек, аның бәгырен кайнатып җибәргәндәй булды бу сорау...

Иртәнчәк әле болыты да рәтләп күренми иде, кай арада болыт чыкты да, кай арада зәңгәр нурлар белән балкып, елмаеп торган күк битен каплап алды. Ул гынамы? Җәйге күк күкрәү алдыннан гына була торган бер рәвештә салкынча җил исеп китте, аның артыннан тагы тып-тын булып калды да бурап-ишеп җепшек кар яварга тотынды. Кар башына кар җитә торган чаклар хәзер, табигатьтәге соңгы тартыш, кыш белән яз тартышы шушыдыр инде, дип уйлады Васил. Ул, өстен кага-кага, вагон рәвешендәге озынча каралтыга килеп керде. Тактадан вакытлыча салынган бу каралтыны, бер башында буфет урнашканга күрәдер инде, буфет дип йөртәләр иде. Инде гадәте буенча эчкә кергәч, бүреген салса, аңа да әрсез март карлары сырышырга өлгергәннәр иде.

Васил шушында гына капкалап алырга булды. Буфетка чират зур түгел иде. Озак көтәргә туры килмәде, үзенә коры-сары кайбер ашамлыклар алып, ул якындагы озынча өстәлләрнең берсе артына чүмәште.

Бу өстәлдә барысы да хатын-кызлар. Арырак ир-ат. Васил да ипләп кенә тәгам җыярга тотынды. Ара-тирә ул күзен өстәл артындагы кешеләргә төшереп-төшереп ала бар. Ашарга күбесе өйләреннән алып килгәннәр. Һәркемнең диярлек кечкенә биштәре яки сумкасы бар, һич югында буфеттан компот һәм сөттән башка әйбер алмыйлар диярлек. Әнә кемнәрдер тырнаклары белән сак кына очлы башыннан ватып йомырка әрчеп ашыйлар, кемдер әбисен мактый-мактый өчпочмак «бөгә». Васил тирәсендә утыручы хатын-кызлар, аннан тарсынудан булса кирәк, мөмкин кадәр тын, авыз-борыннарын җыйнабрак ашыйлар. Каяндыр бик тәмле булып, борыннарны кытыклап, кайнар бәрәңге исе килә иде.

— Әх, нинди тәмле ис,— дип куйды Васил.

Бәрәңге дигәне аның күршесендә генә икән. Елмайганда авыз кырыйларында бик сөйкемле чокырчыклар хасил була торган һәм шуның белән сөйкемле күренгән зәңгәр яулыклы кыз шаяртып аңа сүз кушты:

— Рәхим итегез, абый. Исе борыныгызга кереп өмсендергәч, авыз итмичә ярамас.— Ул Васил алдына зурлыгы бәләктән аз кайтыш диярлек ике бәрәңге куйды.

— Рәхмәт,— диде Васил һәм алдына теге кыз куйган, кабыгы азмаз көйгән бәрәңгене бармакларын пешерә-пешерә әрчеп, пары чыгып торган хәлдә, тәмләп ашарга кереште. Әйтерсең лә, ул бу тәмле бәрәңгене гомерендә беренче мәртәбә ашый, хәтта авызы яхшы ук пешкәнен дә соңыннан гына сизенде. Ары почмакта мичкәне бозып ясалган тимер мич яна, аның коры җылысы бөтен тәнне йомшартып, һавага тарала. Бәрәңгене дә шундагы кайнар күмергә тәгәрәтеп пешергәннәр икән. Васил бәрәңгене ашап туйгач, чәй сорарга исәпләп буфетчыга мөрәҗәгать иткән иде, анысы башын селкеп тимер мич янына күрсәтте. Ул да булмады, яшь кенә юантык бер хатын аңа зур кружка белән булары чыгып торган чәй китерде. Васил соңыннан бу хатынның, йөкле булганлыктан, шушында җиңел эштә, ягъни дневальный хезмәтен үтәп, тактә бинаны ягып-җылытып торганлыгын белде. Ашаган чагында кешеләр тын утырсалар да, ашап туйгач, телләре чишелде. Хәтта кайсыларыдыр җырлап та җибәрделәр. Ир-ат арасында тәмәке көйрәтеп һавага күксел төтен тарала башлагач, хатын-кызлар ду күтәрделәр. Василга бәрәңге биргән Зәңгәр яулык тегеләрне әләп алды:

— Чыгып тартыгыз, иптәшкәйләрем. Сезнең арада йөреп инде болай да бар киемнәргә тәмәке сасысы сеңеп бетте.

Берничә ир кеше буфеттан чыгып киттеләр. Тик хатын-кызлардан ерак түгел сипкелле бер егет (Васил аны Фиргали бригадасында күргән иде) һаман каршылык күрсәтте, һаман сүз көрәштерде, үзе һавага төтен тузгыта.

— Рафис, киреләнмә инде,— дип, ялынулы тавыш белән дәште аңа Зәңгәр яулык.

Тегесе муенын бөгәргә теләми иде бугай, киреләнеп маташты:

— Мин учыма гына тартам.

— И кире беткән баш.

— Бу безнең ял итү, ашау-тарту урыны. Төтенне яратмасагыз, үзегезгә аерым буфет ачтырыгыз, Мәдинә туташ,— диде Рафис дигәне.

Мәдинәне яклап башка хатын-кызлар кушылды:

— Чык, чык, валлаһи өстерәп чыгарабыз, Рафис, рисвай итәбез.

— Килеп карагыз, чыпчык урынына очарсыз минем яннан.

Ләкин сүз көрәштереп хикмәт чыкмагач, биш-алты хатын-кыз аны тартып-сөйрәп урыныннан кузгаттылар. Нишләсен, Рафис та чыгып тартырга мәҗбүр булды.

Васил әле күптән түгел генә төзелешкә беренче тапкыр килгәндә шушы хатын-кызлар белән бергә тар сукмактан атлавын искә төшерде. Шулай утырганда Василның күзләренә йокы элена башлады. Ләкин

мондый оюэ озакка бармады, тиз үтте. Зур өстәлләр артында бая ашап утыргандагы тынлык юк иде инде. Берничә ир кеше шалт-шолт домино сугарга керештеләр. Икенче яктан, Василга каршы утырган Мәдинә, иреннәрен кыймылдатмый гына, авыз эченнән ниндидер яңа көй көйли иде. Васил инде чыгып китәргә дип торганда хатын-кызлардан кайсылардыр сүз куерта башладылар:

— «Ялга туктар» чаклар житә инде.

— Һәр елны шулай булганны, бер быел гына...— диде берсе.

— Әх, шул юл өзек чаклар,— дип офтанды икенчесе.

— Әшебез шундый күнелле йөгереп барганда, чокырга төшеп тәкмәрләү кебегрәк була инде бу,— дип өстәде Мәдинә.

Василга калса, кешеләр сораулы карашларын аңа таба төбәгәннәр кебек иде. Аңа гүя инә белән китереп чәнечтеләр дә бөтен тәне калтырап ниндидер салкын дулкын тез буыннарына йөгерде. Васил тик бер хакыйкатьне ачыклады: төзелешнең байтак көннәргә тукталып тору куркынычы турында бер ул гына кайгырмый икән, эшчеләрне дә бик нык борчый, бик нык хәвефкә сала, һәр яклап уйландыра һәм күңел тынлыкларын качыра икән бу хәл.

Соң аңа нишләргә? Тирә-якта эңгәмә корып утыручыларга ләм-мим дәшмичә, Васил урыныннан кутәрелде. Авыр уйлар аның җилкәсенә басалар сыман тоелды. Ул проммәйданнан поселокка таба атлады.

## 8

— Бик ашыкма, бик кабаланма, бик куырма, вакытыннан элек яныл бетәрсең,— дигән сүзне ул башлап әтисеннән ишеткән иде. Билгеле, моңарга күп еллар үтте. Салмак табигатьле, һәр нәрсәнең үз вакытын белеп, җайлап кына эш итүчән әтисе инде моннан бик күп еллар элек дөнья куйды. Яшь чактарак ул әтисе карттан ишеткән сүзләргә игътибар итмәсә дә, бара-тора андый сүзләр аның хәтеренә ешрак төшә башлады. Зариф Салихович Юлдашев карт кеше булмаса да, нигәдер соңгы елларда салмаклыкка күнә башлады. Көндез әбәткә кайткач, хатыны Зәйтүнә әзерләгән тәмле ашны телләрен йотардай булып, үтә тәмле итеп ашады ул. Хатыны китергән какао да бик тә охшады аңа. Аннары диванга кырын ятып, газеталар карарга кереште. Ул арада Зәйтүнә, тадәтенчә бер минут та соңга калмаска тырышып, поликлиникага китеп барды. Ул һәрвакыт шулай инде, уймак төбедәй кечкенә алтын сәгатенә күз төшереп кенә тора. Төгәл дисәң, төгәл инде, бер минут иртә бармас, бер минут соңгармас. Юлдашевның тәрәзәгә күзе төште. Хатыны кечкенә капкадан чыгып бара иде инде. Зәйтүнәнең зур һәм калын гәүдәсе ничектер аңа ят сыман тоелды. Аларның уртак гаилә тормышы корып яшәп башлауларына байтак гомер бит инде. Бер уйласа, әле күптәнме соң аның нечкә билле, күбәләктәй очып китәргә торган житез хәрәкәтле көләч Зәйтүнә артыннан йөргән чаклары. Кайчандыр ул аңа мәңге карап туймас, мәңге аннан күзләрен алмас сыман иде. Өйләнгәч тә баштагы елларда тик күтәреп кенә йөртмәде бит ул аны. Алай гынамы? Эштән кайту белән яшь хатынының иңбашларыннан һәм тез астыннан кочып алып, бүлмә буйлап күтәрепочынып йөрүләренә нихәтле еллар үтеп киткән... «Әх, сез еллар, еллар... Агым сыман сизелми генә үтәсез дә маңгайларга җыерчык саласыз, төп-төз гәүдәләрне бөкрәйтәсез, текә тауларга гайрәтләнеп менә торган аякларның буыннарын йомшартасыз... Нигә бу болай?»

Үз башында туган мондый сорауларга Юлдашев җавап тапмады, хәер, ул аларны алай бик ясканып эзләмәде дә. Ни генә булмасын, хәзер аның Зәйтүнәсе элекке инә күзеннән үтәрлек, бер кашык суга бал итеп йотарлык чибәр дә, язгы чәчәк кебек нәфис тә түгел иде инде. Хатынының торган саен калыная, тупаслана баруы вакыт-вакыт аны

пошаманлыкка калдыра һәм куркыта иде. Җитмәсә, җимешсез агач кебек, икәүдән-икәү генә, ялгыз бит алар. Башта Зәйтүнәнең бала тапмавына, тормышларының мәшәкатьсез, ыгы-зыгы, чыр-чусыз тыныч һәм рәхәт баруына ангап да куанган кеше булмагандыр бу дөньяда. Ә бара-тора Юлдашевның да башкалар кебек улларын яки кызларын кулына тотып сөясе, башларыннан сыйпап иркәлисе килде. Әмма әкренләп еллар йомгагы сүтелә торды, мәгәр дөньяга аларның балалары тумады да тумады. Ә баланы ярату тойгысы һич кенә дә сүнмәде аның күңелендә. Моннан шактый еллар элек Казанда яшәгән чаклары каяндыр калкып хәтеренә килде...

...Алар биш катлы, балконлы зур йортның икенче катында торалар иде. Шул ук коридорда аларга каршы ишектә генә Тутченко фамилияле кешеләр яши иде. Бер чак Зариф Салихович шуларның Сережа атлы дүрт яшьлек малайлары белән дуслашып алды. Ул елны җәй нигәдер бигрәк матур килде. Тутченко үзе каядыр төньяк экспедициясе белән озак сроклы командировкага китеп барды. Юлдашевларга анда-санда гына кереп йөргәләгән Галина Степановна бер-ике көн аларда кечкенә Сережаны калдырды. Мәктәп яшендәге икенче кызлары пионер лагеренда булганлыктан, малайны карар кеше юк иде. Ничектер шунда Зариф Салиховичның өйдә утырган көннәре иде. Ул малайны бик риза булып, якты чырай күрсәтеп алып калды. Билгеле, балага сусаган кеше Сережага чын күңеленнән яратып карады. Көне буе малай белән уйнады, шаярды, ат булып дүрт аяклап малайны өстенә атландырып йөртте. Өендә нинди тәмле әйбер бар, малайга һәммәсеннән авыз иттерде. Аны кулларына тотып йоклатып, йомшак урынга салды. Тора-бара малай аңа шулкадәр ияләнде, әнисе эштән кайткач, аны ят күргәндәй, Юлдашевлардан чыкмаска тарткалаша башлады. «Мин дядя Зариф малае булам, өйгә кайтмыйм»,— дип әйтә торган булды, ул Зариф Салиховичка нинди генә рәхмәтләр әйтсә дә, аз булырдыр сыман тоелды. Ул «дядя Зариф»ны күрсә, чырае яктыра, күзләреннән шатлык нурлары сирпелә һәм бит алмалары алсулана башлый иде. Балага карата шундый самими караш, шундый кешелек күрсәтү Галина Степановнаны бөтенләй юлдан яздыра язды. Ул көннәрдә төнлә дежурлыкта торучы Зәйтүнә арткы планга күчте. Хәтта аның дөньяда барлыгы да онытыла башлады... Бер көнне Зәйтүнә, кәефсезләнеп, төнге дежурлыкка икенче врачны калдырып өйгә кайтса, ни күзе белән күрсен: аның сөекле Зарифы өйдә юк иде. Бичара Зәйтүнә кая барып сугылырга урын таба алмыйча, иңсерәп, тинтерәп төште. Хатын аптырап диванга барып егылды. Аннары кинәт айнып, өендәге әйберләрне барларга кереште. Һәммәсе үз урынында, кадерле иренең костюм, чалбарлары да шифоньерда. Бер вакыт ачык ишекне үз ачкычы белән «ачып» Зариф Салихович кайтып кермәсенме!

— Син кайда булдың?

Теге-бу, ык-мык...

Күрше хатын белән башланган бу элемтә бары тик Юлдашевларның, билгеле, Зәйтүнәнең таләп итүе буенча, квартирларын алмаштыргач кына тукталды. «Әх, бу җебегәнлек, шул чакта мәсьәләне бер якка өзгән булсам»,— дип офтанып куйды Зариф Салихович. Менә бит бу тормыш дигәнең. Балалары булса, Зәйтүнәнең ямьсезләнә баруы да сизелмәс иде кебек.

Ә ул үзе? Еллар үткән саен яшәрүгә, матурлануга бармый. Ләкин кеше үзенең нинди халәттә икәненә исәп-хисап бирәме соң? Һәр вакыт нәфисне, матурны, сафны эзли. Юлдашев, элеге шул фәлсәфәсен бик нигезле санап, папирос кабызды.

Әллә нинди көн булды әле аның өчен! Нигә бу үткәннәр каяндыр калкып чыгып, гел искә төшеп торалар? Красноярскида эшләгән еллары, тимер чыбык белән уралып алган лагерьлар, тоткыннар, шунда

аның яңа завод салдыруы, соңыннан инде тормышның өөтенләй яңа эздән бара башлавы, моңарга күнегүе аңа авыр булуы — бер-бер артлы аның күңеленнән узды.

Ул әле төзелеш начальнигы белән дә нык таныш түгел. Хәзергә ярый сыман күренсә дә, сонрак эшләре ничек тәгәрәр, ничегрәк барыр? Бәлки ул Сафин кебек кадрларны туплап, дөрес эшли торгандыр, бер-дән, үзенә йөкне сөйрәү җиңелрәк булыр, икенчедән, үзе сайлап алган кадрлар киләчәктә аның үзен дә ташламаслар. Аңа таяныч булырлар.

Ә Зәйтүнә? Ул инде яшәрүгә таба бармас, аның чәчәкләре күптән коелган хисапларга мөмкин. Бер көнне диспетчерлык пунктында булганда бик матур, бик ягымлы күренгән яшь хатын Динага күзе төште түгелме соң әле Юлдашевның? Чыннан да, нинди ягымлы булырга тиеш ул! Сүзне сүздән өзми үзе табып, җанга ятышлы итеп сөйләшә торган тагы кемне белә ул монда? Ә менә ничек җаен табарга? Төзелештә шундый зур һәм җаваплы урын тоткан кешегә килешерме соң бу? Шундый зур коллективның ышанычын аклау өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләргә тиеш түгелме соң ул? Эше эш, күңел һәм йөрәк хисләре башкачарак бит әле. «Менә сиңа, яшь олыгая барган саен күңел яшәрә. Бу нинди хикмәт, барлык кешеләр дә шулаймы икән?» — дип, үз-үзенә сорау куйды Зариф. Ләкин аның соравы җавапсыз калды. Шул Дина каһәргә берәр хәйлә табып шалтыратып караса нишләр? Ул телефон трубкасына кул сузарга өлгергәнче, телефон үзе чылтырады. Юлдашев трубкага сузылды:

— Әйе, квартира. Әйе, мин. Тыңлыйм. Тиздән барам. Күрешербез.

Телефон трубкасын куйгач, уйлары бүленүгә ачуланган сыман, Юлдашев ишекле-түрле йөренергә тотынды. «Тынгысыз кеше булырга охшый. Тагы нинди борчулар бар икән?» — дип уйлады ул Васил Сафин турында. Ул инде хәтсез вакытлардан бирле Василның зур башлыкларны көтеп, алар белән очрашырга теләвен белми иде.

Васил Сафин проммәйданнан китеп барганнан соң, турыдан-туры Никитин кабинетына юнәлде. Башында туган уйларын ачып салырга, шуларны әйтеп, тиз арада уртак тел табачакларына ышанып барды. Шундый теләкләр белән атлап керде ул идарә йортына. Инде ул кабинетка керергә торганда, бер көнге ягымлы секретарь-машинистка кырт кисеп әйтте:

— Андрей Акимович китте.

— Кая китте?

— Аны срочно обкомга чакыртып алдылар.

— Кайчан кайта?

— Билгеле түгел.

Менә бит, ни генә эшләргә юрама — синнән алда каршыңа кем тарафыннандыр киртә салып куелган була. Билгеле, ул мәсьәләне баш инженер белән дә хәл кыла алыр. Тик ничек кенә булмасын, Никитин үзе очраган булса, әйбәтрәк булыр сыман тоелган иде аңа.

Васил идарә йорты коридорында гасабиланып йөренгәндә, тәрәзәдән ялтырап торган җиңел кара машинаның автогараж ягыннан килүен күреп, бераз тынычлана калды. Ялгышмаган икән, берничә минуттан Юлдашев баскычтан менеп килә иде.

Юлдашев кабинеты начальник кабинетыннан кечерәк, мәгәр җиһаз-мебель ягыннан бер дә аннан калышлы түгел, бәлки әле артыграк та иде. Тәрәзәдән төшкән кояш нурлары турыдан-туры аның өстәлендә уйнап торганга, күзләр чагыла. Кабинет хуҗасы бер тәрәзәнең шторын кысыбрак куйды. Юлдашев ашыкмыйча гына чәчләрен рәткә китерде, баш түбәсендә ачыла башлаган пеләшне каплый алмый йөдәп бетте.

Ахырында, ничек булса да ярар дигән кыяфәттә, өстәл артына кереп

утырды. «Ягез, мин сезне тыңлыйм»,— дигән сыман, Василга текәлеп карады.

Васил турыдан-туры шулай башлап җибәрде:

— Язгы юл өзекләре чорында төзелештә эш тукталып торуы сезгә мәгълүм инде, Зариф Салихович.

— Мәгълүм.

Эчке бер пошыну һәм күңел ялкыны белән кашларын җыерган хәлдә, Васил дәвам итте:

— Быел бу хәлне булдырмаска кирәк, монын кабатлануы безгә әйтеп бетермәслек зыян китерәчәк. Халык настроениесе белән дә хисаплашырга кирәк. Аннары...

Юлдашев тыныч кыяфәттә күренсә дә, түзеп кала алмады, Сафинның сүзен бүлдерде:

— Васил Закирович, кинәт кенә «зур сикереш» ясап булмый. Хәл белән килешергә туры килә хәзергә. Менә-менә язгы былчыраклар башланыр алдында торабыз. Белмим, язгы былчыракта юл салырга керешкән бер кемне дә күргәнем юк әле минем.

Кабинетка кергәндә Васил баш инженер болай беренче сүздән ук каршы төшәр дип уена да китермәгән иде.

— Ягез, сөйләгез, рәхим итеп. Конкрет тәкъдимегезне ишетәсе килә,— диде Юлдашев, бераз көттереп.

— Производство интереслары... Менә минем расчетлар. Үзегез әйткәндәй, рәхим итеп, карагыз. Васил Сафин баш инженерга вакытлы юл төзү буенча исәпләгән сызма-расчетларын бирде. Һәм үзе, һәрбер сүзен исәпләргә тырышып, кабынып сөйләвендә булды. Юлдашев ул биргән кәгазьләрне карарга кереште:

— Мин сезне аңлыйм, Васил Закирович. Мачталар кору өчен чистартыла торган мәйданнардагы агачтан файдаланырга дисез сез. Вакытлыча юл салырга дисез. Дөрес, болар барысы да бик кыйммәтле тәкъдимнәргә ошыйлар. Ләкин...

Васил түзмәде, урыныннан ук торды:

— Ничек?

— Ничекме? Безгә бит ул агачны бушка бирмәсләр,— Юлдашев уң кулының бармакларын уйнатып дәвам итте: — Аннары язгы кар сулары төшә торган әлеге Коры Саз чокырыннан ничек котылырга? Анда күпер салган сурәттә дә хикмәт чыкмаячак ич.

— Нишләп чыкмасын?

— Су кала бит. Суга ничек итеп юл салырга ди. Бу тиклесе бөтенләй сыймый минем башка. Җир-су кипкәч...

— Уйлашыйк. Коры Сазны бәлки өстәнрәк буарга кирәктер. Ул чагында күпер салуның да кирәге калмый,— диде Васил.

— Һе, ансат кына сез. Туң җир, санап бетергесез чокыр-чакырлар. Андый урыннарга машина-ниең белән кереп чумарсың. Техниканы харап итәргә безгә бирәү дә рөхсәт бирмәс.

— Алайса нишләргә?

— Бераз сабыр итик. Бер-ике көннән кереп чыгарсыз, мин кайбер иптәшләр белән сөйләшеп куярмын,— диде Юлдашев.

— Вакыты көтми бит, Зариф Салихович.

— Ничего, житешербез, дөнья янып килми, мондый чакларда артык ашыгу файда бирми ул,— дип, Сафинны тынычландырырга тырышты Юлдашев.

Васил һаман көяләнеп йөрде. Тик икенче көнне генә Юлдашев телефоннан шалтыратты һәм Василны төзелеш идарәсе конторасына чакырды. Васил инде үзенең куйган сорауларына җавап табылгандыр, дип куанып барган иде. Ләкин Юлдашев әңгәмәне бөтенләй башка юнәлештә башлап җибәрде:

— Беренче труба нигезен казырга хәзерләнә башларга кирәк,— диде ул. Проектлары килгән икән. Баш инженер сызымнарны Васил-га сузды. Электр станциясенең биек-биек өч трубасы булачагы Васил-га билгеле иде инде. Ул бәхәсләшмәде. Бу эшне бик кирәк санап, Юлдашев әйткәннәрне җөпләп барды. Трубалар салуга хәзерлек җа-ваплы бурыч икәнен бик ачык күз алдына китереп, ул сорау куйды:

— Белгечләр кайдан киләчәк, Чиләбедәнме?

— Әйе, Чиләбедән.

— Куәтле оешма,— дип өстәде Васил.

Сугышка хәтле әле андый биек трубаларның бик сирәк булуын, аларның да кирпечтән корылулары турында сүз кузгатып алдылар. Хәзерге шартларда төзелә торган трубаларның тоташ тимер-бетоннан салынулары, аларның таза булуы хакында да тел тибрәтеп алдылар. Ләкин Юлдашев Василны әле хәзергә һәммәсеннән дә ныграк кызык-сындырган һәм борчыган мәсьәләне ни өчендер һаман читләтеп узды. Бара-тора Василның түзәрлек тәкате калмады:

— Зариф Салихович, минем тәкъдим ни хәлдәрәк?

Бу сорау ничектер шунда үзеннән-үзе Юлдашевның чырайдагы көләчлекне юып төшергән кебек булды. Ул бер кавым иреннәрен бө-рештереп, уйлангандай тын утырды да кинәт өстәл артыннан калкып чыкты. Гадәттәгечә ике каш арасындагы тар сырларны тирәнәйтеп җавап кайтарды:

— Мин сезгә фикеремне әйттем шикелле, Васил Закирович.

Васил кулларын җәеп салды:

— Сезнең ачык фикерегез юк иде бит әле башта сөйләшкәндә. Ки-ңәшергә, кемнәр белән сөйләшергә булган идегез.

— Мин сөйләштем инде. Булмый. Барып чыкмый сезнең бу хыя-лыгыз.

— Нигә хыял булсын? Минем расчетларны кая куясыз сез?

— Сер итеп кенә әйткәндә, сезнең тарафтан житди караш түгел бу.

— Ничек инде ул алай?

— Шулай! Унбиш-егерме көн, күп булса бер ай өчен генә юл төзеп булмый.

— Нишләп алай гына булсын?

— Җир-су кипкәч, нык итеп, капитальный юл салырга керешербез. Шунда бары да хәл кылыныр.

— Ә җир-су кипкәнче?

— Нишлисең? Хәл белән килешергә туры килә.

— Меңнән артык кеше бер ай буе тик торсынмыни? Бу акылга сыя торган хәл түгел бит. Төзелешкә миллионнарча зыян...

— Эшчеләрне торак төзелешенә күчерергә кирәк булыр. Аннары сезнең СМУда юл өзеклегендә дәвам итәрлек эшләр аз түгел ич. Кеше-ләрнең бер кадәресен кыскартсагыз да була.

— Мин үз фикеремдә калам, Зариф Салихович. Андрей Акимович та моңа каршы килмәс, минемчә.

— Ай-һай, риза булмас ул мондый «сикереш»кә.

— Нишләп «сикереш» булсын?

— Үзен акламый торган юлга басу беркайчан да уңыш китерми. Шул хакыйкатьне онытасыз кебек.

— Мин үз фикеремнән кайтмаячакмын.

— Артык кайнарлануның берәүгә дә файдалы яки отышлы булга-нын хәтерләмим әле мин. Сез...

Бер сәгатьтән артык барган тарткалашудан соң кинәт кенә икесе дә туктап, әйтерсең лә, сугышып алҗыган этәчләр шикелле, яңа бәре-лешкә көч җыйгандай, тынып калдылар. Васил үзенең элекке укыту-чысына гаҗәпләнеп карады. Ул үзе үк Васил шикелле борчылу хислә-ре кичерергә тиеш иде түгелме? Дөрес, аның яңа юл салу турындагы

фикере яхшы. Ә аңарчы? Һавадагы торнага ышанып, кулындагы чыпчыкны нигә җибәрергә?

Юлдашевка калса, ул Василның бу тәкъдимнәрен тыңларга да, аңларга да теләмәде. «Малайлык. Калай әтәчлек. Яшьлек»,— дип калды ул Васил чыгып киткәч. Менә бит ничек килеп чыга: үзе чакыртты, төзелештәге иң шәп урыннарның берсен тәкъдим итте. Аның өчен төзелеш башлыгы белән бәхәскә керде. Ә ул? Моны ничек аңларга? Юлдашев күңел тынлыгын җуеп, ниндидер әчпошыргыч күңелсез уйларга күмелде.

Башкалар өчен ничектер, әмма Васил Сафин өчен ел кебек озын тоелган тагы ике көн вакыт узып китте. Ул бик көтсә дә, Никитин кайтмады да кайтмады. Ул гына да түгел, аның Казаннан Мәскәүгә китеп баруы турында төзелеш идарәсенә телеграмма килеп төште. Василның борчылу хисен көчәйтеп, аяк асты көннән-көн ныграк җебетә, кояш катырак кыздыра, сыртлык урыннар каралып, кышкы юрганнарын сала да башладылар. Өзлексез машина йөреп торган юллар сазлана, алардагы чокыр-чакырлар тирәнәя барды. Васил кар астына су төшеп килгән бу чакларны тиздән язгы ташулар алмаштырачагын уйлап, бер урында катып калуның иң куркыныч хәл икәнен күз алдына бик ачык китерә иде. Ул нинди дә булса карар кабул итәргә тиеш дип санады үзен.

Үзе эшли торган бер катлы ак йортка җитәрәк аңа Игнат Данилов очрады. Ничектер шунда Игнатның да чырае сытык сыман иде. Василның нинди исәпләр белән йөрүе аңа билгеле иде инде. Икәүләп конторага керделәр. Секретарь аның кабинетының ишеген алар кереп киткәч япса да, Васил кире урыныннан торып үзе ачты, аңа һава җитмәс кебек тоелды. Гадәттә Василның сүзгә саран булмаганын белгән Игнат, аның һаман да телен йоткан шикелле тын торганын күргәч, түзмәде, сорый куйды:

— Юлдашевның муенын бөгеп булмыймы?

— Булмый шул.

Төп башлыклардан тыш әллә ни кырып булмый бит, дигән аптырашлы караш белән ул Василга карап алды. Игнат тагы ни әйтергә теләгәндер, ул хәтлесе белән санашып тормастан, Васил аңа үзе текәлеп карады.

— Син мин уйлаганнарга каршы түгелдер бит?

— Бу хакта сүз дә булырга мөмкин түгел.

— Ни булса, шул, мин бөтен җаваплылыкны үз өстемә алам.

— Ярый ла соңы начар булып бетмәсә...

— Юлдашев аркылы таяк тыгар дип уйлыйсың инде син?

— Кем белә аны? Билгеле, тәгәрмәчне үзе этеп җибәрмәс...

Васил тиз генә аннан карашын алды да өстәл читендәге ак кнопкаларның берсенә басты. Ишектә секретарь кыз күренде:

— Тыңлыйм, Васил Закирович.

— Бүген эш сәгатьләре үтүгә барлык участок башлыклары, прорабլар, мастер һәм бригадирлар конторага җыелган булсыннар. Әйе, минем кабинетка.

Шуннан соң Васил Сафинны башкача конторада күрүче булмады. Ул эш кайнаган урыннарда, кешеләр арасында йөрде. Аның колак төбендә язгы ташкыннар шавы иде...

Менә билгеләнгән вакыт килеп тә җитте. Чакырылган кешеләр кабинетка сыеп бетмәделәр, секретарь утыра торган бүлмәнең дә ишеген ачык калдырдылар. Һәр ике бүлмәдә кешеләр шыгрым тулы. Васил Сафин, чыраена чыккан алсулыкны сизмичә, чигә тамырларының калкуын тоймыйча, йөрәге леп-леп типкән хәлдә, өстәл артыннан күтәрел-

де, тере соры күзләре белән кешеләр өстенә ышанычлы бер караш ташлады да батыр һәм нык тавыш белән сүз башлады:

— Быел яз узган елгы хаталар кабатланмаска тиеш, иптәшләр! Безнең яшь коллектив көчле, ул, кирәк булса, тауларны да күчерә алыр, минемчә. Бөтен эш безнең үз кулыбызда! Шулай булгач, әйдәгез, уйлашыйк...



## 9

Кичә көне буе юмарт кояш шифалы нурларын түгә-түгә шадралаткан кар өсләрен язгы кырыс төн юка гына ак җәймә белән капларга да өлгергән. Күрәсең, кышкы тартыш төнен тәмамламаган, шунлыктан булса кирәк, әле иртә белән дә тары ярмасы хәтле генә кырпак карлар төшкәләп тора иде. Ләкин кояш офык читендә күренеп, бераз калку белән бу ак сәйләннәр, бу салкын бөртекләр гүя кинәт кенә энҗе бөртекләренә әйләнделәр дә отыры сыегаеп, бераздан инде бөтенләй күренмәс булдылар. Һавада җылылык арта барды. Берсеннән берсе калышмаган тракторларның чаналарына утырып баручылар да моны ачык тойдылар. Гомуми эшкә тоткарлык ясамас өчен бригадаларны тулаем җибәрмәделәр, аларның һәр кайсыннан өчәр-дүртәр кеше алдылар да тәҗрибәле бригадирлар җитәкчелегендә урманга юнәлделәр. Фиргали Гатин трактор чанасының алгы ягында, Рафислар, Петр Кузнецовлар, озын таза гәүдәле Викторлар белән бергә бара. Бетон салучы, изоляция ясаучы кызлардан Мәдинә, Лиза, Люда, Гөлзадәләр дә чананың койрыгынарак утырганнар. Алар шат, уйнашалар, бер-берсенең колагына нидер әйтәләр дә тагы күтәрелеп бер көлеп алалар. Рафис та башка кеннәргә караганда житдирәк, хәтта ул бер кадәр үсеп киткән сыман да күренә. Егетнең күзләрендә терелек, нәрсәгәдер ашкынын тору сизелә иде.

Мәдинә кинәт кенә ахирәтләреннән күзен алды да бригадир Фиргали абзыйсына таба башын борды:

— Ул бүрәнәләрне нишләтербез соң, Фиргали абый?

— Юлга түшәрбез, бөтен хикмәт тә менә шунда инде.

— Аннары?

— Сорау дисән, сорау сина,— дип шаяртты Фиргали.— Юл булгач нишлиләр диме? Иөрербез юлдан, машиналар чабар.

Фиргали азрак тын калып баргач, сүзне үзе башлады:

— Смотри, Мәдинә, урманда беренче начальник мин булсам, икенчесе син. Пычкылар үткен йөрмәсә, балталар ботакларны кырт итеп өзмәсә, син җаваплы.

Кайсыдыр әллә чынлап, әллә шаяртып каршы төште:

— Ә Рафисны кая куймакчы буласыз?

— Рафис үз урынында ич, әнә ничек кызларның һәммәсен берьюлы йотарлык булып карап бара,— диде Фиргали.

— Әллә яз Рафисны да уяткан мы? — дип, берсе сүз кыстыргач, һәммәсе дә кычкырып көлештеләр. Рафис исә кешеләрнең әле берсенә, әле икенчесенә караштыргалап алды, кызарды, бүртенде, әмма кайтарып сүз әйтмәде.

Кызлар бер-берсенә карашып алдылар да Мәдинә белән Лиза җыр башлады. Бер дулкынга икенчесе килеп кушылып, аны көчәйткән шикелле, аларга тиздән башкалары өстәлгәч, җыр авазлары көчлерәк яңгырады:

Су буенда кыяк үлән
Язын булмый торгандыр,
Бәлки ул да минем кебек
Яныл-көя торгандыр...
Әйе шул, шулай шул,
Янып-көя торгандыр...

тез килеп життеләр, һәм моңарчы тын яткан урманда тормыш шавы белән эш башланды. Тиешле оешмаларның тиешле кешеләре белән Васил алдан сөйләшеп, агачларны бульдозерлар белән аударудан туктаганнар иде инде. Бер зур гына төркем Фиргали Гатин артыннан атлады. Озакламый дистәләгән пычкы тавышы ишетелә башлады. Ул да булмады, зур-зур усак һәм юкә агачларының гөрселдәп җиргә егылулары күренде.

Мәдинә Фатихова звеносындагылар моннан берничә көн элек бульдозер аударган эреле-ваклы агач өемнәре тирәсенә китте. Бульдозер сындырып-ватып тәртипсез өйгән агачларны аралау җинел түгел иде. Ир-ат халкы андый өемнәрне «сүтәргә» кереште. Бик рәте китмәгән төз һәм яхшырак агачларны аерым җыйдылар. Икенче берәүләр андый агачларның ботак-чатакларын кисәләр һәм билгеле бер эшкәртелгән рәвеш алганнарын аерым өемнәргә җыялар иде. Мондый өемнәр үрчегәннән-үрчи барды. Ике көн үтүгә инде ботакларыннан арындырылган төз агачларны трактор чаналарына төяп проммәйданга ташый башладылар.

Васил Сафин үзе дә эшчеләр янына көн дә килеп-китеп йөри иде. Прораб Игнат Данилов көнозын урманда, әле бер бригада, әле икенчесе янында йөреп, вакытның үткәнен дә сизми кала. Бульдозер аударган агачларның күбесе ярылган, ватылган һәм сынган булганлыктан, яраксыз булып чыкты. Шулай да аларның яраклыларын сайлап алдылар. Инде Фиргалиләр пычкы белән кискәне чын мәгънәсендә әйбәт, карар күзгә дә ыспай иде. Бер көнне Игнат Данилов башын селкеп торды:

— Чыннан да котын алган булганнар урманның. Шул хәтле агачны әрәм иткәннәр.

Фиргали дә бу хәлгә ачына иде. Чөнки ул агачларга үсәргә ни хәтле еллар кирәк булган, ни хәтле җил-давыллар булган табигатьтә. Ул прорабның әйткәннәрен күтәреп алды:

— Әйтәсе дә юк инде, туган. Аларга бары шул егып-ватып булса да план үтәргә кирәк. Мачталарга юл ачык, дип рапорт бирергә ашыкканнардыр. Просто корткычлык та, ерткычлык та димәсәң...

Игнат аның сүзләрен җөпләп ияк какты. Фиргалинең башында икенче сорау туды:

— Син проммәйданга килеп-китеп йөрисең, иптәш Данилов, Коры Саз чокыры ни хәлдә? Бер көн киңәшмәдә Васил Закирович ул хакта өзеп кенә әйтмәде.

— Ни хәлдә булсын, быел аннан су төшмәячәк.

— Ничек? Күпер сугарга булдыларамы?

— Анда Васил Закирович үзе көйли эшне.

— Ничек итеп?

— Километр ярым өстәрәк Коры Саз буыла. Анда хәзер ком, таш салалар. Шуның белән һәммәсе дә җайланырга тиеш.

— Барып чыкса, бик тә ярап куяр бу. Комны су юмаса.

Көчле гүләп трактор килгәнлектән, аларга сүзләреннән бүленергә туры килде. Берничә минут үтүгә инде кешеләр бүрәнә хәленә китерелгән агачларны трактор чанасына төяргә керештеләр.

Ут борчасы дип юкка гына әйтмиләр булыр бу Мәдинә турында. Аны кайда гына күрмисең! Әле генә тракторны озатып җибәрешә, менә болайрак юк, дип кайсыныңдыр кулыннан балтасын алып, үзе юнып күрсәтә. Ул да булмый, инде ул ир-ат арасында, аларга юан-юан бүрәнәләрне күтәрешеп өемгә салыша. Күзләрен генә ияреп житешсен ана. Тышкы киемнәре белән ирләрдән аз аерылып торган, өстенә сырма чалбар, аякларына резин итек кигән, зәңгәр яулыклы Мәдинә ботак кисеп торучы Лизалар янында азрак тукталып торды да алардан ерак булмаган икенче звенога юнәлде. Бирердә ботак-чатакларыннан арын

цырылган агачларны баулар белән бер өемгә таба өстериләр иде. Озын һәм шактый калын бүрәнәнең бер башыннан Рафис, икенче башыннан алып гәүдәле Виктор сөйриләр иде. Мәдинә Виктор тарткан башның жинел баруын, Рафис тоткан як артка сөйрәлүен күргәч, нидер әйтергә уйлаган иде, аның үзен искәрүдән булса кирәк, Рафисның кинәт адымнарын тизләтүен күреп, дәшми калды. Әйе, дөреслектә мондагы эшкә бер дә күңеле ятмый Рафисның. Әмма Мәдинәнең килүен күреп шулай кызулаган итте ул. Мәдинә, килеп җиткәч:

— Барамы? — дип сорады.

— Бара,— диделәр тегеләр икесе бердән.

Егетләр, ул бүрәнәне өемгә илткәч, бу юлы аларга Мәдинә дә булышкан итте. Чират көтеп җирдә яткан юан озын бүрәнәне өчәүләп бергә сөйрәделәр. Егетләр баш-баштан, Мәдинә уртадан тартты. Һәркайсының чырайлары көләч иде.

— Синең белән булгач, нинди җиңел,— дип куйды Рафис.

— Сиңа, Мәдинә, егетләр булып туасы калган,— дип өстәде Виктор.

— Ә кайбер егетләргә юбка киеп йөрисе генә калды,— дип шаяртып алды Мәдинә дә. Мәдинә алар яныннан киткәндә Рафис кинәт кенә әйтеп ташлады:

— Бигрәк тиз китәсең бездән яннан. Бергә-бергә бик күңелле иде. Бу тегетабышмактагы кебегрәк килеп чыга инде: ай күрде, кояш алды.

Мәдинә эчке бер канәгатьләнү хисе белән көйгә генә атлый бирде. Аның авыз читләрендәге елмаю сызыклары тиз генә сүнмәде. Бүген күрешү белән Лизаның Рафис турында ярым шаяртып, ярым аптырап, һиһаять, ярым кинәшеп әйткән сүзләре хәтеренда яңарды. Ничек сүз куерткан әле ул аның белән?.. Ничектер бер көнне аларның кинода урыннары янәшә туры килгән. Гадәттәге аз сүзле, йомык Рафис шул хәтле сүзчәнләнеп киткән. Лиза моңарга шаккаткан. Елдан артык бергәләп эшләү дәверендә «Исәнмесез», «Драстуйте»дан башка сүз әйтмәгән егетнең тартыпмы тарта икән тел тегермәне. Лизаны озата киткән бу, тулай торакка җиткәч тә Лизаны тоткарлап, һаман такылдый да такылдый икән бу. Ахырында: «Син миңа ошыйсың. Мин сине генә яратам», дигән. Шулай әйткән дә Лизаның күңелен кузгаткан, кыз әлегә үзе дә җавап бирмәслек авыррак хәлдә калган. Менә сиңа Рафис?! Менә сиңа басынкы егет. Юаштан юан чыгар, диләр шул...

Эш көне узгач, урманнан кешеләр китеп беткән иде инде. Әллә ничек шулай туры килде, Мәдинә башкалардан артка калды да артык ашыкмыйча гына кайту ягына таба атлады. Кыз үзенең уң ягында кемнеңдер, әйтерсең лә, җирдән үсеп чыккандай кинәт кенә пәйда булуын сизде. Караса — Рафис. Бу нинди хәл? Ул моңарга артык әһәмият бирмәде, алай да сорады:

— Бу ничек булды әле, син кайдан килеп чыктың?

Рафис елмаеп аңа карап алды.

— Кайдан килеп чыгыйм? Мин көне буе урманда ич, үзең күреп торасың...

— Алайса гафу ит.

— Минем сине ачуланырга уйлаганым да юк әле.

Кинәт кабынган ут сүнгән сыман, тагы сүзләр киселде, һәр икесе тын гына атлый бирделәр. Мәдинә бу егетнең төзүче инженерлар институтында читтән торып укуын белә иде инде. Ул аның бу ягына сокланa да, хәтта аннан азрак көнләшә дә иде. Тик менә Рафисның һәр кайчан диярлек көлкерәк кыяфәттә булуы, ниндидер аңлашылмый торган йомыграк табигатьле икәнлеге һәм аннан да бигрәк бригадаларында аңа ялкау маркасы тагылып йөртелүен һич тә ошатмый иде. Аның бу үшәнлеге урманда эшләгәндә дә сизелми калмады. Бара торгач:

— Карале, мин синнән озынрак икәнмен, читтән караганда бер дә алай сыман түгел иде,— дип куйды Рафис.

Рафисның ата казың күкәй саламы, кодагый, дигән сыманрак токтомалдан әйтелгән бу сүзеннән Мәдинә кычкырып көлде:

— Егетләр озынрак булырга тиеш тә.— Кыз сүзне икенчегә борды: — Син институтта укыйсың бит әле?

— Укыйм.

— Укуларың ничек бара соң?

— Зарланырлык түгел. Билгеле, җинел генә тәгәрәми тәгәрәвен. «Удлинчо»ларым да җитәрлек...

— Отлично диген.

— Юк, мин уд... билгесенә генә кушып әйтәм...

— Безнең үзебездә кичке энергетиклар техникумы ачыла ди бит.

— Ишеттем.

— Мин шунда укырга керергә исәп тотам. Син ничек уйлыйсың, барып чыгармы?

— Ник чыкмасын! Дөньяда син булдыра алмаган эш юктыр дип йөрим мин, фуражкам белән киңәшкәч.

— Ай-һай, шулай микән?

— Нәрсә? Ант итү кирәкме?

— Юк, болай гына.

Бер сөйләшеп, бер тынып бара торгач, урман хәтсез еракта калды, поселокка якынлашканнан якынлаша бардылар. Мәдинә кичә Лиза сөйләгәннәрне исенә янә төшереп көлемсери генә башлаган иде, Рафис кинәт сүз кушты:

— Бүген кичне ничек уздырырга исәбең?

Мәдинә гаҗәпләнебрәк Рафиска карады:

— Ничек уздырыйм? Әле өйгә кайтасы бар. Ашыйсы... Аннан күз күрер...

Егет, аңа әйтеп бетерергә ирек куймыйча, үз сүзен кыстырды:

— Әйдә, икәү бергә киногә барыйк, билетын үзем алырмын.

— Кирәкми, бүген мин күргән картина бара инде.

— Булса соң? Әйбәт картинаны ике кат карасаң да ярый.

— Минем хәтерем яхшы. Бер күргәнне бик озак онытмыйм.

— Миңа һәрвакыт кырын карыйсың инде син. Ә минем синең белән барасым килә. Әйе, синең белән генә, башка беркем белән дә түгел...

— Куй әле, шаяртма, егеткәй...

— Чын әгәр, шаяртмыйм. Беләсең килсә...

— Я, нәрсә?

— Беләсең килсә, ни, бәлки, син миңа ошый торгансыңдыр да... Шулай дисәм, ни әйтерсең?

Мәдинә кычкырып көлеп җибәрде. Аннары шактый кырыс итеп әйтте:

— Менә сиңа тыйнак егет! Син шулай кызлар белән ялгыз калсаң, һәркайчан гашыйк буласыңмы? Кичә дә кемгәдер гашыйк булгансың түгелме? Юк, алай барып чыкмый ул, Рафис!

Рафисның йөзе кып-кызыл булды, чәч төпләренә кадәр кайнарлык йөгерде. Ул алдына туры караган килеш ләм-мим дәшмичә бара бирде. Менә ахмак, бу яз нишләтте соң әле аны? Бу тиклесен ул үзе дә аңлап җиткерми иде. Алар телләрен йоткандай тын калып, поселок урамына килеп керделәр һәм, бер-берсенә башкача сүз катмыйча, икесе ике якка киттеләр.

Башта кыенрак сыман күренсә дә, кешеләр урманда эшләргә дә күнектеләр. Көннәр һаман саен җылына, матурлана бара иде. Гүя алар урманга җан керттеләр. Балта-пычкы һәм мотор тавышлары бер генә

инутка да тукталып тормады. Бер көнне бер көтү сыерчык күрделәр. Әллә кайларда диңгез артларыннан кайткан бу дуслар гадәттәгедән шактый арык, ябыкканнар иде.

— Әле алар ерак юл килеп арганнар. Урманда шулай ял итеп, көраз буыннарын ныгыткач, пар-пар булып авылларга ояларына таралалар алар. Анарчы суытып та җибәрмәгәе әле,— диде Фиргали.

Җирләр ала-тиләләнде. Яз кояшы юмарт нурларын түгә-түгә Кыш бабай җәйгән ак катламны көн саен юкарта бара. Узган еллар белән чагыштырганда проммәйданда эш тукталыр чак җиткән иде инде. Тик әллә нинди ел булды быел, эш дигәне үрчегәннән үрчи торды. Коры Саз юкырыннан да ташу төшмәде. Язгы-көзге чорларда машиналар батып иткән төшләрдә, проммәйдан территориясендә юка гына ком түшәлгән урыннарга агачларны аркылы салып, бер-берсенә тимер ыргаклар белән беркетеп юл түшәргә керештеләр. Урман кисүдә Кузнецов бригадасын әле тагы бер звенены калдырып, бүтән кешеләрне үз урыннарына кайтардылар. Юл төзүдә тәҗрибәсе булган, дөнья күргән бригадир Фиргали Гатин җитәкчелек итте.

Эш турындагы кайгыртулар Василның башка уйларын артка чигендерде. Ана инде баштагы кебек көннәрнең үтүе акрын тоелмады, тик менә вакыт дигәне һич тә җитми иде. Чөнки, дөресен генә әйткәндә, уйлаганны җиренә җиткерү, очлап чыгу аның бар күңелен били иде. Тулысынча бирелсәң, үзеңә тапшырылган эшне яратсаң гына уңышка ирешергә мөмкин бит. Юл төзүне тәүлек буенча алып бардылар. Чөнки вакыты шундый, яз бик ашыктыра. Васил һәр адымын, һәр хәрәкәтен шуңа үлчәп, шуңа буйсындырып эшли иде.

Бу көннәрдә аңа Юлдашев белән очрашырга туры килмәде. Ул үзе аның янына бармады да, телефон аша шалтыратуны да кирәкле санамады. Үз чиратында Юлдашев та аны күрмәскә тырышкандай читтә йөрде. Никитинның кайтмавы Василны башта пошындырса да, баратора мондый хис тә суынды. Тик төзелеш башлыгының Мәскәүдә авырып торуы турындагы хәбәр колагына килеп сугылгач кына Васил авыр сулап куйды. Тәвәккәл таш яра дигән мәкальне ишеткәне бар иде аның. Ярый әле, көтеп тормавы яхшы булган, ул чагында нихәтле кыйммәтле алтын вакыт кулдан ычкынган булыр иде.

Ул шулай уйлады.

Юлдашевның да йөрәге түзмәде, төзелеш мәйданыннан ишетелгән хәбәрләр колагына барып сугылган булса кирәк, бер көнне ул ничәмәничә мәртәбә Васил Сафинга шалтыратты. Бу ни хәл, юк та юк? Ахырында, төштән соң ара табып, проммәйданга китте. Күбесенчә кабинетыннан чыкмый торган бу кешегә шушындый пычрак вакытта проммәйданның икеләтә кайнап торуы һич тә акылга сыймаслык хәл сыман күренде. Нигә соң ул Василның тәкъдимнәренә баштанаяк каршы килде, нәрсәгә нигезләде соң ул үзенең ризасызлыгын? Моның кирәге бар идеме? Төзелеш мәйданында йөргәндә Юлдашевның башына әнә шундыйрак исәпләр калыкты. Ләкин ул аларга җавап табудан гаҗиз иде. Юлдашев кая бармасын, кайсы гына бригадада йөрмәсен, гомуми күтәренкелек белән эшләгән кешеләрне күрде. «Димәк, бу кайнар баш кузгатып йөргән эшләр кешеләрнең күңеленә тап килә»,— дип уйлап алды ул. Ләкин бу турыда Василга әйтергә, аның алдында баш иярга теләмәде.

Күп булса ярты көнлек эш калгандыр, озынлыгы өч километрдан ким булмаган, бүрәнә түшәлгән юл тирә-яктагы казылмалар арасында үзенә бер күңелле төс алып тора иде. Төнен юлдан машиналар чабарга тиеш иде. Нәкъ шул чакта Васил Никитинның кайтып төшү хәбәрен ишетте. Шуннан соң аның күңелендә ниндидер каушау хисләре баш

калкытты. Аннары ул үз-үзенә сукранып куйды. Нигә соң әле болай үзен малайлар хәленә куя? Ул бит гаеп эшләмәгән... Шундый уйлар аның башыннан тиз генә китмәде. Ахырында, төзелештә иртән булырга да, аннары Никитин янына үзе барырга уй беркетеп ятты.

Иртән торгач, башта бирегә килгән көннәрдәге кебек, Васил ашханәгә йөгермәде. Ул инде, башка кешеләрнең күпчелеге кебек, бүлмәсендә чәй эчеп китә иде. Кайсыдыр кибеттән лимон да юнәткән иде. Ак икмәккә калын итеп май ягып, лимон салган әчкелтем-татлы чәй эчү аның башын җиңеләйтеп җибәрде. Васил төзелешкә барганда иртәнге сменада эшләүчеләр әле килә генә башлаганнар иде. Әмма ул инде хәзер үзе күнеккән беткән бер катлы ак таш йорт янында яңа газик күреп тукталып калды. Һәм ялгышмаган икән, конторага керсә, әле хезмәткәрләр килмәгәннәр иде. Җыештыручы хатын аңа төзелеш начальнигының моннан егерме минут кына элек килеп төшүен һәм проммәйданга китүен әйтте. Васил, йөрәге леп-леп типкән хәлдә, проммәйдан буйлап атлады. Ни күзе белән күрсен: җир күкрәген бизәп торган бүрәнә юлдан аңа таныш гәүдә, аңа таныш төс — Никитин, гүя юлның озынлыгын адымлап санап үлчәгән шикелле, эре-эре атлап килә иде. Василны күрү белән зур кулларын сузып килеп күреште ул.

— Сәлам, Васил Закирович, сәлам,— дип татарчалатып әйтте башлык.

— Сәлам! — дип кабатлады Васил үзе дә.

Никитинның кәефе иң шәп чакта гына «сәлам» сүзен әйтеп күрешү гадәтен Васил белми иде әле. Алар бер кавым тын гына бер-берсенә карашып тордылар. Күрәсең, мондагы эшләр турында кайту белән Никитинга бәйнә-бәйнә сөйләп биргәннәр булса кирәк.

— Сәламәтлегегез ничек, Андрей Акимович? — дип сорады Васил.

— Хәзер яхшы. Юлда каяндыр грипп эләктердем. Җәфалады берничә көн, үтте инде, ярый.

Никитин тирә-якка карашын йөртә торды, гүя бу җирләр, бу балчык өемнәре аңа бик якын, бик кадерле иде. Васил аңа булган хәлне сөйләп бирү өчен авызын гына ачкан иде, Никитин аны шунда ук бүлдерде:

— Миңа барысы да мәгълүм, туган, әнәсеннән җебенә кадәр.

— Ничек алай? Сез өйдә юк идегез ич?

— Миңа Зариф Салихович шалтыратты.

— Шалтыратты?

— Әйе.

Васил аптырабрак калды. «Ничегрәк аңларга бу Юлдашевны?». Ләкин ул бу турыда Никитинга ләм-мим сүз әйтмәде.

Кыска гына вакыт эчендә зур эш башкарылуга ихлас күңеленнән куанган Никитин Василның кулын кат-кат кысты.

— Котлыйм сезне бу адымыгыз өчен. Шәп! — диде.

— Рәхмәт, Андрей Акимович!

— Бик шәп килеп чыкты. Рәхмәт сүзе миңа түгел, сезгә, сезнең коллектив кешеләренә кагыла, Васил Закирович.

Василның җиңелчә генә бит очлары янып киткәндәй булды. Димәк, кызарды. Ул кайчандыр институтта сопроматтан уңышлы имтихан тапшырган чакларын исенә төшерде. Ул чагында да аның бит алмалары шулай янган иде бит. Никитин төрле яңалыклар турында дәртләнеп сөйләде. Якын араларда электр станциясе өчен җиһазлар кайтарыла башлый икән. Тик аларны монтаж эшләре башланганчы бик пөхтәләп, чын хуҗаларча саклык һәм дикъкать белән урнаштырырга туры киләчәк.

Алар партком секретаре Сабировны да төзелештә, бер бригада кешеләре белән әңгәмәләшеп торганда очраттылар.

— Сәлам, Солтан Сабирович! — дип тантаналы тавыш белән дәште Никитин.

Быелгы юл өзеклеге алдында тугарылып калмау һәркайсы өчен күңелле иде. Тын елга буйларыннан килгән жил, жылы дулкын булып, хушлык һәм сафлык тарата, бу тиклесе үзе бер рәхәт иде.

## 10

Шатлык булырмы бу, кайгымы?

Аларның очрашмый калган көннәре юк диярлек. Төзелештән кайткач, бераз вакытлары булу белән бер-берсенә керешәләр. Һәркайсының сөйләрлек сүзе, уртаклашырлык хисләре булмый калмый. Сөйләшеп эчләрен бушаткач, шахмат уйнарга утыралар. Дөрес, шахмат уйнауда һәр икесенең осталыклары чамалы чамалысын. Алай да тарткалашып маташырга яраталар. Бүген дә шулай булды. Васил урнашкан бүлмә иркенрәк тә, берьюлы бар кешеләр дә өйдә булмау Зиннурга ошый. Зиннур төп корпустан читтәрәк эшли иде. Бу арада аны эштә Васил-ның күргәне булмады.

— Ничек, тәгәрәтәсезме? — дип сорады Васил.

— Хәзер яхшырак китте. Техника арта тора бит.

— Тимер юл белән гел килә тора шул,— диде Васил.

— Юл турында вакытында чара күрдегез, иң яхшысы шул,— диде Зиннур.

Алар шулай гәп корып утырганда, каяндыр колакларына гармун тавышы килеп сугылды. Матур көй иде бу, моңлы көй иде. Аннары жыр тавышлары да ишетелде. Ләкин сүзләрен аерырлык түгел иде.

— Авыл монда да үзенең традицияләрен алып килгән,— диде Васил.

— Үзем уйный белмәсәм дә, яратам гармун моңнарын,— дип җөпләде Зиннур. Ул үз гомерендә өйрәнү нияте белән бер тапкыр гармун сатып алып та караган икән. Ләкин аның көрәктәй зур кулында гармун балалар уенчыгы кебек кенә күренгән һәм бармаклары гармун телләренә сыймаганнар. Бу басып карый икән, бер бармак ике телне иңләп ала. Нишләсен, гармунны яңадан кайсынадыр сатып жибәрергә туры килгән. Шуннан бирле Зиннурның гармун тотканы юк, ә тыңлау дигәндә үлеп китә ул. Шахмат фигураларын беразга хәрәкәтсез калдырып, таныш моңнарга колак салып утырдылар.

Ул ара да булмады, коридорда аяк тавышлары ишетелде һәм ишектән «юан вахтерша» дип йөртелә торган хатын күренде. Ул, әле генә почтальон калдырып киткән кәгазьләрне кулына тоткан килеш, әйтә салды:

— Икегезгә ике телеграмма суккаииар. Иң элек кемгә? Яле, биеп күрсәтегез,— диде.

— Иң элек укып карыйк әле, бәлки жыларга туры килер,— диде Васил.

Һәркайсы үзләренә килгән телеграммаларны уку белән мәшгуль булдылар. Зиннурның хатыны акча сораган. Ә Васил... Зиннур аңа күтәрелеп карауга аптырап калды. Дустының иреннәре калтырый, төсе киткән иде. Зиннур түзмәде:

— Нинди телеграмма, хатыныңнанмы?

Күтәрелеп карамыйча гына Васил сары дүрткел кәгазьне Зиннурга сузды. Анда чыннан да күңелсез хәбәр язылган: «...Әтиең бик авыр хәлдә нокта Бик тиз арада юлга чык нокта Нурзилә»,— дигән иде.

Зиннур исәбенчә, әле Хәмидәнең акчасы булырга тиеш иде. Хатыныныңң акча соравына азрак борчылса да, кием-салымыннан берәр әйбер юнәтү ихтималын уена китереп, ул тиз тынычланды. Иртәгесен эшкә барганчы, шул ук үзе яши торган баракның икенче башындагы почта бүлекчәсе урнашкан бүлмәгә кагылып чыкты.

Телеграмма алуына дүрт көн узгач, бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Зиннур эштән кайтуга аның кечкенә кызы гостиницаның баскыч төбендә уйнап йөри иде. Ул кызчыгын кулына күтәреп алды.

— Килдегезмени?

— Килдек. Әни колидолда,— диде бала.

Эче жу иткән, йөрәге бик еш типкән хәлдә, Зиннур гостиница коридорына керде. Ни күрсен: хатыны чемодан өстендә утыра. Аңа таныш әйберләр, таныш төенчекләр, таныш капчыклар һәркайсы да җайлары белән стена кырыйларына кунаклаганнар. Кайберләренә пычрак чәчрәгән. Зиннур, эчке каушавын сиздермәскә тырышып, Хәмидәнең кулын кысты:

— Исән генә килеп җиттегезме?

— Күрәсең, исән,— Хәмидәнең төсе күңелсез, күзләрендә бүтән чакларда булмый торган ниндидер ачулы очкыннар яна сыман иде. Иреннәрендә калтырау сизелә, әйтерсең лә, менә-менә әрләшергә тора иде.

Бу үзгәрешләргә мөмкин кадәр игътибар итмәскә тырышып, Зиннур Хәмидәне үзе тора торган бүлмәгә чакырды. Керделәр. Биш карават тезеп куелган озынча бүлмәгә Хәмидә ятсынып карап торды. Чемоданнарны һәм кайбер кечерәк төеннәрне Зиннурның караватастына куйдылар. Сандык белән бер зур төенне коридор почмагына китереп җайлаштырдылар. Монда башкача һич мөмкинлек юк иде. Зиннур кызының аякларын салдырып, аны җайлап кына караватына утыртты. Хәмидә бу бүлмәдәге бердәнбер өстәлгә табак-савытларының иң кирәкләрен генә алып урнаштырды. Зиннур кеше-кара кайтып күренгәнче, эчен пошырып, күңелен тырнап торган ризасызлыгы турында хатынына әйтергә, тиешле шартлар булмый торып, ашыгып килгәне өчен азрак шелтәләп алырга исәбе бик булса да, түзәргә тырышты. Алай да читләтебрәк булса да әйтми калмады:

— Ни чана юлы түгел, ни арба юлы...

— Койрык куймыйча гына, сырландырмыйча гына сөйләсәң икән.

— Иртәрәк кузгалгансыз.

— Сине көтсән...— Хәмидә бер тын тукталып, ни әйтергә икәнен ачыклаган сыман торгач, янә дәвам итте: — Синең безне юатып язган хатларыңнан тун тегеп булмый, әтисе. Аеры-чаеры торудан да читен...

— Анысы шулай, монысына мин дә кул куям.

— Куйсаң, чакыртуны һаман сузып килмәс идең әле...

— Үзең дә бик яхшы беләсең ич.

— Белсә? Ышан син ирләргә... Күп аеры яшәсәң, берәрсе башыңны-күзеңне әйләндереп куюы да бар...

Хәмидәнең бу соңгы сүзләренә Зиннур ачуланып та, шаярып та ни әйтергә белмәде, башта җавап кайтармаска да уйлаган иде, ләкин түзмәде:

— Шаяртуларыңны бер якка куеп тор әле.

— Бер дә шаярткан кеше юк.

— Ә кайда торырбыз?

— Син семьяга баш, син ир кеше, син шуны миннән сорарга тиешме? Яңа Наратлыгызда берәү дә урамда кунмый торгандыр әле. Әни әйткәндәй, иншалла, без дә урамда тормабыз.

Баш эшләп җиткерми сиңен, Зиннур. Сине сагынып, сине юксынып килгән хатынына шулай каты орыныргa тиеш идеңме? Зиннур соңыннан шулайрак уйлады. Ләкин авыздан чыккан сүз очкан кош кебек үзенә юл тапкан иде. Хәмидә инде тынычланды дигәндә генә, Зиннурның сүзсез торуына үч итепме, ничектер шунда тагы кайнарланып дәвам итте һәм чын үпкә сүзләрен ишеттерде:

— Алай бик күпсенсәң, без тәртәне борырга да күп сорамабыз, әйеме, кызым?

Бу тиклесен Зиннур бөтенләй көтмәгән иде. Менә ничек булып чыга

икән. Бик сак, бик уйлап ачарга кирәк авызыңны. Бу хатын-кыз дигәнең белән бигрәк тә шулай. Туксан тугыз тапкыр яхшы сүз әйтеп, бер тапкыр аның сырт йонын каршыга сыпырсаң — бетте, ул синең барлык яхшылыгыңны аяк астына салып таптый... Зиннур бу уйларын эчендә калдырып, тизрәк Хәмидәне юату, тынычландыру ягын карады:

— Бетте. Житте. Бәхәсләшмик, энисе. Берәр рәте чыгар. Ничек әле, безнең эти, жан биргәнгә җүн биргән, ди торган иде. Шуның шикелле, бер михнәтнең бер рәхәте дә булмый калмый ул.

Ләкин соң иде инде, Хәмидә кызчыгын кулына алып, күзләрен зәңгәрсу кулъяулыгы белән каплады. Зиннур йомшак, жылы сүзләр әйтеп, аны иңбашларыннан сөйде. Гүя Хәмидәгә шул гына кирәк иде, ул эчке ярсулы һәм бер үк вакытта жылы тавыш белән телгә килде:

— Туйдым өйдә утырып. Минем дә эшлисем килә.

— Таптың сүз, бер ай өйдә ял итү ничек туйдырды сине?

— Туйдырды. Дөньяда тик торудан да читен нәрсә юктыр. Тап миңа тизрәк эш. Дөньяны кайнатам. Краннар бармы?

— Дистәдән артык, кайсына телисең, шунысына рәхим ит!

Тиздән бүлмәдә торучы башка кешеләр дә кайтып життеләр. Булган үзгәреш алдында каушап калмадылар. Үзара киңәшеп, берсе күрше бүлмәгә чыгып йокларга булды. Тәрәзәсез стена ягына карават куеп, чаршау белән бүлеп, йокы бүлмәсе сыман урын әзерләп тә куйдылар. Нишләсеннәр, баш-күз алганчы шунда торып торырга булдылар. Тик менә баланы калдырыр урын булмаганлыктан, Хәмидәгә эшкә урнашу ягы һаман хәл ителми калды.

Көндезге тәнәфес вакытында Зиннур янына прораб Игнат Данилов килде. Ул Зиннур Гафиятуллин экипажының үзләренә нигез салу эшләрен дәвам иттерү өчен мәйдан хәзерләвенә гаять канәгать калган иде.

— Чын күңелдән рәхмәт сезгә, егетләр!

— Төп хикмәт эчке юлларның тәртипкә салынуында, юллар каралмаса, без генә әллә ни кыра алмас идек,— диде Зиннур.

Шуннан сөйләшә киттеләр. Василның әле һаман кайтып житмәве һәркайсын борчый, ничектер ул монда чакта барысы да жырлап бара шикелле иде. Сүз сүзне ияртә, тарта торгач, гаиләсенең кинәт килеп төшүе турында да тел язып алды Зиннур. Инде сүзләр бетеп, Зиннур экскаваторына менәргә барганда, Игнат бер кулын күтәреп, аның исемен әйтеп кычкырды. Зиннур кире борылып килә башлауга, Игнат: «Ярый, соңыннан...» — дип китеп барды. Аның бу кыланышыннан һич ни аңламаган Зиннур экскаваторга менеп, рычагка басты. Үзбушаткычлар үз тәртипләре белән килә тордылар, экскаваторның зур чүмече аларга үзле кызыл балчыкны төйи торды. Эш әйбәт бара, бу чаклысында Зиннурның шиге юк иде. Тик менә шушы көннәрдә килеп төшкән Хәмидә аның тынычлыгын бозды да куйды. Бераз сабыр иткән булса, ай утыз биш көннән килмәс иде ләбаса. Башта ул Никитин катына барырга исәп тоткан иде. Ләкин квартир мәсьәләсендә мөмкинлекнең соң дәрәҗәдә кыен икәнен уйлап, бу уеннан да чигенде. Кешеләр белән сөйләшү, сораштырып карау да нәтиҗә бирмәде. Якын тирәдәге татар һәм рус авылларының һәркайсында төзелештә эшләүчеләр тора. Фатир табуның үтә дә кыен икәнен белде ул. Инде нишләргә аңа? Зиннур бу турыда бер генә секундка да исеннән чыгармады, баш ватты.

Шул ук көнне кич белән гостиницага Игнат Данилов килеп чыкты. Ул юан вахтер хатыннан сорады да турыдан-туры Зиннур торган бүлмәгә керде. Зиннурлар бу вакытта чәй эчеп утыралар иде. Хуҗа урыныннан торды:

— Рәхим итегез, иптәш Данилов, каграс мактап кына йөрисез икән.

— Анысы кеше хурлап йөргән юк югын,— дип, Игнат түргәрәк узды.

Булмәдәге ерып чыга алмаслык тыгынлыкка исе китеп, иңбашларын сикертеп, карап торды да әйтте:

— Мин сезгә квартир таптым.

Зиннур аның көндезге тәнәфес вакытында нидер әйтергә җыенып та, кире борылып китүен хәзер генә аңлады.

— Кайдан? Ничек?

— Билгеле, җирдән, күктән түгел,— дип шаяртты Игнат. Ул йөк машинасы белән килгән икән, Зиннурларны ашыктыра башлады. Моңдый көтелмәгән күңелле хәл алдында Хәмидә башта каушый калды, соңра үзен бик тиз кулга алды. Ул гомерендә беренче мәртәбә күргән, шушы әйбәт тәкъдим белән килгән Игнатка карашын салды...

— Ин элек барып карап кайтасы иде.

— Ихтыярыгыз. Ирегез белә,— диде Игнат якты чырай күрсәтеп.

Зиннурның төсенә елмаю сызыклары чыкты, баштагы аптыравы, юып төшерелгән шикелле, юкка чыкты. Ул бер Игнатка, аннары Хәмидәгә карап:

— Мина ярәган — сина ярар,— диде.

Тиз генә әйберләрне төяп, Хәмидә белән кызчыкны кабинага шофер янына утырттылар да, Зиннур белән Игнат кузовка әйберләр өстенә урнашып, күченеп тә киттеләр. Юан вахтер хатын, мең төрле бәхетләр теләп, аларны кул болгый-болгый озатып калды.

Варвара карчык Зиннурларны ачык чырай, такта чәй белән каршы алды. Әйбер, җиһазларны да тиз генә урнаштырдылар. Тик карчык кайта-кайта бер сүзне кабатлады:

— Өй кин, урын житәрлек, күнел тагын да кинрәк. Ошатасыз икән, торыгыз да торыгыз. Үземә дә бер иптәш булырсыз ичмасам. Безнең Гнат ул рәтләп өйдә тормый. Аның ни, эш тә клуб, клуб та эш, дигәндәй.

Менә бит ничек килеп чыкты!

Яна Наратлыга килеп, берничә көн торгач, Васил белән бергә булганнар иде бит алар бу өйдә. Ул чагында монда килеп квартирант булып торырбыз дип кем уйлаган инде? Тормышта көтелмәгән хәлләр шулай аяк астыннан гына килә лә чыга икән ул.

Төннең байтак өлеше авышкан иде инде. Зиннур үзләренә кайсы якта урын бирерләр икән дип уй йөртә иде. Ятар вакыт житкәч, Варвара карчык аларга түр якны, олы якны тәкъдим итте. Зиннур Хәмидәгә карап алды да әйтә салды:

— Мәшәкатьләнеп үзегезне тарсындырмагыз, апа, безгә кече якта да бик шәп булыр.

— Кайсы якта теләсәгез, шунсында торырсыз. Алай булешеп маташмабыз. Үз өегездәге кебек йөрегез, балакайлар. Күршедә Гөлсинәгә уйнарга иптәшләр дә табылыр,— диде карчык.

Алгы якта ике кешелек зур гына карават тора иде. Аны кузгатмадылар. Хәмидә карават һәм мебельләрне контейнер белән тимер юлдан озаткан иде. Алар килеп житкәнче, монда һәммә әйберен булуы аны куандырып жибәрде. Караватка бик унайлы көйләнгән сырма-матрацны да кузгатмадылар. Варвара әби балага да кечкенә карават табып куйды. Байтак сөйләшкәч, гөрләшкәч, утларны сүндереп йокларга яттылар. Гостиницадагы тарлыктан, бигрәк тә ят ирләр, ят кешеләр арасында оялган хәлдә тарсынып яту түгел иде инде бу. Хәмидә иркен сулап куйды һәм Зиннурга ярым пышылдап сөйли бирде:

— Синен сүзен дөрес, этисе. Менә жан биргәнгә жүн бирде бит!

— Әлегә ярап торыр, бара-тора квартир бирми калмаслар. Барып чыкты, бәреп екты бу,— дип жөпләде Зиннур.

Теге-бу турыда сүз алгалашып ятә торгач, йокыга киткәннәрен дә тоймый калдылар. Әмма бу озакка булмады. Зиннур, карават астындамы, әллә мич арасындамы, нәрсәсендер кыштырдавына уянып китте. Бу

кыштырдау бер көчәйде, бер тынып торды, аннары тагы кабатланып Зиннурның йомыла башлаган күзләрен ачтырды. Әле генә йокыга китә, тагы кыштырдау, тагы нәрсәләрдер шакы-шокы йөриләр кебек... Бер караганда өй артында кемнәрдер бар сыман... Менә кайсыдыр өй почмагына килеп какты, шакыды бугай. Бара-тора Зиннурның йокысы бөтенләй качты. Ул малай чакта карчыклардан ишеткән җен-пәриләр турындагы төрле куркыныч уйдырмаларны исенә төшерде. Хәтта бер тапкыр ат саклаганда, бер өлкән абзый аятелкөрси догасы укып, алар яткан чирәмлеккә сызык сызып чыккан иде. Янәсе, җеннәр керми, янәсе, шайтаннар шаукымы тими... Зиннур сак кына башын калкытты, тәрәзә пәрдәсенең бер читен күтәреп, тышка карады. Берни күренми, тирән тынлык, караңгылык сөреме эчендә каралты-куралар да йоклыйлар кебек. Ул яңадан мендәргә башын салырга өлгермәде, Хәмидә пышылдап сүз кушты:

— Син дә йоклый алмыйсыңмы? Урын үзгәлисеңдер.

— Кая монда йоклау? Әнә тагы тотынды, идән астын кимерә бугай.

— Ахры, бу өйдә күсе бардыр. Каптык...

— Иртән торгач хуҗалар белән сөйләшербез. Базга агу куярга кирәк булыр.

— Мин инде бая идәндә ниндидер ала-тилә әйбер күргән сыман да булдым,— диде Хәмидә.

— Курыкканга куш күренә ул,— дип, Зиннур аны юатырга тырышты.

Нинди тынгысыз төн булды соң бу? Хәмидә урыныннан торып кызының өстенә рәтләп япты да, инде урынга ятыйм дигәндә, аның аяк астында гына шокыр-шакыр иткән тавышлар ишетелде. Ул яшен кебек атылып караватка ауды. Бу инде кыштырдау гына түгел иде, шакырдау әледән-әле кабатланып торды. Хәмидә, куркынган хәлдә, Зиннурны каты кочаклап алды:

— Әнием генә... Әллә җен дигән нәрсә чыннан да бар микән?

— Тынычлан, әнисе, нинди җен булсын ди.

Зиннур белән Хәмидә күселәрдән шигәеп, күңел тынычлыклары тәмам югалган хәлдә, озак йоклый алмыйча яттылар. Бары тик таң әтәчләре аваз бирә башлагач кына, алар интегеп, ватылып йокыга талдылар.

Варвара карчык, гадәтенчә, караңгылы-яктылыда ук, йокыдан торды. Ул башта квартирантларның тынычлыгын качырмас өчен аяк очларына гына басып йөрде. Ләкин бераздан аларның таралып, изрәп йоклауларын күргәч, батыраеп китте, сакланып йөрергә кирәклеген исеннән бөтенләй чыгарды. Карчык бер өйгә, бер чоланга кереп-чыгып йөрийөри, мал-туарын туйдырды, тавыкларына җим сипте. Ал як белән түр як арасындагы пыяла ишекне ачып куйды. Яңа никель ак самовар да җырлый-җырлый ак «эшләпә»сен кырын салып өстәлгә килеп утырды. Аның Гнатын уятып мәшәкатьләнәсе юк, ичмасам. Баш очындагы будильник кыңгыравы шалтырау белән сикереп тора ул. Нигә соң әле звонок чыңламый, әллә югыйсә кичтән борып куярга оныттымы ул аны? Юк ла, онытмаган икән, менә бер вакыт будильник чыңларга тотынды. Ул арада Игнат та сикереп торды. Звонок тавышына иң элек Хәмидә күзләрен ачты. Тиз генә Зиннурның кабыргасына төртеп уятты. Ашыкпошык киенеп, юынып, иртәнге чәйгә утырдылар. Өстәл башында, самовар артында утырган Варвара карчык йомрыларга чәйне һаман саен агыза торды. Аның төсе шат, күз, авыз читләрен каплаган җыерчыклар, елмайганлыктан, гел яктырып күренәләр иде. Карчык Зиннурларның иртән изрәп йоклауларын күз алдына китереп сорый куйды:

— Иртә белән үзем торгач инде сезне уятырга да кыюсынмадым. Яңа урын бигрәк килеште, ахры, шундый татлы итеп йоклый идегез.

Безнең монда шулай инде, машина тавышы ишетелми, тыныч урын, аулак урам.

Зиннур белән Хәмидә мәгънәле генә итеп бер-берсенә карашып алдылар. Колак төпләреннән әле дә китмәгән төнге кыштырдау, шакуларны оныта алмый, ни әйтергә белмичәрәк аптырап утыра бирделәр. Билгеле, бер яктан караганда карчыкның сүзләрен җепләү кирәк тә булгандыр. Ләкин ничек инде, күрә торып, акны кара, яшелне зәңгәр дисең? Варвара карчык өйдәге тынычлык турында сүз куерткандa Зиннур ничегрәк итеп күселәрне бетерү турында баш ватып утыра иде. Һәм ул экрен генә әйтә куйды:

— Төнлә нәрсәдер йөрде кебек.— Аннары Варвара карчыкның хәтерен калдырмау нияте белән авызыннан ычкынган сүзгә ямау салырга ашыкты: — Әллә саташтым, бәлки төштә генә булгандыр...

Карчык көлеп үк җибәрде. Ул гына булмады, урыныннан кузгалды. Мич астыннан кечкенә агач табак тартып чыгарды:

— Төш дигәннән, онытып җибәргәнмен, казымны да ашатканым юк бит әле бүген. Дөгә, дөгә, дөгә, дөгә... Минем сорыкаем, бик ачыккандырсың инде. Кара, бүтән чакта үзе чыга торган ие кагарь...

Карчыкның сайрау-чакыруы суынганчы Зиннурлар йоклаган карават астыннан соры каз килеп чыкты. Ара-тирә йомшак кына сукранган рәвештә как-кыйгак дигән аваз биреп, ишек катындагы табактан көрпә чүпләргә тотынды. Зиннур белән Хәмидә тагы бер-берсенә карашып алдылар да ирексездән көләргә тотындылар. Хәмидә шәһәрдә үскәнлектән, аның өчен яңалык иде бу. Зиннурларның да каз асраганнары булмады бугай. Хәмидә кызарып-бүртенеп булса да:

— Нишләп ул шакылдый? — дип сорады.

Казына су эчертеп йөргән Варвара карчык аның бу сүзенә җәһәт колак салды:

— Йомыркасын әйләндерә ул, кызым, шулай утырганда.

— Ә нигә әйләндерә?

— Бар төше дә тигез җылынсын өчен, томшыгы белән шулай гел әйләндереп тора ул йомыркасын.

Соры каз тиздән караватн астындагы оясына кереп утырды. Варвара карчык утыра башлаганнан бирле казының шактый ябыгуын, «чырае»ның агарып калуын, йомырка сала башлаганчы, абзарда салам җыеп, үзенә оя ясавын һәм озакламый өйгә керергә сорап нигез мүген чукуын, аның күрше-тирәдәге иң тәүфыйклы, иң акыллы казлардан булуын бербер артлы сөйләп бирде.

Хәмидә Зиннурдан калмады. Кызчыгын карчык янында калдырып, төзелешкә китеп барды. Моңарчы үзенең мал-туары, кош-кортлары белән генә көн уздыручы Варвара карчыкка яңа иптәш булды, ул нинди дер үзе дә аңламый торган бер эчке рәхәтлек кичерде.

## II

Телеграмма килгәннең икенче көнендә үк Васил юлга чыкты. Иң элек Казанга очты, аннан яхшы җиһазланган зур самолетта шул ук көнне Куйбышевка барып төште. Аның этисе карт авылда тора иде. Анда барганчы, Нурзилә янына тукталырга булды.

Таныш шәһәр, таныш йортлар, таныш кварталлар, таныш юллар һәм таныш бакчалар... Бу күренешләр алдында Василның күңеле нечкәреп, йөрәге ташып китте. Ул бер бөртек карсыз, җәйге вакыттагы шикелле коры, чиста тротуардан салмак кына атлый бирде. Шәһәр чын мәгънәсендә язгы онытылмас чакларны каршыларга әзерләнә: агач башлары тигезләп кыркылган, чәчәк клумбаларының тәбәнәк коймалары төзәтелгән, буялган иде. Әле көннәрнең ул хәтле күңел куандырырлык җылы булмавына карамастан, бик күп кеше язга хас җиңел, язга

сас пәхтә киенгәннәр, ә хатын-кызлар бигрәк тә. үтәдән-үтә күренә торган капрон оеклар кигәнгәдер инде, аларның балтырлары бөтенләй шәрә кебек. Васил аларга ни хәтле карамаска тырышса да, күзләре аны тыңламыйлар иде. Ул җирне күкрәтеп килгән, табигатьнең яшьлек чоры булган язның һәммәсен һәммәсен — үсемлекләр дөньясын да, кешеләрне дә яшәртүен уйлап алды.

Ул яңа урам. үзләре тора торган урамга килеп кергәндә, кояш яхшы ук түбән тәгәрәгән иде инде. Хәтта урамда көннең кояшлымы, түгелме икәнен аерырлык та түгел, зур йортлардан төшкән озын күләгәләр аны каплап торалар. Кайчандыр йортларның нигез чокырлары гына казылган бу урын аның күз алдында үсте, үз күз алдында калыкты. Беренче йорт... ул шактый і сен ташлаган, штукатуркаларының купкан урыннары да бар. Кешеләрнең эштән кайткан чаклары туры килгәнгәдер инде, тротуарлар халык белән тулы. Әле бу таныш урыннардан аның китүенә күптән булмаса да, әйтерсең лә, берничә ел вакыт узган, әйтерсең аерылып торган арада бик күп сулар аккан.

Квартирның ишеге бикле иде. Васил ишек алдына чыгып таныш эскәмиягә утырды. Юк! Әллә нишләде ул, берсенә дә күңеле утырмый. Тизрәк Нурзиләне күрәсе килде. Аннары этисе карт ни хәлдә икән? Ул-бу булып куйса — нишләрсең? Яшен тизлеге белән башына килгән мондый күңелсез уйлардан арынырга теләп, Васил урыныннан торды, тагын утырды. Шул ук минутта аның күз алдына Яңа Наратлы килеп баскандай булды. Ул анда чакта мондагы уйларны, мондагы исәпләрне башына да китерә алмаган иде. Андагы киеренкелек аны бөтенләе белән үзенә йотып алган иде шул. Тукта, чү! Аның тавышы түгелме соң бу? Васил яшен тизлеге белән эскәмиядән торды да үзенә каршы килүчеләргә таба атлады.

— Нурзилә!
— Васил!
— Ринат!
— Папа!

Тирә-яктагы кешеләр бармы-юкмы, берсенә дә игътибар итмәстән, кайнар рәвештә кочаклаштылар, кысыштылар. Васил кечкенә Ринатны кочагына күтәреп алды. Малайның кулларын авызына капты, битләрен малайның битенә тидерде. Ринат үзе дә дөньяда иң матур, иң сөйкемле бала, аның исе дә иң тәмле ис кебек тоелды аңа. Бүлмәләр һәркайсы Васил киткәндәге кебек үк җыйнак һәм тәртипле, һавасы татлы иде. Көньякка караган тәрәзә төбендәге балчык чүлмәктәге яран гөлләре шау чәчәктә утыралар, алсу кызыл чәчәкләр күз явын алырлык гаять матур төстә кешеләргә сәлам биреп торалар кебек.

Нурзилә чәй хәзерләү нияте белән кухняга чыгып китте. Васил аның хәл-әхвәлләр турында сөйләргә ашыкмавын аңлый алмады һәм үзе кухняга чыгып, аны җитәкләп олы бүлмәгә алып керде. Үзе, эштән кайткач, яратып ял итә торган йомшак креслога чумып, Нурзиләне каршысындагы култыксалы урындыкка утыртты. Ярым моң, ярым сагыш белән янып торган күзләрен хатынына текәде:

— Ашау-эчү соңыннан. Хәлләрегез ничек? Әти ничек?

Нурзилә нигәдер бер мизгел тын калып утырды, аннары кинәт башын күтәреп, кабарып торган чәчләрен рәтләгән итте дә Василга карады.

— Безнең хәлләрне күрәсең. Яшибез. Исән-саулар. Тик син генә ташлап киттең...

Васил Нурзиләнең сүзләрен кайнарланып бүлдерде:

— Алай әйтмә. Кирәкми.
— Нигә, дөрес түгелмени?
— Түгел! Син аны үзең дә бик яхшы аңлыйсың. Нигә хат язмадың?

— Эш күп, җитешеп булмый. Алай да бу араларда язарга исәплэп торадыр идем. Менә әтиләр...

— Берәрсе килдеме? Ничек?

— Телефоннан теге, районда эшли торган кардәшегез, кем әле, Үткүзев хәбәр итте.

— Нәрсә булды икән соң әтигә?

— Бик каты авырып урында ята, ди, Васил кайтмый калмасын, дип әйтә, ди. Карт бит инде. Ничә яшьтә әле ул безнең биатай?

— Җитмешнең өске ягында.

Беркадәр гаиләсе янында сөйләшеп утыргач, авылдан әйләнеп кайтканда яңадан кагылу нияте белән Васил тагы юлга чыкты.

Ул поезддан төшкәндә караңгы иде инде. Әле алда тагы ни хәтле юл — унбиш километрлар барасы. Станциягә керен, кешеләр белән сөйләшкәч, Васил язгы кар сулары төшкәнгә машиналарның йөрмәвен, станция белән ике арада вакытлыча юл өзелгәнен белде.

Нишләргә соң аңа? Васил тимер юл станциясендә ишекле-түрле уйланып йөрде дә телефоннан авылга шалтыратты. Аңа ат җибәрергә булдылар. Озак көтәргә туры килмәде. Күрше бер егет җайдаклап килгән иде. Василга дип җибәрелгән ат та көр генә булып,ияре дә яңа. Ике җайдак адым саен, ат тоягы баскан саен лач-лач су ерып, атлатып кына кайтсалар да, станция белән авыл арасы тиз үтелде.

Бу соңгы елларда аның туган авылына кайтканы булмады. Басу капкасыннан керү белән багана башларында янган электр лампаларын күргәч, Васил беркадәр гаҗәпләнә калды. Өлгергәннәр. Әйбәт! Бу урамнарда караңгылык сөзеп йөри-йөри, аның үзенең дә ни хәтле интеккәне булды. Вакыт шактый соң, тәрәзәләрдә утлар бик сирәк күренә, авыл керфеген йомган иде инде. Авылны уртадан икегә кисеп үтә торган Камышлы инешенә салынган күперне чыккач, икенче өй Василныкы. Шунда җиткәч, ул аттан төште, авылдаш егет атлар дворына китеп барды.

Өй эче артык үзгәрмәгән сыман күренде аңа. Шактый картайган әнисе, бер яктан, бик бетеренгән һәм кайгылы күренсә, икенчедән, улы кайтканга әйтеп бетермәслек куанды. Василның әтисе Закир карт түр яктагы киң караватта каты ыңгырашып ята иде. Күрәсең, хәле бик авырдыр инде, улының кайтып төшүен дә, аның өйгә кергәч исәнләшүен дә, сөйләшкән авазларны да ишетмәде ул.

Василның әнисе әтисеннән алты-җиде яшьләргә кече булса да, дөнья мәшәкатьләре, тормыш борчулары белән үткән еллар аны нык картайткан иде. Бөкрәя төшкән бу карчыкның кулларына зәңгәр тамырлар бүртеп чыккан, күз төпләрендә һәм авыз читләрендә тирән җыерчыклар бар. Карчык ярым пышылдап, улына миһырбанлы карап сөйли иде:

— Әткәңне бик нык хәстә тотуына атнадан артты инде. Башта йоклый алмый интекте. Юньлегә булса гына ярар иде инде. Өйгә сестра килеп уколлар да кадап карады. Файдасы шуның хәтле генә, күрәсең.

— Тамагына үтәме?

— Бөртек тәгам җыймаганына дүртенче көн дияр идем, бүген иртән бер-ике йомры сөтле чәй эчте.

— Авыр хәл, кыен хәл,— диде Васил.

— Бик бетерешке әтиең, хәлсезләнде. Быелгы кар сулары апкитмәгәе дип куркам, улым. Бу дөнья хәлен белмәссең. Сиңа хәбәр итәргә киленгә телефоннан шалтыраткан көнне бик авырлашты шулай. Ясин чыгарга картлар чакырырга ниятләп торганда үзе ничектер күзләрен ачты, чыраена тереклек йөгерде.

*Дәвамы бар*

## Илдар Юзеев

# Юк, мин яши алмыйм алай...

Юк, мин яши алмыйм алай:
Әзер утлар табып,
Җил кай якка иссә,
Шунда таба авып.
Юк, мин яши алмыйм алай:
Мичкә арка терәп,
Кеше яккан утта
Кызынырга теләп.
  Үзем — утлар ягам,
  Үзем — дөрлим, янам...
  Үзем булып яшим,
  Үзем булып калам.
Юк, мин яши алмыйм алай:
Күккә карап ятып,
Ялган алла ясап,
Сүзгә үрә катып.
Юк, мин яши алмыйм алай:
Көчлегә — баш орып,
Язмыш колы булып,
Җирнең үксез улы булып.
  Кеше — кодрәтле көч,
  Кеше — алла-тиңсез.
  Юк, мин китмәм Җирдән,—
  Дөнья нишләр минсез?

●

— Хушыгыз! Мин китәм еракка!
Хушыгыз!
Ишетелде бер аваз колакка
— Хушыгыз!
— Мин китәм кайтмаска, озакка,
Хушыгыз!
Яфраклар пышылдый колакка:
— Хушыгыз!
— Анда да моңдагы шикелле
Каеннар, чишмәләр табылыр...
Хушыгыз!
— Картайгач күңелең сагыныр,
Хушыгыз!..

— Мин китәм бөтенләй кайтмаска!
Хушыгыз!
Тау-ташлар, диварлар әйттеләр:
— Кайтырсың...
— Юк, кайтмам!
— Сугышта үлгәннәр кайттылар
Я туфрак, я ядкарь-таш булып.
— Юк, кайтмам!
— Галәмдә үлгәннәр кайттылар
Көл булып,
метеор шикелле ашкынып.
— Мин кайтмам, түзәрмен!
Бар тарту көчләрен өзәрмен.
(Туган як җилләре тәкрарлый
колакка:)
— Аңларсың киткәчтен еракка...
Бабайлар туфрагы тартыр ул,
тартыр ул,
Ни белсен яшь бала... Рәнҗемик,
Барыбер кайтыр ул,
кайтыр ул...

## Бәрәңге чәчәге

Исми җил, үсми гөл,
Кая ул яшеллек...
Көтмә дә яңгырны,
Күкрәүне, яшенне.
Күзгә дә күренмәс
Иң тыйнак бер чәчәк
Беренче төнне үк
Төшеңә керәчәк.
Бәрәңге чәчәге —
Хыялда тирбәлә.
Күз яше аркылы
Әйтәлми ир бала.
Сызыла күңелең,
Тойгыңны тый, яшер.
Бәрәнге чәчәге,
Туган җир, өй, нәсел...

Бәрәнге чәчәге
Сарылы, ак, көрән.
Далада юксынып,
Багларга мин керәм.
...Яныңда чагында
Без сине күрмибез.
Тантана-бәйрәмгә
Күтәреп йөрмибез.
Мактану, шау-шудан
Ераксың, димәк, син.
Тормышта бик кирәк
Бик кирәк бизәк син.
Туган өй нигезен
Балкытып ул чәчәк
Еракка киткәч үк
Төшеңә керәчәк.

●

Үз-үзеңне эзләп табыйм диеп,
Айлар, еллар үтә.
Үз-үзеңне югалтырга
Бер минут та җитә.
Ычкындырсаң шул мизгелне —
Бар гомерең газап.
Үз-үзенә турылыклы шәхес —
Мәгърур, көчле, азат.

•

Аннан бирле күпме печән үсте,
Яшел җәйләр узды, ак кышлар.
Нигә, нигә хәтеремнән китми
Җыелмыйча калган покослар?
Яшь ирләрнең чалгы янаулары
Йөрәгемдә уелып калдылар.
Киленнәрнең яшьлек чәчәкләре
Атар-атмас коелып калдылар.
Чалгы тоткан куллар мылтык алды,
Печән чапты яшь-яшь киленнәр...
Ир бәхетен күрә алмадым дип,
Пышылдады кайнар иреннәр.
...Картаела, ахры, туган якка
Кайтып килүләрне ешайттым.
Печән чапкан ыспай егетләрне
Мәрхүм әтиләренә охшаттым.
Яшь ирләрнең чалгы янаулары
Йөрәкләрдә уелып калмасмы?
Киленнәрнең яшьлек чәчәкләре
Атар-атмас коелып калмасмы?..

•

Заман агышыннан калуларын
Әллә сизә инде атлар да:
Чыбыркысыз-нисез, сүгенүсез
Тырышалар тизрәк атларга.
Оеп кайта бераү буш арбада,
Кулда — дилбегәсе бушаган.
Хуҗасының хәле атка күчкән:
Сорап-нитеп тормый, мөним эштән
Читләтелгән картка охшаган...

•

Яшьтәшләре бар да яуга киткән:
Үзе теләп, авыру килеш тә...
Ул ничектер калган, табып алган
Рәхәт яши торган бер эш тә.
Сугыш узган.
Кайтмаганнар — тыныч иләлдында
Кайтканнарның — йөзе ак кына.
Ә ул йөри,—
Ныграк басса — берәр мина-фәлән
Шартлап китәр кебек, сак кына.
Еллар тыныч, дәшми закон да,
Ул сөйләшми сугыш хакында...
Яшьтәшләрнең сүзсез карашлары
Ап-ак башын түбән идерә.
Сугыш кырларында тими калган
Кайнар кургаш кебек көйдерә.

Йокыга талды арып кайткан
Гүзәлләр.
Тынып калды җәйрәп яткан
Үзәннәр.
Түгелерлек мөлдерәмә
Тулган Ай,
Нурлар ташый, тау-тәхеткә
Кунган Ай.
Яңа туган сабый башы
Диярсең.
Кулларыңа алырсың да
Сөярсең.
Мичтән чыккан икмәкмени —
Түгәрәк.

Туп шикелле төшәр таудан
Тәгәрәп.
Таулар, таулар... Зәңгәр ефәк
Шәл сыман.
Ай башына бәйләргә дә
Җәл сыман.
Нурлар ташый, тау башына
Кунган Ай.
Шагыйрь күңеле — мөлдерәмә
Тулган Ай.
Бер ташыр ул, таң калырлар
Үзәннәр,
Сикереп торыр йокыга талган
Гүзәлләр.

●

Балалыкка кире кайтыйм әле,
Кире кайтыйм әле тагын бер,
Туфлиләрне салып, тыкрыклардан
Ялан аяк чабып карыйм бер...
Эшләпәмне җилгә очырыйм да,
Костюмымны элеп куйыйм да,
Яшел түмгәкләргә башны салып
Ятыйм әле Гәрә буенда.
Шагыйрь халкы шулай була инде,
Хыялланган икән дисеннәр,
Теләсә нәрсә, әйдә, сөйләсеннәр,
Тик картайган икән димәсеннәр...
Шикләнмәгез миннән, авылдашлар,
Зыян итәр өчен кайтмадым,
Кызык өчен, сорамыйча гына,
Чәлдеримче колхоз шалканын.
Кич клубта кино була икән,
Билет алмый гына карыйм бер,
Тик кызганыч, гәүдәм калынайган,
Тәрәзәдән сыймам барыбер.
Түбән очтан кайтып керимче бер
Урам тутырып елап, кыйналып,
Кайгыларга батып йөримче бер
Кызлар сөйгән булып кыланып...

## Йөзек кашы

Һич кенә дә көтмәгәндә,
Уйламаганда,
Синең белән очраштык без
Зәңгәр аланда.
Йөзек салыш уйнаганда
Син туктап тордың.
Йөзегеңне минем учта
Онытып калдырдың.
Бигрәк нурлы йөзең, кашың,
Ник оныттың йөзек кашың?

Моңа кадәр уйнап йөргән
Моңсыз бер бала
Күңелендә сызылып-сызылып
Моннар кузгала.
Тыныч кына яшәгәндә —
Уенчан — уймак.
Төннәр буе йоклый алмыйм
Гел сине уйлап.
Биграк моңлы йөзең, кашың,
Ник оныттың йөзек кашың?
Үзең киттең, йөзек кашың
Онытылып калды.
Яшь күңелем сиңа таба
Омтылып калды.
Әллә уйнап, әллә уйлап,
Кайда йөридер,
Әллә чынлап оныткандыр,
Әллә юридер.
Кайда үзең, йөзең, кашың?
Ник оныттың йөзек кашың?

## Мин сине нигә яратам?..

*Кызга егет җавабы*

Мин сине яратам,
Үзем дә белмим, ни өчен.
Әллә борын очындагы
Бәләкәй генә миң өчен?
Мин сине яратам:
Үзәккә үтүләрең өчен.
«Кит аннан, мәхәббәтсез», дип
Ташлап китүләрең өчен.
Мин сине яратам:
Кабат кайтуларың өчен,
«Мәңге, мәңге үптермим» дип,
Саргайтуларың өчен.
Мин сине яратам
Кулга иялэшмәүләрең өчен,
Ялгыш бер кызга карасам,
Сөйләшмәүләрең өчен.
Мин сине яратам:
Шулай ялындыруларың өчен,
Бер кыз миңа караса,
Борын салындыруларың өчен:
Кагылыйм дисәм, «Каравыл!»
Кычкыруларың өчен,
Тоттым дигәндә, кулымнан
Ычкынуларың өчен.
Мин сине яратам
Һич тә кача алмавың өчен,
Күпме хыялланып та, сине
Коча алмавым өчен.
Мин сине яратам:
Усал, үтереп карауларың өчен,
Бездән үткен керфегеңне
Йөрәккә кадауларың өчен.
Мине өзелеп яратып та,
Шуны сиздермәвең өчен,
Әнә шул сиздермәвең белән
Мине биздермәвең өчен.
Күпме мине газапладың —
Ни ачуым, ни үчем...
Мин сине яратам. Ни өчен?
Үзем дә белмим ни өчен?

## Габдрахман Әпсәләмов

# КАРТ

хикәя



Кайчак бик авыр минутлар була. Мин, йөрәк ярсуымны басарга теләп, бер үзем генә яр астына төшеп утырам. Моннан күренмәсә дә, беләм, өстән асфальт юл үтә, бертуктаусыз арлы-бирле машиналар узалар, бирегә бары тик гүләүләре генә ишетелә. Алдымда кояш яктысында киң Идел җәелеп ята, читтәрәк йөзләрчә балачага шаулашып су керәләр, кояшта кызыналар, ял итүчеләрнең күңелле шау-шуы ишетелә, моторлы көймәләр җилдереп үтеп китә, халык белән тулган су трамвайлары уза, ә мин шул ике арада йөрәгемне кысып утырам. Халыктан читкәрәк китүем аны яратмаудан, аның шатлыгына каш җыерудан түгел, бәлки шул гөрләп торган матурлыкны бозарга, ямьсезләргә теләмәүдән генә. Кем генә булмасын, күрсә, хәлеңне сораша, ә үз хәлең болай да сине туйдырып бетергән, аны сөйләү түгел, телгә аласы да килми. Идел генә сине аңлый кебек, ул синнән берни дә сорамый, кешеләргә күрсәтергә теләмәгән кайгыңны сүзсез генә каядыр еракларга агызып алып китеп яшерә, сиңа текә ярында сыеныр урын бирә. Иделнең сөзәк ярында да, Боровой тирәсендә дә шундый текә урыннар бар. Син сөяк кебек ап-ак агач төбендә яки яртылаш черегән, беркемгә дә кирәкмәс ташландык юан бүрәнә өстендә утырасың. Кояшта җемелдәгән вак дулкыннар, чулт-чулт килеп, ниндидер бетмәс җыр көйлиме яки серле әкият сөйлиме — син шуның тәэсирендә бирелеп әкрен генә онытыласың. Баш түбәңдә, текә ярда, түгәрәк-түгәрәк тишекләр — яр карлыгачларының оялары. Карлыгачлар шул тирәдә күз иярмәс тизлек белән очып йөриләр. Ярда һәм су эчендә бик күп агач төпләре күренә. Әле күптән түгел генә бу тирәләрдә куе урман булган, зур Идел килә башлагач, аны кискәннәр, төпләрне чистартып бетермәгәннәр яки бетерә алмаганнар, хәтта кискән агачлар да калгалаган. Хәзер аларны ләм каплаган, су баскан. Дулкыннар агач төпләре тирәсендәге комны юа һәм язгы ташу шул төпләрне берәм-берәм ярга чыгарып ташлый. Ләкин аларны берәү дә җыештырмый, алар һинде кирәксез, яз көне яңадан дулкыннар иркендә калалар. Былтыр, Иделдә су азрак булганга, алар әллә нихәтле күренә иде. Быел, агач төпләре артык күренми, бар да су астында. Ләкин күзеңне йомсаң, алар су астыннан калкалар кебек

һәм шунда әллә нәрсәләрне искә төшерәләр. Ихтыярсыз көрсенеп куясың.

Мин бер үзем уйланып утырырга яраткан урында моннан берничә көн элек бер карт күренә башлады. Ул какча гәүдәле, озын кулларын артына куеп, картларча башын ия төшеп, арлы-бирле йөрәнә. Өстендә, иске булса да, чиста ак костюм, башында салам эшләпә. Ап-ак мыеклы, түгәрәк кечкенә сакаллы. Уң колагы янында шактый тирән яра эзе бар. Йөзендә — карчыга кыяфәте, мыегы белән кашлары кара чагында ул шактый кырыс күренгәндер.

Без исәнләшә башладык. Бер көнне ул минем яныма — агач төбенә килеп утырды. Эшләпәсен салып, такыр башын кулъяулыгы белән сөртеп алды, аннары тагын эшләпәсен башына каплады.

— Һавалар әйбәт тора әле. Игеннәр өчен яңгыры бик кирәк, ял итүчеләр өчен — кояшы,— диде ул. Бу картларча гадәти сүз башлау гына, моннан әле бер нәрсә дә көтмисең. Шуннан карт минем исемемне сорады, үзенекен дә әйтте: Вәлиша абзый икән.

— Курәм, синең дә кайгың бар, ахры, кешеләрдән читләшәсең,— диде ул, Идел өстенә карап.— Кайгыңны кешеләргә күрсәтеп, үзеңне кызгандырасың килми шул. Кызгану синә җәберсетә. Кеше, билгеле, рәхәт яшәр өчен туа да бит, нишлисең, тормыш үзенчә ага. Барысын күреп тә бетерә алмыйсың. Бүген ничәнче число әле?

— Егерме икенче июнь,— дидем мин.

— Әйе, егерме икенче июнь, сугыш башланган көн. Каһәр генә суксын иде шул фашист ләгънәтләрен. Гитлерның муенын сындырдык, анысы бик яхшы булды, менә Көнбатыш Германиядә яңа фашистлар борын төртә, ди. Әнә Идел буенда бала-чага ничек чыр-чу килә. Менә шул сабыйларга кизәнә бит алар, явызлар. Без инде ак этен дә, кара этен дә күргән кешеләр, кемлекләрен беләбез, яшьләр менә яхшы танысыннар иде. Ил язмышы, ни әйтсәң дә, алар кулына кала. Мин үзем илбасарларга каршы гомеремдә ике тапкыр сугыштым, ике тапкыр алар мине тыныч тормышымнан аерды. Дөресен әйткәндә, минем сугышырга бер дә ниятем юк иде. Без бит көрәк, сәнәк тотып үскән кешеләр,— хәзер дә тормышым авылда. Монда төпчек кызыма кунакка гына килгән идем, ул больницада врач булып эшли, кияү дә — доктор, анысы операцияләр ясый. Шул көрәк, сәнәк, ни әйтсәң дә, безнең кулга ятышлы. Берәүгә бер зыяның тими, явызлык эшләү уеңда да юк. Эш кешесе гомумән андый нәрсәләрне белми. Ә алар, йөзе каралар, безне коралга тотынырга мәҗбүр иттеләр. Гражданскидан җиңеп кайткач, империалистлар кем белән эш иткәннәрен аңлаганнардыр дип уйлаган идем. Без ул чакта аларга яхшы ук төшендергән идек югыйсә. Авыз-борыннары канагач та сугыштан туймаганнар икән. Сез инде укыган кешегә охшыйсыз, тарихны яхшырак беләсездер, мин үземчә, авылча гына фикер йөртәм. Ну, кияүнең атасы эшче, электә Алафузовта эшләгән кеше — минем белән полный килешә. Дөрес әйтәсең, дип әйтә, империалистлардан безгә игелек булмаган да, булмас та. Пример, Алафузов ишеләр ни уйлый? Фабрикаларын кире үзләренә кайтару, эшче халыкның каның эчү турында. Врешь, монысы булмас! — дип кычкыра кода. Сөйләсәң, хикмәтләре бар аның. Но мин үзем яшь чакта шактый кайнар холыклы кеше булсам да, политикага артык үрелмәдем. Белем дә юк иде, җаным да тартмады. Ләкин үз тормышымны туры юлдан алып бардым, вакыты килгәч, колхозга да кердем, бригадир да булдым. Мин әйтмим колхозда бар да җиңел булды, майлаган кебек кенә барды дип. Төрле чак килде, ләкин анысы үзебезнең эчке эшебез иде. Сикереп мендек, егылып төштек, но ятка сер бирмәдек. Шулаймы? Бигрәк тә хәзер, ул еллардан ераклаша төшкәч, партиянең никадәр алга карап эш иткәнен аңлыйсың. Мәсәлән, без кәрәчин юклыктан да интегә идек, лампа куыгы да булмый иде, хәзер, рәхим ит, колхозыбызда электр, радионы әйтмим дә, ул һәр өйдә дә бар, теле-

визор да күп. Төрле машиналарны санап бетерерлек түгел. Шундый чакта менә картайдык кына. Картлыкның һәркемгә киләсен беләсең, тик кайчак аның белән дә килешәсе килми, әдәм баласының хыялы чиксез бит. Менә әле Иделгә карап-карап йөрим. Тормыш та шулай мул ага бит. Җиң сызганып аңа катнашасы иде, яр астында утырмыйсы иде!.. Ләкин дәрт бар да, дәрман юк дигәндәй... Син менә, авыргач, Идел буена килеп бик яхшы иткәнсең. Идел обязательно авыруны җиңә, аның һавасы шифалы. Картлык башка. Менә мин быел җитмеш алтынчы белән барам. Ә сиңа алтмыш та юктыр әле. Бу яшьтә ир кеше полный җитлегеп кенә җитә. Син әзрәк эшләштергәлисеңме? — дип, кинәт сорады карт һәм үзе үк җавап та бирде.— Эшлә, туган, кулыңнан килгәндә тик торма. Эш ул бөтен авыруга дәва. Минем җитмеш яшькә хәтле белмәнәм фартук төшмәде, авыруның да нәрсә икәнен белмәдем. Җитмеш алтынчы киткәч кенә бераз шыгырдый башладым, шуңа күрә кызу эш вакытында кызымны күрергә дип килдем. Карчык әйтә, синең шыгырдавың күп сөйләгәннән, ди. Күп сөйләвемне үзем дә беләм. Сине дә туйдырып бетердем бугай инде.

— Юк, юк. Вәлиша абзый.

— Алай булса ярый. Үземнең дә Идел буенда эчемне бер бушатасым килгән иде. Менә, картлык бәласе, ахрысы, сөйли-сөйли җеп очымны югалттым. Бер нәрсә турында башлыйм, аннары, китә-китә, кайдан башланганын да онытам. Мин малай чакта әле безнең авылда Җиһанша исемле бер карт бар иде. Шул сөйли-сөйли ычкынып китсә, әйтәләр иде: Җиһанша бабай, Күгәрченле ялгыз нараттан уң якта калды дип. Күгәрченле — безнең авыл, ялгыз нарат дигәне басу капкасында үскән бер агач. Күгәрченле уң якта калды, дисәләр, димәк, үз авылыңны узып киткән була. Шуның шикелле мин дә сөйли-сөйли үз авылымны узып киттем бугай. Сугыш турында әйтә башлаган идем түгелме? Ватан сугышында мин төп солдат булмадым инде. Иң элек арсландай өч улым сугышка киттеләр. Икесе тракторчы иде, алары аның танкист булды, берсе авыл хуҗалыгы институтында укый иде, анысын башта артиллериягә алдылар, аннары «Катюша»га күчергәннәр. Исән кайтырлар дигән өмет бик зур иде, башта Ленинград фронтында өлкән малаем Надирша үлде. Командирлары бик зурлап хат язган иде: Надиршалар, дошманга бирелмәгәннәр, танк эчендә януны артык күргәннәр. Икенче малай, Гаделша, инде Болгариядә сугышканда һәлак булган. Анысы бик күп орденнар, медальләр алган. Берсен, истәлек өчен, өйгә дә җибәргәннәр иде. Шулай итеп, кара ефәк белән урап, Надирша белән янәшә Гаделшаның да рәсемен стенага элдек. Актык өметебез Әхмәтшада калган иде. Анысын каһәр суккан мимеч җиренә кергәч аяктан екканнар. Иптәшләре, плащпалаткага салып, сугыш кырыннан алып чыккан булганнар, санчастька җитә алмыйча җан биргән. Соңгы улыбыз Мөбәрәкшаны кырык дүртенче елның көзендә армиягә алганнар. Анысы Берлинны штурмлаганда баш куйган. Шулай итеп, дүрт малайның берсе дә исән кайтмады. Стенадагы рәсемнәре генә сагынганда карарга калды. Нәселебезнең тамыры корыды дияр идем, өлкән малай Надиршаның игезәк уллары үсеп житте. Шулай да ата-анага авыр, туган,— диде карт, тирән көрсенеп.— Без, ни әйтсәң дә, солдатлар, сугыш кырында дус-ишләрне җирләгән кешеләр, күз яшен тыя беләбез. Менә бичара карчыкларга читен. Аларга ачуланып та, кычкырып та булмый, үлгәннәр кайтмый, дип тә әйтә алмыйсың. Менә сугыш беткәнгә дә егерме елдан артык инде, ә алар сугышка киткән балаларын һаман тәрәзәдән карап көтәләр. Андый аналар бик күп бит алар. Төнлә тәрәзә капкачы шыгырдаса да, капканы җил дөбердәтсә дә, карчык урыныннан сикереп тора, улларым кайтмадымы, дип ян тәрәзәгә йөгерә. Аннары тәрәзә катында таң атканчы бер үзе басып тора, күз яшьләрен берәүгә дә күрсәтмичә, әкрен генә җылый. Менә шунысы бик тә, бик тә авыр, туган. Барысына да түзәр

иден, барысын кичерер идең, менә карчык аналарның сүзсез кайгысы, кешегә күрсәтми аккан күз яшьләре үзәкне өзә. Аларны берни дә эшләтә алмыйсың, алар актык көннәренә хәтле шулай газапланырлар инде. Солдат аналары! Аларга юату сүзләре дә әйтеп булмый, чын кайгыны андый сүз белән генә юып ташлау мөмкинмени?!. Кайчагында сугыш чукмарлары шул аналарның кайгысын үзләре күрсен иде, диләр. Монысы да, минемчә, кирәксез эш. Безнең кайгыдан дошманның йөрәге әрнеми. Безнең халык үзе, бигрәк тә сугышны кичермәгән яшьләр моны күрсеннәр, аңласыннар иде...

Вәлиша абзый сүздән туктый, Идел киңлегенә карап тора. Хәзер йөзендәге карчыга чалымы аермачык. Бу карт болай бик тыныч, ләкин аны ачуландырма инде, аннары үкенеп бетә алмассың. Мин Вәлиша абзый шул турыда берәр нәрсә әйтмәсме дип көтәм. Кешегә үзеңнең сизенүеңне раслату канәгатьлек бирә бит. Бу очракта сүз тирәнрәк — халкыбызның күңелен аңлау турында бара. Ләкин карт, җил өреп торган утлы күмер кебек кызса да, ялкынланып китми, гүя аның бөтен игътибары агымга каршы менеп барган су трамваенда. Аннан кемнәрнеңдер җырлавы ишетелә.

**Идел бит ул, киң бит ул...**

Җыр ераклаша, аннары бөтенләй тына. Бераздан Вәлиша абзыйның «йөзе» сүнә, әйтерсең, күмерне уpләтеп торган җил туктый. Вәлиша абзый башын селкә, көрсенеп ала, гүя эчендәге утын бөтенләй баса һәм инде мыек очын картларча бөтергәли башлый. Бармаклары юан, бирчәйгән, күрәсең, үз гомерендә ул бик күп эш эшләгән. Анысын сорап та торасы юк.

— Әйе, туган, Идел бит ул, киң бит ул,— диде Вәлиша абзый авыр сулап.— Халык күңеле дә шундый киң, тирән. Менә җырны җырлыйлар да суга ташлыйлар кебек. Юк, алай түгел ул, аны кемнәрдер ишетә, йөрәкләре кузгала, кабына...— Вәлиша абзый тагын тирән көрсенеп куя.— Ярый, бу турыда күп сөйләргә мөмкин дә, калып торсын инде... Менә сина карап торам да уйлап куям әле: син әллә бик күп беләсең, әллә мин картка хөрмәт күрсәтеп, бер дә белдермисең, минем килде-китте сүземне бик игътибар белән тыңлыйсың.

— Миңа дөнья күргән кешеләрнең сүзләре кадерле, Вәлиша абзый. Сез килде-китте сөйләмисез.

— Рәхмәт, туган. Ләкин мин акылымны җилгә чәчеп бетердем бугай, белмим, рәтле нәрсә калгандырмы. Солдат учаклары янында күпме сөйләнгән, окопларда тагы... Ике сугышны башымнан кичердем дигән идем бит. Совет влачтен туган көненнән алып корал белән яклаштым, чөнки аның үз влачтыбыз икәнен йөрәк белән тойдым. Аннары Ленинны тыңладым. Солдат массасы арасында, билгеле. Ул минем белән сөйләшмәде, ләкин нәкъ минем йөрәктәге сүзләрне әйтте кебек. Шуннан безне кая гына җибәрмәделәр, тотарга рәтле корал, киярга рәтле кием дә булмады, ну, революцияне сакладык, бер дошманга да бирмәдек. Менә колак янындагы бу яра эзен күрәсеңме? Кырымда барон Врангельга каршы сугышканда алдым. Монда тагын йөрәк астында, аннары аркада яра эзләре бар. Алары бу сугышның тамгалары. Мине, яшем олы булганга, бу сугышка соңрак алдылар. Башта тыл эшләренә куелдым. Эш эш инде ул, без аңа күнеккән, авыр булса да, зарланмадык. Ләкин малайларның үлгән хәбәрләрен берәм-берәм алгач, түзмәдем, командованиедан алгы сызыкка җибәрүләрен сорадым. Син үзең сугышта булган кешеме?

— Булдым, Вәлиша абзый.

— Алай булгач, аңлыйсың инде. Безнең агай-эне арасында тылда ялап калырга тырышучылар да, алгы сызыкка омтылучылар да

байтак иде. Берәүләрне ил кайгысы алга илтә, берәүләр үзләренең жаннарын ничек тә саклап калырга тырышалар. Ул чакта бит хәл кискен, сугыш иде, шуңа күрә ике чикне генә алып сөйлиләр иде. Я ил белән, я илгә каршы. Югыйсә һәркемнең жаны үзенә газиз. Безнең взводта бер солдат бар иде. Башын иеп, жиргә карап кына йөри иде. Дошман-фәлән түгел ул, элекке бай да түгел, фашистларны да эрә яратмый, кушканны кулыннан килгәнчә эшли. Болай мактап та, хурлап та булмый. Минем алгы сызыкка жибәрүләрен сорап командирларга рапортлар бирүемне ишеткәч, бер үземне очратып шул:

— Командирларга язу язгансың икән, Вәлиша кордаш, дөресме? — дип сорады.

— Бар иде шундый теләк, малайларым өчен кулымнан килгән кадәрле үчне кайтарасы килә, дим.

— Анысы бик аңлашыла, бик изге теләк, Вәлиша кордаш. Ләкин гайрәт күрсәтер өчен безнең инде яшь узган бит. Хөкүмәт үзе дә белә, югыйсә безне тыл эшенә куяр идеме? Аннары карчыгың турында да, улларыңның семьялары турында да уйларга кирәк. Хәзер бит аларның синнән башка терәге калмады. Кешегә ничек булса да яшәргә кирәк бит. Берәү дә үзе теләп бу дөньяга килми дә, бу дөньядан китми дә. Күпме бирелгәнен тартасы бар.

— Төпчек малайны быел солдатка алырлар, ахрысы, аларның еллары быел карала,— дидем.

— Менә бит, Вәлиша кордаш. Яшьләрне бераз өйрәтерләр дә вермәгә кертерләр. Берни эшли алмыйсың, заманы шундый. Сиңа, кордаш, бик тә, бик тә уйларга урын бар,— ди.

Вәлиша абзый уйга калды. Вакыт-вакыт аның карт күзләрендә ниндидер чаткылар кабынып китә, йөзеннән ниндидер кичерешләренең күләгәләре чагылып үтә кебек, карт хәзер ярсый башлар шикелле иде. Әмма ул әүвәлгечә сабыр гына сөйли бирде:

— Болай бик дөрес, бик төпле сөйли кебек әлеге солдат. Тел төбен бераз соңрак аңладым. Мин болай сабыр кеше, юкка-барга дуламыйм. Миңа карчыга Вәлиша дигән кушамат малай чактан ук тагылып калган калуын, анысы инде малай чак дуамаллыгы өчен — кем авыз-борынын канатышмаган да, кем дөмбәсләшмәгән. Олыгайгач, акылга утырлым, картая башлагач — бигрәк тә. Ну тегенең төп уен белгәч, валлаһи дип әйтәм, чак яңагына салып жибәрмәдем. Аның миндә дә, минем семьяда да эше юк икән, анысы аның сүзе генә, ул үз тиресе турында пошынган икән. Алар, ди бу, командирларны әйтә, безнең барыбыздан сорап та тормаслар бит, солдатларның үзләреннән шундый патриотически язулар бар, дип барыбызны да ут эченә жибәрерләр. Ә монда безгә нәрсәсе ярамый? Кушканны эшлибез, өстебезгә пуля яумый, тамакка бирәләр. Башыңны бөгеп эндәшми генә тор да тор. Орден-медальле безгә нәрсәгә, аларын яшьрәкләр алсыннар, ди... Менә бит ул чакта безнең үз арабызда да нинди кешеләр бар иде. Явызраклары да булган, диләр, ләкин мин үзем күрмәдем. Тамчы тама-тама ташны тишә дигәндәй, тора-бара теләгемә ирештем, бер жае чыгып, алгы сызыкка киттем. Монысы инде кырык бишенче елның гыйнварында булды. Күп сугышларда катнаштым, Берлинны алышуга да, Прагасына да життем. Орден-медальләр дә бирделәр. Сөйләсәң, китап язарлык булды инде. Бер заман, сугыш беткәч, өйгә кайтам. Шатлык та, кайгы да. Мин менә, карт булсам да, кайттым, ә сукса тимер өзәрлек егетләр кайтмады. Киресенчә булса жиңелрәк булыр иде дә, нишлисең, кеше каберена кеше керми шул. Бер ел үткәч, өлкән килен килеп керә. Малай, өйләнгәч, башка чыккан иде. Жылый. Нишлим, көттем-көттем, ди, сугыш та бетте... Яшь-яшь хатынга ике бала белән тормышны алып бару кыен бит. Бу турыда сөйләп торасы да юк, кыен икәне һәммәбезгә күренә

Озак елагач, килен әйтте: үз авылыбызныкы бер солдат иортка керергә сорый икән. Үз хатыны сугыш вакытында ук йортын-җирен сатып каядыр шәһәргә киткән дә иргә чыккан... Сугыш вакытында андыйлар аз булмады. Без карчык белән киңәштек тә киленгә фатиха бирдек. Нишлисең бит, Надирша белән гөрләп торасылары иде дә, бәхетләре булмады. Без киленнән, мөмкин булса, балаларын безгә тәрбиягә бирүен үтендек. Хәзер инде карчык белән икәү генә калып барабыз, төпчек кызыбыз укырга китәм дип тора. Аннары кыз кешене барыбер өйдә бикләп тота алмыйсың. Килен «уйлыйм әле, киңәшим әле, бәгыр алмаларым бит, ничек йөрәгемнән өзеп алыйм» ди. Ә бер атнадан соң балаларны безгә китерде, әгәр түзәрлегем калмаса, кире алырмын, сез инде каршы килмәссез, диде. Ана сүзенә каршы килеп буламы. Ну балалар егет булганчы бездә үстеләр. Икесе дә әтиләренә охшаганнар, карчык: «Надиршам уллары», дип, әле дә теленнән төшерми. Килен башта бик ямансулады, аннары яңа иреннән балалары булды. Хәзер инде Надиршаның уллары армиядә дә хезмәт итеп кайттылар. Берсе — бригадир, берсе — шофер. Бик яхшы егетләр, чын солдат балалары. Берсе күптән түгел генә өйләнде, икенчесе көзгә күзле-башлы булырга җыена. Хәзергә барыбыз бергә торабыз, икенчесе өйләнгәч, анда күз күрер. Безнең авылыбыз уртасында Ватан сугышында һәлак булган батырларга һәйкәл бар. Анда минем дүрт малаемның исеме язылган. Надиршаның уллары һәйкәл салуда бик тырышып эшләделәр...

Минем икенче малайның — Гаделшаның бала-чагасы юк иде. Хатыны, иренең үле хәбәре килгәч, күрше авылга — әти-әниләренә күчеп киткән. Әхмәтша белән Мөбәракша өйләнмәгән егетләр иде... Менә безнең тормыш шулай, туган. Бөтенләй белмәгән кешегә хәл-әхвәлне сөйләп биргәч, ничектер җиңелрәк булып китте, югыйсә эчтә җыеп йөртсәң, авырга килә башлый. Безнең якларда булырга туры килсә, кунакка рәхим ит. Ә хәзер кайтыйм инде, кияү белән кыз, коданы алып килербез, дигәннәр иде. Үз машиналары булгач, аларга рәхәт... Битне-башны юмыйбызмы? Идел суы бик йомшак бит...

Без төп өстеннән тордык. Күз ирмәс тизлек белән очып йөрүче яр карлыгачларына карап алдык, аннары Иделнең салкынча суы белән юынып алдык. Текә яр янында тагын бераз басып тордык та Вәлиша абзый бер якка китте, мин икенче якка юл алдым.

## Рифгать Закиров

### Яшим әле...

Хәтеремдә: сабан сөргән чакта
Бураздага битем куюга
Сизә идем җылы туфракның мин
Талгын тирбәлүен куенымда.
Тоя идем, исертерлек булып
Җир җылысы тәнгә күчкәнен;
Шуннан бирле һаман айный алмыйм
Шушы изге, татлы хистән мин!..

### Буразналар сызам...

Язлар җитсә басуларга чыгам,
Буразналар сызам кабартып,—
Буразналар сызам җиргә булган
Сөюемне кабат яңартып.

Буразналар сызам тезеп-тезеп,
Калдырмыйм дип кысыр кишәрлек.
Кырны иңләр тоташ хәтфә булып
Җырым бара гүя түшәлеп!..

### Дуслык

Бер җырладым ишкәк ишкәндә, дип,
Сез дусларым искә төшкәндә, дип.
Җырлап кына күңел тынмый ул;
Дөнья булгач, барыбер бер булса да
Моңаймыйча, дуслар, булмый ул.

Шундый чакта үзе нигә тора
Бер дустыңның ишек кагуы!
Атлыгасың аңа, әйтерсең лә,
Башкалардан сиңа яшереп кенә
Алып килгән әҗәл даруы!..

Чалт аяз булса да бүген көн,
Еракта урманнар күгелҗем;
Күгелҗем урманнар артына
Керден дә күмелден...

Сизелер-сизелмәс җил бәрә,
Кыр буйлап, күр, рәшә тирбәлә.
Ә йөрәк талпына: син аны
Эзләмә... эзләмә...

Син шуна йөзеңне качырып,
Карыйсың үрелеп, ятсынып.
Һәм кинәт шәүләгә әверелеп
Качасың ашыгып...

Эзләмәс идем дә — уй баса,
Сагынмас идем дә — моң баса;
Берсен дә эшләмәс идем лә
Чын сөю булмаса!..

## Ялга кайткач

Җыр матурмы әллә тормыш кебек,
Яки тормыш үзе җыр мәллә!
Син туктыйсың кинәт исең китеп
Аералмыйча шуны бер мәлгә,
Туган якны иңләп йөргәндә...

Әнә, болыннарга нидер ява,—
Яңгыр микән, әллә бал микән?
Шулай ширбәт явып торган чакта,
Җанга якын шушы гүзәл якта
Син бер чәчкә булып кал икән!

## Һаман көтәсең...

«Бер кайтырбыз,— диеп,— киткән юлдан» —
Китсәләр дә... алар кайтмады.
Алар өчен бары җилләр генә
Ачып-ябып йөрде капканы...

Алар өчен янды ялгыз ана
Күз нурларын сирпеп еракка...
Тик: «Ил өчен геройларча...» дигән
Хәбәр генә кайтты бу якка.

Хәбәр генә кайтты бу якларга
Ядкарь булып газиз анага,
Һәм ир даны кайтты югалмыйча,
Мәңгелек ут булып янарга.

Ана! Ана! Сүрелмисең. Әллә
Шундый утның берсе микән син:
Белсәң иде бераз хәлләрен дип,
Кайда йөри Кәшфи, Хәйдәрем дип,
Көтәсең дә һаман көтәсең...

## Шахтерлар сүзе

Без — шахтерлар... диеп берәүнең дә
Булмас, ахры, исен китәреп.
Тик белегез шуны: юкка гына
Йөрмибез без исем күтәреп!

Без шахтерлар!.. Димәк, чын шахтерлар! —
Көнләр хәтта кайсыларыгыз:
Заманалар кичеп алга барган
Җир-корабның... кочегары без!!!

## Мәхәббәт турында җыр

Егет җырлый...
Беренче кат
Ишетәм мин бу тавышны:
Каян ала ул шул кадәр
Үзәк өзгеч моң-сагышны?!

Егет җырлый...
Һәм бусы да
Җырлый әле ничек кенә
Шатлыктан ул, әйтерсең лә,
Җырлап түгел, биеп килә,—
Башы күккә тиеп килә!..

Югыйсә бит икесе дә
Бер үк җырны җырлый алар.
Һай, дөньялар, вай, дөньялар...

## Кошлар юлы

Барыгыз да кайтып җитәсезме? —
Дип сораган Вагиф кошлардан...
Кошлар юлы бигрәк ерак шул ул,
Шулай итеп аны кем салган?!
Кемнәр салган аны?.. Нигә болай
Тынгы бирми миңа бу сорау?..
Нигә кошлар кайткан юлга карый,
Китәсесе аның күп урау?!
Чөнки киткән чакта торналарның
Тавышлары була моңлырак...
Ә кайтканда бүтән... Димәк, чынлап
Илгә кайтыр юллар турырак!

●

Кайвакыт төн буе поездда
Үтәли тишеп төн карасын,
Йокламый уйланып-күзәтеп
Барасың, барасың, барасың...

Бер — авыл, бер — шәһәр
үтелә...
Һәм менә бер якка карагач,
Тын учак яктысы күренә,
Мәһабәт чыршылар аралаш.

Күр, ничек дөньяны гөл итә
Аз гына утның да яктысы!
Бит шулай төннәрне көн итә
Тормышта кешенең яхшысы...

## Манара

Гөмбәзен шәфәкънең
Алына мана да,
Таунын нәкъ очында
Нурлана манара.

Хөкемдар анарга
Илаһи бер тынлык.
Кош кына һавада,
Янында бер кем юк.

Чөнки тик шул эшкә
Ярый ул манара:
Картларга яшь чагын
Юксынып карарга...

Ә яшьләр... ал таңга
Карыйлар үрелеп:
Күкләрнең җиденче
Катына ук менеп!

●

Инде вакыт...
Күпме сагыш татып,
Бер моңланыйм әле!
Сез тыймагыз мине:
Бер моңланып —
Мең юаныйм әле!..

Кызганмагыз...
Бераз кайгы татып,
Бер көеним әле.

Күпсенмәгез...
Бер бәхетне табып,
Мең сөеним әле!

Тик шулай да
Миңа болар гына
Бик аз икән әле.
Бер гомердә
Мең үлемне җинеп
Булмас микән әле!..

## Кадыйр Сибгатуллин

### Туу

Миндә — буыннарның дәвамы.
Җирдә туып, Җирдә җан
алдым.
Әтиләрем миңа калдырган
Җиргә карап минә таң калдым.

Аяк бастым йомшак чирәмгә,
жылы жилгә сөрттем йөземне
Үлән исен тойдым, Җир исен,
тере итеп тойдым үземне.

Чәчәкләрдә бик күп төс күрдем,
диңгезләрдә—зәңгәр тирәнлек.
Арыш басулары эченнән
якты күккә карыйм кинәнеп.

Тәмнәр тоям, ишетәм авазлар,
тәнем сизә, күрә күзләрем.
Рәхәтенә чыдап торалсам,
михнәтенә генә түзәрмен.

Һәр тузаны яши, һәр ташы,
урын юктыр монда үлемгә.
Яшел үлән, туфрак, мин булып
Әтиләрем кайта бүгенгә!

### Юл башы

Әтием дә әйтеп үлмәде:
авыр булыр, диеп, юл башы.
Мин үземә-үзем эзләдем
юл чатына чыгып юлдашны.

Дәшми генә үтте кешеләр,
минем якка түгел, күрәсең.
Кемнәр кая таба сәфәрле,
олы юлда каян беләсең.

Кешеләрнен юлы бер түгел,
кемгә иркен, кемгә таррак.
Берәүләргә инде ахыры,
берәүләргә кирәк арырак.

Бик житәрлек минем, җитәрлек
бәхетләрем, шатлык,
сагышым...
Иңнәремә төяп барысын
ерак юлга чыгып барышым.

Юллар, юллар, өстәр кешеләр,
Илем, Җирем бирер калганын.
Тоташ томан, тоташ кар түгел,
Таң шәүләсе кебек алларым.

### Әманәт

Нишлисең, дип сорамагыз, сорама.
Тормыш, миңа язмышымны юрама.
Киләм әле, каршылагыз гадәти.
Үзем беләм; көчем ни, халәтем ни.

Бизмәннәргә салып бәя итмәгез —
бәяләрдән кыйммәтрәк икән без.
Заманына зарур булып яралган,
Җир-анадан гомер алган, җан алган.

Бирелгәне бирелгәндер хаҗәткә,
барысын да алып торган әҗәткә,
Сарыф итсәң — ничәнче кат Җир әрнер —
яшәү дә бер, гомер дә бер, мин дә бер.

Нишлисең, дип сорамагыз юлымда,
Җир-анамның әманәте уемда.
Аның өчен мең яшәргә әзер мин,
Җирем күрсен гомеремнең әҗерен!

## Заман көтә

Җинел түгел тормышы да, заманы да.
Безнең өстә шатлыгы да, газабы да.
Кешеләрнең кайсы җырлап сөендерә,
кайсы елап, кайсы чыдап сүгендерә.

Берәү дәшми дәшәр чакта, түзеп тора,—
бер җансызы күгәрченгә мылтык кора.
Көләр чакта ачу белән каш төелә,—
кешеләргә бик кирәкле нур өзелә.

Очрап куя арабызда җан телүче,
иман алып, иман сатып көн күрүче.
Бик тәртипле, бик тыңлаучы егетләр бар:
нәфес иркен, йөрәк нәни, күңелләр тар.

Көннәр килә көлтә-көлтә шатлык төяп,
зәңгәр күзле яшьлек йөри шигырь сөйләп.
Иманлылар, инанганнар — безнең халык
Җиргә карый, күккә карый таңга калып.

Кеше булып Җирдә йөрү җиңел түгел,
бик күп нәрсә безнең сүзне көтә бүген.
Тоегыз, ди, ишетегез, күрегез, ди,—
туар моңнар, туар җырлар урын эзли.

Мәшәкатен түкми-чәчми иңгә салган,
бер керфекнең чыклануын күрә алган,
мең шатлыкны бергә төйнәп күтәрерлек,
Ил кайгысын йөрәк аша үткәрерлек,

туры сүзгә, туры йөзгә карый торган,
намусларны стаканга салмый торган,
чиста куллы, чиста уйлы ирләр генә
безнең сүзне, дөрес сүзне әйтә белә!

Аналардан малайлар туа, ир тумый,—
малайларның туган бере гел ир булмый,
Сабыр итеп һәр мизгелдә заман көтә:
кыл өстеннән кемнәр үтә,
ничәү үтә!

Йөз дусың юкта
йөз сумың,
йөз сумың юкта
йөз дусың
булуы кирәк икән.
Йөз дусың да,
йөз сумың да
булган чак сирәк икән.

## Мәҗнүн

Мин — бер ялгыз.
Җаным җылы сорый,
су сораган коры кыр сыман.
Танырмы, дип үземнекен көтәм,
җырлаучысын көткән җыр сыман.

Мин — тоташ моң.
Күзгә кичләр төсле
бер яктырып алам, бер — болыт.
Күгем иркен,
мәңге якты булып,
кемнәр чыгар икән Ай булып?

Мин — зур өмет.
Бәхетлеләр өчен
тинсез сөю бар дип ышанам.
Кайларда ул?!..
Кайгысына кайгы,
бәхетенә бәхет кушалам.

Мин бит Мәҗнүн,
гашыйк кына түгел.
Гашыйклар да сүнми кабынса...
Мин бит Мәҗнүн!
Аны эзләп йөрим,
Ләйлә генә таныр таныса!

## Киткәндә

Йөрибез урамнар уратып,
туктарга бер урын тапмадык.
Бер яңа шәһәргә кергәндәй
чатлардан чатларга атладык.

Һәр урам башлана киңәеп,
һәр чатның үтәрлек юлы бар.
...Йөрибез урамнар уратып,
борылсаң сулы бар, уңы бар.

Ә безгә барыбер баруы,
һәр урам түренә чакыра.
Фатыйха сорарга кергәндәй,
үтәбез оялып чак кына.

Тукталыйк. Бик азга, бик азга!
Урамнар таныш та, яңа да.
...Бәхетнең иң татлы вакыты —
бер йолдыз атылган арада.

Ак карда ике эз бер кебек.
Бармаклар аралап тотылган.
Кырларга ак нурлар бөркелә
урамның иң соңгы йортыннан.

Уйларның шаһиты булыгыз,
Көн саен төшегез хәтергә.
Бәхетле булалсак, урамнар,
без сезгә кайтырбыз әйтергә!

Аяз Гыйләҗев,
Альберт Яхин

# ШАМИЛ УСМАНОВ

## 3 ПӘРДӘДӘ ГЕРОИК ДРАМА

### КАТНАШУЧЫЛАР:

Куйбышев — Самарада ревком секретаре һәм Губерна Башкарма Комитеты председателе.
Шамил Усманов — татар батальоны комиссары.
Кариб Хәйруллин — татар батальоны командиры, элекке вахмистр.
Мәхмүт Урманаев — хәрби белгеч, элекке поручик.
Зәкия — шәфкать туташы.
Хәйруш — карт гвардеец, элекке крестьян.
Тажетдин — озын гвардеец, элекке эшче.
Сәгъдетдин — авыл карты, 55 яшендә, гвардеец.
Сәкинә — асрау кыз, хәзер шәфкать туташы.
Гөлҗамал — аның әнисе, пешекче.
Сары бай — Оренбург бае.
Сәхи — аның улы, кызылгвардеец.
Каюм — гармунчы гвардеец, моряк.
Сакаллы гвардеец.
Күшәүче гвардеец.
Садрый Ваһапов — аклар капитаны, шпион.
Телеграфчы кыз.
Сакчы.
Әлемтәче.
Белевич — мадьярлар батальоны командиры.
Лайош — мадьяр солдаты.
Әптери — гвардеец.
Мулла.
Мыеклы казак.
Сары чәчле ханым.
Кара чәчле ханым.
Хәсән — аклар ягыннан чыккан солдат.
Кара бай.
Үсмер гвардеец.

Кызыл гвардеецлар, шәһәр халкы, анархист, намазга килүчеләр, бала-чага, хатын-кыз һәм башкалар. Вакыйга 1918 елда Оренбург шәһәрендә һәм Оренбург далаларында бара.

### ПРОЛОГ

1918 ел. Самара. Губерна Башкарма Комитеты бинасы. Почмакта аппарат янында телеграфчы кыз утыра. Аның янына Башкарма Комитеты председателе Валериан Владимирович Куйбышев килә. Ул зифа буйлы, зәңгәр күзле, мул чәчле утыз яшьләрдәге чибәр кеше. Ярым хәрби киемнән, хәрәкәтләре салмак.

Куйбышев. Арыдыгызмы, кадерлем?
Телеграфчы. Билгесезлек йончыта... Бөтен җирдә аклар. (*Аппаратын күрсәтеп.*) Безнең Самара тиздән уртада калачак. Давыл астындагы утрау кебек...

К у й б ы ш е в. Мәскәү җавап бирмиме?

Т е л е г р а ф ч ы. Көтәм, иптәш Куйбышев.

К у й б ы ш е в. Әйе, давыл көчле булачак!.. Ләкин без бирешергә уйламыйбыз...

Т е л е г р а ф ч ы. Билгесезлек кимегән төсле булды! *(Көлә.)*

К у й б ы ш е в. Нигә?

Т е л е г р а ф ч ы. Шундый камалышта, шундый дәһшәтле көннәрдә Губерна Башкарма Комитеты председателе шулай уйлый ала икән, мин тыныч...

К у й б ы ш е в. Революциягә ышанам, бары шул гына!

Аппарат эшли башлый, лента сузыла, кыз иҗекләп укый.

Т е л е г р а ф ч ы. Сезне Оренбург губкомы сорый. *(Укый.)* «Ашыгыч яр-дәм бул-маса, Орен-бург-ның хә-ле чамадан тыш а-выр».

К у й б ы ш е в *(лентаны алып)*. Хәле авыр... Башта Самара, Сызрань, аннары Казан, Мәскәү...

Т е л е г р а ф ч ы. Оренбург сездән җавап сорый, иптәш Куйбышев.

К у й б ы ш е в. Җавапны бераз көтәргә кушыгыз. *(Пауза.)* Әйе, Оренбургның гына түгел, революциянең хәле кыенлашты.

Т е л е г р а ф ч ы *(шатланып)*. Иптәш Куйбышев, телеграфта Владимир Ильич!

К у й б ы ш е в *(тиз-тиз телеграфчы янына барып җитә, әйтеп тора)*. Иптәш Ленин, дутовчылар гаскәр туплап яңадан баш күтәрделәр. Алар Советка теләктәш кешеләрне кырып-үтереп, бала-чагаларны суеп, даланы канга батырдылар. Оренбург хәл эчендә. Моңа кадәр бирелгән ярдәм генә җитми. Бүгенгә үзебезнең хәлебез дә мөшкел. Ак чехлар ябырылып Самарага якынлашты, контрреволюция баш күтәрә!

Аппарат бер секунд кына тик тора да эшли башлый.

Т е л е г р а ф ч ы. Владимир Ильич сөйли! *(Укый.)* «Оренбургта Урал Кызыл гвардиясенең төп көче җыйналган. Аларны таркату революция алдында зур җинаять булыр иде. Ул көчне саклап калу безнең бурыч. Мөмкин булган ярдәмне оештыруыгызны үтенәм. Ләкин ул Самараны саклауга зыян китермәскә тиеш».

К у й б ы ш е в. Тырышырбыз, иптәш Ленин.

Аппарат тына. Тагын тавыш бирә. Ул почмак караңгылана. Куйбышев яктыга, уртадагы өстәл янына килә. Ишектә сакчы.

С а к ч ы. Сызраньнан Шамил Усманов килде, иптәш Куйбышев.

К у й б ы ш е в. Чакырыгыз үзен. Мин аны көтәм.

С а к ч ы. Яхшы.

Чыга. Гаскәриләрчә төз атлап Шамил Усманов керә.

Ш а м и л. Чакыруыгызны алдым, иптәш Куйбышев.

К у й б ы ш е в. Узыгыз, утырыгыз, иптәш Усманов. *(Үзе Шамил каршысына бара, кулын бирә, җилкәсеннән дусларча кагып өстәл янына алып килә. Өстәлнең алгы ягындагы кара-каршы көрсиләргә утыралар. Куйбышев елмая.)* Дөресен әйтим, революционер Шамил Усмановны мондый итеп күз алдына китермәгән идем. Сезгә ничә яшь соң, туган?

Ш а м и л. Унтугыз тулып үтте.

К у й б ы ш е в. Сызрань совдепы председателенә унтугыз тулып та үттемени инде? *(Ишектә сакчы.)*

С а к ч ы. Труба заводыннан вәкилләр килде, иптәш Куйбышев.

К у й б ы ш е в. Залга озата торыгыз. *(Сакчы чыга.)*

Ш а м и л. Мин Казан хәрби округы Советы члены, Сызрань ревкомының секретаре да.

К у й б ы ш е в. Титулларыгыз патша генералыныкыннан бер дә ким түгел алайса?

Ш а м и л. Ким түгел, Валериан Владимирович!

К у й б ы ш е в. Димәк, сезнең турыда легендаларны юкка гына чыгармыйлар?

Ш а м и л. Бәет турында әйтәсездер? Ялган ул, иптәш Куйбышев. Үз абыйсын атып үтерде дип, авылдашлар бәет чыгарган. Ләкин асылда ялган ул! Туганнарым арасында революция дошманнары юк. Сүз ак офицер, чыбык очы, таш башы кебек кенә кардәш турында бара. Гурьевта фабрикант Акчуриннар өенә тикшерергә кертмәскә маташа. Үтсәгез, минем гәүдә аша гына, ди...

К у й б ы ш е в. Һәм шулай булды дамы?

Ш а м и л. Гвардеецларның берсе түзмәде...

К у й б ы ш е в. Ә бәетне җитәкче иптәш турында иҗат иткәннәр! Менә шулай... Массалар белән җитәкчелек эшенә алынган кеше үзенең ничек яшәве турында тирәнтен уйланырга тиеш. Бигрәк тә менә хәзерге кебек кыен вакытларда, иптәш Усманов! Бер якта уянып килгән халык массалары, икенче якта, без, большевиклар. Масса белән җитәкче мөнәсәбәтләре ифрат дәрәҗәдә җитди мәсьәлә. Ул гомер-гомергә шулай булып барачак. Шул турыда уйлаганыгыз бармы?

Ш а м и л. Тормыш үзе мәҗбүр итә, иптәш Куйбышев. *(Ишектә сакчы.)*

С а к ч ы. Тимер юлчылар килде, иптәш Куйбышев.

К у й б ы ш е в. Залга керә торсыннар. *(Сакчы чыга.)* Мин сезне Оренбургка җибәрергә уйлыйм.

Ш а м и л. Оренбургка?

К у й б ы ш е в. Ак чехлар ярдәмендә дутовчылар зур көч җыйдылар. Төрле шәһәрләрдән Оренбургка чигенгән кызыл отрядларның хәле кыл өстендә. Без аларга ярдәм итә килдек, ләкин бу аз! Бер полкны Мәскәүдән Владимир Ильич җибәрде. Бу да җитенкерәми!

Ш а м и л *(торып баса)*. Миннән нәрсә таләп ителә, иптәш Куйбышев?

К у й б ы ш е в. Оренбург тирәсендәге татар крестьяннарын революция көрәшләренә ныграк тартасы иде. Аларның күбесе теләктәшлек күрсәтә. Шуларны оештырырга, җитәкләргә, сугыш кырларына алып чыгарга сыналган иптәшләр — татар большевиклары кирәк. Нәрсә эшләргә кирәклеген әйтү кыен, һәр очракка әзер өлгеләр табып булмас, әмма үзегезнең бар булганыгыз, һәр хәрәкәтегез, сүзегез, шәхси тормышыгыз белән эшче-крестьяннарга, кызыл гвардеецларга большевик-революционерның нинди булырга тиешлеген күрсәтегез. Мөгаен, хәзергә иң кирәге шулдыр. Һәм, миңа калса, бик аз да түгел бу!

Ш а м и л. Мин риза, Валериан Владимирович.

К у й б ы ш е в. Сезнең юл бик-бик кыен булыр... Аклар чолганышын үтү тәвәккәллек һәм акыл сорый. Татарлар арасында эшләрлек кыю, тапкыр егетләрне сайлагыз. Үз урыныгызга кемне тәкъдим итәсез, аны сын да уйлагыз. Сезгә юлдашлар итеп берничә тимер юлчы һәм нәни генә состав бирербез. Әзерлек өчен ярты көн вакыт җитәме?

Ш а м и л. Тырышырбыз, иптәш Куйбышев. Китәргә мөмкинме?

К у й б ы ш е в. Хуш, Шамил. Хәерле юл.

Ш а м и л. Хушыгыз, иптәш Куйбышев. *(Чыга.)*

К у й б ы ш е в. Син монда да бик кирәк, Шамил Усманов! Ләкин бүтән чара юк, унтугыз яшьлек юлбашчы! Оренбург бездән ярдәм көтә!

Сакчы керә.

С а к ч ы. Чакырылган кешеләр җыелып бетте, иптәш Куйбышев.

К у й б ы ш е в. Бик яхшы! Әйдәгез!

Чыгалар. Пәрдә төшә

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Оренбург. 1918 ел. Июнь ае. Эссе көн. Кәрвансарай ишек алды. Сарай почмагына кызыл әләм эленгән. Парадный ишектән алдарак кызыл эскәтер җәелгән өстәл. Берничә урындык. Ишек өстенә чуарлап: «Мөселман кардәшләр, кызыл гвардиягә язылыгыз!» дип сырланган. Җирдә кәгазь кисәкләре, төрле чүп-чар ауный. Байрак бер җилферди, бер сүнә. Кәрвансарай ишек алдында кызыл гвардеецлар. Кайсы ята, кайсы йөреп тора, өс-башлары өтәләнгән берничә кеше карта сугалар.

Арткы планда шәһәр. Кәрвансарайга терәлеп диярлек мәчет тора. Зәкия өстәл янындагы урындыкта утыра, язу-сызу белән мәшгуль. Мәхмүт өстәл тирәли йөренә. Өстендә бераз таушалган хәрби кием, фуражкасына зур кызыл бант таккан. Вакыт-вакыт көмеш чылбырлы сәгатен чыгарып карый. Үтеп-сүтеп йөргән гвардеецлар очраганда чыраен сыта. Ашыгып, шпорларын шалтыратып Кариб Хәйруллин кайтып керә.

Кариб *(өстәл янына барып баса)*. Приказ алынды, дуслар, татар батальоны бүгеннән сугышка керә! Ал-люр, алга!

Шау-шу, кычкырган, хуплаган тавышлар. Кариб янына үсмер гвардеец килә.

Үсмер гвардеец. Кайттыңмы, Кариб абый?

Зәкия *(сикереп тора)*. Ур-ра! *(Кәгазьләрне күрсәтә.)* Хәзер күчереп бетерәм, Кариб абый.

Мәхмүт *(тирә-яктагы шау-шуны яратмыйча тыңлап тора)*. Штабта җүләрләр утырамы әллә? *(Зәкиягә.)* Кайда ул батальон? Татар батальоны кайда, Зәкия туташ?

Зәкия *(исемлекне Карибка сузып)*. Менә ул батальон! Дүрт йөз туксан тугыз кеше теркәлгән.

Мәхмүт. Дутовның кавалериясенә, пулеметларына, бронемашиналарына шушы кәгазь каршы тора алса, сез кодрәтле алла, Зәкия туташ.

Зәкия. Безнең якта дөреслек, идея.

Мәхмүт. Ертык чалбар балаклары, ялан аяклы гвардеецлар, ун кешегә бер винтовка...

Кариб *(исемлектән башын күтәрә)*. Син, Мәхмүт, батальонның хәрби белгече. Безнең өскә нинди бурыч йөкләнүен дә сорамыйсың.

Зәкия *(канатланып)*. Һөҗүмгә күчәбезме, Кариб абый?

Үсмер гвардеец. Әллә һөҗүмгә үк?!.

Мәхмүт. Ачуланмагыз, Кариб, барын да аңлыйм. Татар батальоны дип аталган, әле борынлый гына башлаган толпага сугышчан задание бирелә икән, бу инде итәккә ут капкан дигән сүз.

Кариб. Хәл авыр. Аны берәү дә яшерми. Штабта да беләләр. Безнең әзерлек юк, корал аз. Әмма гвардеецларга кара, сугышка дип атлыгып торалар. Күбесе аклар тарафыннан кыерсытылган кешеләр.

Мәхмүт. Аннан ни мәгънә?

Зәкия *(Мәхмүткә, ачу белән)*. Революционермы сез, җылак күрсисткамы?

Мәхмүт. Барыннан да элек, мин хәрби белгеч. Батальон беренче сулышында ук тар-мар ителгәч, кем җавап бирер?

Кариб. Постой, постой!.. Ә син тар-мар иттермә! Шашки во-он! Куак казакны җәһәннәмгә!

Мәхмүт *(нәзакәт белән)*. Гафу сорыйм, Зәкия туташ. *(Карибка.)* Кариб, сез мине Оренбург фронтына чакырганда ниләр гәпләштек? Ызаннан башлары чыкмаган тузанлы агайларны сөреп һәлакәткә алып барырга мин вәгъдә бирдемме? Бирегез миңа вакыт, мин менә шушы мужиклардан менә дигән гаскәр ясыйм. Бер ел, юк икән, ярты ел вакыт бирегез.

Кариб. Ах, вакыт кирәкме сиңа? Вакыт!.. Оста... Батальон сугышка бүген керергә тиеш. Губком вакытлыча Оренбургны калдырып чыгарга карар кылды.

Зәкия. Сугышмыйча-нитмичә чигенәбезме?

Кариб. Канлы көрәш фронтларында йончыган кызыл отрядларны шелоннарга төяп шәһәрдән озатыр өчен ике көн вакыт кирәк. Без, яңа, вежий батальон, Дутовны ике көн Сакмардан чыгармый торырга тиеш.

Мәхмут. Ә ни өчен именно без?

Кариб. Башка отрядлар сугышта йончыганнар, яралылар күп. ез аларның куркынычсызлыгын тәэмин итәргә тиешле. Аңлашылдымы? Әзерләнегез, шашки во-он, и походка! Быргычы, алга!

Хуплау, дәртләндерү тавышлары, кемдер гармун сызып куя.

Зәкия. Ишетәсезме, элекке поручик әфәнде, походка!

Мәхмут. Зәкия туташның хисләре аңлашыла... Әмма ләкин герман фронтында булган, ике тапкыр яраланган, газ белән агуланган, сугышың каһәрен җилкәсендә татыган вахмистр Хәйруллинның болай сөйләве...

Кариб. Ялгышасың, Мәхмут... Мин күптәннән вахмистр түгел инде. Революционер, большевик мин. Оренбург далалары синең поручиклык тутыгын да кырып чыгарыр, чарлар, күрерсең.

Зәкия *(Мәхмуткә)*. Ә мин сезгә ышанган идем...

Мәхмут *(наз белән)*. Без икәү ничек тә аңлашырбыз.

Кариб. Дутовчылар Сакмар күперенә якынлашканчы далага үтеп чыгарга да аларны шунда бик шәплэп пешерергә кирәк!

Мәхмут. Батальон бу хәлендә ике көн түгел, ике сәгать тә каршы тора алачак түгел.

Кариб. Ә без аны кызыл гвардеецларның үзләреннән сорыйбыз. *(Кычкырып.)* Иптәшләр! *(Кызыл гвардеецлар берән-сәрән алар янына җыелалар)*. Иптәшләр! Безнең командование вакытлыча Оренбургны калдырып торырга булды.

Гвардеецлар арасында ризасызлык тавышлары.

— Ничек, сугышсыз-нисезме?
— Урам тулы кызыл этрәт!
— Һай, эттәгенәсе!

Кариб *(дәвам итеп)*. Без үз гаскәребезнең чигенүен тәэмин итәргә тиешле. Я, ничек, Дутов алдында махы бирмәбезме?

Гвардеецлар җиннәрен сызганып кычкыралар.

— Кырабыз без аларны!
— Җир күмере ясыйбыз!

Мәхмут. Казаклар яхшы коралланган. Өйрәтелгән. Бер полклары фәкать офицерлардан гына тора.

Бер гвардеец. Укытабыз эфисәрнең арт сабагын!

Көлешәләр. Тавышлар.

— Ур-ра!
— Ак этәчләрнең муенын борабыз!
— Татар бар җирдә хәтәр бар.

Бер гвардеец *(Мәхмуткә)*. Иптәш командир, шул аклар көчле дә көчле дисез, кораллары шәп дисез, әнә, йөз кешелек этрәт Сызраньнан чыккан да акларны кыра-кыра күпме җир үтеп Ырынбурга килеп житкән. Дөресме икән шул?

Кариб *(шатланып)*. Рас, иптәшләр. Әйтергә өлгермәдем, биш пулемет белән коралланган отряд Куйбышев боерыгы буенча аклар божрасын өзә-өзә монда чыккан. Үзләре барысы да татарлар икән. Штабта әйтеп тордылар, алар да безнең батальонга кушылачак.

Гомуми җанлылык, урра тавышлары.

Мәхмүт. Ай-һай, кушылырлармы? Андый отрядның командиры кадровый военный булырга тиеш.

Бер гвардеец. Базарда бая сөйләп тордылар, командирлары яшь кенә егет ди. Ут ди инде менә, ут!

Атылып-бәрелеп Сәхи килеп керә.

Сәхи. Бирегез миңа мылтык, бирегез кылыч!

Кариб. Нинди мылтык? Кем син?

Сәхи. Алар нидер уйлаганнар! Сак булыгыз. Карыйм, бүген таңнан чаж да чож кемнәрдер кереп-чыгып йөри, чышын-пышын нидер сөйләшәләр, киңәшәләр.

Кариб. Әй, егет, йомышыңны әдәмчә генә аңлат әле.

Сәхи. Сары бай малае мин. Әткәйнең дус-ишләре байгуралар тузыналар.

Кариб белән Мәхмүт бер-берсенә карашалар. Гвардеецлар арасында: «Бай малае!», «Шпион!» дигән тавышлар.

Сәхи. Кызыллар Ырынбурны ташлап чыгалармыни?

Кариб. Кем тарата? Каян ишеттең?

Сәхи. Әткәйләр сөйләшә! Юкны-барны лыгырдап йөрмә дип үзен складка бикләдем дә монда чаптым. Мылтык, кылыч бирегез миңа.

Бер гвардеец. Мылтык сиңа түгел, гвардеецларга да эләкми әле.

Сәхи. Мылтыгын бирәсезме, юкмы... языгыз мине кызыл этрәткә! Шәһәрдә калмыйм, валлаһи!.. Бай буласым юк, Дутов казаклары белән гаепсезләрнең җанын кыеп йөрисем килми.

Кариб. Язып куй булмаса үзен, Зәкия.

Зәкия (*шатланып*). Фамилияң ничек? Исемең? Биш йөзенче булырсың.

Сәхи (*тирен сөртеп*). Сәхи мин, Таһиров. Рәхмәт, иптәш командирлар.

Мәхмүт (*Карибка*). Ошамый бу егет миңа. Чикылдап торган анархист.

Кариб. Шәһәрдә бунт әзерләнеп ятмасын, штабка хәбәр итәсе, ахры.

Мәчеткә акрынлап халык җыела. Менә аркасына зур капчык күтәргән Хәйрүш керә. Аның артыннан мылтыклы Таҗетдин килә.

Хәйрүш (*авызы ерык*). Ну, малакаем, Кариб җаным, бие. Кырык кешегә обмундирование алып кайттык.

Мәхмүт. Командирга шулай докладывать итәләрме?

Хәйрүш (*капчыгын җиргә ташлый, чишә*). Товарын кара син, Кариб җаным, малакаем, товарын, первой сорт! Нинди генә размерын җаның тели, билләһи!

Кариб. Син, Хәйрүш агай, армиягә беренче көн килгән кебек кыланма инде.

Хәйрүш (*кинәт смирно басып*). Гафу үтенәм, вахмистр... тьфу! Боерыгыгыз үтәлде, иптәш командир. Аяк киеме белән кырык гвардеец тәэмин ителде. (*Мылтыклы гвардеецка*). Яле, Таҗетдин, бушат, күрсеннәр.

Капчыкны икәү күтәреп бушаталар. Аннан чабаталар килеп төшә. Барысы да исләре китеп карап торалар.

Кариб. Сукыр бер тиен дә акчаң юк, Хәйрүш агай, талап алмагансыңдыр бит?

Хәйрүш. Никак нет, вахмистр әфәнде... тьфу, иптәш командир! Гадел юл белән алмашып алдым. Базар аша үтеп барабыз, бер бәндә җилән сатып йөри. Менә дигән җилән! Үзе мыдыр-мыдыр большевик-

рны сугә. Байга җиләп нәрсәгә аңа? Кирәк булса, сатмас иде. Зна-ітся, артык мал. Революция файдасына кон-фис-ка-ция-лә-дек.

Сәхи. Минем эткәйнең җиләне.

Хәйрүш. Дөрес, менә бу җирән егет тә революция өчен тырышты. ғыйсә безне базарның этәм-сәтәм халкы урап алган иде. Яныйлар, ну ·з, кыскасы... *(Ишарә белән аңлатып бирә.)*

Таҗетдин *(калын тавыш белән)*. Точно так, иптәш командир. Іуннан Хәйрүш агай җиләнне сукнога, сукноны чабатага алыштырды.

Хәйрүш *(мактанган сыман)*. Шәп бит! *(Селкеп күрсәтә.)* Ак казак-ı куа башласаң үзе җиңел, үзе иркен. Җитмәсә, тирләтми, форточка-әры күп.

Кариб. Хәйрүш агай, үзең белеп өләш. Ялан аяклыларга беренче іратта бир.

ıбаталарны кәрвансарай ишек төбенә алып киталәр. Шау-гөр килеп өләшәләр, киенә-ләр. Кариб бер-ике кешегә өстәл-урындыкларны читкәрәк алырга куша.

Кариб. Язылу тәмам! Боларны да кертеп куегыз.

Тавышлар:

— Шәп мал!

— Киндерәсе Дутовны асып куярлык.

— Корсагы зурдыр, чыдатмас...

Үсмер гвардеец. Шадра ике пар эләктергән!

Мәхмүт *(Карибка)*. Байракны да алыргамы?

Кариб. Флаг торсын.

Мәхмүт. Мин аптырашта: хәзер нәрсә эшләргә?

Кариб. Поручик Урманаев! Поход алдыннан нишлиләр? Әзерләнер-гә кирәк. Аннары, шашки во-он!

Зәкия. Медикаментлар, дарулар бик аз, Кариб абый.

Кариб. Әзләргә! Иң соңыннан язылган егетнең исеме ничек әле? Иярлә шуны!

Зәкия. Бишйөзенчеме? Таһиров!

Кариб. Таһиров!

Сәхи йөгереп керә.

Сәхи. Мин ул, иптәш командир.

Кариб. Хәзер менә безнең сестра белән каланың астын-өскә әйләндерегез. Тик бел: урламаска, таламаска. Безгә дарулар, бинт, мамык кирәк.

Сәхи. Була анысы, иптәш командир. Киттекме, чибәр туташ?

Мәхмүт. Шомлы вакыт, сезгә куркыныч булыр, Зәкия туташ. Озатучы бирикме?

Зәкия. Курыкмагыз, Мәхмүт, мин буш кул белән түгел.

Кесәсеннән браунинг алып күрсәтә. Сәхи капка яныннан аңа сокланып карап тора. Мәхмүт Зәкияне озата. Чыгып китәләр.

Мәхмүт. Туганымнан да якын ул миңа... Аңлыйсызмы, Кариб?.. Ант биргән патшадан коры калып, дәрәҗәмнән, хыялларымнан баш тартып Сызраньга кайтып егылганда, Зәкия туташ минем бердәнбер терәгем иде.

Кариб. Әйе... Безне дә ул таныштырды... Бар иде синең җебеп калган чакларың!

Мәхмүт. Соңгы бер елда без гел бергә... Тик Оренбург далалары безне аерыр төсле.

Кариб. Дала дусларны аерамы, җүләр? Иптәшлек далада сынала, бел! Их-х, айкыйбыз аны даланы! По коням!

Мәхмүт. Ә атлар юк... Гвардеецларны...

Сагъдетдин килеп керә. Ул як-ягына каранып, курка-курка гына килә. Аркасында, ян-якларында капчык, кулында таяк.

Сәгъдетдин. Әссәләмәгаләйкем, мөселманнар.

Кариб (*кырыс*). Мәчет монда түгел, әнә тегендә.

Сәгъдетдин. Мөселман гаскәренә шушында язалармы?

Мәхмүт. По коням! Биш йөз дә беренче драгун! Кайда кылыч, черкеска, шпорлар... Язылырга килгән, честное слово!

Сәгъдетдин. Өстенә бастың, нәнкәм, кая, үзең иң кәттә лачанник булсаң, мөбәрәк кулың белән, бисмилла и рахманирәхим, шунда бер читкә безнең исемне дә төртеп куй әле.

Кариб. Нәрсә эшли аласың соң син, бабай?

Сәгъдетдин. Син миннән нәрсә эшли алмыйсың дип сора, нәнкәм.

Мәхмүт. Мылтык ата беләсезме?

Сәгъдетдин. Ә син тәрәзә борысы утырта аласыңмы?

Мәхмүт. Утыртырга туры килгәне юк.

Сәгъдетдин. Ә мин утырта беләм. Белгәч, сине өйрәтергә дә кулымнан килә. Мылтык атарга, ходай насыйп итсә, мине син өйрәтерсең. Өйрәнергә калгач, нишләрсең.

Мәхмүт. Абзый, болай баш катырып йөрмәгез.

Сәгъдетдин. Хак сүз әйттең, үзем дә ашыгам. Намаз вакыты да бик житте. Каячы, язып кына куегыз да... Сәгъдетдин Билалетдин угылы Фәсхетдинов булабыз инде без. Ягъни...

Кариб. Тай моннан, бабай, тай!

Мәхмүт (*аның колагына килеп кычкыра*). Язылу бетте, бабай.

Сәгъдетдин. Ишетмәдем. Һай, ишетми калганмындыр шул. Кайчан бетте әле ул ак казаклар?

Кариб (*кызыксынып*). Казак бетмәде...

Сәгъдетдин. Бәс, шулай икән?.. Язылу бетә диме?.. Һай, намазга соңга калдырмасагыз иде, тәһарәт тә алынмаган, дигәндәй...

Кариб. Бар, бабай, намаз-ниязларыңны тәмамла әлек.

Сәгъдетдин. Шулай диген, нәнкәм, рәхмәт яугыры.

Кереп китә.

Мәхмүт. Көлке.

Кариб. Уйнама, ничек китереп терәде ул безне?.. Бер әйбәт комиссар булса, болардан менә дигән гвардеецлар ясар иде.

Мәхмүт. Командир гына житмиме?

Кариб. Икебез тиң авызыбызны ачып кызыл гвардиягә язылырга килгән картның мәчеткә кереп китүен карап калдык ич.

Тажетдин килә.

Тажетдин. Иптәш командир, бер олау мылтык китерделәр.

Кариб. Мәхмүт, коралларны кабул итеп ал. Әйбәтләп сана. Мылтык тота белгәннәрне ныгытып барла. (*Мәхмүт чыга.*) Тажетдин, син кал әле. (*Тажетдин юаш кына басып тора.*) Я, туган, ни сөйлиләр?

Тажетдин. Сүзләрнең рәте-башы юк, иптәш командир.

Кариб. Шулай да?

Тажетдин. Халык бик чуар... Безнең өлешкә даладагы жыен икеле-микеле, калдык-постык калган бит.

Кариб. Күз-колак булыгыз. Тегенди-мондый кешеләр килеп кермәсен. Дөнья бит!

Кәрвансарайдан Хәйрүш чыга.

Хәйрүш. Иптәш командир, сине телефонга дәшәләр.

Кариб. Тажетдин, син шушы тирәдә чуал. Чит кешене кертмә. Үзебезнекеләрне корал белән чыгарма.

Тажетдин. Шулай итәрмен, иптәш командир.

Кариб ашыгып кереп китә. Тажетдин ишек янында басып кала. Гвардеецлар үтеп-сүтеп йөриләр. Жанлылык. Шау-шу. Хәйрүш Тажетдин янына килә, чүгәләп тәмәке тарталар.

Х ә й р у ш *(моңаеп)*. Таҗетдин, нәнкәм, унсигезенче елның печәнен кыю да насыйп түгелмени инде миңа?

Т а җ е т д и н. Насыйп булмас... Ак казаклар ком бураны кебек килә-ләр бит... Иң әүвәл аларны кырып бетерергә кирәк.

Х ә й р ү ш. Синең нәрсә, кашың да күзең, мылтыгың да үзең. Гомер-гомергә пролетар. Минекеләр жиде җан бит, җиде җан!

Т а җ е т д и н. Гурьевтагы фабрикант Акчуриннарны, мөгаен, сөр-гәннәрдер инде... Санияқәй көтә-көтә зарыгып беткәндер... Кайтасы иде...

Акрын гына җырлыйлар.

Без утырган машинаның тоткалары җиз генә,
Бер илләрдән аерылгач кайтып булмый тиз генә...

Чыгып килүче Кариб белән Мәхмүтне күреп тиз генә торалар.

М ә х м ү т. Патроннар бик аз, Кариб.

К а р и б. Губком секретаре иптәш Коростылев сорый: татарлар кузга-лырга әзерме, ди.

М ә х м ү т. Ни дип җавап бирдегез соң?

К а р и б. Ярты сәгать эчендә хәл итәрбез дидем. Хәзер батальонны тез, сөйләшергә кирәк!

М ә х м ү т. Хәйрүш агай, Таҗетдин абый, гвардеецларны җыегыз.

Хәйрүш белән Таҗетдин кычкырып чакырып йөриләр. Мәхмүт белән Кариб бер кырыйда күзәтеп торалар.

М ә х м ү т. Батальон, становись!

Тезеләләр. Гвардеецларның кайсы күши, кайсы сөйләшә. Аркаларда төрле зурлыктагы капчыклар. Төрле формадагы мылтыкларны теләсә ничек тотканнар. Нәкъ шул вакытта мәчет манарасыннан мәзин азан әйтә башлый.

Т а в ы ш л а р:
— Нәрсә ди? Тезелегез диме?
— Шулай ди.
— Үкчәгә басма.
— Кая алып китәләр икән?

Шушы ыгы-зыгыны көчәйтеп, кәрвансарайдан бер-берсенә атланып ике гвардеец чыга. Аларны шаркылдап көлеп каршы алалар.

К а р и б. Бусы нәрсә тагын?
Т а в ы ш л а р:
— Иптәш командир, Әхмәтҗан кәрттә уйнап оттырды.
— Кәрвансарайны өч рәт әйләнеп чыксын.

К а р и б. Туктагыз хәзер үк! Тоже мне кавалерия! Марш!

М ә х м ү т. Тагын кабатлыйм: тезелегез! Батальон, смирно! *(Стройны күзәтеп чыга.)* Әнекәй генәм...

Сәгъдетдин дә стройга кереп баскан, янындагы капчыклары мәзәк булып сузылып тора. Кариб белән Мәхмүт строй буйлап баралар, Сәгъдетдин янына тукталалар.

Бу нәрсә, пулеметмы?

С ә г ъ д е т д и н. Пуләмәт дип мөселман кешедән көлмә инде син, нәнкәм.

К а р и б. Коралны капчыкка тыгып йөриләрме?

Капчыкны чишеп җибәрсәләр, анда ялтырап торган җиз комган.

М ә х м ү т. Нәрсә бу?

С ә г ъ д е т д и н. Соң, лачанник улым, ул казак мәлгуньнәрне, дин-сез дәһриләрне теге дөньяга тәһарәтсез ничек җибәрәсең?

Кушәүче гвардеец. Иптәш командир, сүз бар иде.

Кариб. Сүзегезне соңыннан сөйләрсез. Команданы ишетмәдегезме әллә?

Сакаллы гвардеец. Анысы шулай, аңладык. Шәйхетдиннең сүзе кирәкле бит. Аны һич тә сонга калдырырга ярамас.

Кушәүче гвардеец. Җәмәгать, әнә намаз башлана.

Сакаллы гвардеец. Митингны намаздан соң тәмамларбыз, иптәш командир.

Сәгъдетдин. Бәрәкалла, акыллы балалар икәнсез, намазсыз һич кенә дә ярый торган эш түгел.

Тавышлар:

— Җан турында да онытмыйк.

— Мөселман батальоны ич без.

— Мәчет күруләр яңадан насыйпмы-юкмы, диген...

Хуплау авазлары, рәтләр таркала, гвардеецлар мылтыкларын жиргә куеп мәчеткә кереп китәләр.

Кариб. Иптәшләр, иптәшләр!

Мәхмүт. Кая барасыз? Таралырга команда булмады.

Кариб. Туктагыз, тукта!

Батальонның күпчелеге мәчеткә кереп китә. Ишек алды уртасында берничә гвардеец, Кариб, Мәхмүт, Хәйрүш, Таҗетдин басып калалар. Тынлык.

Кариб. Их, коралларын ташлап киттеләр!.. Коралларын! Революциягә хыянәт!

Мәхмүт. Хәйрүш агай, коралларын җыеп кәрвансарайга кертегез.

Хәйрүш, Таҗетдин, гвардеецлар коралларны җыеп алып кереп китәләр.

Кариб. Мәхмүт, син бит поручик булган кеше. Аңлат, ни кылырга? Мин бит... үзең беләсең: шашки в-он, марш, марш! Их, далага чыксак өйрәтер идем мин аларны!

Мәхмүт. Бу кадәресен мин дә көтмәгән идем.

Кариб. Губкомга барып хәлне аңлатмый ярамый. Отказ бирергә кирәк. Ичмасам, теге отряды да килеп җитмәде. Хәйрүш агай, Таҗетдин, әйдәгез минем белән!

Таҗетдин. Арага провокатор кермәдеме икән?

Кариб, Хәйрүш, Таҗетдин чыгып китәләр. Мәхмүт ары-бире каранып торгач, кәрвансарайга керә, аннан саквояж тотып чыга. Капкага бара башлый, кызыл бантын йолкып алып кесәсенә яшерә. Аның каршысына китаплар, тартмалар күтәргән Зәкия килә.

Мәхмүт. Зәкия туташ?

Зәкия. Сез миңа булышырга киләсезме?

Мәхмүт. Әлбәттә!

Зәкия. Ә саквояжыгызны нигә алдыгыз?

Мәхмүт. Аңлыйсызмы, Зәкия туташ...

Зәкия. Батальон кайда?

Мәхмүт. Беләсезме, бөтен революцияләрдән, байраклардан, идеяләрдән өстенрәк көч бар икән әле монда.

Зәкия. Нинди көч? Кем?

Мәхмүт. Әнә шул мөнбәрдәге бетәшеп беткән карт.

Зәкия. Сез, революционер, шул карттан курыктыгызмы?

Мәхмүт. Юк... Мин толпадан курыктым.

Зәкия. Атлаган саен икеләнерлек булгач, нигә Сызраньнан киттегез? Нигә безгә иярдегез?

Мәхмүт. Зәкия туташ, җирдә мин табынган алла сез. Мин исә корыч инәгә тагылган төссез, ярым черек җеп. Инә — сез, җеп — мин. Инә кая, мин шунда.

Зәкия. Матур сөйләп бер тапкыр харап була язган идегез инде, агын кабатлыйсыз.

Мәхмүт. Ходай хакы өчен, үткәннәрне искә төшермәгез.

Зәкия. Сызрань хәрби горнизоны. 1917 ел. Ялтыравыклы погоннары уйнатып, шалтыравыклы сүзләр сибеп сез трибунага мендегез. Җиңгәнгә кадәр сугышны дәвам итик!» Гади солдат Шамил Усманов ыгып отпор биргәннән соң, сезне трибунадан сөйрәп төшерделәр... Шамил коткармаса...

Мәхмүт. Шул исемне телгә алып, җанымны кызган табага саласыз!

Зәкия. Бәлки сез Сызраньнан да бары Шамилдән качу өчен генә китkәнсездер?.. Революция икеләнүләрне кичерми, Мәхмүт! Кайда батальон?

Мәхмүт. Таркалды, тумас борын үлде...

Зәкия. Кариб абый кайда?

Мәхмүт. Шуны хәбәр итәргә штабка китте... Зәкия туташ! Хәзер ин тыныч чак: китик моннан!

Зәкия. Китәргә?

Мәхмүт. Хәзер штабтан тикшеренүчеләр килер. Провокаторлар юкмы дип тикшеренә, казына башларлар.

Зәкия. Сугыш алдыннан батальонны ташлап качаргамы?.. Кариб абыйны? Әнә Сәхиләрне?.. Юк! Батальон яшәр!

Мәхмүт кычкырып кала. Зәкия ярсып чыга. Мәхмүт нишләргә белмичә әрлы-бирле сугыла, урам яктан тавышлар килә. Әле тәкбир әйтеп кычкыралар, әле янылар.

Мәхмүт. Монысы ни афәт тагын?

Атылып Сәхи керә.

Сәхи. Иптәш командир!

Мәхмүт. Нәрсә бар анда?

Сәхи. Коткарыгыз. Әткәй үтерәм дип яный. Монда киләләр. Калада бунт!

Мәхмүт. Ахмак сез! Үз әтиегез белән дә уртак тел таба алмагач...

Сәхи. Ничек? Сары бай диләр ич аны!..

Ярсыган халык төркеме кәрвансарайга килеп җитә. Сәхи ишек артына кача. Халык. Оренбургның вак-төяк байлары, кибетче, сәүдә әһелләре. Арада хатын-кыз да бар. Бер кырыйда ярлы-ябагай, Гөлҗамал, Сәкинә дә шунда.

Тавышлар:

— Ояларьі шушында.

— Азгыннар, кяферләр.

Сары бай. Җәмәгать, мөэмин мөселманнарны котыртып атна буе шушында язып яттылар. *(Кызыл байракны барып йолкып ала.)*

Берәү. Мәккә кяферләры.

Икенчесе. Алардан мең яманды́р, билләһи.

Сары байның байракны ертырга азапланганын күреп, кайберәүләр куркышып читенәләр.

Сары бай. Курыкмагыз, аларның ике өтеккә бер күгәргән кистәннәре юк. Дутов хәзрәтләре өермә булып килсә, без дә монда тик кенә ятмадык. *(Корал күрсәтә.)*

Мәхмүт. Сезгә нәрсә кирәк?

Сары бай. Әһә, менә ул үзе! Комиссар, кая качырдың минем азгынны?

Мәхмүт. Мин сезгә җавап бирергә теләмим.

Сары бай. Күрдегезме, сүзне каян чыгара?

Мәхмүт. Сезгә нәрсә кирәк? Нигә шаулыйсыз?

Т а в ы ш л а р:
— Сорап торган була!
— Жиргә ахырзаман индерсеннәр дә шаулама, имеш!
М ә х м ү т *(аптырашта)*. Мөселманнар, самосуд ясарга закон юк
Б е р ә ү. Ә-ә, закон исенә төштеме? Үзең бетердең законны, хәзер теләсә нишләсәк ирек!
И к е н ч е с е. Башын бетерик.
С а р ы б а й. Туктагыз, үзем! Безнең балаларны моннан болай котыртып йөрмәсен.

Обрезын чыгара. Сәхи ишек артыннан чыга.

С ә х и. Әгәр канга сусасаң, чыгар канымны!
С а р ы б а й. Менә үзе килеп капты!
С ә к и н ә *(арага килеп керә)*. Сәхи жаным, кач!
Г ө л җ а м а л *(килеп җитә)*. Кызым, балам, кайтыйк...
С а р ы б а й. Кит, зиначы! *(Сәхигә)*. Изге коръәнне атып бәргәндә бик батыр идең, хәзер нишләрсең икән!
Т а в ы ш л а р:
— Коръәнне атып бәргән? Ах, мордар!.. Жир йотар!
С ә х и. Кый жанымны, дәҗҗал!
С а р ы б а й. Жаның җәһәннәмлек!
М ә х м ү т. Байлар, самосуд ясарга ирек бирмәм.
С а р ы б а й. Мөселманнар! Менә бу бер явыз бәндә. *(Мәхмүтне күрсәтә)*. Динебездән көлә, үзебезне мыскыллый. Безнең балалар шул дәҗҗалга ияреп тәмуг юлыннан киттеләр. Нишләтәбез аны?
Т а в ы ш л а р:
— Үлем аңа!
— Җәһәннәм!
С ә х и. Кагылмагыз командирга!
С ә к и н ә. Жибәрегез Сәхине!

Сәхине, Мәхмүтне эләктереп алалар, кулларын каерып ишеккә таба сөйриләр. Зәкия кайтып керә.

З ә к и я. Нишлисез, явызлар?
С а р ы б а й. Җәмәгать, әнә кәнтәйләре кайтты.
М ә х м ү т. Кыргыйлар! Мин сезнең йөзегезгә төкерәм.
З ә к и я. Мәхмүт бәгырем!

Зәкияне тотып Мәхмүт янына бастыралар.

Б е р ә ү. Төкеренмә, җәһәннәмдә эссе таба ялатырлар.
С а р ы б а й. Дин юлында шәһит китсәм китәм, әмма изге коръәнне мыскылларга юл куймам. *(Акрын гына обрезын күтәрә.)*
Т а в ы ш л а р.
— Комиссарга үлем!
— Доганны укы, комиссар!

Дүрт-биш яхшы коралланган гвардеец иртеп, капкадан Шамил Усманов килеп керә. Халык ахылдап куя. Сары бай обрезын тоткан килеш ялт кына борыла.

Ш а м и л. Кемгә комиссар кирәк? Мин комиссар!
М ә х м ү т. Я, аллам, тагын Шамил Усманов.
З ә к и я. Шамил!
Г в а р д е е ц л а р д а н б е р ә ү. Сызрань отрядының командиры.
С а р ы б а й. Мөселманнар, чыннан да бит Шамил Усманов. Җамалый бай тегермәнендә малай булып йөргәндә үк җыен этрәк-әләмне котыртып ырволюция ясап йөргән юньсез.
Ш а м и л. Таныдың, Сары бай. Мин дә сине онытмадым. Тегермәнгә жандармнар иртеп килгән идең.

Сары бай. Үзе килеп капты! Шушы мөртәт анның башы! Бәлшәвикләрнең иң усал эте шул!

Зәкия. Шамил, саклан.

*...резын күтәреп атам дигәндә генә Шамил кесәсеннән наган чыгарып ата. Сары байның обрезы атылып төшә, үзе чыгып йөгерә, җыелганнар куркынып чигенәләр.*

Шамил. Бүре сукмагыннан ерак китә алмассың, Сары бай!

Зәкия. Шамил, мең, мең рәхмәтләр дә аз сезгә.

Шамил. Исәнмесез, Зәкия туташ. Сезне монда очратырмын дип ич уйламаган идем. Мәхмүт әфәнде үзгәргән... Сары байның обрезы тигәрттеме?

Мәхмүт. Сызраньнан чыккан отрядның командиры сез алайса?

Шамил. Мин. Ә сезне нигә әсир иттеләр? Моңарчы байлар белән уртак тел таба торган идегез...

Мәхмүт. Әгәр батальон дигәннәре яшәсә, мин шунда хәрби белгеч.

Зәкия. Мәхмүтне алуларын Кариб абыйдан мин үтендем.

Шамил. Ә батальон кайда? Кариб кайда?

Сәхи. Әнә намаздан чыгып киләләр.

Шамил *(гвардеецлар каршысына барып)*. Командирларын көпәкөндез дошман кулына тапшырган егетләр шушы буламыни? *(Уңайсызлану тавышлары.)* Шушы кадәр батырлар арасыннан хатын-кызны коткарырлык берәү дә табылмадымы?

Сәгъдетдин. Кем уйлаган бит аны...

Шамил. Иптәшләр, дутовчылар революция яклы кешеләрнең үзләрен генә түгел, хатын, бала-чагаларын, туганнарын кырып Оренбургка ыкынлашып киләләр. Ак казаклар аяз көндә күтәрелгән әшәке ком бураны кебек. Әгәр без шундый таркау, оешмаган булсак, казак гаскәренә каршы тора алырбызмы? Я, менә син әйт. *(Күшәүчегә күрсәтә.)*

Күшәүче гвардеец. Ә син үзең кем буласың?

Сакаллы гвардеец. Әйе шул. Кем син безне өйрәтергә? Без доброволь!

Шамил. Мин Шамил Усманов булам. Татар батальонына комиссар итеп билгеләндем. Каюм!

Каюм. Тыңлыйм, иптәш комиссар.

Шамил. Хәзер үк безнең отряд кәрвансарайга килеп житсен. *(Каюм чыга).* Ә сез, батыр гвардеецлар, үзегезне кеше төсенә кертегез. Тиздән походка!

Гвардеецлар *(тигезсез генә)*. Ур-ра!

Шамил. Ә сез, чибәр апа белән чибәр әби, ни йомыш?

Гөлҗамал. Минем кызым ул, бердәнберем. Сары байда асраулыкта иде...

Сәкинә. Без дә кызыл гвардия белән китәр идек...

Сәхи. Иптәш командир, Сәкинәгә отрядта калырга рөхсәт итегез. Әйбәт кыз ул!

Зәкия. Шамил, ул миңа ярдәм итәр.

Гөлҗамал. Дөнья булгач, кыты-мыты эше миңа да табылыр әле. Әнә ич, кием-салымнары ничек өтелгән.

Шамил Телисез икән, мин каршы түгел. Без революциягә төрле юллардан киләбез. Безне кузгаткан сәбәпләр дә төрле, максатыбыз гына бер! Мәхмүт, ишек алдын чит кешеләрдән арындырсыннар. Батальонны тәртипкә кертегез.

Мәхмүт. Тыңлыйм.

*Төләр-теләмәсрәк китә. Гөлҗамал, Сәкинә, Сәхи кәрвансарайга керәләр. Шамил янында Зәкия генә кала.*

Шамил. Зәкия туташ, сез чак кына көтегез. *(Пауза.)* Мәхмүт белән китүегезне беләм идем... Тик артыгыздан эзләп килгән дип уйламагыз.

З ә к и я. Уйламыйм, Шамил... Сезне монда революция китерде...

Ш а м и л. Мәхмүтне ярату ыгызны ачык беләм...

З ә к и я. Сез аннан үч алырга тырышмассыз дип өметләнәм.

Ш а м и л. Юк, Зәкия туташ... Тик шулай да әйтми кала алмыйм: сезне күрүем белән бәхетлемен... Качып китсәгез дә очраштык!

Мәхмүт керә.

М ә х м ү т. Тагын кабатлыйм: батальон бу рәвешендә сугышка керә алырлык түгел.

Ш а м и л. Ничек?

Капкада Кариб, Хәйрүш, Тажетдин күренәләр

К а р и б. Шамил! Комиссар! Штабта сине безнең янга китте диделәр. Аймылыш булдыкмы? *(Күрешәләр.)*

Ш а м и л. Юк, командир, мин батальонга йөкләнгән бурыч турында штабта белештем. Аннан үзебезнең разведчиклар белән Сакмар күпере буеннан әйләнеп килдем. Сугышырга шунда туры киләчәк.

К а р и б. Булмады инде, безнең батальоннан эш чыкмас дип әйтеп кайттым.

Ш а м и л. Әгәр сездән булмый икән, күперне сакларга үземнең йөз кешелек отрядым белән барам.

К а р и б. Нигә күперне? Нәрсәсен саклыйсың аның? Дутовчыларны җәелеп далада каршыларга иде!

Ш а м и л. Нигәме? *(Күзе белән эзләнә, өстәлне күрә, аны күтәреп уртага куя.)* Менә карагыз! *(Каешын чишеп өстәлгә суза.)* Менә бу Сакмар. Дутовчылар моннан килә. Атлары, туплары белән туп-туры күпергә агылалар!

К а р и б. Күперне шартлатырга боердылар.

Ш а м и л. Ярамый. Без шушы күпер төбенә урнашабыз да аларның төп көчләрен тоткарлыйбыз. Ул арада Оренбургтан гаскәр дә, бала-чагалар да чигенеп өлгерәчәкләр.

М ә х м ү т. Ике тәүлек оборонада тору өчен бик күп корал сорала.

Ш а м и л. Корал аз чакта батырлыкны эшкә җигәбез!

Каюм керә. Отряд килгән тавышлар.

К а ю м. Иптәш комиссар, отряд килде.

Ш а м и л. Каюм, хәзер үк штабка чап: күперне шартлатмасыннар. Татар батальоны оборонада торып дутовчыларның кирәген бирергә әзер диген! Син ризамы, Кариб?

К а р и б. Син булганда барына да риза!

К а ю м. Есть, иптәш комиссар!

К а р и б. Мәхмүт, батальонны тезегез!

М ә х м ү т. Карап карыйк.

К а р и б. Сезне күргәч беләккә көч керде.

З ә к и я. Алар булмаса, без беткән идек, Кариб абый.

М ә х м ү т. Батальон, становись! Смирно!

Шамилгә докладывать итә.

Иптәш комиссар, батальон тезелде.

Ш а м и л. Иптәшләр, без хәзер үк кузгалырга тиеш. Безнең бурыч Оренбургка дутовчыларны кертми тору булачак. Ике көн, нибарысы ике тәүлек түзәргә кирәк. Ризамы сез шуңа?

Т а в ы ш л а р:

— Риза!

— Барабыз!

— Алып бар безне, Шамил!

Шамил. Шуны искәртеп куйыйм: без тимердәй нык, бердәм, куркусыз булырга тиеш. Бик күп кешеләрнең, гаскәрнең, халыкның язмышы синең ныклыкка бәйләнгән. Куркакларга безнең арада урын табылмасын! (*«Ур-ра» тавышлары.*) Я, иптәш командир, батальон белән җитәкчелекне кабул итеп ал. (*Үзе дә стройга баса.*)

Кариб. Батальон, походка марш!

Каюм керә. Кулында гармун. Уйнап җибәрә. Батальон капкадан чыгып китә, сафлар «Галиябану» көенә җырлыйлар.

Алдыр Урал буйлары,
Гөлдер Урал буйлары.
Ал булса да, гөл булса да,
Галиябану, сылуым иркәм,
Калды Урал буйлары.

Пәрдә

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сакмар елгасы ярындагы бер урын. Камышлык. Зур-зур тирәкләр. Якында гына күпер. Уйда, агачлар арасында, вагон. Сул якта кухня. Кухня янында Гөлҗамал карчык. Сәгъдетдин дә шунда утыра. Сугыш тынып торган ара. Сирәк-мирәк кенә атыш тавышлары ишетелә. Гөрселдәп снаряд ярыла. Каюм йөгереп керә, аңа ияреп кенә элемтәче ияргән. Вагонга таба баралар, аннан Кариб чыга.

Каюм. Иптәш командир, командующий штабыннан элемтәче килде.

Кариб. Тыңлыйм.

Элемтәче. Иптәш командир, хәзерге вакытка Оренбургтан отрядлар, җиһазлар төяп, сиксән эшелон озатылды.

Каюм. Тагын утызны җибәрәселәре калган, Кариб абый.

Элемтәче. Губком секретаре иптәш Коростылев шуны тапшырырга боерды: вагоннар җитми, ягулык аз, эшелоннарны туплау кыенлашты. Ә бер генә хатын-кызны да, бала-чаганы да калдырырга ярамый. Дутовчылар бөтен авыллардагы большевик семьяларын суеп киләләр. Оренбургны бары сезнең батальон гына саклый.

Кариб. Ә корал?

Элемтәче. Сездән тагын ун сәгатькә түзү сорала.

Кариб. Димәк, корал булмаячак. (*Каюмга.*) Разведка кайтмадымы?

Каюм. Күренмиләр, иптәш командир.

Кариб. Комиссар кайда?

Каюм. Күпердә. Хәйрүш агайлар белән динамит куялар.

Элемтәче. Аннары, иптәш командир, шәһәрдән килдем, беркем мине туктатмады. Үткән юлы да постларыгыз ятып йоклаган иде. Дутовчылар Сакмарны югары яктан ат йөздереп чыгулары бар.

Кариб. Каюм, постларны күздән кичереп чык!

Каюм. Есть, иптәш командир.

Элемтәче белән чыгып китәләр.

Кариб (*бинокльдән карый*). Эх, бер-ике атлы сотня булса!.. Помран кебек казынып ятыр идекме? Шашки во-он, ал-люр! (*Ат тоягы тавышы.*) Эх, тояк тавышлары Дутов кабере өстендә җеназа булып яңгырар иде.

Гөлҗамал. Теге егетләр исән-аман кайтып җитә алырлар микән, командир улым?

Кариб. Кайтырга тиешләр. (*Чыгып китә.*)

Г ө л җ а м а л. Бирсен ходай. *(Сәгъдетдингә.)* Шул Каюмны күрсәң күзеңне алмыйсың, Сәгъдетдин.

С ә г ъ д е т д и н. Улым мәрхүм исемә төшә.

Г ө л җ а м а л. Улым дигәннән, инде үзең олы гына кеше, чал, синең монда йөреп ни калган.

С ә г ъ д е т д и н. Кулымнан килә торган булса, мин бу нәләт ак казакларны Гали батыр рәвешле бер үзем дөмектерер идем. Мәңгегә, ходай бирсә, мин аларның берсенә шәфкать күрсәтә торган кеше түгел. Тукта, Гөлҗамал, мин сиңа бер нәрсә күрсәтим. *(Капчыгын чишеп бер кәләпүш чыгара.)* Менә күрәсеңме моны? Мәрхүм улымның соңгы кәләпүше. Дөнья бәясе егет иде, акылы дисеңме, сабырлыгын әйтәсеңме, тыйнаклыгын сөйлисеңме, бер дә килмәгән җире юк иде... Ә менә кәләпүшнең ике читендәге ике тишекне күрәсеңме? Ул пуля тигән җир. Шул мәрхүмнең күрше авылдан кайтканда, ак казаклар канын коеп киттеләр.

Г ө л җ а м а л. Синең улың бәлшәвик идемени?

Күпер ягыннан Шамил килә.

Ш а м и л. Ничек соң, бабай, аклар йокыны бик бозмыймы?

С ә г ъ д е т д и н. Йокы дигәне күптән качты инде, комиссар улым.

Ш а м и л. Кулыгызда нинди кәләпүш ул.

Г ө л җ а м а л. Аның улын ак казаклар атып үтергән.

Ш а м и л. Сезнең улыгызнымы? Ягез әле, ягез, Сәгъдетдин абзый. Утырыгыз, утыр. *(Кәләпүшне ала.)*

С ә г ъ д е т д и н. Бәлшәвик булмаса да, бик ипле бала иде.

Ш а м и л. Син шул кәләпүшкә карап җылап утырыр өчен батальонга язылдыңмы? Монда җылау файдасыз, ак казакның тамырын кортырга кирәк.

С ә г ъ д е т д и н. Мылтык бирмисез бит.

Ш а м и л. Иптәш Урманаев!

Мәхмүт керә.

Бабайны өченче ротага беркетегез, мылтык бирегез.

М ә х м ү т. Яхшы, иптәш комиссар.

С ә г ъ д е т д и н. Рәхмәт, Шамил улым. *(Тора, шатлыгыннан кабаланып егылып китә, капчыгыннан җиз комганы, вак-төякләр, кәләпүш тәгәри.)*

М ә х м ү т. Бабай, бу нинди тәтәйләр? Мин сезне музейга түгел, өченче ротага илтәм.

С ә г ъ д е т д и н. Алай ук димә инде, командир улым.

Ш а м и л. Ә нигә музейга илтмәскә?.. Бала каны сеңгән кәләпүш безнең ал байраклар белән янәшә музейда торырга лаек түгелмени? Вакыты килер, куярбыз! Сөйләрбез дә! Күрсәтербез дә. Язып та чыгарбыз.

С ә г ъ д е т д и н. Мин каршы килмим, Шамил улым.

Мәхмүт, Сәгъдетдин чыгалар. Атыш тавышлары. Кариб керә.

К а р и б. Кыймылдыйлар. Их, бер-ике сотня булса! Урап артларыннан керергә дә шашки во-он!

Ш а м и л. Ике түгел, бер сотня да юк. Булмаячак та. Үзебез тырышыйк, командир!

Бер-ике кеше ияртеп Хәйрүш керә.

Х ә й р ү ш. Булды, Кариб малакаем, динамитларны оялаттык. Боерсаң, хәзер күперне күккә очырабыз.

К а р и б. Әллә тондырабызмы?

Ш а м и л. Көтик. Әле утыз эшелон китәсе бар. Инде чара калмаса, аннан күз күрер.

Каюм. Аклар җанланды, бер-ике атлы теге таучыкка менде.
Шамил. Каюм, берүк постларны үзең тикшер. Арттан төшмәсеннәр.
ин күпердә булам. Нык торыгыз.

га. Каюм икенче якка йөгерә. Сәкинә юылган марлялар элә. Кариб йөренеп тора. айталар, кайталар!» дигән тавышлар. Таҗетдин, ят кешегә таянган Сәхи һәм ике гвардеец керәләр. Монда җанлану, шау-гөр килеп аларны каршы алалар.

Таҗетдин. Иптәш командир!
Кариб. Исән-сау кайтуыгыз шәп! *(Сәхигә.)* Син яраландыңмы?
Сәхи. Сәхине пуля аламы?
Бер гвардеец. Ак казак итеге үкчәсен кырды.
Кариб. Эш уңышлы чыктымы?
Таҗетдин. Белгән кадәресе шул. Дутовның төп көчләре Павлов-ада булырга тиеш. Ул станицага якын барырлык түгел. Шунда җыела-ар. Берсен юлдан эләктергән идек, разбой салырга тотынды. Сәхи азрак ыйпаган иде, мәрткә дә киткән каһәр... Шул әйтеп маташты, бөек ата-ан гаскәр туплап кына бетерсен, җаннарыгызны тубалга төйибез, ди.
Кариб. Телне әрәм иткәнсез... Бусы кем тагын?
Сәхи. Юлда иярде, иптәш командир. Кызыллар ягына киләм, ди. отып алып кайттык.
Кариб *(ят кешегә)*. Яле, дус кеше, сөйләп җибәр.
Ят кеше. Садрый атлы мин. Ваһапов. Чебенкидән. Моннан ерак үгел шундый авыл бар, Чебенки диләр.

Мәхмүт керә.

Мәхмүт *(Карибка)*. Күпернең аръягына атлылар җыела. Пушка-ар китерделәр. *(Садрыйны күреп туктап кала, ул аны бик яхшы таный.)*
Кариб. Хәзер.
Садрый. Әтием рабочий минем. Үзем дә рабочий. Менә кәгазьлә-эм. *(Кәгазьләр чыгара.)* Аклар көчләп мобилизовать иткәләгәнче үзе-зннекеләр ягына чыгып калыйм дидем.
Кариб. Хәзерге заманда кәгазьгә ышанып булмый.
Мәхмүт. Калсын, сынап карарбыз.
Кариб. Ата беләсеңме?
Садрый. Белмичә, сунарчы мин.
Кариб. Кал, күз күрер. *(Мәхмүткә.)* Аклар көчләрен тарттыралар иген. Каушап төшмәсәк ярый ла... Их, күзгә-күз далада очрашып, кы-ычка кылыч киләсе иде... Ярар инде!

Садрый чыга, һаман шунда урала. Гвардеецларны ияртеп Кариб чыгып китә. Мәхмүт Садрыйны сагалый.

Гөлҗамал. Сәхи улым, тамак ялгап ал.
Сәхи. Тамакны ялгарга була, тәмам эчелеп китә язды.
Сәкинә. Кайтмыйсыз дип шундый курыктым, шундый курыктым. акмар буена барам, гел аталар, гел аталар.
Сәхи. Кайтмый ярамый иде.
Гөлҗамал. Атаң күзеңә чалынмадымы?
Сәхи. Очраса котылу юк аңа хәзер!

Мылтыгына сугә, чыгалар. Садрый күренә, аның янына Мәхмүт килә.

Мәхмүт. Капитан! Әгәр берәрсе сезне танып алса?
Садрый. Ничек таныр икән?.. Адәм баласына үзгәреш хас. Эво-юция. Менә сез, поручик, кызыл командир булып киткәнсез.
Мәхмүт. Сез дә сунарчы икәнсез ич, белми идем.

С а д р ы й. Мәхәббәт авазы кызыллар станына китердеме? Кызармагыз, поручик!.. Ах, шул сихерле көч! Биргән антны оныттыра, идеалларны җиргә таптата!.. Поручик!..

М ә х м у т. Монда поручик юк! *(Шыпырт.)* Сез шпионмы?

С а д р ы й. Шпион булсам, тотып бирер идегезме?

М ә х м у т. Юк, мин болай гына... Бәлки сез чыннан да рабочий булып киткәнсездер... Бәлки сез чын сунарчыдыр... Тик үзегезнең элекке капитан икәнлегегезне командирга әйтергә иде. Беленсә, соңы хәерле булмас. Нигә дисезме?.. Алар ышана беләләр. Менә мин дөньядан ваз кичкәндә үз араларына алдылар, ышанып эш тапшырдылар.

С а д р ы й. Нинди кызыклы әкият!.. Тыңларга сабыйлар гына юк.

М ә х м у т. Миңа ышанмыйсызмы?

С а д р ы й. Араларына кемне алуларын беләләрме? Ә, поручик?! Черноярдагы карательный экспедициянең командирын...

М ә х м у т. Мин ул чакта күп нәрсәне аңламаганмын. Приказ утәп...

С а д р ы й. Ә алар аны беләләрме?

М ә х м у т. Тс-с, юк андый командир! Черноярда да юк, ишеттегезме?!

С а д р ы й *(җиңел сулап)*. Алайса, борыныннан юеше кипмәгән комиссарыгызга әйтегез, мин атаман Дутов җәнапларының үз фәрманы белән килдем. *(Мәхмут сискәнеп китә.)* Поручик, сез акылсыз түгел, татар батальонының ныклы бер һөҗүмдә үк һәлак буласын аермачык беләсез. Сез бит тәҗрибәле, укымышлы офицер. Ләкин атаман Дутов — бөек гуманист. Аның бер генә гаепсез мөселманны да харап иттерәсе килми. Югыйсә без ике көн буена шушы күперне ала алмас идекме?

М ә х м у т *(явыз тантана белән)*. Алганыгыз күренми, ә тырышып карадыгыз!

С а д р ы й. Батальонны бөтен килеш саклап калыйк. Татар батальонының лаеклы командиры итеп атаман Дутов сезне билгеләде, поручик әфәнде.

М ә х м у т. Ә хәзер, әлбәттә, казакларны күпердән үткәрегез дип сорыйсыз.

С а д р ы й. Дөрес, поручик. Без чигенүче большевикларның койрыгына басарга тиешле. Аларның паровозлары да, вагоннары да җитешми. Комиссар белән командирны юк итик тә...

М ә х м у т. Командир минем дустым.

С а д р ы й. Ул вахмистр. Без килешә алырбыз. Соң чиктә ялгышын ул да аңлар.

М ә х м у т. Капитан әфәнде, китегез моннан, югалыгыз. Дусларыма хыянәткә өндәмәгез. Үз гомеремдә беренче тапкыр чын дуслар таптым. Каян килеп чыктыгыз сез, кара күләгә?!

С а д р ы й. Ул чагында комиссарны...

М ә х м у т. Комиссарга якын барасы булмагыз!

С а д р ы й. Поручик, сез, чыннан да, кансыз кеше икән. Бер көчле атакадан батальоннан йомычка да калмас!

М ә х м у т. Үзем дә шулай уйлап курыккан идем, капитан. Калдылар, җан кисәкләрем. Яхшы батальон, әйбәт солдатлар!

С а д р ы й. Кызыллар китеп ычкынганчы, без барып басарбыз! Сез шушы һәйбәт батальонның бердәнбер командиры.

М ә х м у т. Мин болай да аның командиры. Капитан, буталмагыз монда!

Чыгып китә, Садрый да ана ияр ә. Куаклыкта кала. Шамил белән Зәкия очрашалар.

З ә к и я. Бүген йоклаган да юк кебек, төшемә әллә ничек гимназия килеп керде. Танцалар икән дим... Сез дә шунда, имеш. Кадет формасыннан. Бинбез, бинбез... Фабрикант Акчурин да шунда. Пычак тотып сезнең арттан әйләнә.

Шамил. Төш артык куркыныч булганда уянасың да котыласың... Закия туташ! Аклар пушкалар тарттыра. Ниһаять, батальонның каты кешене икәне аларның исерек миләренә барып җитте!..
Закия. Аңлыйм...
Шамил. Сезгә дә эш кыенлашыр.
Закия. Үзегезне саклагыз, Шамил...
Шамил. Оренбург өчен борчылам.
Закия. Сез миңа кинә саклямыйсызмы?
Шамил. Нигә?
Закия. Очрашсак, сөйләшмибез дә...
Шамил (*көлеп*). Дутов атаман гаепле. Аның казаклары без очрашканны сагалап кына торалар, хәзер атыш башлана.
Закия. Мәхмүтне Сызраньнан алып китеп дөрес эшләгәнмен бит, Шамил. Ул монда бөтенләй үзгәрде... Чын командирга әйләнеп бара...
Шамил. Нигә ата башламыйлар инде?
Закия. Сез мине тыңламыйсыз...
Шамил. Мин аръякны тыңлыйм... Шөбһәле тынлык... Мәхмүт үлгәнмедегезме?.. Аңа, кайчан да исә бер, кеше булырга тырышырга кирәк иде ич! (*Атыш башлана.*) Ниһаять! Башлана!.. Әйдәгез... Дошман белән кара-каршы торганда тынлык һәрчак куркыныч.

Чыгалар. Садрый Шамилне сагалый. Тажетдин белән Кариб керәләр.

Кариб. Тажетдин, күзең аттта да, алда да булсын. Кешеләр бик алҗыган, куркынып-нитеп чигенер булмасыннар.
Тажетдин. Карармын, иптәш командир.

Чыга. Элемтәче керә, ул арыган, тирләгән.

Элемтәче. Командир!.. Командир, иптәш Коростылев сездән тагын сигез сәгатькә түзүне үтенде... Су бирегез, су!

Гөлҗамал су бирә.

Тагын егерме ике эшелон... Кемдер паровозларны ваткан... Соңгы эшелон тулаем сезнеке! Ул резервта...
Кариб. Ә корал? Корал?
Элемтәче. Дутовчылар Шәңгәр авылында йөз сиксән кешене суеп чыкканнар. Бер кемне аямаганнар.
Кариб. Иптәш Коростылевка әйтегез: батальон сынатмас!

Чыгалар. Биш-алты гвардеец кача-кача камышлыкта күренә.

Тавышлар:
— Күперне алмакчылар...
— Аръякта кырык мең казак җыелган ди...
— Алайса, бетте инде башлар.
Мәхмүт (*чабып керә*). Кайда винтовкаларыгыз? Хәзер үк урыннарыгызга марш!

Тегеләр алга үрмәлиләр, агачлыкта Садрый күренә.

Садрый. Поручик әфәнде, Черноярны мин онытырмын. Тик сез дә, сез дә!.. Ишетәсезме, хәзер иң уңайлы момент! Батальон соңгы сулышын ала.
Мәхмүт. Юк, капитан. Без әле сугышып карыйбыз!

Сәгъдетдин керә, Садрый кача.

Сәгъдетдин. Кайда ул мәлгунь?
Мәхмүт. Син нишләп урыныңда түгел, бабай?

С ә г ъ д е т д и н. Теге яңа бәндәне эзлим. Садретдин атлымы диде, эт белсен. Комиссар миңа үзе кушты, күзеңне алма диде. Карасам, качкан.

Агачлыкта Садрый күренә.

Әнә йөри бит.

С а д р ы й *(Мәхмүткә)*. Иптәш командир...

М ә х м ү т. Барыгыз... Аны мин чакырткан идем.

С а д р ы й. Киттек, кәҗәсакал.

Чыгалар. Мәхмүт гвардеецларны әйдәп китә. Гөлҗамал керә, әйбер-караларны җыештыра. Туп ярыла.

Г ө л җ а м а л. Ходаем-мәүлям, үзең сакла.

Балык күтәреп Күшәүче гвардеец керә.

К ү ш ә ү ч е   г в а р д е е ц. Әбекәй, кеше-мазар күргәләгәнче шушыны майда куырып кына бирче.

Г ө л җ а м а л. Әнекәй генәм, әллә тере инде? Каян алдың?

К ү ш ә ү ч е   г в а р д е е ц. Сул флангка ярга куйдылар безне. Таң белән йокыдан уянсам, Сакмар өстендә балык уйный. Менә әкәмәт! Җиләннән җеп сүтеп алдым, тимер чыбык бөгеп кармак әмәлләдем. Балык кап, яр буенда ялтырап ят. Салуым булды, колак төбемдә пуляләр выж галләм! Аклар, тегеләр, карап кына яталар икән. Юк инде, абзыкайлар дим, балыкны тиккә эпипәгә биетеп булмас. Тотындык атышырга. Иптәшләр ата, мин кармак салам. Икене төшердем, өченчесе какраз килеп капты. Чат май, иеме?

Каюм үтеп бара.

К а ю м. Инде монда килеп суган сатасыңмы?

К ү ш ә ү ч е   г в а р д е е ц. Бер аягым монда, икенчесе тегендә.

К а ю м. Урыныңнан киткәнеңне тагын бер күрсәм, мәңге онытмаслык итәм. Кыямәттә дә кымшана алмассың.

К ү ш ә ү ч е   г в а р д е е ц. Йә, йә, кәпәренмә! Синең каршыңда надан патша солдаты түгел, доброволь красный гвардеец.

Гөлҗамалга ым ясап чыгып китә, Кариб белән Шамил керәләр.

Ш а м и л. Менә, командир, сыналыр чак башлана.

К а р и б. Куркыныч...

Ш а м и л. Пулеметларны фланглардан алырга туры килер.

К а р и б. Мәхмүт белән киңәшик.

Мәхмүт керә.

Я, военспец, нәрсә тәкъдим итәсең. Күрәсең, кысалар.

Ш а м и л. Без боҗрада түгел, бусы шәп.

М ә х м ү т. Патроннар аз, күперне шартлатыйк.

К а р и б. Нигә куркып калдың, дуҫ кеше. Комиссар, син сөйлә.

Ш а м и л. Сүз кыска: түзик. Дутов төп көчләрен күпер аша чыгарырга ашыга. Аның кабалануыннан файдаланыйк, бер йодрык булып тупланыйк.

К а р и б. Дөрес. *(Кычкырып.)* Әйдәгез!

Китәләр. Атыш тавышлары. Ур-ра кычкыралар. Гвардеецлар куркынып чигенәләр. Иң алдан Садрый кача.

С а д р ы й. Бетерәләр безне. Форсат барда качып котылыйк. *(Яшеренә.)*

Тавышлар.
— Беттек, егетләр. Туптан җибәрәләр.
— Илле мең солдатларына йөз илле туплары бар, ди.
Үсмер гвардеец. Фәсхетдинне үтерделәр, күрше абыем иде. *(Егый.)*
Кариб *(чабып килә)*. Кая качасыз? Стой! *(Наганнан ата.)* Туктагыз! *(Тегеләр яталар.)* Урыннарыгызга барыгыз, туганнар.
Сакаллы гвардеец. Безнең урын җәһәннәмдә. Ашыксаң, әнә Дутов туп-туры шунда озатам, ди.
Кариб. Кругом марш!

Гвардеецларны әйдәкләп җибәрә. Каюм керә

Каюм. Командир! Дутовчылар күпергә керә башладылар. Безнекеләрне кысрыклыйлар.
Кариб. Пулеметларны фланглардан алып, күпер маңгаена куегыз... Бар, чап!

Каюм чыга. Гвардеецлар чигенәләр. Капчыкларын күтәргән, мылтыгын кочаклаган Сәгъдетдин дә керә.

Сәгъдетдин. Я алла, пәрвардикар... Өскә үк киләләр бит, өскә үк... Тәмамысы котырганнар.
Кариб. Туганнар, үлсәк үләбез, чигенмибез! Их, бер сотня кылыч!
Бер гвардеец. Түзәр әмәл юк, командир.
Кариб. Тагын бер карыш чигенсәгез, үзем атып бетерәм.

Тәртипсез чигенү. Сахи, Каюм, Шамил керәләр.

Шамил. Сез монда икән. Сәгъдетдин абзый, син дә мондамы? Капчыгыңны ташладыңмы? Яле, чиш, күрсәт, ни бар анда? *(Сәгъдетдин кабаланып капчыгын чишә, кәләпүшне ала.)* Карагыз, иптәшләр, бу кәләпүшнең ике ягында да тишек. Пуля эзе! Сәгъдетдин абзыйның улын ак казаклар атып киткән. Бер гаепсез сабый баланың канын койганнар. Әгәр без хәзер казакларны үткәреп җибәрсәк, алар бер түгел, мең баланың гомерен кисәчәк. Дошманга үкчәңне күрсәтергә алып килдеңме ул кәләпүшне, Сәгъдетдин абзый?!
Каюм. Комиссар, мин синең белән!
Сахи. Шамил абый, мин дә синең белән!
Шамил. Пулеметчылар, алга! Хәзер патроннарны кызганмагыз!
Сәгъдетдин. Мин дә синнән калмыйм, Шамил улым.
Башкалар. Ур-ра!

Шамил иң алдан, башкалар аның артыннан күпер ягына ташланалар. Мәхмүт күренә, Садрый керә.

Садрый. Мәлҗерәгән бәндә икәнсез, поручик.
Мәхмүт. Ничек, күперне алдыгызмы?
Садрый. Комиссарыгызны...
Мәхмүт. Комиссарга кагыласы булмагыз!

Садрый китә.

Кирәк булса, комиссарны мин үзем... Үзем!

Чыга. Гөлҗамал, Сәкинә, Зәкия яралыны алып керәләр, бәйлиләр.

Сәкинә. Куалар, күпер өстеннән акларны куалар.
Гөлҗамал. Ходаем, бар булган афәтеңне ак казак өстенә сал!
Зәкия. Мәхмүт тә Шамил янында. Иң алдан баралар!

Сәкинә белән Зәкия яралыны алып кереп китәләр, куаклыкта Күшәүче гвардеец күренә.

Күшәүче гвардеец. Әбекәй, әбекәй! Сакмар өстендә туплар ярыла... Ул балык, ул балык... Чиләк бир әле. Аклар ягына акмасын. Ашамый торсыннар! Җыеп алам мин аны.

Гөлҗамал. Һәй, яхшы атадан яман туган! Каюм урыныннан кузгалма дидеме? Бирермен мин сиңа чиләк, Дутов фиргавене! Бар урыныңа!

Күшәүче гвардеец. Совет балыгын аклар ашасынмы? Һе, шәп, шәп... Йә, йә, ипләбрәк.

Гөлҗамал. Чүмеч белән кундырсам, ипләп булыр.

Күшәүче гвардеец чыгып китә.

Сәгъдетдинне күр син, тора-ята, өйләндерерлек егет икән ләбаса!

Көчле ур-ра тавышлары. Кариб, Шамил, Мәхмүт, Сәгъдетдин керәләр.

Кариб. Коткардың, Шамил, батальонны коткардың. Егет син.

Шамил. Оренбургны коткарган егетләргә укы рәхмәтеңне. *(Гвардеецларга күрсәтә.)* Исәннәргә дә, Сакмар ярларында ятып калганнарга да укы...

Мәхмүт. Һич ышанмаган идем, честное слово!

Кариб. Сиңа да рәхмәт, Мәхмүт... Ничек чаптылар!.. Эх, бер эскадрон булса. Куып барып йоннарын туздырыр идек. Шашки во-он! *(Күз яшьләрен сөртә.)* Ничек чабалар!.. Рәхмәт сезгә, егетләр. Батальон исеменә тап төшермәдегез.

Элемтәче керә.

Элемтәче. Иптәш командир! Иптәшләр! Оренбургтан соңгы эшелон озатылды. Сезгә чигенергә приказ бирелде. Иптәш Коростылев большевиклар партиясе исеменнән татар батальоны сугышчыларына, командирларына рәхмәт белдерә. *(«Ур-ра» кычкыралар.)*

Шамил. Хәйрүш агай! Менә хәзер шартлатсак та була!

Хәйрүш. Үтибез аны, Шамил малакаем, кадерле иптәш комиссар. *(Чыга.)*

Шамил *(кәләпүшне Сәгъдетдингә бирә).* Мә, Сәгъдетдин агай, сакла кәләпүшеңне.

Гаскәр туплана башлый. Көчле шартлау тавышы. Барысы да киемнәрен чөяләр, «ур-ра» кычкыралар. Бер кырыйда төксе генә торган Садрый янына Мәхмүт килә.

Мәхмүт. Күздән югалыгыз, капитан... Яхшы чакта югалыгыз!

Сәгъдетдин *(Садрый янына барып).* Син дә табылдың!

Садрый. Монда мин, кәҗәсакал. *(Стройга басалар.)*

Шамил. Рәхмәт сезгә, батырлар! Төрле чаклар булды, әмма сезне яралы Оренбургтагы бик күп большевик, эшче семьялары онытмас. Сез аларны ак казак үченнән саклап калдыгыз. Ил моны бер чакта да онытмас. Ә илнең хәтере мәңгелек! Хәзер походка!

Мәхмүт. Песню начинай! *(Батальон дәшми.)*

Кариб. Сәләхетдин, башла әйдә.

Бер гвардеец. Ул юк инде, командир. *(Тынлык.)*

Кариб. Алайса, Бари башласын.

Таҗетдин. Ул да калды.

Кариб. Кәлимулла.

Сәхи. Сакмар ярына күмдек.

Шамил. Алайса, егетләр, җырламыйча гына барыйк.

Акрын музыка. Батальон сак кына кузгала. Пәрдә.

ækcнə генə тимер юл станциясе. Дала. Эшелоннар утын, су алырга туктаганнар. ырда ачылганда утын, су күтәреп мадьяр, татар солдатлары үтеп тора. Алгы планга тар батальоны гвардеецлары җыелышкан. Бер егет гармун уйный, Күшәүче гвардеец ıп кенә бии. Садрый, Сәгъдетдин, Сакаллы гвардеец тамаша итәләр, кул чабып такмаклыйлар.

Күшәүче гвардеец *(биеми торучыларга)*. Нәрсә карап катты-ıз? Селкенеп калыгыз. Вагоннарда килә-килә аяклар чабагач таягына ıлэнде.

Бер гвардеец. Хак шул, җилкәләр кунадай катты.

Сакаллы гвардеец. Тузаннарыгызны коеп калдырыгыз, югый-ı паровозга авырга килә, чак тарта, бичара, пуф-пуф килеп бара.

Каюм керә, гармунчыга барып ябыша, туктата.

Каюм. Бетер сабан туең!

Күшәүче гвардеец. Командирлар ишәйде түгелме? Эте дә эмандир, бете дә командир. Иснәп кара әле, ни исе килә? *(Йодрыгын аюмның борын төбенә тери.)*

Каюм. Син әрвах утырган эшелон Дутов итчеләре кулына төшмә-ıн өчен чыбыкны мин ташырга тиешме? Куып җитсәләр, кәтлит ясый-ар бит үзеңнән!.. Ал йодрыгыңны, черек бәрәңге исе килә... Син, син, ıн! *(Берәм-берәм төртеп күрсәтә.)* Типтереп ятасызмы? Әзегезне суы-ıгыз моннан! Хәзер үк.

Садрый. Каты куя, каты... Фәрман ташучы фәрештә кебек. Хуп, уп...

Каюм. Әй, син, сунарчы, авызыңны үлчәп ач.

Күшәүче гвардеец. Юлыңда бул, Каюм. Без доброволь, уйна, гет!

Анархист. Дөнья бүген генә!

Берәү. Шулай шул!

Анархист. Әйттереп-типтереп калыйк.

Каюм. Әйләнеп килгәндә монда булсагыз, карагыз аны. *(Чыга.)*

Сәгъдетдин. Каюм дөрес әйтә бит, балалар, хак сөйли.

Сакаллы. Хак сөйләсә дә, нахак сөйләсә дә үз авызы.

Күшәүче гвардеец. Комиссар ялагае диген.

Сәгъдетдин. Эшләмичә алга барып булмас балалар. *(Чыга.)*

Күшәүче гвардеец. Акылы зәгыйфьнең биле бөгелә!

Сакаллы гвардеец. Җәмәгать, торып-торып шак катам: кыш здырыр өчен далага чыгу кемгә хаҗәт икән?

Садрый. Йомшак җиреңне утлы этәч тешләсә кая барасың?

Күшәүче гвардеец. Ничек кая?

Садрый. Шәһәргә кайтыр идең — Дутов... Унда — аклар. Сулда — ехлар. Бабай мәрхүм әйткәндәй, кругом шестнадцать! Хочешь не хо-ешь, далада кышларсың.

Берәү. Бергә-бергә кышлыйбыз аны, егетләр.

Икенчесе. Мадьярларны кара син, кырмыска күк эшләп йөриләр.

уплау тавышлары, барысы да чыгып китәләр. Зәкия утын күтәреп килә. Мәхмүт аны каршы ала.

Мәхмүт. Зәкия туташ, сезгә яралылар янында да эш җитәрлек ч! *(Утынын ала.)*

Зәкия. Уф...

Мәхмүт. Сез беләсез микән, кышны дала уртасында утырган Ак-үбә станциясендә уздырачакбыз.

Зәкия. Шамил әйтә, Ташкент тимер юлын аклардан сакларга арабыз, ди.

М ә х м ү т *(ирония белән)*. Ну, ул әйткәч рас була инде.

Чыгалар. Утын күтәреп Садрый керә. Шамилне күреп юри абына, утыннары чәчелә.

Ш а м и л *(кереп)*. Аварияме, Садрый иптәш.

С а д р ы й. Зарар юк, хәзер җыям.

Шамил иелеп чәчелгән утыннарны җыеша, Садрый шул чак куныҹыннан пычак алып кадарга итә, Мәхмүт күренә.

Ш а м и л. Сез үзегезне рабочий дидегезме?

С а д р ы й. Әти дә, бабай да рабочий булганнар.

Ш а м и л. Рабочий кеше эшне тизрәк һәм пөхтәрәк эшләр иде! *(Чыга.)*

С а д р ы й. Комачаулыйсың, поручик.

М ә х м ү т. Бик тиз үзегезгә теләктәш итмәкчесез, капитан әфәнде.

С а д р ы й. Көлке, бер асрау кыз өчен большевикларга сатылгансыз.

М ә х м ү т. Беренче бурычыгызны үти алмадыгыз, капитан. Кызык, атаман сезгә икенче бурыч та йөкләмәдеме икән?

С а д р ы й. Өченчесен дә йөкләде, поручик әфәнде.

М ә х м ү т. О?!

С а д р ы й. Сездән сер юк. Татар батальонындагы ризасызлыктан файдаланып, Ташкентка китәргә үгетләргә кирәк. Батальон чигенүче Оренбург гаскәрләрѐннән аерылсын. Юлда, җай белән генә, без аларны үзебезнекеләр ягына чыгарырбыз.

М ә х м ү т. Югыйсә, капитан әфәнде Дутов җәнаплары янына кайтырга курка!.. Ха-ха-ха!

С а д р ы й. Онытмагыз, сез татар батальонының командиры.

М ә х м ү т. Булып чыкмас, капитан.

С а д р ы й. Минем түземлекнең дә чиге бар, поручик.

М ә х м ү т. Минем түземлекнең чиген оныттыгызмы, капитан?! Югалыгыз моннан!

Чыгалар. Шамил белән Сәхи керәләр. Икесе дә утын күтәргәннәр.

С ә х и. Чыннан да безнең тормыш сез сөйләгәнчә булырмы, Шамил абый?

Ш а м и л. Безнең көрәшнең корбаннарының мәгънәсе шунда, Сәхи.

С ә х и. Заманнар узар, сез әйткәндәй, яңа тормыш төзербез. Шулчак миңа, «Әһә, син Сары бай малае идең бит!» дип, беркем дә бәйләнмәсме?

Ш а м и л. Без кешелексезлекне рәхимсез рәвештә кисеп ыргытырбыз.

С ә х и. Мин бит надан, Шамил абый. Күргәнем кибет тә мәчет кенә.

Ш а м и л. Юк, Сәхи, син хәзер надан түгел. Ирек өчен көрәшеп караган кеше, ирекнең нәрсә икәнен татып караган кеше — иң бәхетле кеше, Сәхи!

Үтеп китәләр. Сәхнәдә хәрәкәт дәвам итә. Менә утын күтәреп, иренеп кенә Сакаллы гвардеец, Күшәүче гвардеец һәм башкалар үтеп баралар. Вагон астыннан иелеп Берәү бу якка чыга. Кызыл чапан кигән, гвардеецлар аны туктаталар.

С а к а л л ы г в а р д е е ц. Абзый, монда мәчет юк.

К ү ш ә ү ч е г в а р д е е ц. Бәй, үзебезнең Әптери ич бу.

С а к а л л ы г в а р д е е ц. Каян мондый чапанны эләктердең?

Ә п т е р и. Әчтерханнан. Монда якында гына базар бар икән бит. Өр-яңа чапаннар унбиш тиен көмеш тора. Йөге белән ал.

Узып барган җиреннән Садрый да туктала.

К ү ш ә ү ч е г в а р д е е ц. Китчәле.

Ә п т е р и. Чәчрәп китим.

Аны урап алалар, чапанны капшыйлар, тешләп карыйлар.

Б е р ә ү. Мал дисәң дә мал.

Икенчесе. Авылга шундый чапан киеп кайтсаң, ә? Күзләре чабата (алыбы була инде, ә?

Тавышлар:

— Нәрсәгә ул чапан?

— Бушлай бирсәләр дә, тьфу!

— Ат булсын иде ул, ат!

Әптери. Туң исәрләр! Бер йөк чапан сатасың да акча аласың. Акчаң булды исә — ат синеке.

Күшәүче гвардеец. Төтене туры китте түгелме моның? *(Янчыгын чыгарып акча санарга тотына.)*

Сакаллы гвардеец. Базар шушында гына, дисеңме?

Садрый. Йөрмәгез! Шушындый чүпне алалармы? Күзегез чыккан-мы әллә? Тегелеш ипсез, ефәге кыштырдамый... Чын кытай ефәгеннән тегелгәне унбиш тиен көмеш тора аның.

Күшәүче гвардеец. Кайда, Кытайдамы?

Берәү. Кытайда анда чапанга өстәп кыз да бирәләр, ди.

Әптери. Чыгарып тоттыралар...

Садрый. Нигә Кытайда? Кытай ерак... Ташкентта да өелеп ята мондый мал.

Икенче. Чапан дип җир читенә барып булмый инде.

Әптери. Әтрәтне ташлап кем йөрсен? Әнә гена ич базар, әчтерханнар.

Садрый. Отрядны һич тә ташларга ярамый. Дөрес! Бөтен отряд белән китәргә кирәк.

Берәү. Ничек?

Садрый. Без бит доброволь! Сүз берләшәбез дә бөтенебез китәбез. Анда ичмасам җылы, кыш булмый, утын ташып чиләнәсе юк. Ул Ташкент базарын күрсәгез икән, ул сатучы үзбәкләр. «Әкә, нугай әкә!» дип өзелеп торалар, татарларны яраталар.

Күшәүче гвардеец. Теге йөземле яклар бит әле ул, йеме?

Сакаллы гвардеец. Чын кытай ефәгеннән теккән дисеңме? Ун тиен дисеңме?

Садрый. Җәннәт белән тиң йөртәләр аны Ташкентны. Кыш буена ач далада буранда ыжлап утырганчы, Ташкентта ак күмәч ашап ятырбыз. Аклар анда да житәрлек.

Әптери. Приказ булса, китәрсең, булмаса, нишләрсең?

Күшәүче гвардеец. Авыз ачып утырсаң, чабата киптереп калырсың, вәт. Рабочий дөрес сөйли.

Сакаллы. Әллә соң, егетләр, чынлап торып тәвәккәллибезме?

Әптери. Башкалар китсә, без ник калыйк? Түлке бу чапанны берәрсенә бөдәп килеп житеп булырмы? Ә, әчтерханнар?

Күшәүче гвардеец. Кышның корсагы зур... Утыз ике житезне кыштэдә тотып булмас. *(Тешләрен күрсәтә.)*

Садрый. Персидәтел сайлыйбыз! Менә сине!

Күшәүчене күрсәтә. Хәйрүш үтеп бара.

Хәйрүш. Китәбез дә китәбез дисез, каюк бармакчы буласыз?

Тавышлар:

— Китәбез!

— Төркстанга барабыз!

Хәйрүш. Китәсең икән, кит. *(Күшәүче каршысына баса.)* Безне котыртма. Оренбурдан бер кая китмибез. Шушында революция ясадык, шунда сугышабыз, шушында үләрбез дә!

Берничә тавыш. Дөрес!

Күшәүче гвардеец. Инде син дә комиссарга ялландыңмы? Блюхер китә, Жлобин отряды китә, син безне төпсез чуманда утыртып

калдырмакчы буласыңмы?.. Бернәрсә булса, сөекле комиссарың белән җиңел генә утырып сызарсыз, без, җүләрләр, терсәк тешләп калырбыз.

Садрый. Дөрес сөйлисең, агайне. Кыш уртасында әллә кая барып йөри алмассың!

Хәйрүш. Кем җибәрде сине монда коткы таратырга?

Берәү. Ошамаса тыңлама, сыптырт моннан!

Кариб белән Каюм керәләр.

Кариб. Нигә ташымыйсыз? Хәзер кузгалырга команда булачак.

Хәйрүш. Кариб малакаем, иптәш командир, әле дә ярый килеп җиттең. Батальонны Төркстанга китәргә котырталар, гаскәрдән аерырга.

Сакаллы гвардеец. Кем безне көчли ала? Без доброволь!

Әптери. Китәбез!

Күшәүче гвардеец. Мәнә бу халык сөйләшү өчен мине персидәтел итеп сайлады, эһем-эһем!

Кариб. Мин сине персидәтел... (*Наганына тотына.*) Көлсидәтел ясыйм!

Каюм. Шамилне чакырырга кирәк, комиссарны! Китегез бер кырыйга, тайпылыгыз, а ну!

Шау-шу, кычкырыш, Шамил, Сәхи, Сәгъдетдин, Мәхмүт, Зәкия керәләр.

Сакаллы гвардеец. Гайрәт җитмәгәч наганга ябышасызмы?

Кариб. Комиссар! Батальонда фетнә. Төркстанга китәбез, аерылабыз, дип кычкырыналар.

Сәгъдетдин. Әллә инде хаҗга ук баралармы?

Күшәүче гвардеец. Вәгаз укып маташма, комиссар, барыбер китәбез.

Әптери. Наган белән дә өркетмә.

Сакаллы гвардеец. Бауга бәйләп йөртергә үркәчле дөяләрме әллә без? Китәбез тек китәбез!

Кариб. Тынычланыгыз! Җибәрермен мин сезне!

Каюм. Тайпылыгыз, ну!

Кариб. Нигә дәшмисең, комиссар?

Сәхи. Шамил абый, иптәш комиссар, нишләтәбез?! (*Пауза.*)

Шамил. Китәргә теләгәннәр китсеннәр.

Кариб. Ничек?! Берәүне дә җибәрмим. Каюм, чап мадьярлар вагонына! Бездә фетнә диген.

Шамил. Ашыкма, Каюм... Иптәшләр! Большевиклар партиясе оешмасының карары буенча без Актүбәдә тукталабыз. Чигенү тәмам. Аннан ары бер адым да китәчәк түгелбез. Без Ташкент тимер юлын дошманга бирмәскә бурычлы. Сафларны ныгытып төзибез дә Оренбургка һөҗүм башлыйбыз!

Тавышлар:— Китәбез! Даешь!
— Ур-ра!

Тавышлар:— Китмибез!
— Ур-ра!

Сәгъдетдин. Аерылганны аю ашар, ә Дутов кебек ерткыч җанвар батальон кадәр батальонны бер генә кабып йотар.

Шамил. Алда җиңеллек булыр дип берәү дә көтмәсен. Далада ярым камалышта кышлау уен түгел. Ком бураннары, ком буранынна да хәтәррәк дутовчылар булыр. Икмәк, кием, ягулык, хәтта бер төрерлек тәмәке дә күктән яумас. Барын да аклардан сугышып алырбыз. Җиңү өчен без барын да үзебез башкарырга тиеш. Кем авырлыктан курка, кемнең җилкәсе җылыны сагынган, китсен. Хәзер кыен, алда тагын да авыррак булачак!

Кариб. Җибәрмим. (*Шыпырт.*) Батальонсыз калыргамы?

Шамил. Борчылма, Кариб. (*Кычкырып.*) Китәргә теләгәннәр әнә ѳге читка басыгыз.
Сәхи. Егетләр, куркыныч алдында бил бирер өчен Кызыл гвардиягә зылдыкмы?
Каюм. Китүче куркакларны арестовать итеп атарга!
Кушәүче гвардеец. Китәбез, җәмәгать! Актүбәдә бет симерел ятыр җай юк.

Беренче булып читкә чыгып баса, берән-сәрән генә аңа ияреләр.

Кариб. Бетә, бетә батальон! Мәхмүт, нигә дәшмисең?
Мәхмүт (*Садрыйдан күзен алмый*). Ни әйтим соң?
Каюм (*Садрыйга*). Ә син нигә чыкмыйсың, бушбугаз? Рабочиймы ле син?
Садрый. Басмыйм. Революция өчен монда эшлисе эшләрем бар.
Хәйруш. Алайса, ник кычкырындың?
Каюм. Унҗиде куркак... Башкалар китәргә теләмиләр, иптәш командир!
Шамил (*Карибка*). Күрдеңме?.. Яхшы. Барыгыз, китегез. (*Садрыйга*). Ә сине, бик шәп үгетләгән өчен, азрак капшап карарбыз. Сәхи, сак астына ал.

Сызгырып, шау-шу белән тегеләрне озаталар. Сәхи белән бер гвардеец Садрыйны сак астына алалар.

Таҗетдин (*керә*). Иптәш командир, су, утын җитәрлек кадәрле ташылып бетте.
Кариб. Вагоннарга утыра башлагыз!

Гвардеецлар вагоннарга төяләләр.

Шамил, әгәр бөтен халык китеп барган булса?
Шамил. Китмәделәр ич.
Кариб. Боларын да юкка җибәрдек.
Шамил. Үзебезне сынап карыйсым килде! Батальонга ышанмыйча булдыра алмый идем. Безгә хәзер башка отрядлар белән кушылырга туры килә. Владимир Ильич Кызыл Армия төзергә куша. Кушылырдан әлек без регуляр армиягә кемнәрне алып баруыбызны анык белергә тиешлеме? Беләсең килсә, бүген шул сынау көне булды.

Паровоз кычкырта.

Кариб. Кушылырбызмы, юкмы, анысын әле кем белгән?!
Шамил. Кузгалабыз.

Чыгалар. Сәхи Садрыйны алып бара, Мәхмүт аларга каршы килә.

Сәхи. Нигә туктадың, атла!
Садрый (*Мәхмүткә*). Командир, ни гаебем бар иде минем?
Мәхмүт. Безнең ихтыяр белән эшләнмәде, дус кеше.
Сәхи. Тизрәк, тизрәк. Кузгалалар.
Садрый. Хәзер, хәзер...
Сәхи (*Мәхмүткә*). Иптәш командир, эшелон кузгала.
Мәхмүт. Ашыгыгыз, ашык.
Садрый. Хәзер, хәзер...

Иелә дә пычак алып Сәхигә кадый.

Мәхмүт. Син нишләдең, явыз!
Садрый. Поручик, Черноярны онытма.
Мәхмүт. Куркытма, бандит.
Садрый. Ансат кына котыла алмассың! (*Мәхмүткә барып ябыша*). Дутов җәнапләренең өченче поручениесе бар дидемме? Сезне алып

чыгарга тиеш идем мин, поручик. Курыкма, безнекеләр моннан дүрт-биш чакрымда гына.

Мәхмүт. Юк! Дутовның бер поручениесен дә үти алмадыгыз, капитан. Аклар станына кайтырга куркасызмы?

Садрый. Поручик! Черноярдан карательный экспедициядән кайткач язган рапортыгыз минем кесәдә. Сез лично дүрт большевикны...

Мәхмүт. Бүре сез, капитан!..

Садрый. Чапкын белән мин аны Шамил Усмановка җибәрә алам... Җүләр сатмагыз, поручик, без гомерлеккә бергә бәйләнгән! Әйдәгез!

Мәхмүт. Бәхил бул, Зәкиям!

Садрый. Дөньяда матурлар беткәнме, поручик?!

Вагоннар теркелдәп китеп баралар, кинәт Сәкинә тавышы яңгырый.

Сәкинә. Сәхине үтерделәр, Сәхине үтерделәр!

«Көзге ачы җилләрдә» көе яңгырый. Җыр көчәя, паровозлар туктаусыз кычкыралар.

Пәрдә

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Актүбәдә мәдрәсә бинасы. Хәзер монда татар батальонының штабы. Пәрдә ачылганда Сәкинә бүлмә җыештырып йөри. Аяк очларына гына басып Каюм керә. Кулында гармун. Бер почмакта песи булып кына утыра да уйный. Сәкинә елый.

Каюм. Синең күңелне юатыйм дип уйнаган булам тагын...

Сәкинә. Сәхинең югалуына да ике атна узды бит, Каюм...

Каюм. Әйе... Актүбәгә килгәнгә дә ун көн...

Сәкинә. Нигә шул чакларда вагоннан сикереп төшмәдем икән дип өзгәләнәм... Әгәр мин җирдә ятып калсам, ул ике уйлап та тормас, сикерер иде...

Каюм. Хәлләр булган анда, чуалчык хәлләр... Теге, бездән аерылган, Ташкентлы хөрәсәннәр шунда урала... Ала күз Садрый шунда. Рабочий булмады ул!.. Җитмәсә Мәхмүт абый... Үзе дә бик шикле кеше.

Сәкинә. Зәкия апа шул Мәхмүтне ничек ярата ала икән?

Каюм. Аптыраган инде... Комиссарны кире кагып, шул селәгәй офицерны... *(Тынлык. Каюм гармун уйный.)* Юк, Сәкинә, Сәхи исән булса, әсир төшә торган егет түгел ул.

Уйный. Сәгъдетдин керә.

Сәгъдетдин. Кызлар ничек чыдый синә, Каюм?.. Без картларның да үзәккәен өзәсең.

Сәкинә. Бу заман кызларның үзәкләре күптән өзелеп беткән, Сәгъдетдин абзый. Ак казаклар күпме яшь гомерләрне кыймаган?

Сәгъдетдин. Каюм, нәнкәем, миңа Шамил кирәк иде бит.

Каюм. Таңнан мадьяр, немец командирлары белән сөйләшеп утыралар.

Сәгъдетдин. Немец белән диген, һе... Әллә кайлардан килеп революция ясап йөриләр диген...

Каюм. Немецларның да төрлесе бар. Бар эшчесе, бар буржуе... Сиңа үз ишең немец ярлысы якынракмы, әллә алтын погонлы татар офицерымы? Моны да бик аңларга вакыт.

Сәкинә. Йомыш тапкан булып көн дә комиссар янына килә башладың әле, Сәгъдетдин абзый.

Сәгъдетдин. Бүген ни бит, теге, гает көн

Каюм. Комиссарны намазга өндәп килгән!

Сәгъдетдин. Монда гына җыелып укыр идек. Актүбә мулласы ...ннен яртеп тегеләр белән качкан, нәләт... Тьфү-тьфү, әстәгефирулла, ...а ни әйтеп салырсың... Елга бер килә торган бәйрәм ул, Каюм нәнкәм. ...селман гаскәре ич без!

Каюм *(фуражкасын алдын артка әйләндереп кия).* Бисмиллаһи ...ман рәхим... Купты, купты, яр башында очты... Авызы бияләй, боры- бармакча... Акча, акча! Я, суз тизрәк сәдаканны. Урының җәннәттә, ...ланыкы тәрәттә... Доганын, гаетнең иң шифалысын укып бирәм. Суз, ...акчаңны, чыгар янчыгыңны!

Сәгъдетдин. Син, Каюм нәнкәм, бала гына ич әле.

Каюм. Ә комиссар?

Сәгъдетдин. Комиссар — егет. *(Чыга.)*

Каюм. Әйтә бу карт! Нык әйтә!

Сәкинә. Солдатлар яткан бүлмәләрне әнкәй җыештыра. Штабка ...и үзем керәм. Шунда Шамил абый очрар да берәр сүз әйтер төсле.

Каюм. Их, Сәкинә! Комиссар егет шул!.. Барыбыз да аңа киләбез...

Кыз янына баса, кыз башын аның иңенә сала. Борчылган Зәкия керә.

Зәкия. Сәкинә!

Сәкинә. Әү, Зәкия апа.

Зәкия. Сырпаланма егетләргә. Синең Сәхиең бар. Онытма.

Каюм. Зәкия апа, Сәкинә арып кына башын салды ич.

Зәкия. Берничек тә ярамый... Кем генә булмасын,ниләр генә кү- ...ргә язмасын, начармы-яхшымы, турылык белән үзенекен көтсен.

Сәкинә. Исән генә булсын берүк, кайтсын гына...

Зәкия. Кайтамы, юкмы, барыбер көт.

Сәкинә. Иөз ел юлдан күземне алмам төсле... *(Чыга.)*

Каюм. Кыз баланы юкка рәнҗеттегез, Зәкия апа.

Зәкия. Кыз түзәр дә... Егет халкы әрсезрәк. Гармуныңны акырта- ...ң да аның янына киләсең.

Каюм. Дуслар ич без аның белән... Үзегез дә комиссар янына тая- ...ш ял итәр кеше эзләп килмәдегезмени?

Зәкия. Юк! *(Пауза.)* Минә анысы юк, Каюм.

...та. Гармун уйнап Каюм да чыгып китә. Хәйрүш, Таҗетдин, берничә гвардеец керәләр. ...ннәр сизелерлек үзгәргән, кораллар да башкачарак. Арвда билләрен патрон лента- лары белән ураган солдатлар да бар.

Хәйрүш. Кайтмаган комиссар...

Таҗетдин. Комиссар каршы килмәс, командир гына, белмим...

Хәйрүш. Каршы киләме соң? Ул үзе дә шундый кинәтлекне ...ата!

Берәү. Командир да ризалашыр. Тәмәке югын белә бит. Берәр ...ындагы станицага һөҗүм итеп аласы иде.

Таҗетдин. Киемнәре безгә күчеп бара. *(Өс-башын күрсәтә.)* ...глийский сукно!

Икенче *(чабатасына ишарәләп).* Мин генә һаман Хәйрүш агай илә- белән йөрим.

Хәйрүш. Синең алып аяк булуыңа кем гаепле?

Икенче. Әле дә ярый ике пар әләктереп калганмын.

Хәйрүш. Синең ике аягыңа ике бишек кирәк. Ак казакка каян кил- ...н андый итек?

Таҗетдин. Моннан болай син аклар арасыннан иң-иң эреләрен ...лап ат. Чуртаннарын. Югыйсә, кышны ялан аяк чыгарсың.

Хәйрүш. Аларда бар! Бөтен дөнья буржуйлары җибәреп тора!

Сәгъдетдин керә.

Сәгъдетдин. Бүген ни, гает көн бит, оланнар. Ни әйтсән дә, мөселман батальоны.
Берәү. Юк белән йөрмә әле, абзый.
Икенче. Әйт, мәрхәмәтле аллаң тәмәке табып бирә аламы? Бирә, ягъни мәсәлән, гаеткә барам.
Сәгъдетдин. Мартукка барып гает укып кайтабызмы әллә?
Хәйрүш. Барып кара, Мартуктагы аклар арт сабагыңны укытып җибәрерләр.
Таҗетдин. Тәмәке бетте әле, Сәгъдетдин абзый, интегәбез.
Берәү. Вәт Мартукта тарталар инде ул тәмәкене!

Көлешәләр. Сәгъдетдин күңелсез генә чыгып китә. Мадьяр солдаты Лайош керә.

Лайош. Мөселман иптәшләр, мадьяр-татар — дус. Мадьяр-татар революция! Интернациональ! *(Күкрәгенә кулын куеп күрсәтә.)* Тәмәке суыртыгыз, кардәшләр. Мадьяр үлә, ярамый. Мадьярны өйдә кыз көтә. Гүзәл кыз!

Барысы да ашыгып-ашыгып янчыкларын чыгаралар, кесә актаралар.

Хәйрүш. Берәүдә дә калмаганмыни?
Таҗетдин. Лайошны буш җибәрергә ярамый.
Тавышлар:— Юк бит, карга чукыгыры!
— Биш төрерлеге җәл түгел.

Һәркем янчыгын Лайошның фуражкасына кага.

Лайош. О! Менә бу безнең батальонга бүләк! Рәхмәт! Мадьяр-татар — дус, интернациональ!
Тавышлар:— Интернациональ, Лайош туган!
— Шулай!
— Мировая революция.
— Акларны кырып кына бетерик, аннары кунакка йөрешербез.

Шул чак Шамил белән Кариб кайтып керәләр.

Хәйрүш. Смирно! *(Барысы да басалар.)*
Шамил. Утырыгыз, утыр. *(Лайошны күреп.)* Без анда батальоннарны берләштерү турында командирлары белән сөйләшеп утырабыз. алар бездән алданрак өлгергәннәр түгелме, Кариб?
Лайош. Мадьяр-татар — интернациональ, иптәш комиссар. Сугышта бергә пуф-муф, тәмәке уртак пыф-пыф!

Хәйрүшне кочаклап ала да командирларга честь биреп чыгып китә.

Хәйрүш. Киңәш бар иде, комиссар.
Таҗетдин. Тәмәке бетеп китте.
Хәйрүш. Аклар ягына тагын бер сәфәр ясап алыйк, дибез.
Таҗетдин. Рейд кебегрәк нәрсә булсын дибез...
Шамил. Сәфәрләр ошап китте тагын үзегезгә... Корал өчен сәфәр, кием өчен сәфәр... Уйлашырбыз! *(Гвардеецларны озата.)* Кариб, күңелле хәбәр ишетәсең киләме? Мадьяр отряды татар батальоны белән кушылырга ризалык бирде.
Кариб. Кая әле монда кушылу... Эшләр яман! Мин иптәш Коростылев янында булдым. Ашхабадта контрреволюция. Мәскәүдән приказ алынган: ике полкны шунда җибәрәләр.
Шамил. Ә Оренбург нишли?
Кариб. Әйтеп бетермәдем. Дутов Орскига каршы зур көч ташлаган. Бер полкны шунда озаталар.
Шамил. Ташкент тимер юлының әһәмияте бермә-бер арта...
Кариб. Мәскәүдә бунт. Сул эсерлар кораллы фетнә күтәргәннәр.

Шамил. Димәк, регуляр Кызыл Армия төзү турында Владимир льич үз вакытында карар биргән! Сигез яктан ташланган сигез башлы югә каршы без йодрык булып оешырга тиеш! Мадьярлар белән нәкъ әргәндә сөйләшкәнбез! Корал ягы гына... Фәкать корал гына... Төрк-аннан патроннар нигәдер килеп җитми...

Кариб. Ком чүлләре аша акрын адымлы дөяләрдә кичү җинел гелдер...

Шамил. Солдатларны хәзер үк җыябыз, аңлатабыз. Илдә, үзебез-ең арада ни барын белеп, әзер булып торсыннар.

Кариб. Чак кына сабыр итәбезме әллә?

Шамил. Нигәдер әйтеп бетермисең.

Кариб. Әйе шул, менә газета...

Шамил. Ә-ә, «Алга» дип аталса да артка сөйри торган, татар бур-уйлары, сәүдәгәрләре, ак гвардиячеләре газетасы. Каян кулга төшер-ең ул чүпне?

Кариб. Анда тагын сине телгә алганнар.

Шамил. Ачка койрык чәнчеп чаба дигәннәрме? Чабаталы ба-льоныи бетләр кимерә дигәннәрме?

Кариб *(борчулы)*. Бу юлы яңачарак. Мә, укы... *(Шамил ала.)* Сөй-н кызы өчен ак шпион Садрый Вәһаповны һәм хыянәтче поручик рманаевны Дутов җәнапларь янына хәвеф-хәтәрсез генә озатып калды. ганнәр.

Шамил. Кабахәтләр, төрле яктан капшаналар.

Кариб. Капшана торгач, шактый нечкә җирне эзләп тапканнар.

Шамил. Син шушы газетага ышанасыңмы әллә?

Кариб. Газетаны миңа Зәкия бирде, аны гвардеецлар да укыган. ни кергәндә бәхәсләшеп яталар иде... Димәк, кемдер аны безнең итальонга житкергән!.. Син кара, зинһар, Зәкия белән ягымлырак бул...

Шамил. Кинаялар белән сөйлисең, Кариб... Кисәтәсең... Кемдер ушы эшкә, кара ялганга ышангандыр, мөгаен...

Кариб. Анысы ук булмас! Шулай да бу хәбәр җайсыз вакытта ки-лп ирешге.

Газетаны ерта-ерта чыга. Каюм керә.

Каюм. Шамил абый, сине Зәкия апа сорап кергән иде.

Шамил. Беләм! Мәскәүнең үзендә фетнә!.. Ашхабадта контррево-люция... Орскига ак бандитлар һөҗүм итә... Киләсе корал кайдадыр әле... Шундый чакта Шамил Усмановның мәхәббәт мажаралары... Юк, юк юк!

Сәгъдетдин керә.

Сәгъдетдин. Исәнме, Шамил улым. Иптәш комиссар.

Шамил. Уз, Сәгъдетдин абзый, утыр.

Сәгъдетдин. Вакытсызрак кердем дип әйтимме?

Шамил. Юк, юк, зарар юк.

Каюм. Мин монда гына, Шамил абый. *(Чыга.)*

Шамил. Солдат тормышына күнегәсеңме, Сәгъдетдин абзый?

Сәгъдетдин. Хәлләр ярыйсы. Өйрәнәм. Мылтык та җиңеләйгән кебек булды. Бомбасына да күнегәм. Шулай да чалгы сабы сагындыра...

Шамил. Өйрән, Сәгъдетдин абзыкаем, ух, ничек нык итеп өйрән!.. Әле шундый каты, аяусыз сугышлар булыр, ух, хәтта мин аны күз алды-на да китерә алмыйм. Моңарчы булган сугышлар балалар уены кебек улып калыр... Полклар, дивизияләр, Кызыл Армия!..

Сәгъдетдин. Мин ни... теге бит, бүген...

Шамил. Әйе, әйе, дөрес сөйлисең. Бүген, Сәгъдетдин абзый, бүген!.. Штаблар, тәҗрибәле командирлар... Корал! Болар барысы да булыр... Совет власте барын да булдырачак. Нәкъ менә бүген! Ул чагында

провокацияләр дә, почмактан торып чалуларга да урын калмас! Күзмә-күз, Кариб әйткәндәй, шашки во-он!

Сәгъдетдин. Ни инде... теге, кәләпүшне синдә калдырый дип кергән идем. Дөнья хәлен белеп булмый. *(Кәләпүшне чыгарып бирә.)*

Шамил. Ник алай уйладың әле? Үләргә җыенма. Рөхсәт юк. Ярамый. Беребезгә дә үләргә ярамый.

Сәгъдетдин. Синдә торуы хәерлерәк булыр.

Чыга. Шамил нервланып йөри, Зәкия керә.

Шамил. Зәкия туташ!

Зәкия. Исемем һаман үзгәрешсез, үзем тәмам коры сөяккә калдым.

Шамил. Әйе, сез үзгәрдегез.

Зәкия. Зәкия — революционерка, Зәкия — Акчуриннар фабрикасында большевиклар агитаторы, хәзер җылак кыз... Нишлим соң?

Шамил. Хәзер Зәкия — сугышчы!.. Мин дә элегрәк бер кулыма кылыч, икенчесенә чәчәк тотып йөри алырмын дип уйлый идем. Булмый, Зәкия туташ. Менә сез шуның мисалы! Кылычка да үреләсез, чәчәккә дә. Әгәр минем дүрт кулым булса, барысына да кылыч тотар идем.

Зәкия. Шамил! Батальонның хәрби белгече, командирның дусты эшелоннан калсын инде! Әкият бит бу!

Шамил. Монда мин гаепleme? Гомумән, мин сезне Мәхмүткә тыптыныч кына, сабыр күңел белән тапшырды дип уйлыйсызмы? Монда сугыш гаепле! Кулларым буш түгел, Зәкия туташ. Сез мәхәббәт телисез, ә мин сугыш...

Зәкия. Беләм, сез Мәхмүтне яратмыйсыз.

Шамил. Яратмыйм, Зәкия туташ.

Зәкия. Шуңа күрә аннан котылуны җиңел кичерәсез дә!

Каюм керә.

Каюм. Шамил абый, сине бер кеше сорый.

Шамил. Керсен соң.

Каюм чыга, өлкәнрәк солдат белән керә.

Солдат. Пластунский полкның өченче батальоны солдаты Хәсән Биктимиров булам. Вольный казак.

Шамил. Ни йомыш, вольный казак?

Хәсән. Гаепсез кешеләрне үтереп йөрисем килми.

Шамил. Хуш! Нинди ярдәм күрсәтә алам сиңа?

Хәсән. Сине дөреслек өчен көрәшәсең икән, дип ишеттек. Мин синең якта булырга телим.

Шамил. Бездә кәнфит суырырга туры килер дип ялгышмыйсыңмы? Канга кан дип көрәшәбез ич!

Хәсән. Дөреслек шуны сораса, мин әзер.

Зәкия. Шамил, бәлки ул Мәхмүт турында беләдер.

Хәсән. Белгәнне яшереп булмас, матур туташ, кирәген сөйләрбез.

Шамил. Кызыллар ягыннан чыккан Мәхмүт Урманаев дигән поручикны белмисезме?

Хәсән *(уйланып тора)*. Татар поручигын әйтәсезме? Нигә белмәскә беләм.

Зәкия. Ул хәзер исәнме?

Хәсән. Исән. Әсир дип әйтимме, болай гына йөридерме, капитан әфәнде белән гел бергә алар. Миннән Мартукта калдылар.

Зәкия. Аны әсир иткәннәр!

Шамил. Әсирләр арасында Сәхи Таһиров дигән егет күренмәдеме? Ишетәсеңме, вольный казак, Сәхи Таһиров!

Хәсән. Әсирләрне атып торалар... Күрмәгәнне күрдем дип әйтә алмыйм.

Шамил. Каюм, абзыйны урнаштыр. Ял итсен. Аннан сөйләшербез. зең монда кил!

Хәсән. Рәхмәт, комиссар туган, ышандың. Безнең гәҗитәләр юкка ына көчәнмиләр икән, егет икәнсең! *(Чыгалар.)*

Зәкия. Шамил, ул һаман исән! Тик сез... Мәхмүтне кызыллар гыннан чыккан дип нигә әйттегез?

Шамил. Үзем дә белмим.

Зәкия *(тагы да ярсып)*. Әгәр мине элекке кебек яратсагыз, котка- ргыз Мәхмүтне. Үтенәм, ялварып сорыйм.

Шамил. Сез миннән булдыра алмастайны сорыйсыз.

Зәкия. Аклар тылына ничә кат куркынычлы рейдлар ясадыгыз. агын бер тапкыр!.. Сез аны ике тапкыр үлемнән коткардыгыз. Өч бул- ын! Мин ике кулыма да кылыч тота алмыйм, Шамил, аңлагыз...

Шамил. Мәскәүдә фетнә... Ашхабадта контрреволюция... Орск хәл чендә!..

Зәкия. Ә мин гап-гади хатын кыз, Шамил!

Шамил. Моны мин үзем генә хәл итә алмыйм!

Зәкия. Ә газета?..

Шамил. Газета?.. Яхшы!

Каюм керә.

Каюм. Мин килдем, комиссар.

Шамил. Килдең.

Каюм. Мин әзер, комиссар.

Шамил. Каюм! Мине монда озатканда Куйбышев, Валериан Вла- димирович, «үзеңнең һәр адымың, һәр эшең белән большевик-револю- ционерның кем икәнлеген күрсәт», диде.

Каюм. Күрәбез, комиссар, шикләнмә.

Шамил. Әгәр кем дә булса берәү минем чынлыгыма шикләнсә?

Каюм. Ул бәндәне юк итәргә кирәк. Ул хыянәтче.

Шамил. Әгәр икәү шикләнсә, өчәү?.. Монда пуля гына хәл итә алмас. Акыл кирәк монда, кыюлык, зирәклек...

Каюм. Без әзер, комиссар!

Шамил. Бар, Хәйрүш агайны, Садыйкны, Фәхрине чакыр. Сөйләш. Әзерләнегез. Без митингка кадәр әйләнеп кайтырга тиеш. Үз тирәмдәге шикнең тамыр җәюенә ирек бирмәм.

Зәкия. Шамил!

Каюм. Без әзер, Шамил абый. Кая барабыз?

Шамил. Дошманның иң-иң хәтәр өненә!

Пәрдә

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мартук станицасы. Мәчет белән янәшә мулла йорты. Мәчет алдында ике бай тора. Аның берсе Сары бай. Ара-тирә кораллы дутовчылар үтеп китә.

Сары бай. Чехлар теге явызларның иманнарын укыталар, ди.

Кара бай. Инде кем сүзенә ышанырга да белмәссең. Бәлшәвик- ләр тамамысы бетте дип кайтып кына сөйлиләр, ә алар әле Яйсанга ки- леп чыгалар, әле Каратүбәгә һөҗүм ясаганнар. Теге, Актүбәдә, шул бәлшәвикләрнең җаннары мордар киткән мөселманнары ята, ди.

Сары бай. Син азрак гәҗитәгә күз салмыйсыңмыни? Беткәннәр алар, беткәннәр! Алла боерса, чехлар бүген-иртәгә Мәскәүне алырга торалар, ди.

Кара бай. Бирсен ходай, бәрәкалла! Шулайлар була күрсен. Югыйсә дөньяның астын-өскә әйләндерделәр, кяферләр. Матур гына барган тормышның яме китте. Иләнмәгән биш йөз тирем ята.

С а р ы  б а й. Аллаһе боерса, мин дә озакламый Ырынбурга кайтам. Таш кибетемне бикләп киттем бит, бикләп...

К а р а  б а й. Аны сорармын дигән идем, чын булса, синең улың Сәхиулла да шул Мәскәү кяферләренә ияргән, диләр.

С а р ы  б а й. Иярде, кода, иярде. Тик башы беткәндер инде. Дутов җәнаплары кырды инде бәлшәвикне, бик кырды.

Чыгып китәләр. Атыш тавышлары ишетелә. Мәчеттән яшел чапанлы мулла килеп чыга. Сәгъдетдин аңа каршы бара.

С ә г ъ д е т д и н *(йомшак тавыш белән)*. Ни ашыктым инде, барыбер соңга калдым... Әссәләмәгаләйкем, хәзрәт, гает шәрифләрегез мөбәрәк булсын.

М у л л а *(үз алдындагы гаскәри киемле кешене күреп, сискәнеп китә)*. Вәгаләйкем, энем. Син нинди кеше? Нишләп йөрисең? Кем ягыннан? Үзебезнекеләрдәнме, тегеләрдәнме, ягъни?

С ә г ъ д е т д и н. Үзебезнекеләрдән, хәзрәт, Кызыл Армиядән. Сезне гает мөбәрәк белән котлап, фатыйхагызны алырга килгән идем.

М у л л а. Алай икән, алай икән...

Ат чабып килгән тавышлар ишетелә, атлар туктый, хәзрәт тиз генә капкадан кереп китмәкче була.

С ә г ъ д е т д и н. Хәзрәтем, җаным, казаклар килә! Коткара күр, тотсалар харап итәләр.

Капкага кереп китәргә тырыша, хәзрәт җибәрми. Ниһаять, керә, капка ябыла. Беренче казак йөгереп керә.

К а з а к. Мулла ич!

М у л л а. Кто там?

К а з а к. Без, казаклар. Ач.

Мулла ача, капка төбендә тора.

К а з а к. Мулла, синдә большевиклар яшеренгән диләр, чыгар үзләрен!

М у л л а. Миндә беркем дә юк, яй-богу, валлаһи-таллаһи, юк.

К а з а к. Керде бит, үзебез күреп тордык. Станицага унлап большевик үтеп кергән, шуларның берсе синдә.

И к е н ч е  к а з а к. Алдалашма, мулла.

М у л л а. Правда, юк, господа, яй-богу, юк.

К а з а к. Тентегез бөтен йортны.

Мулланы бер якка селтәп кереп китәләр. Сары бай күренә. Ул капка төбендә калган казакка эндәшә.

С а р ы  б а й. Шунда, шунда. Үз күзем белән күрдем. *(Югала, мулла чыга.)*

М у л л а. Бетерде башымны теге явыз! Указ, йорт-җир эрәм китте, эх!

Казаклар Сәгъдетдинне алып чыгалар.

С ә г ъ д е т д и н. Имею честь представиться, сверхсрочной службы рядовой 121 го батальона Сәгъдетдин Фәсхетдинов. Кызыллар тарафыннан көчләп мобилизовать ителгән.

К а з а к. Хәзер карарбыз. Ну-ка, тентегез. *(Тентиләр, кәгазь тартып чыгаралар.)* Бу нәрсә? Карап карыйк. Әһә, удостоверение. «Мөселман отрядының күңеллесе Сәгъдетдин...»

С ә г ъ д е т д и н. Хәйлә генә ул, гаспадин хороший. Мин кызылларның серләрен алып йөрүче, мулланың якын кардәше.

К а з а к. Мулла, дөрес сөйлиме бу?

Мулла. Юкны сөйли, убыр, кяфер, жен! Сафсата! Кызыллар арасында бер генә кардәшем дә юк.

Казак. Я, ничек, картлач?

Мулла. Ул мине таларга килгән угры!

Сәгъдетдин. Назад! *(Бомбасын күтәрә.)* Назад! *(Казаклар һәм мулла куркышып өелешәләр.)* Юк, кулым күтәрелми... Дошманны үтерәм дип хәзрәтнең, изге кешенең җанын кыям. Хәзрәт, әйт, туганың ич минем!

Мулла. Әстәгефирулла тәүбә, түгел, туганым түгел!

Казаклар Сәгъдетдинне эләктереп алалар, бомбасын йолкып үзен бер читкә сөйриләр.

Сәгъдетдин. Хәзрәт, гомерем буе михрап алдындагы кешене олуглап килдем. Башкалар сезне сүккәндә якладым. Сезнең чапан өстындагы кара җаныгызны күрмәдем. Хәзрәт, җанымны кыйганга шатланма, минем канымны иптәшләрем болай калдырмаслар.

Урамнан капитан формасында Садрый, Мәхмүт һәм ике ханым керәләр, барысы да кызмача.

Садрый. Әфәнделәр, ышаныгыз, дөньяның кучәре безнең кулда!

Кара чәчле ханым. О, нәрсә бу?

Мәхмүт. Туктагыз.

Садрый. Ба-а, кемне күрәм? Иске таныш. Сәгъдетдин карт. Кызыл армиянең иң батыр солдаты. Каһарман! Хөрмәтле ханымнар, таныш булыгыз: бу мужик кызыл гаскәрнең иң батыр солдаты.

Сәгъдетдин. Ә син койрык болгап йөрүче әнчек. Ике яклы күгәргән пычак.

Садрый. Браво, Сәгъдетдин карт!

Сары чәчле ханым. Капитан, сез юмористлыгыгызны һаман ташламыйсыз.

Мәхмүт. Ничек килеп чыктың син монда?

Сәгъдетдин. Бүген ни бит, ураза гаете... Бәйрәм... Без мөселманнар, ни инде, теге...

Казак. Безне шартлата язды, капитан әфәнде. Алар күбәү әле, дозорлар күреп калган.

Садрый. Как? Станицада большевиклармы?

Кара чәчле ханым. Әнекәй генәм!

Казак. Тыныч булыгыз, ваше благородие, хәзер аулап бетерәбез без аларны.

Сары чәчле ханым. Әгәр аларның иң батыр солдатлары шушындый булса...

Садрый. О, аларның комиссарларын күрсәгез иде! Борыныннан юеше килеп торган малай.

Сәгъдетдин. Шул малай алдында меңәрләгән гаскәрегез дер калтырап тора.

Кара чәчле ханым. О!

Казак. Телеңә салынма! Иптәшләрең кайда?

Сары чәчле ханым. Большевикны якыннан беренче күрәм.

Мәхмүт. Капитан әфәнде, намазга килгән карт, әйтегез, атмасыннар.

Садрый. Юк, поручик, мин синең сыман икеләнеп яшәргә җыенмыйм. Минем өчен киләчәк юл ачык. Эш җиңеләер, бере кими торсын. *(Казакларга ымлый.)*

Казак. Кайда иптәшләрең, карт җүләр?

Сәгъдетдин. Большевик иптәшләрен сатмый.

Кара чәчле ханым. О! Капитан әфәнде, ә комиссарны безгә кайчан күрсәтәсез?

С а д р ы й. Бәйләп шушы мәйданда аяк очыгызга салачакмын. Алыгыз, җанын җәһәннәмдә көтәләр!

К а з а к. Мулла, моннан соң алдашып маташма.

М у л л а. Юк, юк, господин казак.

Казаклар Сәгъдетдинне шунда ук диярлек аталар.

С а р ы ч ә ч л е х а н ы м. Фу, ераккарак алып китә алмаганнар.

М ә х м ү т. Картны юкка аттырдыгыз, капитан. Юкка...

С а д р ы й. Бала булмагыз, поручик.

С а р ы ч ә ч л е х а н ы м. Комиссарны эләктергәч, безгә күрсәтми калмагыз.

С а д р ы й. О! *(Сары бай күренә.)*

С а р ы б а й. Большевикны каптырдыгызмы?

С а д р ы й. Рәхмәт сиңа.

Мәчет ихатасы ягыннан картларча киенгән биш-алты кеше күренә. Алар мәйданчыкны урап алалар. Кинәт берсе киемен салып ыргыта. Бу — Шамил.

Ш а м и л *(көр тавыш белән)*. Урыннардан кузгалмаска!

Аның бер кулында бомба, икенчесендә наган. Башкалар да чапаннарын салып ыргыталар. Бу Хәйрүш, Каюм, гвардеецлар.

М ә х м ү т. Шамил, комиссар!

Х а н ы м н а р *(чырылдыйлар)*. Комиссар?!

Ш а м и л. Ханымнар, тынычыз. Каюм, иң элек капитанны. Сары бай да монда икән.

С а р ы б а й. Минем монда бер гаебем дә юк, мин, мин...

К а ю м. Сәхи кайда? Нишләттегез аны, явызлар?

Ш а м и л. Ә сезгә, Мәхмүт әфәнде, безнең белән китәргә туры килер.

Садрый юаш кына торган җиреннән кинәт хәрәкәт ясап, эчке кесәсеннән наган тартып чыгара, Каюм аны бәреп төшерә.

К а ю м. Шаярма, «рабочий» әфәнде, әйт, Сәхи кайда?

С а д р ы й. Күрмәдем.

М ә х м ү т. Юк Сәхи... Юк!

Х ә й р ү ш. Шамил малакаем, комиссар, алар монда Сәгъдетдинне үтереп ташлаганнар.

Ш а м и л. Ничек?!

Х ә й р ү ш. Гает бит бүген, мәчеткә барам дигән иде.

С а д р ы й *(Сары байны күрсәтеп)*. Менә кем тотып бирде аны.

С а р ы б а й. Минем һич гаебем юк, мин кызылларны яратам, минем үз улым красный гвардин...

Ш а м и л. Бандитлар! *(Картның гәүдәсен карый.)* Сәгъдеттин абзый өчен менә боларны! *(Сары байны һәм Садрыйны күрсәтә)*.

С а д р ы й. Сез чолганышта. Дозорлар хәзер килеп җитә.

К а ю м. Әйдә, тарттыр, тарттыр!

С а д р ы й. Комиссар әфәнде!

Ш а м и л. Юк!

М ә х м ү т. Мине дә, комиссар.

Ш а м и л. Тынычлык саклагыз.

М ә х м ү т. Сезнең сабырлык мине җенләндерә! Атыгыз мине дә! Сезне дә, үземне дә күрә алмыйм!

Ш а м и л. Сезнең яшәү-яшәмәвегезне мин хәл итмим.

М ә х м ү т. Атыгыз мине дә!

Якында гына мылтык тавышлары. Каюм, Хәйрүш борылып керәләр.

К а ю м. Булды!

Шамил. Сәгъдетдин абзыйны алыгыз. Мәхмүт әфәнде, хыянәтче булу өстенә куркак та булмагыз инде!

Ашыгып чыгып китәләр. Ханымнар чыр-чу килеп кычкыралар. Баягы казак керә.

Ханымнар. Тотыгыз, тот, комиссар!
Казак. Боже мой?! Ни булды!
Кара чәчле ханым. Капитанны үтерделәр.

Чыгып йөгерә, атыш тавышлары.

Казак. Минем арттан марш!
Сары чәчле ханым. Тотарсың аларны хәзер!
Кара чәчле ханым. Ә комиссар нинди симпатичный егет!
Сары чәчле ханым. Бәркет! Юкка большевиклар арасына китмәгәнбез!..

Пәрдә



## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Актүбәдә мәдрәсә яны. Кызыл байрак элгенгән. Монда татар батальоны урнашкан. Лазарет. Лазареттан ерак та түгел дала башлана. Дала ягында бер төркем гвардеецлар басып торалар. Мылтыклардан залп бирәләр дә акрын гына таралышалар. Шамил төркемнән аерылып алгы планга килә. Мадьяр отряды командиры Белевич керә.

Белевич. Татар батальоны кемне күмде, иптәш комиссар?
Шамил. Татар батальоны комиссар Шамил Усмановны күмде.
Белевич. Җитди сорауга шаяртып җавап бирдегез, иптәш Усманов.
Шамил. Шаярту гына булса икән, иптәш Белевич!.. Гәрчә без үзебезнең иң батыр солдатларыбыз Каюм белән Сәгъдетдин абзыйны күмдек.
Белевич. Мартукка бик хәтәр рейд ясагансыз дип ишетелгән иде.
Шамил. Ләкин ни бәрабәренә һәм ни өчен?!. Ашхабадта контрреволюция...
Белевич. Мәскәүдә сул эсерлар фетнәсе... Орскида Дутов котырына!
Шамил. Әйе...
Белевич. Отряд командирларын штабка чакырдылар. Иптәш Коростылев үзе булачак. Берләшү мәсьәләсен анда сөйләшәбез дә батальоннардан вәкилләр җыярбыз.
Шамил. Ашыгырга кирәк безгә, Белевич туган! Татар батальоны кушылырга каршы килмәс дип уйлыйм.
Белевич. Димәк, бергә-бергә?
Шамил. Бергә-бергә, иптәш Белевич.

Белевич чыга. Кариб керә.

Кариб. Кем килеп китте ул?
Шамил. Инде минем янга килеп китүчеләр дә синдә шик тудырамыни, командир?
Кариб. Акыл белән түгел, ачу белән сөйләшәсең.
Шамил. Белевич ул, мадьяр отряды командиры.
Кариб. Һаман бер балык башын чәйниме?
Шамил. Ул мәсьәләне хәл ителгән дип саныйм.
Кариб. Ашыкмый тор! Сиңа ашыгырга гына булсын. Уңын-сулын уйлап тормыйсың кайчак, Шамил.
Шамил. Гомуми хәрәкәткә каршы баруның зарарлы булуы бар.
Кариб. Җайсыз көнне кушылырга өндисең!.. Кыз өчен батальонның иң яхшы егетен әрәм иттең!.. Мондый хәлдә кушылуны кирәкле сана-

мыйм. Мадьярлар да, башкалар да безгә кырын карарлар. Үзебез дә әйбәт сугышабыз ич!

Шамил. Үзем кылган эшләр өчен макталырга да, әр сүзләре ишетергә дә әзер. Мин гомергә комиссар булып тумаган!

Чыга. Кариб янына Мәхмүт килә.

Кариб. Дусларны соңгы юлга озаттык, нигә күренмәдең, Мәхмүт?

Мәхмүт. Мине берәү дә чакырмады.

Кариб. Син чакырган җиргә генә барасыңмы?.. Аңла, синең өчен мин җавап бирәм! Батальонга хәрби белгеч итеп сине мин тәкъдим иттем.

Мәхмүт. Анысы өчен рәхмәт, Кариб.

Кариб. Кайларда булдың, ниләр эшләдең? Нигә качып чыкмадың?

Мәхмүт. Җибәрмәделәр. Әсир итеп сакладылар.

Кариб. Бүген трибуналдан килергә тиешләр.

Мәхмүт. Аларның татар батальонында ни катнашы бар? Без бит аерым, мөселман гаскәре! Син аның бердәнбер командиры!

Кариб. Батальон... Бүген безне кушалар. Интернациональ полк төзелә. Анда инде командирлар күп булачак. Трибунал да якын.

Мәхмүт. Алар мине әсир иттеләр!

Кариб. Әсирләрне аталар! Нигә сине атмадылар? Ник исән калдың?

Мәхмүт. Бу хатаны да мин ясамадым! Кариб, нигә кушылырга кирәк безгә?

Кариб. Нигәме? Кушылырга Ленин куша! Владимир Ильич!

Чыгып китә. Мәхмүт гасабиланып йөри, Зәкия үтеп бара.

Мәхмүт. Зәкия туташ, Зәкия туташ!

Зәкия. Ә? Кулыгызда нәрсә?

Мәхмүт. Кулларым буш.

Зәкия. Әнә, Шамил Усманов, дүрт кулым булса, дүртесенә дә кылыч алыр идем, ди.

Мәхмүт. Мактанчык!

Зәкия. Кем?

Мәхмүт. Шамил Усманов. Карап карарбыз, хәзер нәрсә тоттырырлар икән кулына.

Зәкия. Тавышыгызда явыз тантана ишетәм.

Мәхмүт. Бүген батальон полк составына керә. Күп сугыш юллары үткән немец, мадьяр отрядлары белән аралаша. Әле аерым чакта буш авантюралар остасы Усманов комиссар булып йөри ала иде. Регуляр гаскәрдә, чибәркәем, калай этәчләргә урын юк.

Зәкия. Әй, сез, поручик!

Мәхмүт. Нишлисең, анысы да мин...

Зәкия. Мин сезне фабрикант Акчуриннар өендә беренче тапкыр күрдем... Сез ярым асрау, ярым ятимә кызны тиң санап сүз каттыгыз. Күңелем эреп китте... Хәер, нигә боларны хәтерләп торырга!

Мәхмүт. Киләчәккә карыйк... Сугыш тиздән бетәр... Безгә җайлы вакыт табып моннан китәргә генә кирәк.

Зәкия. Кайчан инде ул җайлы вакыт?

Мәхмүт. Бүген, Зәкия туташ. Кыргыз далаларына китик! Бу ыгы-зыгылардан, мәхшәрдән күңел катты...

Зәкия. Әй, сез... Сезне аклардан йолып алуны Шамилдән мин сорадым. Тагын бер кат йөзегезгә карыйсым килде... Нинди куркак, җебегән бәндә өчен күз яшьләре түккәнмен бит!

Хәйрүш белән бернича гвардеец үтеп баралар.

Хәйрүш. Ничек батальон бетсен ди? Аны кем бетерә алсын?

Зәкия. Хәйрүш агай, комиссарга нәрсә булыр?
Бер гвардеец. Комиссар гаепле, туташ.
Икенче. Яшь тай кебек ярсу, тәртәне сындыра...
Өченче. Тыеп кала алмадык...
Хәйрүш. Дүрт аяклы ат та абына. Аңа карап кына атның аягын кисмиләр. Күпер саклаганда ниләр булмады? Онытмагансыздыр әле, батальон сарык көтүе кебек тилереп кача башлады. Ә комиссар нишләде?.. Теге юньсезләр бакыр бугазларын киереп «Төркстанга китәбез» дип дөнья сасытканда Шамил нинди зирәклек күрсәтте. Хәзер дә хата түгел, батырлык кылды!
Бер гвардеец. Барыгызны да аклар әсир итсә?
Хәйрүш. Әсир төшмәдек бит! Егетлеге дә шунда инде аның!
Зәкия. Дөрес, Хәйрүш агай! Комиссарга куләгә төшертмәскә кирәк!.. Әйдәгез! *(Чыгалар.)*
Мәхмүт. Зәкия туташ!
Зәкия. Ә сез теләсәгез нишләгез! Мин сезне сөймим!

Чыга. Шамил керә.

Мәхмүт. Нигә мине алып кайттыгыз? Нигә шунда атып калдырмадыгыз? Хурлар, түбәнсетер өченме? Трибуналга тапшырыр өченме?
Шамил. Һәркем үзе кылган эшләр өчен җавап бирә белсен!
Мәхмүт. Ах, алаймы?.. Китим дигән идем, калам! Бүген Зәкия туташ кына түгел, татар батальонының бар солдатлары сезнең гап-гади бер авантюрист икәнлегегезне күрерләр.
Шамил. Вакыт бар, сөйләп калыгыз.
Мәхмүт. Сез мине коткарган булып яхшы ат казандыгыз, тик сезне бербү дә йолып алмас. Кояшың баеды, Шамил Усманов!

Чыгып китәләр. Хәйрүш белән Лайош керәләр.

Лайош. Сез аклар тылына тагын рейд ясагансыз икән?
Хәйрүш. Комиссар оештырды.
Лайош. Шамил Усманов! О, батыр, герой!.. Хәйрүшка тоже герой. Сугыш бетә, Лайош Венгриягә кайта. Хәйрүшка Венгриягә кунакка килә. О, Венгрия! О, Чардаш! Иштенем!
Хәйрүш. Аннары безнең авылга шулпалы бәлеш ашарга, «Әпипә»гә биергә.

Лайош кесәсеннән авыз гармуны чыгарып «Әпипә»не уйный.

Лайош. «Әпипә» әйбәт. Татарлар батыр. Бүген митинг. Мадьяр-татар-немец бер полк. Интернациональ!

Чыгып китәләр. Кариб белән Шамил килә. Таҗетдин керә.

Таҗетдин. Иптәш командир, батальон вәкилләре җыелды.
Кариб. Яхшы. Әнә, немец, мадьяр вәкилләре дә килә.

Белевич, Шамил, Кариб, башка командирлар күрешәләр. Батальоннардан вәкилләр керә тезелә.

Белевич. Башладык, иптәшләр. Комиссар, сезгә беренче сүз.
Кариб. Бәлки сез әйтерсез?
Белевич. Юк, юк. Шамил Усманов әйтсен!
Шамил. Иптәшләр! Сугышның беренче этабы — аерым-аерым отрядлар булып сугышу этабы тәмам. Владимир Ильич отрядларны берләштереп куәтле Кызыл Армия частьлары төзергә куша. Сугыш эшенә өйрәнгән, дисциплиналы регуляр гаскәр генә мәкерле дошманны тәмам җиңәчәк. Бу — көн кебек ачык.

Сафлар ур-ра кычкыралар. Бер кырыйга тезелгән немец, мадьяр, татар вәкилләре янына Мәхмүт тә килеп баса.

Оренбургны калдырып чыкканнан соң без байтак сугышларда катнаштык. Дошманны каршы алып та, оясына барып та тукмадык. Большевиклар партиясенең губерна комитеты татар, немец, мадьяр батальоннарын берләштереп Интернациональ полк төзергә тәкъдим итте. Сез ризамы, мадьяр иптәшләр?

М а д ь я р л а р. Риза!

Т а т а р л а р. Без дә риза.

Н е м е ц л а р. Риза, риза!

Ш а м и л. Хәзер без Интернациональ полкның командирын һәм комиссарын сайларга тиешбез.

Т а в ы ш л а р.— Ур-ра!

— Командир итеп Белевичны сайлыйбыз!

Ш а м и л. Командир итеп большевиклар партиясе члены Белевичны сайларга дигән сүз булды.

Т а в ы ш л а р.— Сайлыйбыз!

— Яхшы командир!

Б е л е в и ч. Рәхмәт, иптәшләр! Комиссар итеп кемне сайлыйбыз?

М ә х м ү т *(бер читкә)*. Һаман Шамил Усмановнымы?..

Л а й о ш. Комиссар итеп Шамил Усмановны сайлыйбыз!

Н е м е ц л а р. Шамил Усмановны!

Кинәт аткан тавыш яңгырый, Мәхмүт җиргә егыла.

Б е л е в и ч. Нәрсә булды?

Х ә й р у ш. Поручик Урманаев үзен-үзе атып үтерде.

Қ а р и б. Мәетне бер читкә алыгыз.

Б е л е в и ч. Татар батальоны нәрсә әйтә?

Т а т а р л а р. Шамил Усмановны сайлыйбыз!

Т а в ы ш л а р.— Ур-ра!

Сакчы керә.

С а к ч ы. Иптәш командир, Орск полкыннан элемтәче-разведчик килде.

Элемтәче керә.

Э л е м т ә ч е. Сезгә пакет, иптәш командир. *(Хатны Белевич ала.)*

Б е л е в и ч *(хатны укып)*. Интернациональ полк хәзер Орскига китә.

Э л е м т ә ч е. Орскидан безнең полк белән Оренбургка!

Ш а м и л. Оренбургка!.. Иптәшләр, дуслар!.. Без бик ерак юлларга бергә барасы кешеләр... Нык булыйк! Шулай башланды һәм мәңге туктамас безнең юллар!

Командирлар честь биреп бер кырыйга басалар, вәкилләр бер-бер артлы үтә, оркестр бөтен дөнья эшчеләре гимны Интернационал уйный.

Т а в ы ш л а р:— Даешь Оренбургны!

— Яшәсен Интернациональ полк!

— Яшәсен Ленин!

**Пәрдә төшә.**

**ТАҖИКСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ӘДӘБИ ЖУРНАЛЛАРЫ**




# БАЙ ДА, БӨЕК ТӘ, ТИРӘН ДӘ

Таҗикстанның җирле исеме — Кухистан. Бу — биек таулар иле дигән сүз. Өсләрендә мәңге эремәс бозлавыклар белән калын карлар яткан таулар монда, чыннан да, бик күп, чыннан да, бик биекләр. Беренче булып телгә алынырга тиешле Памир үзе генә дә ни тора! Андагы бер түбәнең биеклеге 7134 метр. Аны карталарга бөек Ленин исеме белән язалар. Шунда ук җиде чакрым ярым биеклектәге икенче түбә булуы да бөтен дөньяга билгеле. Шул ике гигант биеклеккә безнең кыю альпинистларыбыз Ватан байрагын һәм юлбашчыбыз сурәтен мендерганнәр! Тау сыртларының Алай, Төркстан, Зеравшан, Гиссар исемле тезмәләре дә Памирдан әллә ни кайтыш түгелләр...

Шул тауларда «Кояш кызы» булып туган гайрәтле һәм җитез сулар Аму-Дәрья һәм Сыр Дәрья, Вахш һәм Пяндҗ, Кафирниган һәм Мургаб елгаларында дулкынланып шаулыйлар. Алар көче белән Кайрак-Ком һәм Вахш (буасының биеклеге 100 катлы йорт чамасы!) электр станцияләре эшли. Шуларның Фәргано, Гиссар һәм Вахш исемле сугару каналлары буйлап аккан шифалы суларын эчеп, тау итәкләрендәге искиткеч уңдырышлы бакчаларда йөзем, өрек, шафталы җимешләре, яшелчә, мамык һәм чикләвек үсә. Куйлар, йон алыр өчен үрчетелгән ап-ак ангор кәҗәләре һәм каракүл тирелә сарыклар йөргән җәйләүләрдә хуш исле үләннәр дулкынлана.

Ул якларда булсагыз, киң күңелле һәм кунакчыл таҗиклар сезне атаклы Памир юлы буйлап тауларга менгереп, Каракүл, Яшелкүл, Искәндәркүл, Кырыкчишмә кебек гаҗәеп матур күлләргә алып барып, яшеллеккә һәм чәчәккә күмелгән шәһәрләрдә тукталып, сүзгә үзләренең ефәк фабрикаларын, трактор һәм электр детальләре заводларын, күмер шахталарын һәм нефть промыселларын күрсәтерләр. Алардан ишетеп

сез Таҗикстанда җир астыннан алтын, вольфрам, кургаш, цинк, сөрмә, терекөмеш, шпат, асбест, таш тозы һәм озокерит кебек кыйммәтле казылмалар алынганлыгын белерсез...

Кыскасы, бирегә бик күп нәрсә биек, бик күп нәрсә матур, бик күп нәрсә яңа һәм бик күп нәрсәнең тарихы бик тирәннән һәм борынгыдан килә. Алар сине кызыксындыралар һәм уйландыралар, сокландыралар һәм сөендерәләр.

Таҗикстанга безнең Язучылар оешмасыннан һәм әдәби журналдан дуслар тәҗрибәсен өйрәнү һәм әдәби әсәрләребез үрнәкләрен алмашу өчен барган (апрель, 1970 ел) бер вәкил буларак, мин, болардан тыш, әлбәттә, барыннан да күбрәк һәм тирәнрәк итеп таҗикларның әдәби тарихы белән һәм бүгенге әдәбияты белән кызыксындым.

Билгеле булганча, тау халыклары тарафыннан тар-мар ителгән гарәп гаскәр башлыкларыннан көлеп, урта гасырларда ук таҗиклар иҗат иткән фольклор әсәрләр бар. Халыкта әкиятләр, бик кечкенә күләмле сатирик хикәяләр (латифәләр) борын-борыннан сөйләнеп килә һәм монголлар һөҗүменә каршы «Гургули» дигән эпос туа. Хәзерге таҗикларның борынгы бабалары иран телендә иҗат иткән язма әдәби һәйкәлләр аз түгел. Мәсәлән: Авестадан «Гаты» — җырулар һәм «Яшты» — гимннар, «Сирия агачы», «Ядгари Зареран», «Кояшка һәм айга гимн». Аннары XI гасырның романтик поэма авторларыннан Унсури, Аюки һәм Гургонилар иҗаты билгеле. Шулардан соң инде Урта Азиядә һәм Хорасанда фарсилар, дарилар һәм таҗикларга уртак телдә XV гасырга кадәр иҗат иткән Рудаки, Фирдәүси, Әбүгалисина, Хайям, Хисроу, Руми, Саади, Закани, Хафиз, Җами кебек фарсы һәм таҗик әдәбияты классикларын әйтеп үтәргә кирәк. Соңрак гасырларда изүләргә һәм җәберләүләргә каршы Румони әсәрләре, дехканнар восстаниесен тасвирлап «Восе турында җыр», эмигрантлар белән ялчыларның җырлар җыелмасы «Гариби» һәм, ниһаять, пролетар рухлы «Тукучылар җыры» язылa.

Совет чорында яңа халык җырчылары (хафизлар) һәм халык шагыйрьләренең дастаннары, газәлләре һәм робагыйлары туа башлый. Ә бүгенге таҗик поэзиясе һәм прозасында исә Айнилар һәм Лахутилардан соңгы яңадан яңа буын шагыйрьләр һәм әдипләр мәйданга чыга. Алар бай мирас, зур традицияләр җирлегендә яңача эзләнеп, ачышлар ясап, новаторлык пафосы белән иҗат итәләр.

Таҗик әдәбияты әсәрләренә тирән мәгънәле фәлсәфи уйланулар, заманның һәм замандашларның яңа характерын күрсәтүгә зур омтылыш, заманча яңа һәм югары сыйфатлы поэтик образлар, күңелгә ятышлы лирик кичереш һәм матур елмаю, яманнак үткен көлә белү хас. Шуңа күрә тәрҗемәчебез Яхья Халитовның таҗик прозасыннан бу сан өчен нигездә әнә шул сатирик һәм юмористик пландагы әсәрләрне сайлап алуы да очраклы хәл түгел. Таҗик шагыйрьләрен тәрҗемә итү минем өчен, мактап буларак, бүтән милләтләр поэзиясен тәрҗемә иткәндә алган һәм инде тупланган азмы-күпме тәҗрибәмә өстәп, шактый ук гыйбрәтле сабаклар бирде.

ЗӘКИ НУРИ

## Мирзо Турсунзода

### Кояш белән хатын-кыз

Дингездә давыл. Җилләр котыра.
Аксыл дулкыннар зур кыя төсле.
Җәйләр янгырны чиләклəп коя...
Болар барысы да бер кояш эше.

Кар һәм боз ява. Көн һәм төн килә.
Күкләрдә болыт йөри буталып.
Кышлар узуга җылы яз килә...
Барчасы кояш эше, ди, халык.

Ерак юл үтеп карлыгач кайта,
Чәчәкләр балкый яз җитсә, түрдә...
Болар барысы да бер кояш эше,
Кояш тирәли әйләнә җир дә.

Шул кояш көче үләп үстерә,
Шушы нур беләп таңнар сызыла.
Яктыра кояш ак төннәр булып,
Тылсымлы күпер булып сузыла.

Шул кояш көче яшәртә-бизи,
Гөлбакча итә сахра-чүлләрне.
Көйдерә ала кояш кырларны,
Киптерә ала кояш күлләрне.

Кайчакта кояш, әйе, шәфкатьсез...
Ләкин барыбер ул мәңге кирәк.
Хатын-кыз белән тиңләргә мөмкин —
Кояш ул шундый! ди һәрбер йөрәк.

Яратса әгәр — иркәли, назлый
Хатын-кыз безне тиңсез көч белән,
Яратмый икән — киптерә ала,
Газаплый белә кайнар уч белән.

Сине үтәли күрә белә ул
Утлы, оялчан, чая күз белән.
Ә кирәк чакта — җиңә ул сине
Дәһшәтле, горур, шаян сүз белән.

Яратса сине — кыю итә ул,
Бер бизсә әгәр — боз кебек салкын...
Әйтә йөрәгем: яшә, хатын-кыз,
Кояштай булып! Яшә син, ялкын!

## Мирсаит Миршакар

### Бөркет

Елады бер бөркет кунып тау башына:
Күрәсең, зур кайгы төшкәндер башына!

Сорадым: «Патша-кош, син таулар түбәсен
Билисең! Ә нигә болай яшь түгәсең?»

Әйе, ул елады, әйе, яшь түкте ул,
Һәм миңа нәрсәне хикәят итте ул:

«Бадахшан тавында җәйләдем, кышладым,
Котларын алып мин барча вак кошларның.

Уздым мин алардан һәм өскә үрләдем,
Миннән дә тиз очкан бер җанны күрмәдем.

Талпындым кояшка күз йоммый карап мин,
Мин шундый кыюмын, шундый киң канат мин.

Ышандым үземә, уйладым биектә —
Миндәй кош булмады һәм булмас! диеп тә.

Ә хәзер мин мескен кичерәм кара көн,
Күкләрдә күрдем зур алып-кош канатын.

Дөньяда иң батыр бөркеткә ул тиңдер,
Патшалар патшасы дияргә мөмкиндер.

Куышып карыйк! дип, ник канат талдырдым
Икән мин... Ул мине еракта калдырды.

Буйсынды күк аңа, күктә ул гүләде,
Ул көчле, ул хәким — күкне ул биләде.

Очышта ул узды. Мин калдым оятка...
Кем аны, кайлардан китергән бу якка?»

Мин әйттем: «Чал бөркет, үзеңне хурла син,
Кешегә дан җырла, кешене зурла син.

Син күргән яшь бөркет — галәмне үтәрлек,
Аны без, кешеләр, күкләргә күтәрдек!»

## Абдуҗаббар Каххори

### Елмаю

Бер вакытны гөлнең һәм кешенең
Елмаюын урлый кемнәрдер.
Кеше үзе нурсыз булып кала,
Сагышлана көннәр-төннәр гөл.

Кеше күзе, матур гөл сабагы
Оныталар кинәт көлүне.
Үлем бит ул елмаюсыз калу,
Елмаймау ул — җырның үлеме.

Кинәт бер көн күктә нур балкый да
Куаналар бар кыр, бар сулар,
Бар чәчәкләр җирдә күтәрелә,
Елмаюын җирнең каршылап.

Бар табигать, барча кеше күрә
Кояш көлү бүләк иткәнен.
Аңлый алар елмаюлар яме
Шатлык белән бердәм икәнен.

Шуннан бирле кеше гел елмая
Хәтта хәле авыр чакта да.
Елмай, кеше, көлү нурын ярат,
Олыла да шуны, макта да.

Мин җыр итеп шуны әйтә алам
Көлә белгән кеше турында:
Аның йөзе — гүя матур чәчәк,
Балкып ачыла кояш нурында.

## Файзулло Ансори

### Юлда

Син мине күрмичә торып
Гел болынга карадың...
Анда чәчәк күп булганга
Дөрес иде каравың.

Ә без уздык тау юлыннан,
Болын ягалап, читтән.
Ул болынны күксел елга
Ал чәчәк белән чиккән.

Килешәм, иркәм, болын бит
Һәр чәчәккә җыр элгән.
Мин — табигатьнең көндәше,
Ә син — аңа бирелгән.

## Муъмин Каноат

### Разлив

Хөкемдарлар мәш киләләр башкалада —
Җандарм да, шымчылар да, башкалар да
Яраталар мактанышып сикерергә.
Бөтен төшне кат-кат тенти, күзли алар,
Бөтенесе бер Ленинны эзли алар,
Тиеш алар инкыйлабны[1] үтерергә.

Алар эше — азатлыкка кабер казу,
Митингларда акырынып, янап азу —
Инде күптән: «Дөмек, ирек!» — диде алар.
Курка алар шул ирекне уттай күреп,
Шул ирекне, ап-ак каен еккан кебек,
Туган җирдән йолкып алыр иде алар.

[1] Инкыйлаб — революция.

Бөек тетрәү якынлашкан көннәр иде,
Ә Ленинны урман, болын, күлләр иле —
Иркен Разлив үз куенында яшереп саклый,
Өе — шалаш. Язу — аның иң төп эше.
Табигатьнең олы җаны, бер өлеше
Ленин монда яшерен ята, яшерен атлый.

Аңкып торды үләннәр һәм җирләр исе,
Җылы яңгыр алып килгән җилләр исте
Сулар тыныч һәм тугайлар киң урында.
Каеннарда куе яфрак шыбырдады,
Нык тамырлар кара җирдә шыгырдады...
Ул уйлады кешеләр һәм җир турында.

Һаман яза аулак, тыныч якта, шунда.
Чык юеше күренә өстәл тактасында.
Куллары нык, каләменең эзе якты.
Туган җирнең җылы куены саклый аны,
Шуңа дошман һичбер җирдән тапмый аны —
Чөнки бит җир аның гадел сүзе яклы.

Кеше теле яфрак була белсә әгәр,
Ленин сүзе шунда ишетелсә әгәр,
Кеше тынар, ул кош булып тыңлар иде...
Сүзләр туды, сүзләр канат ярып китте,
Давыл булып Балтиккача барып җитте,—
Бит ул сүзләр — туа торган томнар иде.

Агыла болыт. Көн арты көн туа тора,
Күкрәүләрне гүя урман куа тора.
Андый чакта тар шалаш та — кулай ирек.
Хезмәт тәмам! — килде бәхет минутлары.
Кабындылар җирдә яңа көн утлары
Кара болыт арасыннан шаулап килеп.

## Убайд Раҗаб

### Сукмак

Кан тамыры итеп күрәм сине
Авылымның чандыр читәсендә.
Синең таңнар, синең эңгер яме
Күз алдыма минем килә көн дә.
Сабый чакта сине күп таптадым,
Һәр тармагың буйлап йөрдем мин дә.
Бусагамнан синең буйлап китеп
Зур дөньяга барып кердем мин дә...
Алып киттең мине бер таңда син,
Олы юлга чыгып китте улың.
Аңкып калды рәйхан хуш исләре,
Фонарь булып тюльпан сипте нурын.

Шау чәчәктә иде ак гөмбәләр,
Сандугачлар өзелеп сайрый иде.
Минем күзләр таң-чулпанга түгел,
Еракларга — алга карый иде.
Таштан ташка тиеп аккан елга
Минем арттан гүя куа барды.
Як-ягымда гүя тукранбашлар
Күз яшьләрен коя-коя барды.
Аерылыштык... Шарлавыклар җырын
Тыңлый-тыңлый алга атладым мин.
«Хуш!» дип калды тауда таныш кошлар,
Үбәр өчен сиңа капландым мин.
Тарлавыктан мине алып чыктың
Көр сулышлы киңлек юлларына.
И сукмагым, минем нәни кулны
Син тоттырдың Тормыш кулларына!
Мин хаклымын: тәүге сабакка ул
Илтте! — диеп сине мактасам да.
Тыңладым мин синең киңәшеңне
Кайсы юлдан җирдә атласам да.
Еллар үтте... Тагын сиңа кайттым,
Синең буйлап тагын узамын мин.
Таныйсыңмы? Мин бит синең улың,
Бер бөртеге синең тузаныңның.
Хыялларым юлы, өмет эзем!
Текә үрдән тагын сиңа төшәм.
Үтәдем мин синең әйткәннәрне,
Кыю канат үсте миңа, ышан.
Ә син һаман олы юлдан читтә...
Бик борчыла шуңа балаң синең.
Вакыт җитте! Инде зур дөньяга
Үзем алып чыга алам сине!

## Мәүҗүдә Хәкимова

### Энҗе бөртеге

Ике гөл кочышты язын — бердәмлекне хис итте.
Ә мине өмет һәм сагыш — шул ике кош дус итте.

Син мине оныттың. Ләкин кил шундый яңгыр булып,
Без бергә торган җирдә там — нур булып там, җыр булып.

Уйларым кебек таркалып толымым туза минем,
Син рәтлә шуны — башыма кулыңны суз да минем.

Бәлки мин юлармен хәзер: яратып батыр булдым,
Үзем яз булдым да кышка: «Килмә!» дип әйтер булдым.

Һәркем белә кеше кулы чәчәккә сузылганын,
Ә мин гел сиңа үреләм — торырмын сүземдә мин!

Мин сөям. Җылы яңгырны сипсен дим көзге болыт.
Кил генә! Үзем балкырмын җирдә бер энҗе булып.

## Лоик Шерали

### Соңгы җыр

Советлар Союзы Герое Исмаил
Хәмзәлиев истәлегенә

Язлар килеп, көмеш тауда тагын
Нурлар уйнар — ләкин мин булмам.
Җир ярасы белән минем ярам
Төзәлерләр — ләкин мин булмам.
Җиңү яме һәм яуланган шатлык
Миннән башка кайтыр — мин булмам.
Халкым каны минем тамырларда
Һаман тибәр — ләкин мин булмам.
Кашларына кызлар сөрмә сөртер,
Мин күрәлмам аны — мин булмам.
Туйда яшьләр «Ер-ер» көен сузар,
Мин кушылмам җырга — мин булмам.
Миннән башка шаулар тормыш. Миңа
Үлем калды — бетте игелек.
Полкым калды миңа — мин булмасам,
Дошман аны кыра иде бит.
Мин — бер таҗик, мин Шеракта тудым.
Ташланам мин дошман дотына.
Минсез, әни, сиңа кыен булыр,
Ләкин кичер, ләкин куркынма,
Мин бүтәнчә була алмыйм монда...
Җирдә юллар булсын киң, әни.
Мин кайтырмын табын җыры булып,
Кара күлмәк кимә син, әни.
Синең өчен, илем өчен, әнкәй,
Гомеремне мин корбан иттем бит.
Ә син мине матур чапан тегеп
Туйларына өйнең көттең бит...
Ул чапанны кече энем кисен,
Җыр җырласын туйда яшьләргә.
Белсен шуны: мин булмасам әгәр
Булмас иде җирдә яшәү дә.

## Хабибулло Файзулло

### Җилгә әйтә агач

Мин әле яшь агачмын,
Мин әле җимеш бирмим.
Нәни яфраклы кием
Кияргә тиешмен мин.

Тәүге кат чәчәк атам,
Миңа каты тимә, җил —
Салкын сулыш өрмә син,
Түзсен әйдә! — димә, җил.

Ботакларым сынмасын,
Уз син мине читләтеп.
Теләм миңа күп чәчәк,
Теләм миңа күп бәхет.

Ә көз житкәч — сызгырып
Кил син миңа кунакка.

Мине иренми селкет
Сул якка да уң якка.

Каты селкет — алмалар
Жиргә төшсен дөп итеп.
Бакчачылар бакчадан
Уңыш алсын күп итеп!

Борһан Гани

# ИЗГЕ ЭШ

хикәя

Соңгы вакытта күп кешеләр вафат булган ата-бабалары, онытылган якташлары турында яза башладылар. Бу хәлне күреп, мин дә кызыксынып киттем. Минем дә ике бабам бар бит. Әйтик, этинең этисе Гыйниятулла бабамның гәзиттә языла торган геройлардан кай жире ким?

Шулай итеп, мин бабам турында эзләнергә, сорашырга, белешергә тотындым.

— Хәтерем ялгышмаса, сезнең бабагыз һәлак булган бугай,— диде миңа авылдашыбыз Җафарбай карт.— Ул кайсыдыр тау итәгендә ниндидер корбашлар дигән банда белән сугышканда зур каһарманлык күрсәткән. Шул хакта миңа абзам сөйләгән иде. Сезнең бабагызны бик таза, бик буйчан кеше дигән иде. Хәтта бабагызның атының йөгәне белән ияре дә хәтерли иде әле. Өзәнгесе жиз, йөгәне каеш иде, ди. Бабагыз бик дәү аяклы бер кеше иде, ди — аңа яраулы чорух тегәр өчен бер кәжә тиресе китәр иде, ди. Әйе, үзем дә хәтерлим әле: моннан берничә ел элек бабагызның йорты янында су үткәрер өчен чокыр казыганда аршын ярым озынлыгында иске бер хәнжәр таптылар, йөзендә язуы да бар иде. Сабы фил сөягеннән ясалган, язуында шул хәнжәрнең Гыйниятулла бабагызныкы икәнлеге әйтелгән иде. Чын әгәр, андый хәнжәрне сезнең бабагыз гына күтәрә алса алгандыр. Шофер Мәжитнең этисе белән сөйләшеп карагыз әле, ул сезгә барысын да әйтеп бирер.

Җафарбай сөйләгәннәрдән мин күп нәрсә белеп, байтак әйбер язып алдым. Хәнжәрдәге «Баһадирга дан!» дигән язуы гына да үзе бер кызыклы факт бит. Бу ике сүз, тәгаен, минем бабама атап язылган булгандыр. Аны зур бер гаскәр башы бабама каһарманлыгы өчен бүләк иткән булырга тиеш. Әгәр шул кадерле истәлек дөньяда әле дә бар булса, аны табасы иде — киләчәк буыннар өчен бабамның каһарманлыгы турында бер таныклык булыр иде ул.

Шофер Мәҗитнең атасы оста Талиптан да сораштым.

— Әйе, Гыйниятулла хакында ишеткәнем бар,— диде ул.— Мәрхүм бабам аны бик мактап телгә ала торган иде, аның хакында бик кызык нәрсәләр сөйли торган иде. Сезнең бабагыз бик буйчан кеше булган, аңа күлмәк-ыштан тегәргә генә дә алтмыш аршын киндер китә торган булган. Мәрхүмнең борынында уң якта ике кара миңе бар иде, диләр. Бусы инде яхшы нәселдән туу билгесе. Бабаң ачуланса, күзләре ут кебек яна иде, диләр. Аннан ары, бик оста атучы булган. Абзам әйтә торган иде: тычканның күзенә тидерер иде дип. Үзе бик зур көч иясе булган! Бер үзе берничә басмачыга каршы сугыша торган булган... Бабагыз хакында андый кызыклы хәлләрне бик күп беләм. Шулай да сез безнең Сабир мулладан сорагыз әле — ул әйбәтрәк сөйләр. Ул сезнең бабагызның Носир додхо Наркаллу ягына берничә тапкыр мылтык атканлыгын үз күзе белән күргән, диләр.

Ярый, яхшы! Оста Талип минем өчен бик кыйммәтле мәгълүматлар әйтте. Бабамның Носир додхо ягына мылтык атуы аның йөрәкле, батыр кеше булуын күрсәтмимени?

Байтак кына эзләгәннән соң Сабир мулланы да таптык.

— Гыйниятулла хакында ишеткәнем бар, тик үзем күргәнем булмады,— диде ул.— Ходай урынын җәннәттә кылсын,— бер тапкыр әти сөйләгән иде: сезнең ул мөхтәрәм бабагыз чит җирдә үлгән булган, шуннан аның изге гәүдәсен авылга кайтарып җирләгәннәр. Андый бәхет һәркемгә эләкми. Минемчә, гүре әле кайчан гына бар иде. Без кечкенә чакта узган-барган кешеләрнең аның кабере янына утырып дога кылуларын күрә торган идек. Кардәшләрегез дә аны зыярәт итә торганнар иде. Бабагызның оста аучы булуы исә бәхәссез — бер тапкыр без алачыктан чакмалы мылтык табып алган идек,— әти аны сезнен бабагыз Гыйниятулланыкы, диде. Мин хәзер ул мылтыкның кайда икәнлеген хәтерләмим инде. Председателебезнең бабасы Идибек абзыйдан сорасагыз... Ул аларның барысын да күргән кеше бит.

Сабир мулланың сөйләгәннәре бабамның тәрҗемәи хәлен тагы да ачыклый төште. Чит җирдә үлеп калу — бик кыйммәтле тарихи факт ул — бабамның каты сугышларның берсендә батырларча һәлак булуын раслый. Аның берәр удар отрядның башлыгы булган булуы да бәхәссез. Бабамның чакмалы мылтыгы бу турыда шикләнергә урын калдырмый.

Идибекне дә эзләп таптым. Бабамның исемен ишетү белән ул, күңеле нечкәреп, елап та алды. Идибек карт минем бабамның һәлак булганлыгын раслады. Дөрес анысы, бабамны кая җирләгәнлекләрен хәтерләми. Аның каравы, бабамның күкбәре ярышында һәрвакыт җиңеп чыга торган булуын әйтте. Атка атланса, аягы җиргә тияр иде, ди. Гыйлем ягына да сәләте булган — мәдрәсә бетергән. Бабай хакында миңа тагы өр-яңа бер факт: аның кабан тешләре авызыннан мылтык штыгы шикелле чыгып тора, йөргән чагында сул кулын ни өчендер селтәми иде, ди.

Идибек картның сөйләгәннәрен бик бирелеп тыңлап утырдым, хәтта күңелем нечкәреп китеп, күзләремә яшь тә килде. Ник дигәндә, бабай без оныклары өчен гомерен дә кызганмаган, ә без моңарчы аның исемен хөрмәт белән телгә дә алмыйбыз.

Иң ахырда мин, җыйган материалларымны туплап, «Батыр көрәшче» дигән исем астында тарихи очерк яздым һәм аны әдәбиятчыларга тикшерергә тапшырдым.

Очеркыма бик зур бәя бирделәр, ул хәзер берничә газетада басыла, хәтта конкурста беренче премияне дә алды.

Хәзер инде мин икенче бабамның — әнием әтисенең каһарманнарча яшәп уздырган гомер юлын өйрәнеп язам.

## Сорбон

# ТӨШ

ХИКӘЯ

Минем йокым куян йокысы кебек бик зирәк. Менә минем битемә кемнеңдер кул шәүләсе төшә, әкрен генә якыная да кире китә, тагы миңа таба якыная. Һәм, ниһаять, кытыршы бер кул йомшак кына итеп иңемә кагыла. Мин шундук икенче ягыма әйләнеп ятам, тагы йокыга куерып китәм.

— Торырга вакыт, улым...— Әнинең бу сүзләре төштә әллә кайдан ишетелгән бер көй шикелле яңгырый.

Мин рәхәтләнеп бер киереләм, уч төбем белән күзләремне угалыйм. Бөтен гәүдәмә ниндидер рәхәтлек тарала.

Ай, йолдызлар чәчәкләрдәге чык бөртекләре төсле ялтырый-җемелдиләр, һава саф, татлы.

Зур чикләвек агачы ышыгында мине әти көтеп тора. Без ишәкләргә атланып, тауларга китәбез. Юл калкулыклар аша менә-менә һаман текәләнә бара. Тау араларыннан дымсу җил исә. Кекләкләр сайравы ишетелә — озакламый таң атар.

Тик без кояш чыкканны көтеп тормыйбыз. Әти агач кисәргә керешә. Балта тавышы тук-тук яңгырап әллә кайларга чаклы ишетелә.

Арча куагы астында яту нинди рәхәт. Чишмә чылтыраган, кошлар сайраган, көтүче нәе уйнаган тавышлар бергә кушылып, искиткеч бер тылсымлы көй тудыралар...

— Улым, ишәкләрне китер,— ди әти.

Мин ике куллап йөк иярен тотып торам, әти ишәкнең сырты аша бауны ташлый да минем якка утын төйи. Утын минем күздән дә биегрәк булып өелә. Мин егылып китмәс өчен утын агачларына терәлеп, аларны иягем белән кысам. Аяк-кулларым тала, калтырый. Ишәкне кигәвеннәр тешли башлый. Ишәк тик тормый, кузгалып китә, мин басып тора алмыйм — егылам, утын ишелеп төшә. Әти мине күтәреп торгыза. Мин аның күзләрендә яшь күрәм.

— Түз, улым, түз,— ди әти. Үзе, калтыранган иреннәрен тешләп, еракта гы офык читенә озак кына карап тора. Карашыннан, шифалы бер үлән исе кебек, зур түземлелек һәм эчке бер акыллылык бөркелә сыман. Аннары ул карашын офыктан ала да, үзендәге көчне миңа да бирергә теләгән шикелле, күзләремә карый.

Шул хәлдә без беркадәр вакыт басып торабыз.

Ул арада инде ишәкләр сукмак буйлап шактый китеп өлгерәләр. Әти, халачубын[1] кулына тотып, аларны куып китә, ә ишәкләр, үзләренә эләгәсен сизеп, башларын аска иялер дә бер урында әйләнгәләп тора башлыйлар.

Әти аларны утын бәйләме янына алып килә, туктаусыз «ыш, ыш» ди-ди, минем яктан җәпле терәүне куя. Утынны шундый күп итеп төйибез, бәйләр өчен өске бау җитми. Шуннан соң әти башындагы чалмасын салып, бауга ялгый. Хәзер инде бу бау, тау төшкәндә утын

[1] Халачуб — тимер очлы таяк.

ишәкләрнең муенына таба шуышмасын өчен, аларның койрык астыннан чалдырырга да житә. Икенче йөкне бәйләү өчен әти икебезнең билбауны кушып ялгый. Өсләренә тау чаклы итеп утын өйгәч, ишәкләр тигез жирдә дә авып китәрләр кебек. Тик әти бер чыбык, бер таякны да ташламый.

Өйгә кайткач, мин, бик ачыкканлыгымны да онытып, ятам да шундук йоклап та китәм. Утыннарны әни бушатыша.

Менә мин тагын үземә йомшак кына булып кул кагылганын тоям. Әтинең мине уятасы килмидер. Әмма без бу төндә утынны калага илтеп сатарга тиешбез: өйдә ашарга бер тәгам ризык юк.

Мин торып, битемне юам, ул арада әни әтигә утын төяшә. Ишәкләргә хәзер жиңелрәк инде, чөнки утынның яртысы өйдә кала.

Әти мине ике бәйләм утын арасына утыртып, бәйләп куйгач, юлга кузгалабыз.

Бишектәге кебек тирбәлеп бара торгач, мин йоклап ук китәм. Вакытвакыт бер якка авып киткәч, әтинең:

— Уян! — дигәне ишетелә.

Куркынып күзләремне ачам. Минем яннан барган әтинең аяклары алга түгел, артка таба атлый шикелле. Кулындагы халачубы сәгать теле төсле селкенеп бара.

Күктә йолдызлар жем-жем итә, бер жайга гына утыннар шыгырдый, ташка чак-чок ишәк дагалары бәрелеп, очкыннар чәчри.

Калага житәрәк, юл жимеш бакчалары буйлап бара башлый. Юл буенда базарга терлек китерүче кешеләр ял итә. Кала капкасы янына житкәч, без дә туктыйбыз. Әти мине чишеп жиргә төшерә. Минем аякларым оеп беткән, жиргә баса да алмыйм.

— Әти мине жилкәмнән тотып, әкрен генә этеп жибәрә дә:

— Бераз йөреп кил, бетәр. Менә шулай, менә шулай... И аллам, кайчан кеше булырсың икән син! — ди.

Ул утыннарны күбрәк күренсен дип тараткалап алгач, аулак тыкрык буйлап таныш чәйханәгә таба китәбез.

Чәйханәче Одина самоварга ут тергезеп ята иде. Әтине күргәч:

— Мин өч бәйләм утын алдым инде,— ди.

Әти авыр сулап куя, шулай да нидер өмет иткән сыман, чәйханәнең ысланып беткән стеналарына әкрен генә күз йөртеп чыга.

— Я, ярый, бөтенесе өчен кырык сум бирәм,— ди чәйханәче, әтине кызганган кебек.

Әти уйлана кала.

— Тагын биш сум өстә инде,— ди.

— Юк, өсти алмыйм. Кырык сум да бик житкән,— ди чәйханәче.

Әти риза булып башын ия. Миннән гафу үтенеп, берни эшләп тә булмый инде дигән шикелле, миңа карый.

...Яңа көн туганда йолдызларның яшьле күзләре сүнә. Хәзер инде әтинең аяклары нык-нык басып алга таба атлый, мин дә нык басып жиңел атлыйм.

Әти ишәкләрне чәйханә артына илтеп бәйләгәч, базарга китәбез. Әти базарда посылка әржәсе, йөзем һәм чикләвек сатып ала. Посылка әржәсендә буш урыннар калганлыгын күргәч, билбавын чишеп ала да йомарлап әржәгә тыга.

— Билбавың таза булса, кулың да нык булыр,— дип сөйләнә-сөйләнә, әржәне кадаклый. Аннары кесәсеннән карандаш кисәге белән таушалган хат кәгазе алып, миңа бирә:

— Мә, әдресен яз. Кара аны, хәрби частенең нумерен ялгыштырма...— ди.

Менә тагы миңа таба бер кул якынлаша.

— Торыгыз, сезне шофер көтеп тора. Эшкә барырга вакыт,— дигән тавышка күземне ачып жибәрсәм, янымда улым елмаеп басып тора.

**Урун Кухзод**

# ДӨЯ КАЙДАН КИЛЕП ЧЫККАН

Бервакыт бер тау кешесе дөя күреп әйткән, имеш:

— Тәңре бераз саранланган, ахры. Шушы гарип-бөкре бер хайван урынына ике ишәк яратса, яхшырак булмас идеме? — дигән.

Ә чынында эш болай булган.

Көннәрдән бер көнне йөк ташырга ярардай хайван кирәк булган.

— Гәүдәсен ясагыз! Җанын үзем өрермен,— дигән тәңре.

Бу җаваплы эшне җәнлекләр патшасына тапшырганнар. «Син хайваннарның телен дә, гадәтләрен дә беләсең. Уңай һәм тискәре сыйфатларын чамалап, проект заданиесе төзе»,— дигәннәр аңа.

Ә җәнлекләр патшасы, патша булып алганнан соң, бик ялкауланып киткән. Мондый эш кушуларына бик борчыла башлаган. Шуннан соң ул, берьюлы ике куян атарга: бу эшне үзе дә эшләмәскә һәм җаваплылыгын да үз өстенә алмаска ниятләп, урынбасарына тапшырырга карар кылган.

Җыелыш җыеп, проект комиссиясе төзиләр, комиссиягә «йөк күтәрә торган чыдам, көчле һәм матур бер хайван моделе ясау кирәклеге» турында күрсәтмә бирәләр.

Проект төзелә. Осталар коралларын алып эшкә керешәләр. Баштарак эш кайнап тора. Радио һәм телевидениедән бу хакта репортажлар тапшыралар. Иҗат отчетлары җибәрелә. Ләкин шуннан ары эш туктала. Ниндидер имеш-мимешләр, яман сүзләр тарала.

Фәрештәләр комиссиясе, тикшереп караганнан соң, мастерскойда кайбер аерым ярамаган хәлләр барлыгын ача. Башта фәрештәләр мастерской башлыгын тетеп салырга уйлыйлар, аннары бу ниятләреннән кире чигәләр, чөнки мондагы башлыкларны берничә тапкыр алмаштырган булганнар инде. Элекке башлык, эшне тапшырып киткәннән соң, җаваплылыктан үзен азат дип санаган, яңасы исә бөтен гаепне искесе өстенә аударган.

Ахырда эшне өр-яңадан башларга, иң кыска срокта һәм иң зур осталардан эшләтергә карар кылалар.

Хайванны ясап бетерәләр. Эшне кабул итәргә комиссия килә һәм: «Куелган максат тормышка ашмаган. Объект гел кимчелекләр һәм житешсезлекләрдән генә тора»,— дип, кабул итүдән баш тарта.

Шуннан соң моның сәбәпләрен һәм сәбәпләрнең тамырларын эзләргә керешәләр. Нәтиҗәдә шулар мәгълүм була: башлыкның урынбасары Кәҗә проектта каралган житезлек белән елдамлыкны үзенә алган. Баш инженер Качыр проектта каралган туры шома сырт миңа күбрәк килешә дигән карарга килгән. Бер ара өлкән мастер булып эшләп йөргән Төлке көлтә чаклы койрыкны чәлгән дә «үз теләге белән» китеп ычкынган. Ашыгычлык аркасындамы, әллә юриме, аяклары аякка охшамаган, муены адәм карамаслык булып чыккан.

Шуннан бик кыен хәл килеп туган. Бер яктан, хайванны кабул итеп булмый, икенчедән — бик кирәк...

Тәңре бу хәлне күргәч уйланып тора да тамагын кырып әйтә:

— Ярый, дәртләнеп-янып эшләдегез, вакытында башкарып чыктыгыз,— ди. Тагы бераз уйланып тора да: — Моны төзәтү өчен башка акча юк инде. Ел ахыры. Вакытлыча калдырып торыйк. Исеме Дөя булыр,— дип, тегеңә җан өрә.— Эшкә җибәрә торыгыз. Мөмкинлек булу белән үзгәртеп ясарбыз. Сораулар бармы? — ди.

Сорау бирүче булмый.

**Фазлетдин Мөхәммәдиев**

# МӘГЪРИФӘТ УРЫНЫ

Анда чәйханәчедән башка бер жан әсәре юк. Чәчәкле палас җәйгән киң таш сәкеләр күңелсез булып тик торалар. Кызыл комач җәймәсе уңып беткән чатан өстәлдә бер өем китап белән газеталар ята. Стеналарга төрле-төрле плакатлар эленгән.

Яшь кенә бер дәһкан егет чәйханә янында велосипедыннан төшеп, стенага сөяп куйды да, чәйханәгә кереп, сәке кырыена утырды. Чәйханәче, егетнең сораганын да көтмәстән, алдына чәйнек китереп куйды.

Егет сумкасыннан төенчек чыгарды, аны чиште—төенчегендә майда пешкән күмәч белән бераз конфет бар икән. Пыялага чәй агызып, күмәчен тешләп алды, конфет капты. Каршы як стенадагы плакатларны карый-карый, чәйнәргә кереште.

Бер плакатта эчпошыргыч бер житдилек белән терлекләрне ясалма рәвештә аталандыру турында сөйләнелә, икенче плакат санаторий яки ял йортына бару өчен акчаны саклык кассасына сала барырга өнди, өченчесендә ДТ-54 тракторының төзелеше аңлатылган. Дүртенчесенә коточкыч бер чебен сурәте ясалып, астына: «Чебеннәрне үтерегез!» — дип язып куелган. Бер плакат «Трахома» дип аталган. Шунда кызарып, яшьләнеп торган күз сурәте төшерелгән, схема рәвешендә бу авыруның стадияләре күрсәтелгән.

Егет, кулына күмәч белән пыяланы тоткан килеш, ашавыннан туктап калды. Карашын икенче як стенага күчерде. Анда «Җирле ашламалар — мул уңышның нигезе», «Дизентерия — йогышлы авыру» дигән плакатларны күрде... Пыяласындагы чәен идәнгә түкте, төенчеген яңадан төйнәп, сумкасына салды да, өстәлгә акча ташлап, чәйханәдән чыгып китте.

Анда тагын жан әсәре калмады.

Илбарис Надиров

# ХӨРЛЕККӘ ӨНДӘҮЧЕ МОҢНАР

Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, татар халкының сугыш чорындагы фольклорын җыю, өйрәнү эше белән шөгыльләнергә туры килде. Бу өлкәдә элек эшләнгән эшләр дә, элек җыелган әсәрләр дә байтак иде. Яңа экспедицияләр яңа материаллар табарга ярдәм итте. Тупланган шигъри байлыкны бергә кушкач, калын гына бер китаплык хәзинә җыелды. Аның бер өлеше 1961 елда «Халык һәм җыр» дигән хезмәттә басылып чыкты. Ул китап чыкканнан соң да экспедицияләр оештырыла торды, сугыш чоры фольклорына караган поэтик хәзинә һаман тулылана, байый барды.

Мин шул хәзинәдәге сәхифәләр белән кабат танышам, унлаган экспедицияләрне күз алдыннан үткәрәм. Гадәти бер күренеш искә төшә. Кайсы гына авылга барсаң да, кайсы гына йортка керсәң дә, стенага эленгән фоторәсемнәргә күз ташлыйсың. Рәсемнәр арасында кара кайма белән уратып алганнары да аз түгел. Ватан өчен һәлак булган батырлар алар. Берәүләрнең улы, берәүләрнең кияве, берәүләрнең сөйгән егете. Сугыш чорындагы хәлләрне телгә алып, тегесен-бусын сөйләшкәч, сүзне шул еллардагы җырларга, бәетләргә, хатларга күчерәсең.

Сөйләшә торгач, яшел сандыклар ачыла. Сандык төбеннән инде саргая башлаган солдат хатлары, дәфтәрләр килеп чыга. Әмма хәзинәнең иң күркәм өлеше халыкның күңел сандыгында. Моннан ничә йөз ел әүвәл булган вакыйгаларның шигъри авазын да, бүгенге көннәр аһәңен дә үзенә җыйган тылсымлы бер сандык ул. Шигърият һәм музыка белән, сурәтле фикерләр һәм милли көйләр белән тулган шул сандыкның кадерле бер почмагында данлы, газаплы Ватан сугышы чорына караган әсәрләр дә саклана.

Бөек Ватан сугышы елдан-ел тарихның түренәрәк күчә бара, әмма ул легендага әйләнерлек ерак заман түгел әле. Сугыш еллары һаман-һаман искә төшеп тора. Язучылар язган әсәрләр битеннән, сәхнәдән, экраннардан шул елларны искә төшергән образлар, геройлар белән очрашабыз. Композиторлар, шагыйрьләр язган яңа җырларның да бер өлеше күңелне шул елларга алып китә. Авылларда, шәһәрләрдә сугыш чоры корбаннарына багышлап куелган һәйкәлләргә, шул һәйкәлләр янында кабынган мәңгелек утларга карап тын калабыз. Күңелне үткән еллар кабат тетрәтә, кабат моңга күмә. Әйе, дөнья әле дә тыныч түгел. Вьетнамда кан ага, Израиль гарәп илләренә каршы сугыш хәрәкәтләрен дәвам иттерә, төрле төстәге реваншистлар яңа сугышка өндәп ут белән кызыналар. Шундый бер заманда халык күңеле ничек тыныч булсын да, ничек үткән сугыш еллары тиз генә онытылсын соң?

Хәзер татар халкы арасында Ватан сугышы турында яңа поэтик әсәрләр, әйтик, бәетләр, җырлар тумый, күрәсең. Һәрхәлдә, аларның очраганнары юк. Ләкин шул чорда иҗат ителгән әсәрләрнең бер өлеше әле дә яши, яңа булып, заманга авазлаш булып яңгырый. Болар — сугыштан кайта алмый калган батыр егетләрне юксыну җырлары, искә алу бәетләре.

Күптән түгел Шөгердән хат алдым. Аны пенсионерка Хәлимә апа Мияссарова-Ишбулдина язган. Хатына өстәп ул бәетләр, мөнәҗәтләр, шигырьләр җибәргән. «Бу әйберләрне төрле дәфтәрләрдән күчердем. Сугыш вакытында чыккан булсалар да, алар онытылмыйлар, телдән телгә, кулдан кулга йөри бирәләр. Олы яшьтәге хатын-кызлар аларны җыелышып кич утырганда, табын ашларында әйтәләр»,— дип яза Хәлимә апа. Ул җибәргән бәетләрнең берсе «Батыр егет бәете» дип атала. Таныш бәет. Соңгы мәртәбә ул Х. Ярминең «Бәетләр» китабында басылган иде[1]. Китаптагы вариант 1945 елгы фольклор экспедициясе вакытында табылган. Аларны чагыштырып карагач, хат белән килгән текстның шомарган, чарланган булуы күзгә ташлана. Халык бик яхшы, бик зирәк редактор ул. Китаптагы бәетнең өч строфасы озын, өчесе кыска шигырь үлчәмендә иде. Ә хат текстында алар һәммәсе дә озын шигырь үлчәменә күчкәннәр, бер көй белән әйтү өчен яраклашканнар. Строфаларның ничек итеп халыкчан гадилеккә таба камилләшүен күрсәтер өчен, бер генә мисал китерик:

| **Китапта** | **Хат вариантында** |
|---|---|
| **Әнкәй, бәгърем, инде мин юк,** | **Кетмә инде, әнкәй, ярам авыр,** |
| **Хатлар бармас синең улыңнан,** | **Хатлар килмәс газиз улыңнан,** |
| **Яшь гомерем минем сүндерелде** | **Минем яшь гомерем иртә өзелде** |
| **Немец фашистлары кулыннан.** | **Немец фашистлары кулыннан.** |

Халык теленә күчеп көй белән яши башлагач, бәет лирик җырларга якынайган. Соңгы вариант үзенең ритмик яңгырашы, рифмалары, сүзләр сайланышы ягыннан халыкның озын көйләр белән яшәүче җырларын хәтерләтә.

«Батыр егет бәете» ни өчен бүген дә теллердән, дәфтәрләрдән төшми соң? Чөнки аның үзәгендә туган иле өчен үлгән батыр ир-егетнең үлемсезлеге, аларны көрәшкә рухландырган идеалларның мәңге яшәү мотивы ята. Бу мотив халык поэзиясендә дә, профессиональ поэзиядә дә гәүдәләнеп килгән югары фәлсәфи мотивларның берсе. Искә алган бәет герое үзенең хак эш өчен, ил азатлыгы өчен үлүен белә, яшь гомерен өзгән дошманнардан үч алырга чакыра.

**Чәчәк кебек яшь гомрем өзелә,**
**Фашист җитте минем башыма,**
**«Хак эш өчен үлде» диеп языгыз**
**Өстемдәге кабер ташына.**

Хак эш өчен үлгән ил сакчыларының якты образы халык күңеленә, халык хәтеренә тирән булып уелган. Моны раслаган мисаллар бирәү генә түгел, күбәү. Тол калган аналар исеменнән чыгарылган җырлар, бәетләр бәр. Шуларның берсенә, әле узган ел гына язып алынган бәеткә, тукталып үтәсе килә. «Тол солдатка бәете» дип исем кушканнар аңа. Бәет шул солдатка күңелен биләгән катлаулы кичерешләрне сурәтли. «Гөрләп кенә тормыш корган чакта» аның сөйгән ире сугышка китә һәм «ил өчен башын сала». «Үзәк өзгеч кара хәбәр» белән хатын һич тә килешергә теләми, иренең кайтуын көтә, сугыш басылганны көтә. Кечкенә балалар да әтиләрен көтәләр. Тик солдат кайтмый. Кичерешләр үсә, куера. Солдат хатыны «гомерлеккә юлдаш итеп» сайлаган иренең батырларча үлемен туган ил азатлыгы өчен зарури һәм котылгысыз бер трагедия итеп аңлый. Бәетнең соңгы юллары сугышка, үлемгә ачы нәфрәт булып яңгырый:

**Кычкырыгыз: «сугыш булмасын» дип,**
**Ишетелсен дөнья йөзенә,**
**Колак салсын һәркем без толларның**
**Җылый-җылый әйткән сүзенә.**

Сугыш чорындагы тыл фольклорының төп геройлары — татар хатын-кызлары дип әйтсәк, хата булмас. Алар йөрәгендә шыткан җырлар, алар телендә туган бәетләр үзләренең самимилеге, ихласлыгы, шигъри гүзәллеге белән безне бүген дә дулкынландыра. Ул әсәрләргә нечкә, саф лиризм хас. Әмма бу лирика чын мәгънәсендәге патриотик лирика, гражданлык хисләре белән сугарылган лирика.

---

[1] Бәетләр. Төзүчесе Х. Ярми. Казан. 1960 ел. 332 бит.

Алдарак искә алынган «Халык һәм җыр» китабында Ватан сугышы чорындагы татар халык иҗатының поэтик географиясе шактый киң булуы әйтелгән иде. Ул китап нигездә фронт һәм тыл фольклорын, вакытлыча дошман кулында калган Донбасс татарларының поэтик иҗатын тикшерүгә багышланды. Ә фронт шартларында дошман кулында әсир калып төрле лагерьларда газап чигәргә мәҗбүр булган совет сугышчыларының фольклорын өйрәнү эше киләчәккә калдырылды. Чөнки материаллар бик аз иде. Хәрби әсирләр фольклоры турында без хәзер герой шагыйрь Муса Җәлилнең көрәштәшләре сөйләгән истәлекләргә, алардан язып алынган шигъри әсәрләргә таянып та, башка чыганакларга нигезләнеп тә фикер йөртә алабыз. Дөрес, тупланган материаллар әле дә күп түгел. Ләкин булган кадәресенә кыска гына булса да бәя биреп узасы, бу фольклорга игътибар юнәлтәсе килә.

Мәгълүм булганча, әсирләр тормышын күз алдына китергән әдәби әсәрләр байтак. Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» исемле документаль повестен, Әнәс Галиевның «Йолдызлар шаһит» дигән ярым документаль әсәрен, Габдрахман Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» исемле мәгълүм романын искә төшерик. Өчесе өч жанрда, өч стильдә язылган бу әсәрләргә бер нәрсә уртак: алар фашист әсирлегенең бөтен авырлыгын һәм ачысын үз җилкәләрендә татыган кешеләр язмышына, аларның дошманга буйсынмас рухларын, фидакарь көрәшләрен сурәтләүгә багышланганнар. Ә. Галиев китабына язган кереш сүзендә шагыйрь Сибгат Хәким болай ди: «Мең төрле җәһәннәмне үтеп тә, рухлары сынмаган, иленә, халкына тугры булып калган совет кешеләренең Германия җирендә үлгән авыр эзләре бик тиз югалырга тиеш түгел». Урынлы һәм хаклы әйтелгән сүзләр. Аларны сугыш елларында әсирлекнең газаплы һәм рәхимсез язмышын уртаклашырга мәҗбүр булган татар солдатларының поэтик иҗатына карата да әйтергә була. Авторлары билгесез күп кенә бәетләр, җырлар, шигырьләр аша туган илгә һәм намусларына турылык саклап яшәгән, коточкыч авырлыкларга түзгән әсирләрнең җыелма образы күз алдына баса.

Тарих буенча без әсирләрнең күпчелеге дошман кулына сугышның иң авыр, беренче чорында эләгүен беләбез. Алар йөзләгән иптәшләре белән я дошман чолганышында калып, аннан котылу юллары бикле булган шартларда әсирлеккә эләгәләр, я авыр җәрәхәттән, контузиядән аңнары югалган хәлдә дошман кулына төшәләр. Сатлык генерал Власовның явыз хыянәте аркасында әсирлек хәленә калучылар да аз булмый.

Чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган лагерьлар, бараклар... Ачлыктан, ялангачлыктан, авырулардан, салкыннан интегүче меңләгән әсирләр. Алар әсирлек белән килешә алмыйлар, үзләренең язмышы өчен хурлык газабы кичерәләр, өзелеп илләрне сагыналар, бу мәхшәрле дөньядан котылу, качу турында, илгә кайту, дошманнардан үч алу турында хыялланалар. Әсирләр арасында коммунистлар яшерен эш алып баралар, фашизмның әшәкелеген фаш итеп, тоткыннарны яшәргә, көрәшкә рухландырып торалар.

Хәрби әсирләр тормышының әнә шундый шартларда үтүен без искә алган китаплар буенча да, Г. Кашшаф, Р. Мостафин, Ш. Маннур, Ю. Корольковның Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре турындагы әсәрләре буенча да яхшы беләбез. Җәлил белән әсирлектә очрашкан, төрле лагерьларда, төрмәләрдә җәфа чиккән кешеләрдән язып алынган һәм басылып чыккан истәлекләр дә шул хакта сөйли[1]. Хәрби әсирләрнең фашистлар кулында мең төрле газапларны күреп яшәргә мәҗбүр булуын сөйли торган һәм рус телендә чыккан китаплар, документлар гаять күп. Шул ук вакытта без кайбер әсирләрнең фашистлар һәм милләтче эмигрантлар коткысына алданып шымчы, полицай булып китүләрен, алар арасында иленә, халкына хыянәт иткән сатлык җаннар булуын да беләбез.

Мәгълүм булганча, Муса Җәлилнең яшерен оешмасы алып барган политик көрәштә, ялкынлы сүзләр язылган листовкалар, өндәмәләр белән бергә, поэзия, җыр, музыка да катнашкан. Рушат Хисаметдинов, Фәрит Солтанбеков үз истәлекләрендә татар легионы каршысында оештырылган әдәби-музыкаль капелла эшеннән Мусаның күп нәрсә көтүе, аңа ышаныч белән каравы турында язалар. Капелла репертуарын бик уйлап, үзләренә кирәкле фикерләрне уздырырлык итеп төзиләр. «Анда татар халык җырлары,

---

[1] Муса турында истәлекләр. Төзүчесе Гази Кашшаф. Казан. 1964 ел. 125—309 битләр.

илгә мәхәббәт үстерә торган, ата-ананы кадерләү, аларны сагыну кебек җырлар сайлана. Аларга шаян җырлар кыстырыла һәм саклык белән генә дошманга нәфрәт көчәйтә торган җырлар, шигырьләр бирелә»,— дип яза Р. Хисаметдинов[1]. Репертуарда Җәлил, Г. Курмашның патриотик шигырьләре, җырларына зур урын бирелә. Алар тирә-якта үлем биеп торган лагерьларда, крепостьларда телдән телгә, күңелдән күңелгә, дәфтәрдән дәфтәргә күчеп йөриләр, әсирләрдә өмет җылысы, көрәш рухы уятып яшиләр. Җәлил көрәштәшләреннән берсе Гариф Фәхретдинов әсирләр арасында таралган җырларның, шигырьләрнең «штыкка тиң булуын үз күзем белән күрдем»,— дип искә ала[2]. «Йолдызлар шаһит» әсәрендә әйтеп үткән капелланың Демблин лагеренда концерт бирүен тасвирлаган юллар бар. «Артистлар» әсирләр алдында татар халкының һәм композиторларының «Сәлам хат», «Сагыну», «Хуш, авылым» кебек җырларын башкаралар. Ул җырларны әсирләр йотлыгып тыңлый. Җыр «Туган якларны, аның җылы сулышын, газиз туганнарны, сөйгән ярларны күз алдына китереп бастырды. Барлык күргән җәһәннәм газаплары вакытлыча онытылды»,— дип яза автор.

Әдәби-музыкаль капелла тарафыннан эшләнгән эш үзенең асылы белән изге, чөнки аның нигезендә олы, якты идея яткан. Җәлил һәм аның дуслары меңләгән әсирләрне күңел төшенкелегеннән саклап, аларның туган илгә, халыкка булган мәхәббәт хисләрен, фашист ерткычларына ачы нәфрәтен сүндермичә яшәтергә тырышканнар һәм бу тырышлык бушка китмәгән.

Мәгълүм булганча, фашистлар хәрби әсирләрне ачтан тилмертү, кыйнау, юк кына нәрсәдән гаеп табып атып үтерү яисә ерак тылга җибәреп немецлар хуҗалыгында ялчы, батрак итеп эшләтү белән генә чикләнмиләр. Гитлерчылар төрле куркытулар, ялган вәгъдәләр юлы белән аерым милләт әсирләреннән легионнар төзеп, аларны үз туган илләренә — Советлар иленә сугышка җибәрү кебек мәкерле план да корганнар. Бу мәкерле чара гитлерчыларның җинаятьчел йөзен фаш итә, аларның хәрби әсәрләр турындагы халыкара конвенцияләргә төкереп каравын күрсәтә. Әмма милли легионнар фашистлар көткән нәтиҗәне бирми. Алар бер-бер артлы таркалалар. Гитлерчы фашистлар «Идел-Урал» легионы кешеләрен «иң ышанычсыз» дип тапканнар һәм 1943 елда Идел татарларыннан торган батальоннарны коралсызландырырга приказ биргәннәр[3]. Монда Җәлил оешмасының яшерен эшчәнлеге никадәр зур роль уйнавын аңлавы авыр түгел. Ә бу эштә Җәлил төп терәк итеп әдәби-музыкаль капелланы, андагы кешеләрнең фидакарь хезмәтен, димәк, әсирләр арасында таратылган листовкаларны, куелган концертларны, шул чакта яңгыраган шигырь һәм җырларны да санаган. Бу инде әсирләр арасында яшәгән поэзиянең һәм музыканың, шул исәптән фольклорның көрәш һәм тәрбия коралы дәрәҗәсенә күтәрелүен раслаган бер факт.

Фашистлар кул астында хисапсыз күп михнәтләр татыган татар әсәрләренең фольклорын искә алган капелла репертуарындагы әсәрләр белән генә чикләп булмый, әлбәттә. Капеллада катнашмаган һәм хәтта аның концертларын тыңлый да алмаган әсирләрнең поэтик иҗаты да булган. Әсирләрнең бер өлеше яннарында яшерен генә куен дәфтәрләре, блокнотлар йөрткәннәр. Борынгыдан килгән гадәт буенча (язма рәвештә иҗат ителгән иске солдат бәетләрен искә төшерик) алар үз дәфтәрләренә җырлар язганнар, язмышларына багышлап бәетләр, шигырьләр чыгарганнар. Шундый дәфтәрләрнең икесен миңа узган ел Рафаэль Мостафин тапшырган иде. Аңа бу дәфтәрләрне, Җәлил һәм җәлилчеләр турында материал җыеп йөргәндә, төрле районнардан җибәргәннәр.

Оренбургтан килгән бер дәфтәргә татар халкының туган илне, туганнарны, сөйгән ярларны сагыну турындагы 168 кыска җыры тупланган. Бу дәфтәр әсирнең халык җырларыннан өмет һәм юаныч эзләп, шулар ярдәмендә туган илне истә тотуын күрсәткән шигъри бер документ булып тора.

Хуҗасы билгесез икенче дәфтәргә җыелган шигъри әсәрләр исә тоткындагы әсирләр тормышын сурәтли. Дәфтәр хуҗасы, үзенә атап, шундый бер җыр да язып куйган:

---

[1] Шунда ук, 166 бит.
[2] Шунда ук, 204 бит.
[3] Муса турында истәлекләр. 280—281 битләр.

**Аклы ситсы күлмәгемне**
**Эләмен кадакларга,**
**Үтә инде яшь гомерем**
**Польшада баракларда.**

Дәфтәрдә күпчелек урынны шигырьләр алган, бер бәет тә бар, ләкин ул тулы түгел. Шигырьләрнең бер генә кешенеке түгеллеге, арада дәфтәрдән дәфтәргә күчеп йөргән строфалар булуы да сизелә. Ничек кенә булмасын, ул шигырьләрнең һәр юлында үзенең әсирлек язмышыннан хурланып, ачынып яшәгән тоткыннарның йөрәк тибеше ишетелә. Шигырьләрнең берсендә әсир кеше үзенең башыннан кичкән хәлләрне, бәетләрдәге кебек, бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Ул үзе Карабаш авылыннан. Сугышка киткәндә аны әти-әнисе, хатыны, ике баласы озатканнар. Фронтта чагында күзгә караңгы төннәрнең берсендә юл адашып, ул бәхетсезлеккә дучар булган — әсирлеккә эләккән. Менә базар кебек гел хәрәкәттә кайнап торган лагерь, агач бараклар, чәнечкеле чыбыклар.

**Плен хәлен язып бетереп булмый,**
**Үзе булган кеше яхшы аңлый.**
**Ачка тилмерешеп, үлем көтеп**
**Каршылыйсың монда һәр таңны,—**

ди ул.

Ачтан аның якын дусты үлә, үзе дә немец «баландасы ашап» көчкә генә җанын саклап йөри, аның бер генә теләге бар: «сыерчыклар белән язын илгә кайту», кабат рәхәт, тыныч тормышта яшәү. Ул җылы җилләр, җитез кошлар аша туган ягына, Зәй буена, якын кешеләренә сәлам җибәрә, үзен шушы хәлгә калдырган өчен явыз сугышны каһәрли.

Шигырьләр арасында поэтик яктан кытыршы урыннар да очрый. Ләкин, тулаем алганда, ул әсәрләр татар әсирләренең реаль кичерешләрен, газаплы тормыш картиналарын дөрес, ихлас сурәтләүләре белән игътибарны җәлеп итәләр.

Шөгердән Хәлимә Мияссарова-Ишбулдина җибәргән фольклор әсәрләре арасында үз вакытында хәрби әсирләр иҗат иткән өч бәет тә бар. Аларның кемнән, кайчан, кайда язылып алынуы билгесез. Фольклор әсәрен өйрәнгәндә авторлык мәсьәләсе беренчел әһәмияткә ия дә түгел. Игътибар үзәгендә әсәрнең идея-эстетик кыйммәте ята. Шул күзлектән караганда, ул бәетләрне, һичшиксез, өйрәнергә кирәк.

Тормышны чагылдыру, типиклаштыру алымнары ягыннан солдат бәетләре, шул исәптән хәрби әсирләр арасында туган бәетләр икегә аерыла. Аларның бер төркемендә без бәетне чыгарган солдатның биографиясе белән шактый якыннан танышабыз. Солдат бәетне үзе өчен яза, көндәлек язган кеше кебек, ул үз башыннан үткән хәлләр, вакыйгаларны тасвирлый, аларга эмоциональ мөнәсәбәтен белгертеп, кичерешләрен әйтеп уза. Бәет аның конкрет язмышына багышланган, шуңа күрә ул үзе катнашкан сугышның кайчан башлануын, авылдан ничек чыгып китүен искә төшерә, гаскәри булгач, нинди калалар, авыллар аша узуын, кайсы фронтларда йөрүен терки. Шулай итеп, бәет чыгаручының биографиясендәге лирик индивидуаль сызыклар тарихның конкрет бер чоры белән, эпик вакыйгалар һәм заман билгеләре белән кушыла. Мондый төргә караган бәетләрне фольклорчылар лиро-эпик бәетләр дип атыйлар. Алар гадәттә зур күләмле булалар, телдән әйтелеп түгел, ә язма рәвештә яшиләр. Билгеле бер кешенең шәхси язмышына багышланган булу сәбәпле, бу бәетләрнең шактые гаилә ядкаре булып саклана һәм бер өлеше генә халык арасында таралып, мәгълүм булып китә.

Мондый бәетләр традициясе күптәннән килә. Аерым үрнәкләре искә алган «Бәетләр» китабында бар. Бөек Ватан сугышы чорында туган шундый бәетләрнең берсе «Халык һәм җыр» китабында бирелгән иде. Аны элеккеге фронтовик Гайнелвәлиев Габделбарый үзе үткән сугышчан юлларны искә төшереп госпитальдә ятканда чыгарган һәм 1955 елда миңа экспедиция белән Кайбыч районы Борындык авылына баргач тапшырган иде.

Хәрби әсирләр арасында да биографик бәетләр иҗат ителгән. Әсирлектән котылып кайткан аерым кешеләр кулында шундый бәетләр барлыгы мәгълүм. Кызганычка каршы, аларның үрнәкләре безнең кулда хәзергә юк әле.

солдат бәетләренең икенче төре — лирик бәетләр. Гадәт буларак, алар күләмнәре белән кыска, эстетик сыйфатлары белән җырларга якын торган бәетләр. Халыкның лирик озын җырлары шикелле, алар да билгеле бер көй белән яшиләр, психологик сюжетка, дәвамлы хис хәрәкәтенә корылган булалар. Бәет герое башыннан кичкән хәл-вакыйгаларны түгел, ә шул вакыйгалар уяткан кичерешләрне лирик планда гомумиләштереп сурәтли. Шуңа күрә мондый бәетләр халык арасында күбрәк тарала, күбрәк очрый.

Алда искә алган өч бәет менә шушы төркемгә карыйлар. Алар гыйбрәтле мәгънәгә ияләр. (Бәетләрнең тулы текстларын без бу мәкаләгә теркәп бирәбез.) Һәр өч бәетне дә рухлары белән дошманга буйсынмаган совет кешеләре иҗат иткән. Үзләренең эчке мәгънәләре, хис-фикер юнәлеше белән бу бәетләр Җәлил һәм аның дуслары тарафыннан татар әсирләре арасында таратылган шигырьләргә, җырларга аваздаш. Бәетләрнең буеннан-буена туган илгә турылык саклау, аның җиңеп чыгуына ышанып карау мотивы үтә.

Фашистлар әсирләр арасында бертуктаусыз: «Туган илегез сезне гафу итмәячәк, сезнең язмышыгыз хәл ителгән инде», дип агитация алып барганнар, әсирләрне үз якларына аударырга, үз кубызларына биетергә тырышканнар. Ләкин дошман кубызына биючеләр меңләгән кешелек лагерьларда бик аз булган. Намуслылар әнә шул сатлык җаннарны да хурлык тамгасы белән билгеләп, аларның чын йөзләрен фаш иткәннәр. «Тоткын әсирләр бәете»ндә «акча-зиннәткә сатылган», «полицай-куштан булып йөрүче» вак җанлыларга нәфрәт белдерелә.

Әсирләрне ялан саен тентеп торганнар, язулы кәгазьләрне, блокнотларны юк иткәннәр. Шуңа да карамастан, әсирләр «Гитлер этләрен», «явыз фашистларны» үз исемнәре белән атап, аларга нәфрәт белдерүдән курыкмаганнар, туган илгә — Советлар иленә мөрәҗәгать итеп, үзләрен бу аяныч язмыштан коткаруны сораганнар.

> **Чәнечке чыбык, һич булмый чыгып,**
> **Гитлер этләре канны эчә сыгып,**
> **Безнең канатны сугыш каерды,**
> **Туган илләрдән яшьләй аерды.**
>
> **Безнең канатны язмыш каерды,**
> **Газиз башкайлар илгә кайтырмы!**
> **Ташлагыз эшне, җыегыз көчне,**
> **Явыз дошманнан алыгыз үчне,—**

дип тәмамлана «Әсирләр бәете». Калган ике бәеттә дә «безнекеләр шиксез җиңәр», «туган илем җиңеп чыгар» кебек ихлас өмет белдерелә. Әсирләр үз язмышлары өчен ачыргалану газабы кичерсәләр дә, Совет армиясенең фашистларны җиңеп чыгуына тирән ышанганнар, котылу көнен көткәннәр һәм туган илдә кабат «хөр иркенлектә» яшәү турында хыялланганнар.

Революциягә кадәрге иске солдат бәетләренә, җырларына күз салсак, без аларда мондый мотивны таба алмыйбыз. Немец филологы Роберт Лах беренче империалистик сугыш вакытында Германиядә әсир калган солдатларның фольклорын аерым бер китап итеп бастырган. 1925 елда немец телендә чыккан ул китап «Россия хәрби әсирләренең җырлары» дип атала. Китапта татар әсирләреннән язып алынган җыр, бәетләр дә бар. Аларда әсир туган-үскән җирен сагынса да, үзенең хәсрәтле язмышыннан котылу юлын күрми. Сыйнфый тигезсезлеккә корылган патша строе, илендәге социаль тәртипләр аның өчен ят, ул аларны кире кага һәм ярдәмне үз иленнән түгел, ә күбрәк «ходай»дан көтә.

Җыйнап әйткәндә, Бөек Ватан сугышы чорында әсирлектә калган татар солдатларының поэтик иҗаты, бер яктан, фашистларның хәрби әсирләргә карата рәхимсез һәм җинаятьчел политикаларын фаш итсә, икенче яктан, меңләгән әсирләрнең дошман алдында баш имичә, буйсынмас рух белән яшәүләре, туган илгә турылык саклаулары турында сөйли.

Бөек Ватан сугышының җиңү белән тәмамлануына чирек гасырдан артык вакыт узды. Туган илебез өчен гаять авыр сынау булган, социалистик дәүләтебезнең какшамаслыгын, совет халыкларының бердәмлеген һәм патриотизмын күрсәткән азатлык сугышын, ил өчен җаннарын биргән батырларны без истә тотабыз.

Татар халкының сугыш чорындагы фольклоры халыкның шул чордагы кичерешләрен, омтылышларын тирән дөреслек белән, сәнгатьчә чагылдырган шигъри елъязма буларак, үзенең иҗтимагый-тәрбияви һәм әдәби-эстетик кыйммәтен бүген дә саклый.

## Әсирләр бәете

Төштем фетнәгә, нихәл итмәгә,
Тоткынлык каты, булмый китмәгә.
Без әсир монда дошман кулында,
Без корбан бүген Ватан юлында.

Ерактыр илем, моңлыдыр күңелем,
Ялгыздыр үзем, инде бир түзем;
Сөекле илем диеп җан атам,
Әй, туган җирем, кайчан соң кайтам!!

Хөр иркенлектә үстем илемдә,
Ватаным саклап төштем пленгә.
Аяныч хәлем, сөяктер тәнем,
Яндыр бәгърем, һич юк әмәлем.

Без монда җыйнау, аякта богау,
Зобаный кебек алалар сорау.
Суга тилмереп, каты кимереп,
Ятабыз череп, тереләй үлеп.

Аякта башмак, йөрибез шак-шак,
Газиз җаннарны булырмы саклап!..
Без монда ялчы, аркада камчы,
Моны күргәнче җаннарны алчы.

Чәнечке чыбык, һич булмый чыгып,
Гитлер этләре канны эчә сыгып.
Безнең канатны сугыш каерды,
Туган илләрдән яшьләй аерды.

Очар кошлар да, тезелеп сафларга,
Елашып очты безнең якларга.
Кошлар очканда Татарстанга,
Егылып калабыз буылып канга.

Кошлар, хушыгыз, тизрәк очыгыз,
Туган җирләргә барып төшегез.
Хәерле булсын сезнең юлыгыз,
Кайта алмасак, бәхил булыгыз.

Безнең канатны язмыш каерды,
Газиз башкайлар илгә кайтырмы!
Ташлагыз эшне, җыегыз көчне,
Явыз дошманнан алыгыз үчне!

---

Мамадыш ягыннан күчереп алып кайттылар (кунакка барган җирдән). Мин алардан күчердем. (Хәлимә Миңссарова-Ишбулдина искәрмәсе. Хәлимә Ишбулдина 1913 елда туган, озак еллар буе Шөгердә зоотехник булып эшләгән, хәзер пенсионерка.)

## Тоткын әсирләр бәете

Баш өстемнән кара болыт
Кайчан гына китәр икән!
Әсирлектә язган хатлар
Сезгә барып җитәр микән!

Очар кошлар ерак җиргә —
Җитәрләрме туган илгә!
Без җибәргән хат-хәбәргә
Җавап килми нигә бер дә!

Әсирлектә җәфа чигәм,
Сөйләп кенә сүзем бетмәс.
Йөрәкләрдән яра китмәс,
Күзебездән яшьләр кипмәс.

Кая минем туган илем!
Кайталмаслык җиргә килдем.
Туган-үскән илләремдә
Нужа күрми яши идем.

Кая безнең яшел урман,
Бу кайгылар кая торган!
Безнең кебек булыр микән
Көне-төне яна торган!

Берәүләргә назар[1] салсак,
Күзеннән коя канлы яшь,
Берәүләргә назар салсак,
Ашыйдыр татлы-татлы аш.

Берәүләргә назар салсак,
Уралган кайгы-хәсрәткә
Берәүләргә назар салсак,
Сатылган акча-зиннәткә.

Берәүләргә назар салсак,
Кавыштыра дусларына.
Берәүләргә назар салсак,
Бер полицай куштан гына.

Исә җилләр, үтә көннәр...
Саный-саный минутларны,
Явыз фашистлар кулында
Яшь гомер үтә утларда.

Чыда, күңелем, хәсрәтләргә,
Өйрән, күңелем, михнәтләргә.
Туган илем җиңеп чыккач,
Без чыгарбыз рәхәтләргә.

Шәгердә күчереп алдым. Күп кешедә бар. (Хәлимә Мияссарова-Ишбулдина искәрмәсе.)

## Бетәр әле, бетәр сугыш...

Минем тоткын күңелкәем
Чит-ят җирләрдә тарсына,
Үз илемә кайтыр өчен
Очар кошлардай талпына.

Үтәр идек таулы җирдән,
Түзә-түзә салкын җилгә,
Курыкмыйча кара төндә
Кайтыр идек туган илгә.

Талпынабыз — очалмыйбыз,
Канатны язмыш каерды,
Әсирлектә яшь түгәргә
Туган илләрдән аерды.

Тарихларда гына калыр
Бетәр әле, бетәр сугыш,
Дим буе, изге җирләргә
Кире әйләнеп кайтыр бар кош.

Өмет өзмик, бик таралмыйк
Хәзергә булса да авыр.
Безнекеләр шиксез җиңәр
Күргәннәр сөйләргә калыр!

---

Бәет Шәгер ягында таралган. Бер дәфтәрдән күчердем. (Хәлимә Мияссарова-Ишбулдина искәрмәсе.)
[1] Назар — караш.

Альберт Айнетдинов

# ВАТАН СУГЫШЫ ҺӘМ ЯЗУЧЫЛАР

Бөек Ватан сугышы елларында татар язучылары һәм журналистларының эшләре әлегә кадәр җентекләп өйрәнелмәгән. Әдипләр башкалар турында күбрәк язалар. Үзләре турында сөйләргә алар кыенсыналар булса кирәк.

Матбугат йортында урнаштырылган ак мемориаль стенд яныннан беркем дә тыныч кына үтә алмый. Анда алтын хәрефләр белән Бөек Ватан сугышында һәлак булган әдипләребезнең исемнәре язылган. Шушы кадерле исемнәр арасында хәрби журналист Рим Баһау бар. Ул алгы сызыкта сугышчан бурычны үтәгәндә һәлак була. «Суворовчы» исемле фронт газетасы үзенең хәбәрчесе турында 1944 елның 3 август санында некролог урнаштырган.

> «1944 елның 24 июлендә, сугышчан задание үтәгән вакытта, газетабызның сотрудникы өлкән лейтенант Баһаутдинов Рим иптәш һәлак булды.
>
> Иптәш Баһаутдинов 1909 елны Татарстан республикасының Бондюг районында эшче семьясында туа. Ул заводта эшләгән вакытында комсомол сафына кереп, яшьләр арасында актив эш алып бара. 1932 елны, Казан энергоинституты рабфагын тәгәлләгәннән соң, ВЛКСМның Татарстан оешмасында җитәкче эшләрдә эшли.
>
> 1933—34 елларда иптәш Баһаутдинов Кызыл Армия сафында хезмәт итә.
>
> 1935 елдан башлап 1941 елга кадәр иптәш Баһаутдинов өлкә газеталарында җаваплы эшләрдә эшли. Башта ул «Яшь сталинчы» газетасының бүлек мөдире булып, ә аннан соң редакторы булып эшли. 1939 елны «Кызыл Татарстан» газетасының культура бүлеге мөдире хезмәтенә күтәрелә.
>
> 1941 елның июнь аенда иптәш Баһаутдинов Кызыл Армия сафына алына һәм, политик работник буларак, җаваплы постларда эшли. Соңгы вакытта иптәш Баһаутдинов «Суворовчы» газетасының корреспондент-оештыручысы булып эшли иде.

Иптәш Баһаутдинов кайда гына һәм нинди генә постта эшләмәсен, һәр җирдә дә зур авторитет һәм ихтирам белән файдаланды. Үзенең дисциплиналыгы һәм журналистлык таланты белән күпләргә үрнәк булды. Партия члены буларак, ул үзенең бөтен белемен һәм энергиясен Ватанга, үз халкына хезмәт итүгә бирде. Ул бөтен җаны-тәне белән халык эшенә бирелгән ялкынлы большевик-журналист иде.

Ватаныбыз аның сугышчан хезмәтләренә югары бәя бирде. Иптәш Баһаутдинов 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнде.

Иптәш Баһаутдиновның бу сыйфатлары бездә — аның белән бергә эшләгән якын дусларында — озак вакытлар сакланыр. Немец-фашист илбасарларга каршы көрәш фронтында сугышчан постта геройларча һәлак булган батыр журналистның гүзәл образы халкыбызның йөрәгендә мәңге сакланыр.

Н. БУБНОВ, Г. БУРЛАКОВ, В. ХМЕЛЕВСКИЙ, М. ШӘЙМӘРДАНОВ, К. ШӘРИПОВ, Н. ЮСУПОВ, Г. ДЕКОНОИДЗЕ, В. ВАРТАНЬЯН, А. БАЙБИКОВ, Н. ЖЕЛЯЕВ, Я. ФАЙНШМИДТ, Б. МӘҖИТОВ Л. ХӘЛФЕЕВА, К. СӨЛӘЙМАНОВ, Р. КОЧАР, К. ЛАПИН, А. ЛАПИН».

Иптәш Баһаутдинов үзенең түбәндәге мәкаләсен «Суворовчы» газетасы редакциясенә җибәреп өлгерә алмаган. Мәкалә аның кыр сумкасыннан табыла һәм соңыннан гына басылып чыга.

«РИМ БАҺАУ.

## ПАРТОРГ БАТЫР БАСАНОВ

Көчле энергияле бу коммунистта кыю сугышчының һәм партоешма җитәкчесенең гүзәл сыйфатлары берләшкәннәр. Иптәш Басанов үзенең ялкынлы сүзе, сугыш кырында большевистик чакырулары белән сугышчыларны яңа батырлыкларга рухландыра, дошманны җиңүгә булган омтылышны тагын да көчәйтә.

Парторг Басанов рота коммунистлары алдында сугышчан бурычларны дөрес куя белә һәм шунлыктан коммунистлар ул бурычларны зур теләк һәм дәрт белән үтиләр. Рота, коммунистлары сугыш кырында арыслан кебек сугышалар һәм немец хәшәрәтләрен рәхимсез рәвештә кыралар.

Сугыш кырында кыюлык һәм батырлык үрнәге күрсәтү башка сугышчыларны рухландыра. Берәү батырлык эшли алган икән, димәк, бүтәннәр дә аны эшли алалар. Моны сугышчы күрә һәм аннан үрнәк ала. Шулай итеп, батырлар семьясы туа. Парторг Басанов моны яхшы аңлый һәм аерым кешеләрнең сугыш кырында күрсәткән геройлыкларын популярлаштыруга җитди әһәмият бирә.

Менә кайбер мисаллар. Коммунист Зацераннин һөҗүм вакытында алдынгы сафта булды. Ул кыю, кискен сугышты һәм, хәтта яралангач та, немецларны кыруын дәвам иттерде. Коммунистның бу кыюлык үрнәген парторг Басанов шунда ук сугышчыларга җиткерде. Ул бу эштә: «Укы да иптәшеңә бир»,— дигән листовканы файдаланды. Чыдамлы кеше җиңә, кем үз-үзен кызганмый, шул җиңә! Парторг язган листовкада менә шушы суворовчыл фикерләр әйтелгән иде һәм ул сугышчыларны яңа батырлыкларга рухландырды.

Сугышчылар бу листовканы укыганнан соң һөҗүм темпын тагын да көчәйттеләр. Гвардия өлкән сержанты Разумовский авылга беренче булып бәреп керде һәм үзенең уты белән иптәшләренә юл ачты. Омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә авыл бик тиз дошманнан чистартылды.

Гвардия кызылармеецы Булатов бер группа сугышчылар белән немецлар батареясы тылына үтеп керде һәм ике орудиянең расчетын юк итеп, тозек пушкалар кулга төшерде. Иптәш Булатовның геройлыгына багышлап парторг махсус листовка чыгарды. Анда: «Геройдан үрнәк алыгыз һәм Булатов группасы кебек сугышыгыз»,— дип язылган иде.

Һөҗүм башлану алдыннан иптәш Басанов партия җыелышы үткәрде. Коммунистлар үзләренең чыгышларында немецларны гвардиеецларча кырырга, рота алдына куелган сугышчан бурычны үрнәкле рәвештә үтәргә ант иттеләр. Коммунистларның сүзе эштән аерылмады. Алар сугышчан осталык һәм батырлык үрнәкләре күрсәттеләр.

Һөҗүм итүчеләр алдында парторг үзе барды. Ул сугыш барышында листовкалар гына чыгарып калмады, немецларны ничек оста кыйнарга кирәклекне дә күрсәтте. Сугышчылар парторгны һәм коммунистларны һәрвакыт алгы сафта, иң кыен һәм авыр урыннарда күрделәр. Парторг Басанов үзе уникe немецны үтерде, гитлерчы офицерны һәм ике фашист солдатын пленга алды. Коммунистлардан Кузнецов һәм Кулеков, Зеленцев һәм Пиявский иптәшләр батырлык һәм кыюлык үрнәкләре күрсәтеп, геройларча сугыштылар.

Өлкән сержант Батыр Басанов парторг булган ротаның коммунистлары — алар массаның чын җитәкчеләре — сугышчыларны рухландыручылар, ротаны яңа җиңүләргә алып баручылар.

Батальонның героик командиры гвардия майоры Третьяк болай ди: «Коммунистлар миңа бик яхшы ярдәм итәләр. Алар минем иң ышанычлы ярдәмчеләрем». Әйе, коммунистлар командирның ышанычлы һәм якын ярдәмчеләре. Аларны данлыклы большевик — рота парторгы өлкән сержант Батыр Басанов тәрбияләп үстерде. Алар ротаның мактанычы».

«Суворовчы» газетасы. 1944 ел. 6 август.

Менә шулай фронттагы язучылар һәм журналистлар үзләренең сүзләре һәм ралллары белән илбасарларга каршы көрәштеләр. Тылдагы әдипләребез дә фронтка рып, үз күзләре белән хәрби тормышны күрергә теләделәр. Күренекле язучылардан Разин [Г. Бәшир], М. Әмир, Ф. Хөсни һәм тагын берничә кеше фронтта булдылар. а телендә чыга торган хәрби газеталарда үзләренең корреспонденцияләрен бастырылар.

Тылдагы язучылар үзләренең әсәрләре белән халыкны патриотик рухта тәрбиyяделәр. Республикабызның газета-журнал битләрендә даими рәвештә әдәби әсәрләр сылып торды. Менә шушы әсәрләрнең окопларга, алгы сызыкка барып җитүе — ул н-чынлап тыл белән фронтның бәйләнеше. Фронтовик өлкән сержант Г. Акчурин турыда менә нәрсә яза:

> «Офицер Чиняев подразделениесендәге татар сугышчылары «Совет әдәбияты» журналын бик яратып укыйлар. Күренекле татар язучыларының һәм шагыйрьләренең журналда басылган әсәрләре сугышчыларны дулкынландыралар, аларны үз бурычларын тагын да яхшырак үтәргә өндиләр»[1].

Сугышчылар ана телендә чыга торган газета редакцияләренә язган хатларында арстанның культура тормышы турында күбрәк материал урнаштыруны сораганнар. че сержант А. Сәйфетдинов «Ватан өчен сугышка» газетасына язган хатында: «...Язуплар, артистлар, художниклар белән элемтәне ныгытыгыз; аларның мәкаләләрен күбк урнаштырыгыз»,— дип яза.

> «Мин үзем башкорт егете,— ди Г. Илчебаев.— Татар телендә чыга торган «Алга, дошман өстенә» газетасын бик яратып укыйм. Анда төрле кызыклы хәбәрләр басыла. Газетада җырлар һәм шигырьләрне күбрәк язуыгызны сорыйм»[2]».

Татар хәрби журналистлары сугышчыларның үтенечләрен үтәү өчен тылдагы язупларга мөрәҗәгать иткәннәр. Газеталарга бер-бер артлы тылдан халкыбызның гүзәл

---

[1] «Ватан өчен сугышка», 30 сентябрь; 1943 ел.

[2] «Алга, дошман өстенә», 5 май; 1944 ел.

эшләрен, сугышчан батырлыкларын тасвирлаган хикәяләр, очерклар һәм шигырьлар килгән.

Татар язучылары ана телендә чыга торган фронт газеталары битләрендә иҗади эшләре турында отчет биргәннәр.

РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, орденлы драматург Таҗи Гыйззәт фрон товикларга багышланган иҗади отчетында менә нәрсә язган:

«Татар халкы фронтовикларга язган хатында: безнең гасырлар буенч көрәшеп алган азатлыгыбызны, милли бәйсезлегебезне, культуралы бай тор мышыбызны җимереп, үзләренә кол итәргә омтылучы немец илбасар лары белән рәхимсез рәвештә көрәшергә, изге Ватаныбыз туфрагына ая баскан актык фашист шакшысына кадәр тончыктырып бетергәнче сугы шырга өндәп, барлык татар егетләрен чакырган иде.

Сез, әлбәттә, ул чакыруны кабул иттегез, ата-аналарыгызның, кардәш ыруларыгызның һәм бөтен татар халкының намусын саклыдыгыз, үз исем нәрегезне дан, шөһрәт, гайрәт, батырлык белән каплыдыгыз.

Инде хәзер безгә — тылда яшәүчеләргә: «Менә сез үзегез ни эшләде гез!» — дип сорау бирергә тиешлесез. Бу хаклы һәм гадел сорау ди беләм.

Шул сораугa җавап итеп Ватан сугышы чорындагы иҗатым белән сез не таныштырып китәсем килә.

Немец илбасарлары хыянәтчән һөҗүмнәрен башлаганда, мин акфин нәргә каршы булган сугыш тормышыннан алынган «Таймасовлар» исемле әсәремне тәмамлау өстендә эшли идем. Билгеле, сугыш башлану белән бу әсәрнең бик күп җирләрен үзгәртергә һәм әсәр өстендә тагын да шак тый гына эшләргә туры килде. Әсәрем язылып бетү белән, Татар академия театрына куелырга алынды һәм хәзер дә сәхнәдән төшми уйналып килә.

«Таймасовлар»дан соң өч пәрдәлек «Төнге сигнал» дигән әсәрем язылды. Бу әсәр Ватан сугышы тематикасына язылган беренче әсәр булу ягыннан совхоз, колхоз театрларында, клуб үзешчән түгәрәкләрендә ре пертуар кытлыгын бетерүдә яхшы ук хезмәт күрсәтте. Әле хәзерге көнгә кадәр, үзенең актуальлеген югалтмыйча, күп кенә җирләрдә уйналып килә. Шуннан соң мин «Башмагым» опереттосының либреттосын яздым. Бу әсәр комедия булу ягыннан кызыклы, татар тормышында булып үткән кайбер тискәре якларны үткен рәвештә җанландыруы, композитор Җәүдәт Фәйзи тарафыннан язылган музыканың уңышлы булуы аркасында көткән максат ны тулысы белән яклады. Ике елдан бирле Татар Дәүләт опера сәхнәсен дә уйналып килә, йөз меңләгән тамашачыларның иң яратып караган спек такльләреннән берсе булу дәрәҗәсенә ирешә.

«Башмагым»нан соң «Ташкыннар» трилогиясенең икенче сериясе бул ган «Даулы көннәр» дигән әсәремне яздым. Бу әсәр соңгы сериясе язы лып бетмәү нәтиҗәсендә хәзерге көнгә кадәр сәхнәдә уйналмый тора. Тиздән, «Шаулы көннәр» исемле соңгы өченче сериясе язылып бетү бе лән, өч серия бер тоташтан куела барачак. Хәзерге көндә Донбасс тата шахтерларының немец оккупациясе вакытындагы тормышыннан «Зарза ман» исемле әсәрем өстендә эшлим. «Зарзаман» әсәре аша фашизмны безнең илгә никадәр афәт, никадәр газап, никадәр ачы хәсрәт, күз яшь ләре алып килүен, татар халкының, башка халыклар белән берлект явыз дошманга каршы ничек итеп көрәшүен, хәтта кайберләрнең гомум җиңү өчен аңлы рәвештә үз-үзләрен корбан итү кебек батырлыкларг кадәр барып җитүләрен художество образлары аша бирергә телим».

Бу тарихи язма 1944 елның 8 июлендә «Совет сугышчысы» газетасында басылы чыккан. Шушы ук газета 1944 елда үзенең битләрендә язучылардан Гомәр Разы (Бәширов) һәм Фатих Хөсни чыгышларын оештыра:

«Сугыш елларында мин нәрсәләр яза алдым! — дип үз-үзенә сора бирә Бәширов. — Сугыш ялкынының беренче айлары эчендә бер-ике кеч кенә хикәям басылып чыкты, туган ил кичергән иң кыен чорларның ка бер күренешләре берничә очеркта сызылып калды. Төньяк-көнбатыш

фронт сугышчылары белән бергә уздырган ике-өч айда сугышның берничә дәһшәтле сулышын «Гармоньчы егет» исемле очерклар китабында бирергә тырыштым.

Билгеле, болар берсе дә күңелемне канәгатьләндерә алмый әле. Совет сугышчыларының каһарманлыгы каршында культуралы бөтен дөнья зур ихтирам белән баш ия! Бу пәһлеваннар арасында татар халкының ун меңнәрчә уллары безнең халыкның батырлык данын, кардәш халыклар арасында дәрәҗәсен тагын да күтәрделәр. Алар безнең мактанычыбыз, алар безнең куанычыбз.

Хәзер мин сугышчы туганнар турында «Татар егете» исемле бер повесть язам. Балаларың кебек газиз булып әверелгән әнә шул сөекле образлар белән бергә узган бик күп йокысыз төннәр җанга рәхәт, күңелгә чиксез дәрт бирә.

«Намус» исемле тагын бер хикәя язам. Шундый авыр сынау чорында туган иле һәм сөеклесе — фронттагы газизе каршында керсез намус белән бөтен кыенлыкларны җиңеп чыгучы безнең кадерлеләребез — хатын-кызларның чын күңелен, саф мәхәббәтен күрсәтмәкче булам».

Фатих Хөснинең дә фронтовикларга сөйләрлек сүзләре бар иде, ул да фронтның авыр тормышын үз күзе белән күрә.

«Фаҗигаләр һәм якты өметләр бергә үрелеп яшь бүген. Халык гигант көч салып көрәшә һәм без инде бу көрәшнең якты нәтиҗәләрен дә күрәбез — алда җиңү факелы яна!

Язучының һәм художникның бүгенге бурычы — безнең халкыбыз кичергән гаять зур масштаблы, тирәнгә, эчкә киткән вакыйгаларны, кичерешләрне, тойгыларны дөрес итеп чагылдырып калу.

Мин үзем көньякта, фронтта булып кайттым. Татарстан авылларында күп кенә колхозларда булдым һәм, ниһаять, татар совет әдәбиятының көндәлек практикасында, авыр шартларда журнал чыгаруда катнаштым. Кайбер нәрсәләрне күрдем мин, татыдым яки татучыларны күрдем. Хәзер шушыларны тәртипкә салырга, формага куярга кирәк. Күп кенә хикәяләр яздым һәм язып киләм. 1943 елда минем «Урман сукмакларым» дигән җыентыгым басылып чыкты һәм менә фронт хикәяләре һәм «Авыл хикәяләре» циклыннан икенче бер җыентык тапшырдым. «Йөзек кашы» дигән повесть яздым. Хәзерге көндә фронт тәэсирләренә нигезләнгән «Абли авылы» дигән трагедия язып ятам. Әсәр — 1942 елның караңгы көзен, киеренке хәлләрне Иделнең көньяк өлеше буендагы борынгы татар (мишәр) авылы, оккупацияләнгән татар авылы, фонында яктыртачак дип уйлыйм. Әсәр театрга кабул ителде, ләкин эшләү процессының тукталганы юк әле.»

«Данлы сугышчыларыбызга Ватан сугышы көннәрендәге иҗатым турында рапорт бирәм,— дип яза күренекле язучы К. Нәҗми.— Немец илбасарларының безнең иркле илебезгә хыянәтчел төстә һөҗүм итүләре турындагы хәбәрне ишетү белән үк, мин «Фашизмга үлем!» исемле беренче шигыремне яздым. Шул көннән башлап, үземнең бөтен иҗатымны Бөек Ватан сугышы темасына багышладым. Ул әсәрләр «Атакага!», «Таныш урын», «Ватан өчен» исемле җыентыкларда һәм газета-журнал битләрендә басылып килделәр.

Бер үк вакытта миңа публицистик мәкаләләр, очерклар һәм балалар өчен әсәрләр дә язарга туры килде.

Күптән түгел опера өчен очучылар тормышыннан язылган «Фәридә» исемле либреттомны тәмамладым. Хәзер мин татар халкының немец илбасарларга каршы сугышларда катнашуын чагылдырган тарихи повесть өстендә эшлим һәм Татарстанның 25 еллыгына багышланган «Батырлар китабы» исемле әдәби-художестволы альбомга материаллар җыям. Бөек

Ватан сугышы батырлары турындагы бу зур күләмле китапны язу эшенә мин сезне, сугышчы иптәшләр, якыннан торып катнашырга чакырам».

(«Совет сугышчысы» газетасы, 1944 ел, 5 май саны[1])

Язучы һәм журналистларның әсәрләре, иҗади отчетлары, тылдан килгән җылы сүзләр татар сугышчыларына зур тәэсир итте, аларны каһарманлыкка, дошманны җиңәргә өндәде. Бу турыда фронтовик-язучы Атилла Расих 1945 елның 10 гыйнварында «Фронт хакыйкате» газетасында болай дип язып чыкты:

...Өйдән килгән һәрбер хат, җөмлә һәм һәрбер сүз безнең күңелебездә тирән эз калдыра. Чөнки безнең берничек тә андагы кешеләрдән аерылганыбыз юк. Без асылда һаман элекке акыл хезмәткәрләре, чөнки без җансыз кимерүчеләр түгел, без — төзүчеләр, тыныч тормышның гамьле аталары һәм улләры... Тыл безне шатландыра, ул безнең рухи тормышыбызның да яртысы...»

Татар сугышчылары язучыларга зур ихтирам белән караганнар һәм аларга өч почмаклы хатларында солдат сәламнәре җибәргәннәр. Менә шушы хатларны хәрби язучылар — журналистлар эзләгәннәр һәм газета битләрендә бастырганнар. Менә шуларның берсе, Карелия фронтының бер группа сугышчылары хаты:

«Кадерле иптәш Илья Эренбург!

Ерак төньякта фин илбасарларын тар-мар итеп баручы Карелия фронты сугышчыларыннан Сезгә, илебезнең ялкынлы язучысына, күктәге йолдызлар, дәрьялардагы сулар санынча сугышчан кайнар сәлам күндерәбез.

Әле май аенда, алгы кырыйда, тар землянкада җыелып, без, татар сугышчылары, үзебезнең ана телебездә чыга торган газетабызда Сезнең «Төньяк солдатларына» язган хатыгызны укыган идек. Ул хат безнең күңелләрдә чиксез зур горурлык һәм рух күтәренкелеге тудырды. Без барыбыз да Сезгә хат язарга булдык. Ләкин шул ук көнне түгел, ә «Карелиядә яз булгач». Көткән көннәр килеп җитте. Менә бездә дә яз! Без Свирь аръягында. Без Главнокомандующий рәхмәтен алуга ирештек! Финнарны тар-мар итеп, без һаман алга барабыз, безне һичнәрсә туктата алмый. Без таулар, урманнар һәм сазлыклар аркылы үтәбез. Үтәбез һәм акфин палачларыннан барлык явызлыклары өчен рәхимсез үч алабыз.

Кадерле Илья Эренбург иптәш! Сезнең ялкынлы сүзләрегез безне һәрвакыт һөҗүмгә ашкындырып тордылар һәм торалар. Безгә дәрт һәм дәрман бирүегез өчен рәхмәт әйтәбез.

Сугышчан сәлам белән:

Разведчиклар: ЕФРЕЙТОР ГОМӘР САДРИЕВ, ЕФРЕЙТОР ГЫЙЛЬМАН ГӘРӘЕВ; бронебойщиклар: ӨЛКӘН СЕРЖАНТ САЛИХ СИБГАТУЛЛИН, КЕЧЕ СЕРЖАНТ ГАЗЫЙМ МӨХЕТДИНОВ, КЫЗЫЛАРМЕЕЦ ӘМИН МОРТАЗИН, КЫЗЫЛАРМЕЕЦ ШАКИР ФӘСХЕТДИНОВ; санитарлар: СТАРШИНА МӨХЕТДИН ГАЛЛӘМОВ, СТАРШИНА ТӘХӘҮ ДӘҮЛӘТШИН».

ИЛЬЯ ЭРЕНБУРГНЫҢ ҖАВАП ХАТЫ.

30 июль, 1944 ел

Мәскәү шәһәре.

КАДЕРЛЕ ДУСЛАР!

Сезнең хатыгыз мине бик көчле дулкынландырды. Фронтларда миңа бик күп тапкыр батыр татар сугышчылары белән очрашырга туры килде. Сез тыныч, хезмәт сөючән халык идегез, ә явыз дошман безнең хатынкызларыбызны һәм балаларыбызны җәберсеткәндә, туган туфрагыбызны мәсхәрәләгәндә, Сез татарның сугышчы халык булып әверелүен күрсәттегез.

Сезне сугышчан уңышларыгыз белән котлыйм. Сезгә истәлек өчен китабымны җибәрәм һәм каты итеп кулларыгызны кысам.

ИЛЬЯ ЭРЕНБУРГ».

---

[1] Газетаның шушы номерында К. Наҗминең өч җыры урнаштырылган.



Бу хатларны «Ватан өчен сугышка» һәм «Ватан намусы өчен» газеталары бастырганнар.

Татар хәрби язучылары һәм журналистлары газеталары җанлы һәм эчтәлекле булсын өчен сугышчыларның үзләрен газета эшенә тартырга кирәк икәнлеген яхшы аңлаганнар. Һәрбер татар телендәге фронт газеталарының редакцияләре штаттан тыш военкорлар группасын оештырганнар. Алар батыр иптәшләренең исемнәрен мәңгеләштерәләр. Алар изге, мөкатдәс эш эшлиләр— кораллары белән дә, каләмнәре белән дә кабахәт дошманга каршы көрәшәләр. Кайбер газеталарның эшләренә актив катнашкан сугышчыларның исемнәрен күрсәтеп үтик: «Ватан өчен сугышка» газетасына актив язучылар арасында Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов, гвардияче Лотфулла Кашапов, йөздән артык фашистны үтергән снайпер Хәйдәр Сибгатуллин, снайпер Булат Мөхәммәтханов, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнгән сапер Шәүкәт Ильясов, Дан ордены кавалеры минер Мифтах Шәмсетдинов, радист Нәҗип Исмәгыйлев, старшина санинструктор М. Галләмов, кызылармеецлар Мидхәт Яхин, Нури Сәмигуллин, Сәлиха Җиһаншина, разведчик Сәүбан Зарифуллин һәм башка бик күпләр.

Газета битләрен җентекләп караганда, бер фотокарточкага күз төште. Яшь сержант сиңа таба туп-туры карап тора. Фото астындагы язуын укыганнан соң, бу кеше «Тревога» газетасының актив хәбәрчесе Әдип Маликов икәнлеге билгеле булды. Әйе, булачак язучы үзенең каләмен самурайларга каршы көрәштә чыныктыра. Ул Көньяк Сахалинны азат иткәндә күрсәткән каһарманлыгы өчен «Батырлык өчен» һәм «Японияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Ленинград гвардиясе баһадиры, рота парторгы өлкән лейтенант Каюм Яһүдин Ханко ярым атавындагы дәһшәтле сугышларда, Ленинград блокадасын өзүдә катнаша һәм сугыш кырыннан системалы рәвештә «Ватанны саклауда» газетасына хәбәрләр җибәреп тора. Газета битләрендә аның үнлаган материаллары басылган. Менә шуларның берсе белән танышыйк.

«БӨЕК ШӘҺӘР ӨЧЕН

Гасырларча үстең, тимерләндең,
Даның бөек, үзең кадерле!
Җиңелмәдең, мәңге җиңелмәссең,
Изге шәһәр — Ленин шәһәре!

Мөкатдәс таш урамнары, тәкәббер зур йортлары белән бөек Ленин шәһәре — революция бишеге тора безнең артта. Сугыш бүген дә шушы бөек шәһәр — Ленинград өчен барды.

Без батыр сугыштык, гайрәтле сугыштык. Чөнки без бик яхшы беләбез: Ленин шәһәре — безнең революциябезнең, безнең халкыбызның символы. Анда яңа эрага пәрдә ачылды, аның урам ташларында бөек юлбашчының җуелмас эзе бар. Дошман атакаларын кире кактык — бөек Ленин шәһәре өчен, ярсып атакаларга бардык — бөек Ленин шәһәре өчен.

Сугыш башыннан бирле, фашист бандаларын кире какканда һәм дошман өстенә һөҗүмгә барганда бу сүз безнең телләрдә меңнәрчә мәртәбәләр кабатланды, шул ук чакыру авазы астында җәен дә, кышын да, көзен дә, язын да безнең сугышчылар дошман өстенә ыргылдылар.

— Бөек Ленин шәһәре өчен!

Бүген үзенең взводын коммунист Ибраһим Яркаев та шулай дип ата-

кага күтәрде. Һәрбер сугышчы канэчкеч немецларга каршы шушы чакыру астында алга ыргылды.

...Сугыш бик каты бара иде. Немецлар ярсып-ярсып һөҗүм иттеләр. Взвод командиры сафтан чыкты. Ә аның урнын гвардия ефрейторы Ибраһим Яркаев алды. Батыр һәм яхшы иптәш — Татарстан егете. Элекке колхозчы. Ә хәзер — автоматчы.

Взвод, яу булып, дошман өстенә барып җитте. Автомат, миномет, граната, приклад, мылтык һәм штык — барысы безнең өчен көчле корал булды. Дошманга түзәргә мөмкинлек юк иде. Үлесе — аунап калды, тересе — качып китте. Сугыш тулысынча җиңү белән бетте.

Сугыш бетәр-бетмәс автоматчылар ротасының командиры, гвардия лейтенанты иптәш Массальский Яркаевка кечкенә генә кәгазь кисәге җибәрде:

— Кыю, батыр хәрәкәт итүегез өчен сезгә рәхмәт белдерәм.

— Мең рәхмәт Сезгә, иптәш Яркаев,— диде ул соңыннан.— Сез, беренчедән, алдыгызда торган дошманның көчле атакасын уңышлы рәвештә кире кактыгыз һәм, икенчедән, үзегез кыю рәвештә хәрәкәт итеп, каршы атакага чыктыгыз, бик күп дошман солдатларын кырдыгыз. Ниһаять, минем чолганып калган группама ерып чыгу өчен мөмкинлек бирдегез.

Бу операциядән соң командование Ибраһим Яркаевны Кызыл Байрак ордены белән бүләкләде. Хәзер аның күкрәгендә — Кызыл Байрак ордены, Гвардия билгесе, «Батырлык өчен» һәм «Ленинград оборонасы өчен» медальләре.

Татар халкының батыр уллары революция бишеге — бөек Ленин шәһәре өчен менә шулай сугышалар, революция казанышларын, Ватанның бәхетен, намусын һәм азатлыгын менә шулай саклыйлар». («Фронт правда»сы, 1943 ел, 16 ноябрь.)

Бөек Ватан сугышында катнашкан язучыларның һәм журналистларның эшләрен гомуми күләмдә чынлап торып өйрәнергә бик вакыт. Газета һәм журнал битләрендә аларның истәлекләрен ешрак күрәсе килә.

Һәнүз Мәхмүтов

# СӘЕТ ШӘКҮРОВ ДРАМАЛАРЫ

Әдәбиятның башка тармаклары кебек үк, драматургиябез дә сәләтле яшь авторлар хисабына тукаусыз тулыланыП тора. Узган ун-унбиш ел ченда гена дә сәхнә әсәрләре язучылар трядына унлап яңа исем өстәлде. Шуларның берсе — драматург Сәет Шәкүров.

Соңгы елларда Сәет Шәкүров әсәрләре ıəм профессиональ, һәм үзешчән театр әхнәләрендә шактый уңыш белән бара. Аның «Тормыш бусагасында», «Зөһрә юлдыз», «Уракчы кыз» (боларның һәрберсе аерым китап булып та басылып ыкты) һәм «Мәхәббәт газабы» кебек пьесалары тамашачыларга яхшы таныш. Яңа әсәрләреннән «Туган туфрак» драмасы Татар академия театры сәхнәсендә уңышлы ына куелып килә. Драматургның колхоз тормышы, ватан сугышы чорында авыл катын-кызларының язмышы, аларның героик хезмәтләре турында тагын бер әсәр — драматик поэма төгәлләп ятуы билгеле. Шулай булгач, Сәет Шәкүров иҗаты хакында да гомуми бер фикер йөртергә, ниндидер сүз әйтергә вакыт җиткәндер кебек.

С. Шәкүровның яза башлавы утызынчы елларга туры килә. Үзенең каләм көчен ул Казан театр техникумында укыганда һәм, аны тәмамлап, Минзәлә театрында артист булып эшләгән елларда сыный башлый, шул заманда беренче хикәяләрен һәм пьесаларын яза. 1937 елда «Чәчәк атабыз» һәм «Чәчәкләр» исемле җыентыкларда яшь авторның «Таң алдыннан» һәм «Алсу» кебек хикәяләре басыла, 1938 елда исә башлап язучыларның «Пьесалар» җыентыгында «Орденлы Касыйм» дигән өч пәрдәле сәхнә әсәре дөнья күрә. «Орденлы Касыйм» пьесасында стахановчылык хәрәкәтенең авыл хуҗалыгында да җәелә баруы, хезмәт фронтында крестьяннарның зур уңышка ирешүләре һәм тракторчы Касыймның, эштә дан казаныП, Ленин ордены белән бүләкләнүе сурәтләнә.

Авторның бу пьесасын һәм беренче хикәяләрен җитлеккән әсәрләр рәтенә кертеп булмый, әлбәттә. Ул әсәрләрдә чын мәгънәсендә тормышчан итеп корылган сюжет-конфликтлар да, ышандырырлык итеп эшләнгән образлар да күренми диярлек. Аларны яшь авторның әдәби иҗат өлкәсендәге беренче тәҗрибәләре дип карарга кирәк. Кызганычка каршы, беренче каләм тибрәтүләрдән соң С. Шәкүровка егерме елга якын иҗат эше белән ныклап шөгыльләнергә туры килми. 1939 елда ул Совет армиясе сафына алына, ул да түгел, Бөек Ватан сугышы башланып китә. Сәет башыннан ахырына кадәр сугышта катнаша, каты яралана, контузия ала, инвалид булып кайта. Шуңа да карамастан, иҗат эшен ташламый. 1946—1959 елларда Минзәлә һәм Республика күчмә театрларында, шулай ук Академия театры сәхнәсендә байтак образлар тудыра, әкренләп сәхнә әсәрләре язу эшен дә җанландырып җибәрә.

С. Шәкүровның драматург булып танылуы беренче чиратта героик-романтик пафос белән сугарылган әсәрләр иҗат итүенә бәйле. Аның иҗатындагы бу үзенчәлекләргә тәнкыйть тә игътибар итә килә[1].

1 А. Әхмәдуллин. Драматургия уйлана, эзләнә. «Казан утлары» журналы. 1969 ел. 8 сан. 158—159 битләр.

Ул үз әсәрләрендә илебез тарихында тирән эз калдырган чорларны ала. Аның халкыбыз тормышындагы аерым тарихи этапларны гәүдәләндергән «Уракчы кыз», «Зөһрә йолдыз» һәм «Туган туфрак» кебек әсәрләре нәкъ шул төргә карый.

«Уракчы кыз» героик драмасы халкыбыз күңелендә күптән сакланып килгән һәм Н. Исәнбәт сүзләренә җырлана торган җырга нигезләнеп язылган әсәр. Ситуацияләре, кайбер образларның бирелеше ягыннан ул Ф. Хөснинең «Утызынчы ел» романына да якын тора. Драмада утызынчы еллардагы колхозлашу чорының героик һәм фаҗигале вакыйгалары бирелә. Колхозлашу чорында аеруча кискенләшеп киткән сыйнфый көрәш турында сәхнә әсәрләре үз вакытында байтак булды. «Уракчы кыз» драмасы исә, үзенчәлекле сюжетка корылып, бүгенге караштан чыгып язылган әсәр буларак, үзенең оригиналь яңгырашын тапты. Монда колхоз төзү һәм кулакларны сыйныф буларак бетерү кискен көрәш аша киеренке итеп сурәтләнә.

Драманың төп герое итеп уракчы кыз Сәрбиназ алынган. Ул кулак Ишнияз кулында кимсетелеп үскән бер ятимә кыздан курку белмәс, кыю һәм аңлы колхоз җитәкчесе дәрәҗәсенә күтәрелә. Сәрбиназ үзенең тыйнаклыгы, мөлаемлыгы, чын күңелдән сөя белүе, рухи дөньясының байлыгы белән аерылып тора. Әсәр башыннан ахырына кадәр шушы образның күркәм сыйфатлары белән җылытылган. Сәрбиназ күренмәгән эпизодларда да, башка персонажларның сөйләме, күтәренке рухлы җыры аша бу образның сәхнәдә яшәвен тамашачы һәрвакыт тоеп утыра. Хәтта аерым урыннарда аңа эзлекле үсеш, табигый тон җитмәү сизелсә дә, образ җылы тәэсир калдыра, яратып кабул ителә. Сәрбиназ үзенең уй-тойгылары, эш-хәрәкәтләре, мәхәббәте белән шул чорның романтик рухлы бер татар кызы буларак күз алдына килеп баса.

Драмада социализм төзү өчен көрәшнең алгы сафында барган коммунист Искәндәр һәм Шәрәф, комсомолец Гали образлары бар. Бу персонажларның драматик вакыйгалар агышында тоткан рольләре шулай ук зур. Шунлыктан аларны да тулырак эшләнгән образлар итеп күрәсе килә.

«Уракчы кыз» драмасы үзе иңләп алган чор вакыйгаларын һәм геройларын бөтен яклап тирән итеп ачып бирүгә дәгъва кылмый, әлбәттә. Искәндәр, Шәрәф һәм Гали кебек уңай образларның бирелешендә психологик тирәнлек җитми. Ишнияз кулак һәм аның кызы Гөлнәзирә, коткы таратып йөрүче Мәгъри карчык кебек тискәре типлар исә тормышчанрак һәм образ буларак көчлерәк гәүдәләнә кебек. Гәрәй гаять катлаулы һәм кызыклы образ. Әмма элекке партизан Гәрәйнең характерындагы каршылыклы моментлар бар. Аның авыл кешеләре белән начар мөгамәләсе, тупаслыгы, тәкәбберлеге, кулаклар белән буталуының сәбәпләре ныклап ачылмый кала. Авылда беренчеләрдән булып колхоз оештырып йөргән бу кешенең яңа тормышны, яңа тәртипләрне ни өчен аңлый алмавын һәм үзен-үзе атып үтерүгә кадәр барып җитүен тирәнрәк итеп күрсәтү кирәк иде. Гәрәйнең бер юлдан гына бара алмавының төп сәбәбен күрсәтә торган ниндидер деталь җитми кебек. Гәрәйгә якынрак торган Исми картның исә, хәйләкәр төлкедәй аумакайланып йөреп, нәтиҗәдә бер мескен хәлендә калуы ышандырырлык итеп сурәтләнә. Аның тоткан юлы да, инанган кыйбласы да юк, аңа бүген җан асрарлык азык булса шул җитә, кояш кайсы яктан җылытса, ул шул якка тәгәри.

Гомумән алганда, «Уракчы кыз» драмасы колхозлашу чорын шул чорның романтикасы белән рухланып яшәгән геройлар язмышы аша күтәренке пафос белән чагылдырган үзенчәлекле әсәр буларак игътибарны җәлеп итә. Бездә әле халкыбызның үткәне турында мондый пьесалар аз языла. Бу әсәр бүгенге көннең матурлыгын ныграк аңларга, бүгенге тормышның кадерен белергә һәм аны сакларга, намуслы хезмәткә өнди. Шуңа күрә дә менә ничә еллар инде ул Минзәлә театры репертуарында уңыш белән бара. Татарстаннан тыш, аны Башкортстан, Үзбәкстан, Казагыстан республикаларының һәм Астрахань, Свердловск, Пермь, Ульяновск, Ленинград шәһәрләренең тамашачылары да яратып карый. Үзешчән театр коллективларының 1967 елда үткәрелгән Бөтенроссия смотрында «Уракчы кыз» драмасы белән Әтнә халык театры лауреат исеме яулап алды, ә автор беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. Бу аның игътибарга лаек җитди әсәр булуы турында сөйли.

Соңгы елларда татар драматургиясендә бөек идеалларны, зур проблемаларны эченә алган, югары этик һәм эстетик принципларны алга сөргән, вакыйгаларны һәм образларны килешмәүчән кискен конфликт аша калку итеп сурәтли торган, бөек тәнкыйтьче В. Г. Белинский әйткәнчә, «драма-

тик поэзиянең югары ноктасын һәм таҗын» тәшкил иткән трагедия жанры беркадәр сүрелеп торды. Тәрбияви әһәмияте зур булган бу жанр әсәрләре әлегә азрак туа һәм тамашачыга сирәк күрсәтелә. Бу жанр, әлбәттә, һәм язучыдан, һәм театр коллективыннан зур осталык, кыюлык, фәлсәфи фикер йөртә белүне сорый. Трагедия ул тормышның бөтен катлаулылыгы белән һәм каршылыклы ситуацияләрдә гәүдәләндерүне таләп итә. Килешмәүчән көчле конфликтлар аша бөек идеалларга омтылучы геройларның индивидуаль сыйфатларын калку итеп ачып бирүне күздә тота. Трагедия язу өчен, азатлык өчен көрәш яки сугыш һәм тынычлык, гомумкешелек идеяләре белән бәйләнгән мәхәббәт проблемалары аеруча отышлы. Бу яктан караганда, С. Шакуровның Бөек Ватан сугышы чорындагы киеренке вакыйгаларга багышланган «Зөһрә йолдызы» трагедиясе игътибарга лаек.

Сугыш һәм кеше язмышы темасы бу героик чорда меңәрләгән совет кешеләрендә күренгән батырлык һәм патриотик идеалларны шактый тирән чагылдырырга мөмкинлек биргән. Үзе дә озак еллар сугышта булган һәм фашизм алып килгән зур трагедияне үз күзе белән күргән С. Шакуров шул көрәшнең аерым эпизодларына нигезләнеп, аерым шәхесләр язмышы аша трагедия әсәре тудыру юлында житди адым, зур омтылыш ясаган. Трагедия традицион шигъри формада, героик романтика белән сугарылган оптимистик рухта язылган. Автор вакыйгаларны баштан алып ахырга кадәр киеренке һәм мавыктыргыч итеп сурәтләргә тырыша. Җәйге авыл, яшьләрнең уен-көлкеләре, сугыш кыры, партизанлык итү, геройларның дошман кулына эләгү һәм җәзалланулары, җиңү тантанасы күренешләре, шул ситуацияләрдә мәхәббәт, батырлык, хыянәт һәм фаҗига бер-берсе белән үрелеп бирелә.

Вакыйгалар үзәгендә Таһир һәм Зөһрә образлары тора. Болар халкыбызга электән билгеле булган борынгы легенда геройлары түгел, әлбәттә. Әмма С. Шакуров трагедиясенең геройлары да шул мәшһүр дастан геройларына якын, шуларга аваздаш итеп бирелә. Аерма зур, әлбәттә, тегесендә феодаль җәмгыятьтәге шәхесләр алынса, монысында совет җирлегендә тәрбияләнеп үскән яшьләр образы гәүдәләнә. Таһир белән Зөһрә саф күңелле, курку белмәс батыр йөрәкле, соңгы сулышларына кадәр туган илгә турылыклы шәхесләр итеп сурәтләнә. Бу образлар аша автор илебезнең бәйсезлегә өчен авыр көрәштә катнашкан улларыбыз һәм кызларыбызның чыдамлылыгын, рухи өстенлеген дулкынландыргыч итеп бирә алган. Әсәрдә коммунизм идеологиясе белән фашизм идеологиясе арасында көчле тартыш бара, бу бәрелештә азатлык һәм гуманизм идеяләре җиңеп чыга. Бу — идеяләр көрәшеннән торган совет трагедияләренә хас төп үзенчәлек.

С. Шакуровның авыр жанрда, өстәвенә шигырь белән язылган бу әсәре, уңай моментлар өстенлек иткән хәлдә, шулай ук кимчелекләрдән дә азат түгел. Кайбер күренешләр ашыгычлык белән, өстәнрәк эшләнгән, аерым ситуацияләр арасында логик эзлеклелек җитми, геройларның, бигрәк тә Зөһрәнең дошман кулына бик тиз элегүе һәм аның телсез булып кылануы үзе үк шик тудыра, шулай ук рифма эзләгәндә кайбер сүзләр һәм шигырь юллары урынсыз кулланыла. Әсәрдә башка характердагы кимчелекләр, килеп җитмәгән урыннар да бар. Жанр ягыннан чыгып караганда да әсәр трагедия таләпләренә тулысынча җавап бирми кебек. Бәлки, әсәрне тагын да көчәйтәсе, һәр ике лагерь геройларын тагын да үстерәсе, психологик тирәнәйтәсе калгандыр. Ләкин ничек кенә булмасын, «Зөһрә йолдызы» — куелган мәсьәләнең сәнгатьчә чишелеше, идея-эстетик кыйммәте ягыннан сәхнәбезгә кирәкле әсәр. Көчле конфликтка корылган, нинди генә авырлыклар алдында да югалып калмый торган тапкыр, акыллы, һәр яктан да яшьләргә үрнәк булырлык характерларны эченә алган мондый трагедияләрнең тәрбияви әһәмияте бәхәссез. Зур югалтулар белән яулап алынган бүгенге тормышыбызның канлы көрәш тарихы иканлеген мондый әсәрләрдә күрсәтү бик кирәк. Бүгенге көн тамашачысының ихтыяҗларын искә алганда һәм драматургиябезне төрле жанрдагы пьесалар белән баету ноктасыннан караганда, аның кыйммәте тагын да арта. С. Шакуровның трагедия әсәрләре иҗат итүдә осталык күрсәткән Ф. Бурнаш, һ. Такташ, Н. Исәнбәт кебек олы язучыларыбызның традицияләрен үзенчә дәвам итәргә омтылуы, бу катлаулы жанрдагы тәҗрибәсе, эзләнүләре уңай бәягә лаек.

Драматургның олы идеяләрне, ил язмышына бәйле вакыйгаларны, көчле характерларны эченә алган тагын бер әсәре, әйтәнебезчә, «Туган туфрак» дип атала.

Бу әсәр тәнкыйтьтә шулай ук уңай бәя алды[1].

«Туган туфрак» драмасы Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан алып бүгенге көнгә кадәр булган зур чорны эченә ала. Автор вакыйгаларны хроникаль тәртиптә сурәтли. Без монда өч зур этапны: сугыштан соңгы авыр еллар, авыл хуҗалыгын үстерүдәге билгеле бер хаталар һәм алардан арына бару һәм, ниһаять, бүгенге көндә колхоз авылының алга зур сикереш ясавын күрәбез. Авыл хуҗалыгын аякка бастыру өчен көрәш әсәрдә төп тема итеп алынган.

Авторны монда, әлбәттә, беренче чиратта, алынган вакыйгалар үзәгендә торган шәхесләр язмышы, тормышны алга этәрүдә төп көч булып торган заман геройларының һаман алга, яктыга, матурлыкка омтылуы, кыенлыкларны җиңә барып, көчле рухлы кешеләр булып формалашуы кызыксындыра. Әсәрдә игътибарны җәлеп итәрлек кызыклы гына эшләнгән образлар бар. Анда үзенең туган ягын алмаштырырлык изге урынны, туфракны Татарстанда тапкан украин кызы Галина һәм татар егете Арслан кебек күпләргә үрнәк булырлык зур тормышлы кешеләр сурәтләнә. Алар куркү белмәс батыр сугышчы да булганнар, тыныч тормышта да кешe бәхете өчен бөтен көч, сәләтләрен кызганмыйча хезмәт итеп хөрмәт казаналар. Алар семья мәсьәләсендә, мәхәббәттә, шәхси-интим мөнәсәбәтләрдә дә зур сынаулар аша үтеп, бер-берсенә турылыклы булып калалар. Бер-берсенә карата булган һәм беркайчан да сүрелми торган олы мәхәббәт хисләре аларга катлаулы һәм авыр тормыш юлын намус белән үтәргә ярдәм итә. Галина һәм Арслан чын патриотлар итеп бирeләләр, бигрәк тә шушы образларның язмышы, уйтойгылары, хыяллары, эш-хәрәкәтләре аша туган туфрак, туган җирнең ни дәрәҗәдә кадерле булуы ачыклана. Хәйдәр, Гариф, Игорь һәм Мәликә образларының да матур гына тасвирлануын, вакыйгалар агышына ярдәм итәрлек итеп бирелүен әйтергә кирәк.

Әмма Игорь белән Мәликә мәсьәләсе беркадәр бәхәс тә кузгата кебек. Галина Игорьның беренче мәхәббәте булган, алар өйләнешергә дә сүз куешканнар, ләкин бик күп фаҗигаләр тудырган сугыш аларны да аерган. Галина Арсланны очраткан, аның белән яши башлаган. Бу — аңлашыла. Ә менә Игорьның өйләнмичә, беренче мәхәббәтенең башка берәү белән гомер кичерүен күзәтеп яшәгәндәй бирелүе, аның шул бәхет белән дә канәгать булуы табигыйлектән беркадәр читләшә кебек. Автор моны Игорьның фәнгә бирелүе, зур галим, медицина профессоры булгач, шәхси тормышны кирәк тапмавы белән аклаcа, аңлатса бер хәл иде, әмма шуны әйтеп яки күрсәтеп җиткерми ул. Игорьның болай бирелүе отышлы түгел, ул ясалма чыга, ваклана, бер мәзәк кешегә әйләнә. Мәликә мәсьәләсе дә шулайрак хәл ителгән. Аның сөйгән егете сугышта хәбәрсез югалган. Мәликә аны һаман көтә, һаман бер үзе шәхси ялгызлык трагедиясен кичерүне дәвам итә. Бу образ яңалыгы белән дә артык аерылып тормый.

Үз инициативасы булмаган, бары тик югарыдан кушканны гына көтеп ятучы догматик, авыл халкының тормышы белән кызыксынмаган эшлексез колхоз председателе Сөләйман, аның сәеркәсе һәм соңыннан хатыны Маргарэт (Мәрьямбану) кебек тискәре типлар шактый оригиналь, кызыклы һәм үзенчәлекле итеп бирелгәннәр, алар күбесенчә көлкеле сыйфатларда гәүдәләнәләр.

Алынган теманы, вакыйгаларны, образларны автор шул чорга хас авырлыклар, кимчелекләр фонына куеп, кыю гына сурәтли. Әлбәттә, зур чор алыну материалны җыйнак кына итеп, көчле, эзлекле драматизм аша бирүгә комачаулый, пәрдәләр арасындагы озак елларны эченә алган сикерешләр вакыйгаларның өзлексез агышына зыян китерә. Өстәвенә җитди генә башланган һәм матур гына дәвам иткән беренче ике пәрдәдән соң ахырда сентименталь, мелодраматик элементлар килеп кереп, әсәрнең романтик рухын үзгәртә, образларны көчсезләндерә. Бу хәл актерларның уенында да кыенлык тудыра.

Аерым кимчелекләргә булуга карамастан, «Туган туфрак» драмасы сугыштан соңгы еллардагы авыл тормышын, авыл кешеләрен үзенчәлекле итеп, бүгенге караштан чыгып беркадәр яңача чагылдыру белән игътибарны җәлеп итә. Ул тамашачыда туган илгә, туган туфракка мәхәббәт тәрбияли торган җитди әсәр буларак сәхнәдә урын ала.

С. Шәкүров бер пәрдәле әсәрләрдә дә тирән идея-фикер үткәрә алу сәләтен күрсәтте. Аның Октябрь революциясенең 50

[1] Х. Кумысников. Крупным планом. «Советская Татария» газетасы. 1970 ел. 27 январь саны.

ллыгы уңае белән бер пәрдәле пьесалар-
а Республика халык иҗаты йорты һәм
«Казан утлары» журналы үткәргән конкурс-
та «Ана» драмасы иң яхшы әсәр дип та-
былды һәм премиягә лаек булды. Бу әсәр-
дә 1937 елларда хаксызга рәнҗетелгән,
озак вакытка хөкем ителгән ананың бүген-
ге тормышка кайтуы, бер миллионер кол-
хозда председатель булып эшләгән һәм
авыл халкын онытып җибәргән улына хата-
ларын күрсәтүе һәм аңа дөрес юлга юнә-
леш бирүе турында сүз бара. Кечкенә кү-
ләмле булса да, бу драма югары әхлак
принципларын ышандырырлык итеп пропа-
гандалый, олы җанлылык, кеше турында
кайгыртучанлыкның үрнәген бирә.

Авторның «Тормыш бусагасында» һәм
«Мәхәббәт газабы» исемле драмалары бү-
генге көн темасына багышланган әсәрләр
рәтенә керә. Боларда хәзерге заман яшь-
ләренең тормыш-көнкүреше, уй-тойгылары,
гадәт-әхлаклары, омтылышлары, аларга
хас ялгышлыклар сурәтләнә, яшь буынны
тәрбияләү мәсьәләсе куела.

«Тормыш бусагасында» драмасы 1956
елда языла һәм, Минзәлә театрында куе-
лып, берничә сезон уңышлы гына бара.
Аны Әтнә, Азнакай, Түбән Кама, Башкорт-
станның Ишембай һ. б. халык театрлары да
күп еллар уйнап килә. Бу драма семьяда
бала тәрбияләүнең нинди җитди мәсьәлә
булуын, дөрес тәрбия алмау аркасында ял-
гыш юлга баскан балаларның нинди һәла-
кәт алдында торуларын гаять кызыклы һәм
кискен конфликт аша беркадәр маҗаралы
ситуацияләрдә тасвирлавы белән харак-
терлы. Беркемгә дә сер түгел, яхшы гына
тормышлы семьяда үскән балаларның да,
иң элек ата-ананың кечкенәдән баланы ар-
тык иркәләве, тиешле-тиешсезгә аның ки-
рәлегенә, үзсүзлелегенә юл куюы аркасын-
да бозылып, эгоист булып тәрбияләнүе, со-
ңыннан начар юлга басып, кешелектән чы-
гу фактлары әлегә очрый. «Тормыш буса-
гасында» драмасы әнә шундыйларның бер-
се турында сөйли. Милиция полковнигы
Хәйдәров, бала тәрбияләүдә хатыны Дил-
бәргә ышанып, Маратның юлдан язуын
күрми кала. Эшнең нәрсәдә икәнлеген аң-
лагач, әни кеше дә, әти дә хаталарын төзә-
тергә тотыналар, ләкин инде соң була...

Үзсүзле, бозык характерлы булып тәр-
бияләнгән яшүсмер Марат, караклар шай-
касына ияреп, кеше үтерүгә барып җитә,
һәм үзе дә караклар кулыннан һәлак була.

Әсәрдә аналы-уллы Раушан һәм Исмә-
гыйль, аналы-кызлы Зөһрә һәм Фирдәвес
кебек персонажларның да язмышы, ялгыш-
лары, үз-үзләрен тотыш-кыланышлары, үт-
кәне һәм бүгенгесе Дилбәр белән Марат-
ка янәшә куеп, гыйбрәтле итеп тасвирлана.

Әлбәттә, драмада тискәре типларга, кү-
ренешләргә урын күбрәк бирелгән, бу
әсәрне, шулай әйтергә яраса, тискәре ге-
ройлар романтикасы белән сугарылган, дип
тә була, ләкин уңай көчләр барыбер җи-
ңеп чыга, җинаятьчеләр фаш ителә, изге-
лекнең өстенлеге раслана.

Инде «Мәхәббәт газабы»на килсәк, бу
әсәр лирик драма төренә карый. С. Шәкү-
ров башка әсәрләреннән аермалы буларак,
монда төп игътибарын геройларның эчке
психологиясен, нечкә хисләрен, лирик ки-
черешләрен тирәнрәк ачуга юнәлтә. Аның
иҗатындагы бу үзенчәлекле уңай момент-
ны Минзәлә театрының Казандагы гаст-
рольләре уңае белән язылган мәкаләсендә
Б. Гыйззәт тә әйтеп үткән иде[1].

Әсәрдә вакыйга Кама буендагы бер шә-
һәрдә төзү материаллары заводында эш-
ләүче яшьләр турында бара. Ашыгычлык
белән бик яшьли өйләнешкән Фазыл һәм
Сурия, үзе дә сизмәстән алар арасына
килеп кергән авыл кызы Энҗе образлары
үзәк планда бирелә.

Бу драмада С. Шәкүров мәңге искерми
торган, һәр заман һәм чор үзенчә хәл итә
торган мәхәббәт һәм семья мәсьәләләрен
хезмәт темасы белән тыгыз бәйләнештә
күрсәтергә һәм вакыйгаларны геройларның
эчке кичерешләрен тирән ачу аша, бертөр-
ле шигърият белән сурәтләргә омтыла.
Беркадәр шуңа ирешә дә. Әсәрнең рухы-
на туры килгәнчә, яшьләрнең өйләнү күре-
нешләре башта җиңелчә юмор, көлкегә ни-
гезләнеп, комик пландарак бирелсә, соңга
таба инде, геройлар үз ялгышларын аңлый
башлагач, вакыйгалар агышы җитдиләнә,
эчке драматизм белән тулылана.

Бу әсәрдәге җәмгыятьтә үз урынын таба
башлаган, тормышка ышанычлы гына адым
ясаган, әмма шәхси мәсьәләләрдә берка-
дәр югалып калган, уңышсызлыкка очраган
яшьләр образлары белән танышкач, тү-
бәндәге нәтиҗә чыга: семья нык булсын
өчен иң элек бер-береңне аңлау, теләкләр
бердәмлеге, эштә һәм тормыш-көнкүреш-
тә фикер, карашлар уртаклыгы булырга
тиеш икән. Яшь чактагы һәрбер вакытлы

---

1 Б. Гыйззәт. Своеобразие творчества. «Советская Татария» газетасы. 1968 ел. 19 сентябрь.

мавыгу семья кору өчен нигез була алмый. Тормышта сыналган, чын мәхәббәткә нигезләнеп корылган семья гына бәхетле була, зур эшләргә рухландыра ала. Уңышсыз семья чын тормыш, зур омтылышлар белән яшәүгә комачаулый.

Әлбәттә, драмада Фазыл, Сүрия һәм Энҗе образларының бирелешендә кайбер уйлап җиткерелмәгән моментлар да калган. Бер яктан, Сүриянең 6—7 ел торган үз ирен үзе теләп Энҗе белән кавыштырырга карар кылуы, икенчедән, Фазыл белән Энҗе бер-берсен бик нык яратып та, бу яратуның ныклыгы тормыш сынаулары белән исбат ителгәч тә, вакыйгаларның агышы шуңа этәргән хәлдә дә Энҗенең Фазылдан китүе канәгатьсезлек тудыра, мәхәббәт белән шаяругарак кайтып кала. Монда автор мәхәббәткә өстенлек бирүдән шикләнгәнме яисә кысыр булса да инде төзелгән семьяны саклап калу бурычын куйганмы, ачыкланып җитми.

Драмада киң күңелле, олы җанлы, яшьләргә һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торган Гадилә түти, беркадәр комик төсмерләрдә бирелгән Кәүсәрия һәм Рәкыйп образлары бар, алар кызыклы гына гәүдәләнәләр.

Беренче карашка «Мәхәббәт газабы»нда шәхси-интим мөнәсәбәтләр, тормыш-көнкүреш детальләре өстенлек алган кебек тоелса да, чынында исә бу әсәр алынган теманы киңрәк планда тирәнрәк яктырта, без монда аерым геройларның мәхәббәт романтикасы белән җылытылган бер коллектив тормышын, эшен күрәбез. Геройларның уңышына шатланабыз, уңышсызлыкларына борчылабыз. Шулай булгач, бүгенге тамашачы өчен бу драманың да әһәмияте бар.

С. Шәкүров пьесаларын күздән кичергәннән соң, аның иҗатына карата йомгаклап шуны әйтергә мөмкин. Аның әсәрләреннән тормышны, сәхнә таләпләрен яхшы белеп язуы, әдәби теленең дә шактый шома һәм бай булуы сизелеп тора. Ул бигрәк тә илебез тарихында эз калдырган зур вакыйгаларны сурәтләгән әсәрләре белән таныла бара. Аның күпчелек драмаларына югары идеялелек, тирән фикерлелек, заман сулышын тоеп эш итү, патриотик хисләрне бирә белү хас. Зур вакыйгаларны ул аерым шәхесләр язмышы аша кызыклы һәм дулкынландыргыч итеп яктырта ала. Аның үз геройлары, яраткан темалары бар. Жанр мәсьәләләрендә дә ул шактый таләпчән һәм белеп эш итә. Аның әсәрләре күпчелек драма, героик драма яки трагедия жанрына карый. Аның һәр әсәрендә диярлек романтик пафос, көчле лиризм, реалистик һәм романтик детальләрнең бергә үрелеп бирелүе күзгә чалына. Боларны геройларның авыр шартларга куелып, кыенлыкларны җиңеп чыгарга омтылуларында да, тормышны яратып, алга карап эш итүләрендә дә, әсәрләрнең җыр, музыка, табигать күренешләре белән бизәлүләрендә һәм башка бик күп детальләрдә дә күрергә була. Романтикага омтылу С. Шәкүровның үсеш юлындагы үзенчәлекле бер ягы. Ул драматургия мәсьәләләрендә шактый тирән уйлана, эзләнә. Билгеле, әдәби осталыкның чиге юк. С. Шәкүровка да драматургик осталыгын камилләштерүдә әле күп эшлисе, шөмарасы бар. Авторга һәр әсәрендә дә сюжет җыйнаклыгы, композицион бөтенлек, иң әһәмиятле моментларны гына тотып алып тасвирлау, образларның һәрьяклап төгәлләнгән булулары өчен күп эшләргә кирәк. Аңа да хәзерге тормышның күз иярмәс тизлек белән алга баруын, кешеләрнең психологиясе, культурасы үзгәрүен, артистларның да уйнау осталыгы камилләшүен, тамашачының таләбе артуын аңлап эш итәргә кирәк. Татарстанның атказанган культура эшлеклесе С. Шәкүров, художник, сүз остасы буларак, үз-үзенә таләпчәнлекне арттырыр, тагын да камилрәк әсәрләр иҗат итәр дип ышанасы килә.

Рафаэль Мостафин

# «ОҖМАХ»КА СӘЯХӘТ

ЮЛ ЯЗМАЛАРЫ

## Исәнме, Муса!




Барысы да һич уйламаганда башланып китте.

«Муса Җәлил» теплоходы капитанының беренче ярдәмчесе Илдар Кашаев Казанга килгән иде. Ул җир шарының диңгез-океаннары буйлап йөзүче кораб экипажы исеменнән татар язучыларына бүләкләр алып килде. Очрашу вакытында капитан ярдәмчесе диңгезчеләрнең тормыш-көнкүрешләре турында сөйләде. Соңыннан ул, татар язучыларыннан берәрсе безнең белән берәр рейска барса, коллектив тормышы белән дә якыннанрак танышыр, диңгез романтикасын да үзе тоеп белер

иде, диган теләк белдерде. Очрашуда катнашучылар елмаешып, гөжләп алдылар.

Кемдер сак кына:

— Ә сәламәтлек ярар микән соң? — дип кызыксына куйды.

— Әлбәттә, сәламәтлекнең, бигрәк тә йөрәкнең шәп булуы кирәк инде,— диде Кашаев.— Диңгездә чайкалуга авыру йөрәкле кеше чыдый алмый.

Очрашудагыларның күбесе авыр сулап куйды, аннары берсе.

— Ә соң ул язучы корабта нәрсә эшләр икән? — дип сорады.

— Борчылмагыз, эшсез итмәбез. Диңгезчеләр тормышы белән якыннан танышырсыз, аннары, чайкалуга күнегә төшкәч, үзегезнең иҗат эшегез белән дә шөгыльләнергә мөмкин булыр,— диде Кашаев, елмаеп.

Аннары җитдиләнеп:

— Диңгезчеләр Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты турында күбрәк белергә телиләр. Без инде, әлбәттә, сез җибәргән китаплар белән таныш, шулай да алар гына аз әле. Без Җәлил турында сөйләгәнне язучыларның үзләреннән ишетәсебез килә. Минемчә, сезнең арада бу эшне башкарырлык язучы табылыр...

Янәшәмдә утыручы шагыйрь Сибгат Хәким минем иңбашыма төртеп куйды:

— Уңайлы очракны ычкындырма... Син боларның бөтен таләпләренә дә туры киләсең — үзең яшь, таза, Җәлил иҗатын биш бармагың кебек беләсең, шул турыда китаплар да чыгардың... Чынлап әйтәм...

Гаиләне, нәшриятка әзерли торган китабымны, һәм тагын байтак эшләремне ярты елга ташлап китәргә икеләнебрәк торуымны белгәч, ул ныклап ук үгетли башлады:

— Тиле, әле бер генә татар язучысының да мондый сәяхәткә чыкканы юк. Син беренче булачаксың. Бел аны, башкача мондый мөмкинлекнең булмавы ихтимал...

Очрашудан соң мин Кашаевтан булачак сәяхәт турында җентекләбрәк сораштым. Шуннан Одесса пароходчылыгы җитәкчеләре һәм СССР Диңгез флоты министрлыгы белән язышулар, кирәкле кәгазьләр әзерләү, медицина комиссияләре башланды. Барлык комиссияләрне үткәннән соң, миңа үземнең кыршылып беткән гражданский паспортым урынына чия кебек куе кызыл тышлы, өр-яңа диңгезче паспорты бирделәр.

Минем ерак сәяхәткә барырга җыенуымны белгәч, кайбер иптәшләрем:

— Болай булгач, син оҗмахка тин якларны үз күзең белән күреп кайтасың икән,— дигәннәр иде.

Нинди була икән соң ул «оҗмах»?

* * *

Одесса портында тепловоз һәм паровозлар, йөк төялгән вагоннар тагып, озын итеп сызгырта-сызгырта, арлы-бирле йөреп тора, озын муеннарын күккә чөйгән краннар, нәрсәдер таләп итеп, кискен-кискен сигнал бирәләр. Саф диңгез һавасы белән кушылган төтен, нефть һәм черек суүсемнәр исе килә. Причаллар буйлап зур порт краннары тезелгән. Тимер корылмалар, күккә ашкан чыгырлар, мачталар, төтен бөркеп торган морҗалар урманы аша диңгез бөтенләй күренми дә. Баш очыннан тавыш-тынсыз гына, краннарның тимер бармакларына эләктерел-

эн өр-яңа «Москвич»лар, куе кызыл төскә буялган зур тәгәрмәчле Беларусь»лар, ерактан уенчык машиналар кебек кенә күренгән куе шел үзбушаткыч һәм йөк автомобильләре үтеп китә. Монда җир шарыың бөтен почмакларына төрле-төрле йөкләр озаталар һәм килгәннәрен абул итәләр.

Портлар күреп өйрәнмәгән минем ише кеше монда үзен бик җайсыз, ысынкы сизә. Ут чыккандай чабып килүче автокарага юл биреп тә лгермисең, тузан болыты күтәреп, авыр йөк төялгән тимер юл составы стенә ажгырып килә. Котың очып читкә тайпылуга, төягечнең тимер ешләре арасыннан коточкыч тавышлар чыгарып, синең яндагы бетон айданчыкка чуен кирпечләр коела.

Тәрәзәләрен тузан каплаган, авыр тимер ишекләре тәгәрмәчләр стенә утыртылган озын, тәбәнәк складлар рәте буйлап бара торгач, иһаять, кирәкле причалны табам. Зур фанерадагы рус һәм инглиз елләрендә язылган «Сәүдә итәргә, ә сугышмаска»,— дигән язу миңа риентир хезмәтен үти.

Ниһаять, мин диңгезне күрәм. Ул ерактан ук, үзенә чакыргандай, мсындырып тора. Ак күбекле дулкын сыртлары диңгез өстенә озын ызык булып сызылган. Ә яр буенда май тамчылары таралып киткән эм алар, салават күпере шикелле, төрле төсләр белән ялтырый. Ярдан лактый ары, су эчендә, төрле илләрнең флагларын җилфердәтеп, океан ароходлары һәм теплоходлары утыра. Алар сөремләнеп, штормнарда уяулары кубып, йончып беткәннәр. Һәм шулар арасында берсе үзенең урлыгы белән дә, чисталыгы һәм матурлыгы белән дә әллә каян күзгә әрелеп тора. Ул — әле күптән түгел генә Новороссийск догыннан [1] чыкан, безнең үлмәс якташыбыз Муса Җәлил исемен йөртүче теплоход.

Менә син нинди икән, гүзәл «Җәлил»! Ялтыравыклы кара буяуга уялган калын тимер корпус. Койрык өлешендәге ап-ак корылмалар кайаланып-каймаланып өскә күтәрелгән. Чыгырларның мачталары куе ары төскә буялган, зур ак морҗаның кызыл буяу белән уратып алынган леше кызыл балдак сыман ап-ачык булып күренеп тора. Морҗага лтынсу хәрефләр белән урак һәм чүкеч рәсемнәре ясалган. Күңелгә лундый уй килә: әгәр «Җәлил»не безнең Бауман урамына, матбугат йоры янына китереп куйсаң, «Җәлил» бу биш катлы бинага караганда иегрәк тә, озынрак та, мәһабәтрәк тә булып күренер иде...

Дулкынлануымнан бер кулым белән култыксага тотынып, тирбәлеп оручы шыгырдавык баскычлар буйлап өскә күтәреләм. Трап янындагы ахтенный өстенә спай куртка кигән, беләгенә кызыл тасма бәйләгән ез гәүдәле егет, мин күрсәткән кәгазьләрдән бигрәк үземә гаҗәпләнеп арый һәм, ашыкмыйча гына, эчке телефон аша капитанны чыкыра. Капитан килеп җиткәнче, ул минем турыда корабтагы ниндидер бер птәше белән дә сөйләшеп ала.

— Карале,— ди ул,— синең ишеткәнең юкмы, ниткән нәрсә ул — үртенче штурманның дублеры?

— Ник белмәскә! — дип җавап бирә тегесе.— Ярдәм итүче ул... эшсез дәмнәргә.

— Юк,— дип «уфтана» вахтенный,— дөрес чамаламыйсың. Дүртенче рдәмченең ярдәмчесе — ул инде нәкъ арбаның бишенче тәгәрмәче була.

Алар икесе дә рәхәтләнеп көләләр. Вахтенный, я, чамалап карарбыз, әрсәләр майтарырсың икән дигән сыман, миңа карап-карап ала.

---

[1] Док — судноларремонтлый торган урын.

Озакламый капитан да килеп житте. Ул яшь, чиста итеп кырынган, алтын укалы тасмалар тегелгән куе зәңгәр төстәге кителе гәүдәсенә ятышып тора. Дустанә елмаеп һәм хөрмәтләп чемоданымны кулымнан алгач, капитанның инде минем кем икәнемне белүен чамалап, «аллага шөкер» дип, җиңел сулап куям.

— Довгаль Роман Александрович! — ди ул, кул кысып, һәм үзе белән таныштырып.— Күптән көтәбез!

Вахтенный капитанның миңа мондый мөнәсәбәт күрсәтәчәген көтмәгән, күрәсең, гаҗәпләнеп йөзен чытып куя. Мин аңа дусларча күз кысып, капитан артыннан иярәм. Кают-компаниягә кергәч, капитан мине экипаж белән таныштыра. Тирә-ягымда бергәләп берничә айлар йөзәчәк шат һәм кырыс, җитди игътибарлы һәм беренче карауга битарафрак, итагатьле һәм шул ук вакытта ирләрчә тупасрак күренгән ике дистәгә якын кеше. Барысы да кул кысалар, үз исемнәрен әйтәләр, ләкин хәзергә әле мин аларны хәтерләп өлгерә алмыйм. Озак та үтми, диңгез кунакчыллыгы кагыйдәләре буенча, мин ашханәгә барырга тиеш булам.

Иртәнге аштан соң капитан бөтен эшләрен баш ярдәмчесенә калдыра да мине палубалар һәм бүлемнәр буйлап йөртә башлый. Ул кораб турында сөйли һәм, болар моңа ничегрәк тәэсир итәр икән дигән сыман, әледән-әле миңа карап ала.

«Муса Җәлил» 1966 елда Югославиядәге Пула шәһәренең «Ульяник» судоверфендә ясала. Ул — Югославиядә Совет хөкүмәте заказы буенча төзелүче «язучылар флотилиясе»нең алтынчы судносы. «Аркадий Гайдар», «Сергей Есенин», «Александр Блок», «Виссарион Белинский», «Владимир Короленко» һәм «Александр Грин» — төзелү урыны буенча «Җәлил»нең олы туганнары.

Майланган тайгак тимер баскычлардан машиналар бүлегенә төшәбез. Әлегә төп двигатель кабызылмаган, судноны электр энергиясе белән тәэмин итүче динамомашиналар гына эшли. Шулай да биредә үзеңне очраклы рәвештә язу машинасы эченә килеп эләккән кырмыска шикелле хис итәсең — тирә-ягың катлаулы, бер-берсенә уралып-чорналып беткән ток үткәргечләр, мең төрле детальләр белән тулган, шушы кадәр катлаулы әйберләр белән кем генә идарә итәдер — алла белсен. Капитан миңа корабның «Көмешкә аппаратын» — диңгез суын тозсызландыру җайланмасын күрсәтә. Ул суны тозсызландыра һәм бу су экипажның көнкүреш ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә икән. Дөрес, бөтен тозлардан да тәмам арындырылып бетерелгән бу су, гадәттән тыш очраклардан башка, барыбер эчәргә ярамый — тәмсез. Шуңа күрә эчә торган суны яр буенда алалар һәм махсус цемент чаннарда саклыйлар.

Бөтенләй башка урыннан өскә чыгып, бормалы коридорлар, тимер «сукмаклар» буйлап барабыз-барабыз да, яңадан аска чумып, суыткыч камераларга килеп эләгәбез. Кечерәк бүлмә зурлыгы суыткычта бәс белән капланган түшкә-түшкә итләр асылынып тора. Тын да үткәрми торган авыр ишекле янәшә камерада җиләк-җимеш, яшелчә һәм бәрәңге саклана. Өченче камерада сөт, май, эремчек, дүртенчесендә җимеш сулары һәм коры шәрап... Монысын капитан тропик запас дип аңлатты. «Ә суыткыч сафтан чыкса?» «Алай булса эшләр харап,— ди капитан, елмаеп,— җиләк-җимеш чери, итне бик тиз генә тозларга, азыкның күбесен суга ташларга туры киләчәк. Ләкин әле мондый хәлнең «Муса Җәлил»дә бер тапкыр да булганы юк».

Без тагын ярым караңгы коридорлар, баскычлар буйлап өскә күтәреләбез һәм якты апрель кояшы белән өртелгән, стеналары сөт төсле ялтыравык пластиктан ясалган, җиз приборлары күз камаштырырлык итеп чистартылган рулевой рубкага килеп керәбез. Капитан мине ин

яңа җиһазлар белән таныштыра. Менә радиолокатор, гирокомпас[1], авторулевой, пеленгатор[2], лоран[3] һәм мин әле нигә кирәклеген аңлап, исемнәрен хәтерләп бетерә алмаган әллә никадәр приборлар...

Аннары миңа никельләнгән казаннары һәм механизмнарының катлаулылыгы белән шифаханәнең операция бүлмәсен хәтерләтүче камбузны[4], кызыл почмакны, каюталарны күрсәтеп йөри. Стеналар бөтен җирдә дә күзне иркәли торган йомшак төсләрдәге пластик белән капланган, җиз бусагалар һәм бронзадан ясалган түгәрәк плафоннар алтын сыман булып ялтырап тора, кают-компаниягә журнал өстәлләре һәм ял итү өчен йомшак урындыклар куелган. Шушында ук, алтын балыклар йөзеп йөри торган гаҗәеп матур озын аквариум белән рәттән генә, Муса Җәлил почмагы. Стенада шагыйрьнең зур рәсеме — Язучылар союзы бүләге, шүрлекләргә Җәлилнең шигырь җыентыклары һәм аның турындагы китаплар тезелгән. Шулар арасыннан үземнекеләрен дә танып алам.

Барыннан да бигрәк шунсы гаҗәпләндерде: «Муса Җәлил» теплоходында җырларда җырланган атаклы матрос кубригы юк. Монда экипажның һәр әгъзасына аерым каюта. Һәр каютада — стенага беркетелеп ясалган киң ятак, ял итү өчен кечкенә йомшак диван, кием-салым өчен шкаф, өстәл-комод, кайнар һәм салкын су, сафландырылган һава. «Эх,— ди үкенә капитан,— мин бит сезгә һава сафландыру җайланмасын күрсәтергә онытканмын. Хәер, тропикларга барып җиткәч сез аның нинди бәхет икәнен үзегез үк сизәрсез әле. Ул җайланманың рәхәте чит илләрнең өр-яңа корабларында да һәр диңгезчегә тәтеми әле. Алар безнең корабка килгән чакта һәрвакыт шуңа гаҗәпләнәләр».

— Ә монда кино буламы соң?

— Әлбәттә! Атнага өч мәртәбә.

— Ә ипи пешерү урыны?

— Анысы да бар! Юлда без һәрвакыт яңа пешкән бодай икмәге ашыйбыз.

— Ә соң сездә нәрсә генә юк?

— Нәрсәме? — ди капитан, җитди уйланып.— Йөзү бассейны юк. Без, әлбәттә, аны үзебез дә төзи алыр идек, ләкин урын җитенкерәми. Еш кына палубага йөк алырга туры килә. Шулай итеп, рейс вакытында сезгә су коенырга туры килмәячәк. Аннан соң безнең спорт залыбыз юк, хәтта теннис өстәле куярга да урын таба алмыйбыз. Ләкин вакыты җиткәч, барысын да булдырырбыз шикелле...

* * *

Һәр корабның иң мөһим документы — ул вахта журналы. Анда диңгез юлларында узылган ераклыклар да, кораб тукталган портлар да, диңгезчеләргә очраган давыллар да, кыскасы, корабның бөтен көндәлек тормышы язылып барыла.

Ләкин «Муса Җәлил»дә шуннан тыш комсомол оешмасы төзи торган «Кораб тарихы альбомы»да бар. Бик нәфис фоторәсемнәрдән төзелгән ул. Әле битләре дә саргаеп өлгермәгән, ә үзе бик күп кызыклы нәрсәләр турында сөйли.

---

[1] Гирокомпас — җирнең магнит көченнән башка гына кораб юлын билгеләп баручы прибор.

[2] Пеленгатор — яр буендагы объектларга карап, корабның судагы урынын билгеләүче прибор.

[3] Лоран — радио дулкыннары ярдәмендә корабның ачык диңгездәге урынын билгеләү приборы.

[4] Камбуз — кухня.

...1966 елның кырыс февраль иртәсе, Ульяник судоверьфе. Кораб бортына бәрелгән традицион шампанское шешәсе чылтырап ватыла һәм корабның биниһая зур гәүдәсе очлары суга кереп киткән калын такталар буйлап шуыша башлый. Баштан ул акрын гына бара, аннары кызулый-кызулый ике якка зур дулкыннар чәчеп суга ук кереп китә.

«Җәлил»гә исем кушучы хатын кыска, ләкин тәэсирле речь сөйли:

— Мин сиңа «Муса Җәлил» дип исем кушам,— ди ул.— Бу исемне ирек һәм социалистик Ватанның бәйсезлеге өчен тормышын корбан иткән халык шагыйре йөртте. Сиңа хәерле диңгез юллары һәм уңай җилләр телим. Советлар Союзы байрагын җир шарының бөтен диңгез-океаннарында горур йөрт!..

1966 ел — корабның беренче хезмәт елы. Экипаж беренче көннәрдән үк коммунистик хезмәт коллективы дигән исем өчен ярышка кушыла. Диңгезчеләр алдында иң кыска вакыт эчендә корабның бөтен механизмнарын һәм җайланмаларын өйрәнү бурычы тора. Беренче рейслардан соң инде коллективның бу бурычны уңышлы үтәве билгеле була. «Җәлил» «Александр Грин» корабы белән социалистик ярыш башлап җибәрә. Еллык план 10 декабрьга ук 107 процент итеп үтәлә һәм «Җәлил» ярышта җиңүче булып чыга. Шуннан соң инде ул беренчелекне бирми.


...Совет властеның илле еллык бәйрәме булган 1967 елда «Җәлил» ерак илләргә, ярсу диңгезләргә һәм чит-ят портларга яңа рейслар ясый. Ул Арктиканың ачы салкыннарын да, Африканың рәхимсез эссе җилләрен дә татый, Япониядә һәм Һиндстанда, Кубада һәм Монреальдә булып кайта. Октябрь алды ярышларына йомгак ясалгач, «Җәлил»нең илебез кораблары арасында өченче урынга чыгуы билгеле була. Бу уңышлары өчен аңа Диңгез флоты министрлыгының һәм профсоюзлар Үзәк Комитетының вымпелы тапшырыла. «Муса Җәлил» теплоходының исеме Кара диңгез пароходчылыгының почет кенәгәсенә кертелә, экипажның унбер члены Почет грамоталары белән бүләкләнә. Алар арасында капитан Р. Довгаль, баш моторист Л. Заворуев, электромеханик Г. Алферов, матрослардан А. Страцинский, В. Пивоваренко һәм башкалар. Еллык программа 28 ноябрьга 102 процентка үтәлә. Декабрь аенда инде диңгезчеләр бишьеллыкның өченче елы хисабына эшлиләр.

...1968 елда яңа экономик шартларда эшли башлыйлар. Диңгезчеләр алдына йөк ташуда чыгымнарны киметеп, дәүләткә күбрәк табыш алу мәсьәләсе килеп баса. Һәр кварталда җәлилчеләрнең яхшы эшләүләре билгеләп үтелә һәм ярты еллык эш йомгаклары буенча аларга Почет грамотасы тапшырыла. Хәзер экипажда 25 коммунистик хезмәт ударнигы бар. Аннары Ленин комсомолының 50 еллыгы хөрмәтенә социалистик ярыш кабынып китә. Бу ярыш йомгаклары буенча җәлилче-комсомолларның удар хезмәте һәм җәмәгать эшләрендәге активлыгы ВЛКСМ Үзәк Комитетының Почет грамотасы һәм истәлекле вымпелы белән билгеләп үтелә. Еллык план 16 ноябрьга 108,8 процентка үтәлә.

...1969 ел башы. Япония, Индонезия (Борнео утравы), Италия портларына озакка сузылган кыен рейслар... Гомуми җыелышта В. И. Ленин юбилее хөрмәтенә социалистик йөкләмә кабул ителә. Корабтагы бер төркем рационализаторлар Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә тәкъдим ителә.

Шулай итеп, «Җәлил»нең кыска, ләкин данлы тарихы бар инде. Диңгезчеләр яраткан шагыйребезнең намусына тап төшермиләр.

# Сау бул, Одесса!




**Одесса, 5 май, иртәнге сәгать 10.** «Одессада уннарына кадәр утырырбыз әле,— дигәннәр иде миңа дөнья күргән диңгезчеләр.— Хәзер бәйрәмнәр башлана, конторалар дүрт көн буена эшләмәячәкләр, хуҗалардан башка хәл итеп булмый торган буталчыклар килеп чыгачак та чыгачак инде ул... Палуба йөген урнаштыру ул сиңа трюмга тутыру гына түгел... Уйлабрак ныгытмасаң, беренче давылда ук сөякләреңне дә таба алмассың...»

Ләкин Одессада тагын берничә көн «утырып тору» өметләре акланмады. Төяү эшләре бәйрәмнәрдә дә көне-төне, бер сәгатькә дә тукталмыйча дәвам итте. Туапседа «Җәлил» үзенең трюмнарына Корея Халык Демократиясе Республикасы өчен ун мең тоннадан артык марганец концентраты алды. Одессада безнең палубага өстәмә йөк — Сүрия гарәп республикасы өчен нефть җиһазлары төяделәр. Торба итеп төрелгән уннарча тонналы нефть резервуарлары махсус терәткечләр һәм араталар белән бортлар буйлап шундый шәп итеп ныгытылды ки, хәтта иң төпченүче баш ярдәмче дә бәйләнерлек сәбәп таба алмады. Өченче көн кичтән төяү тәмам булды һәм йөзмә кран безнең борт яныннан китеп тә өлгермәде, аның урынына ягулык бирүче танкер килеп тә җитте. Бөтен сәяхәт буена безгә ай-яй күп ягулык кирәк булачак! Безнең бакларга ягулык тутырганда тәүлек буе палубада янгын сүндерүчеләр йөреп торды, ә вахтенныйлар тәмәкечеләрнең махсус урыннарда гына тартуларын таләп иттеләр. Берәрсе ялгышып тәмәке төпчеген иллюминатордан ыргытуы мөмкин дип, хәтта каюталарда да тартырга рөхсәт итмәделәр.

Кузгалып китү вакыты бүген, нәкъ көндезге бергә билгеләнде. Вахтада тормаучылар көндезге сәгать уникегә кадәр генә ярда булырга тиешләр. Таможня декларацияләре тутырылды, паспортлар бирелде. Спикердан[1] инде ничәнче мәртәбә совет акчасы булган кешеләргә акчаларын дүртенче ярдәмчегә тапшырырга кушып белдерү бирәләр. Кичәдән бирле корабка бер-бер артлы әллә ниткән комиссияләр һәм инспекцияләр килә: кайсы куркынычсызлык техникасын, кайсы янгыннан саклык чараларының торышын, кайсы санитария һәм медицина хезмәтен тикшерә. Һәртөрле тикшерүләр һәрвакыт борчу һәм киеренкелек китерә. Кешеләр тынычсызланалар, арлы-бирле чабалар һәм ярсып-ярсып нәрсәдер рас-

[1] Спикер — радиочелтәр ярдәмендә корабта командалар һәм белдерүләр тапшыра торган элемтә системасын диңгезчеләр шулай дип йөртәләр.

лыйлар. Журналга язылган һәр кисәтү кешеләрнең күңелен борлыктырып кына калмый, бәлки бөтен экипажны премиядән колак кактыруы бар. Миңа калса, бу ыгы-зыгыга бары бер капитан гына битараф карый булса кирәк, ул һаман элеккечә тыныч кына челемен төтәтә бирә. Аның сабырлыгы акрын-акрын гына башкаларга да күчә, киеренкелек йомшара һәм, ниһаять, барысы да үз урынына кайта.

* * *

**Көндезге сәгать 13.** Билгеләнгән вакытта кузгалып китә алмадык. Соңгы минутта гына трюмнарның эчке ягын каплау өчен кирәк булган калын такталарны китереп җиткермәүләре билгеле булды. Дөрес, хәзергә безгә аларның хаҗәте юк, ләкин кайтасы юлда дым тарта торган йөк төяргә туры килсә, кирәк булулары мөмкин. График буенча такталарны кичә үк китерергә тиеш булганнар, ләкин баш ярдәмче азык-төлек кабул итү мәшәкатьләре белән булашып, тикшерергә онытып җибәргән, ә тәэминатчылардан кемдер вакытында чарасын күрмәгән. Хәзер инде чырае сытылган баш ярдәмче (ул соңгы ике төндә бөтенләй йокламаган) телефон аша ярсып-ярсып тәэминатчылар белән әйткәләшә, үзе кул сырты белән маңгаеннан тирен сыпыра.

Китәр алдыннан кузгалган ыгы-зыгы инде тәмам басылды. Бары тик дингезчеләр генә тынычсызлана — ярга да җибәрмиләр, кайчан кузгалып китәсе дә билгесез. Җитмәсә соңгы мизгелдә генә һәркемнең ярда эшләп бетермәгән әллә никадәр эше искә төшә.

* * *

**Ун сәгать унбиш минут.** Безнең әле һаман кузгалып китә алганыбыз юк. Башта такта китергәннәрен көттек. Аннары таможнячыларны, аннары чик сакчыларын. Ниһаять, чик сакчылары да корабны әйбәтләп тикшереп (тикшерми ярамый, чөнки кайбер чик бозучыларның корабка утырып китәргә маташулары да була икән) чыгалар һәм безгә бәхетле сәяхәт теләп китеп баралар.

Палуба командасы өчен аврал сигналы бирелә. Күперчектән командалар яңгырый:

— Трапны күтәрергә!

— Борындагы арканны җибәрә төшәргә!

— Сул якорьны күтәрергә!

Аннары инде күптәннән безне көтеп торган ике буксир пароходы «Җәлил»не буксирга алалар да саклык белән генә рейдка чыгарып куялар. «Җәлил» акрын-акрын тизлеген арттыра башлый. Һава сизелеп сафлана бара. Тыгыз дулкыннар корабка бәрелеп чәлпәрәмә килләр. Диңгез вокзалының яктылык тутырылган аквариумга охшаш пыяла бинасы һаман кечерәя бара. Шәһәрнең меңәрләгән җемелдәвек утлары төн куенына кереп югала. Прожекторлар, сары юан җиңдәй булып сузылган яктылык көлтәләрен болгап, маяклар, ялкынлы кызгылт күзләрен кысып, безне озатып калалар.

* * *

Мин, битемне рәхәт иркәләүгә уянып киттем. Ниндидер йомшак, җиңел әйбер битемнән сыйпап узды да, бер яккарак шуышты. Аннары ул бер мизгелгә генә тукталып торды да яңадан битемне рәхәтләндереп иркәли-иркәли икенче якка юнәлде. Мин йокылы-уяулы килеш кенә бу рәхәтлектән оеп ятам. Аннары күзләремне ачып җибәрсәм — иллюминатордан алтын сыман кояш нурлары явып тора, битемне шул нурлар иркәли икән.

Мин иллюминаторга ташланам һәм сокланып хәйран калам. Әллә

айларга китеп югалган офыкның буеннан-буена, ялтыравык терекөмеш ыман, диңгез суы җәелгән. Шушы күз камаштыргыч гүзәл киңлек өсте- э биниһая зур кояш шары эленгән. Күктә мамыктай җиңел алсу болыт исәкләре күренә...

Бүген бөтен диңгезчеләр корабны җыештырырга чыкты. Марганец — ик яман нәрсә икән, кечкенә генә бер бөртеге төштеме, шунда ук зур ына пычрак көрән тапка әйләнә. Ә без бит бер чиметем генә алып бар- ыйбыз, бездә ул тонналап! Өч көн, өч төн буена грейферлар белән рюмнарга эшереп керткәндә марганец корабны шул кадәр пычратып бетергән, боцман бу хәлгә теше сызлаган кеше кебек чыраен сытып арый. Сүз уңаенда шунысын да әйтергә кирәк, безнең боцман (диңгез- ләр телендә — аждаһа) мин күз алдыма китергән боцманнарга бөтен- ләй охшамаган. Бәләкәй буйлы, нәзек, ябык. Кыска итеп кыркылган ары чәчле, җилләрдән һәм диңгез тозыннан уңып беткән шикелле тонык ңгәр күзле. Ул әле чагыштырмача яшь — утыз яшьләр тирәсендә енә — читтән торып диңгез училищесында укый, штурман булырга зерләнә.

Мин бу фикерләремне әйткәч:

— «Әйе, хәзерге боцманнар бөтенләй башкача инде,— ди капитан. инем белән килешеп.— Ә менә мин матрос-җыештыручы булып хезмәт иткән чакта безнең бер боцман бар иде. Вәт ул аждаһа дисәң дә аждаһа иде! Йодрыклары бала башы кадәр, авырлыгы центнер ярымнан да ким булмагандыр. Бервакыт ул кайсыдыр портта артыграк салып җибәргән а аягына да басып тора алмый. Дүрт матрос аны корабка күтәреп кер- ергә азапланa, ләкин көчләре җитми. Шуннан трапка кадәр тәгәрәтеп итерделәр, ә трап тар — ике кеше үтмәле түгел. Тегеләй дә кереп карый- ар, болай да, булмый гына бит. Ахырдан кранга җәтмә элеп, боцманны ароходка кран белән күтәртеп керттеләр. Ул йөгергәндә палуба идән- әре сыгыла торган иде. Барыбыз да аннан курка һәм берсүзсез буйсына идек. Беркайчан да кычкырмас, тавыш күтәрмәс, ләкин күрсәтмәләрен ике тапкыр кабатламас. Әгәр дә корабка яңарак килгән, бездәге тәртип- әрне белеп бетермәгән берәрсе эшне эшләми калдырса, боцман аның елән башкача сөйләшә. Иплә кенә имән бармагы белән чакырып китерә егене, тавыш-тынсыз гына кеше күзеннән ераграк почмакка алып килә э, бала башы кадәр йодрыгына төкереп берне китереп сала мин сиңа йтим, шуннан соң малаен боцман тирәсендә өтәләнеп кенә йөри баш- ый. Шунсы кызык, боцманны берәү дә җитәкчеләргә әләкләми, чөнки эркем үзенә дөрес әләккәнен аңлый. Әйе, хәзер андый боцманнарны өндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың...

Ләкин тәбәнәк буй һәм ябык гәүдә безнең «аждаһа»га үз бурычларын өгәл үтәргә һич кенә дә комачауламый. Ул бөтенебезгә дә — шул исәп- ән мина да — су үткәрми торган киемнәр, озын кунычлы резина итекләр ирде һәм без эшкә тотындык. Башта корабны, көпшәләрдән сиптереп, аштанаяк диңгез суы белән коендырып чыктык. Корабтагы марганец өртекләре эреп агып, диңгезгә кып-кызыл эз сузылып калды.

— Әгәр без Мәрмәр диңгезе тирәсендә батсак, бөтен диңгез сыек мар- анец эремәсенә әвереләчәк,— дип көлештеләр матрослар.

Аннары без палуба һәм идәннәрне сулап һәм содалап, капрон щетка- ар белән ышкып юа башладык. Ак урыннарны юу аеруча кыен, һәр антиметрны әллә ни гомер ышкып торырга туры килә. Ләкин һәр кеше- ең кәефе шәп. Эш тиз һәм күңелле бара.

Һәр сәяхәттә була торган бер-беренне шаяртышулар башланды. Биг- әк тә практикантларга эләгә. Я аларны кулларына чиләк тоттырып, бабай»га — баш механикка — «компрессия» алырга җибәрәләр, я фор- иктан (судноның борын өлеше) брашпиль алып килергә кушалар (э брашпиль дигәннәре якорьләр күтәрә торган дистәләрчә тонналы еханизм), я булмаса кечкенә тимер пычкы бирәләр дә якорь чылбыры-

ның тузган «клиндерен» кисеп ташларга кушалар (ә ул «клиндерне» кисеп чыгару өчен бер ел буе ышкып торсаң да таманга гына килер иде).

Моторист Валановскийны аеруча нык шаярттылар. Аның әле мондый сәяхәттә беренче генә булуы — моңа кадәр ярда электросварщик булып эшләгән. Кемнең ни әйтүенә карамастан, ул һәр сүзне чынлап кабул итә. Аның бу риясызлыгыннан бер «картлач» матрос бик оста файдалана. Одессадан чыкканда ук инде ул яшь мотористка төп винт күчәре подшипнигын бик игътибар белән күзәтеп торырга киңәш итә: «Кара аны, артык кыза күрмәсен, минемчә, ремонтчылар күчәрне ныграк тарттырганнар»,— ди. Ә бу тимер күчәр колач җитмәслек калын, подшипникларның шактый катлаулы суыткыч системасы бар, шуңа күрә ул беркайчан да кирәгеннән артык кызмый. Һәр эшне намус белән башкарырга өйрәнгән Валановский күчәрнең тышлыгына учын куеп карый һәм иптәшенә: «Шулай, күчәр кыза»,— ди. Тегесе бик җитди кыяфәт белән күчәр янына килә, подшипникка кулын куеп карый һәм гаять күңелсез хәл килеп чыккандай башын чайкый, аптырап муенын кашыган була. «Ах, шайтан алгыры,— дигән була ул,— бөтен эшне бозарлар дип уйлаган идем аны... Нишләргә инде хәзер? Болай булса без Босфорга кадәр дә барып җитә алмаячакбыз...» «Бәлки «бабайга» хәбәр итәргәдер?» — дип тәкъдим ясый яшь моторист. «Аңа хәбәр итүдән ни файда? Кораб барганда ул нәрсә эшли ала? Ярда нәрсә карадыгыз дип тотып сүгәр. Юк, монда үзебезгә нәрсә дә булса уйлап табарга кирәк...» — ди тегесе. «Бәлки су сибәргәдер?». «Юк, су күчәр астына агып төшәр дә бөтен тимерләрне күгәртеп бетерер». «Алайса юеш чүпрәк каплыйк». «Менә бу эш ичмасам,— дип мактый аны «картлач»,— булырдайның әллә каян билгеле шул. Ләкин менә аның кадәр чүпрәкне каян алырга? Зуррак бирер нәрсә булсын иде...» Шунда ул «очраклы рәвештә» генә Валановский өстендәге өр-яңа фуфайканы күреп ала. «Менә синең фуфайкаңны эшкә җиксәк шәп булыр иде,— ди «картлач».— Кызганычрак, әлбәттә, бигрәк яңа бит... Эх, минем шундый киемем булса, ике дә уйлап тормас идем... Хәер, син үзең дә алай саран малай күренмисең. Авария булдырмый калган өчен премия биреп куюлары да бар әле, ә бәлки рациональ тәкъдим итеп рәсмиләштерерсең».

Бераздан мотористлар һәм механиклар эчләре катып көлә-көлә Валановскийның чиләк белән су алып килүен (иптәше аңа дингез суы белән түгел, төче су белән чылатырга кушкан), авыр сулап иненнән фуфайкасын салуын һәм чиләктәге суга тыгып алганнан соң бераз гына сыгып күчәр тышлыгына каплавын күзәтәләр. Бүген иртәдән бирле мотористка тынгылык бирмиләр — барысы да фуфайка язмышы белән кызыксына. «Юкка гына суга манчыдың син аны,— дип авыр сулаган була берәү, мотористның кайгысын уртаклашкандай,— пальтоңны эшкә җиксәң берьюлы ярты күчәрне каплаган булыр иде». «Юк, аның пальтосы бик иске бит,— дип сүзгә кушыла икенчесе,— мондый эшкә батмый ул». Валановскийның ачуы килә, ләкин берни эшләр хәл дә юк.

* * *

Диңгездә күңелне гаҗәеп тынычлык, тәнне рәхәт изрәү биләп ала. Бөтен мәшәкатьләр, үкенү-кайгылар артта калган һәм монда, иксезчиксез диңгез киңлекләрендә, алар бик кечкенә булып тоела. Машиналар, корабны салмак кына дерелдәтеп, туктаусыз эшләп тора. Тирә-якта очсыз-кырыйсыз яшькелт киңлек. «Җәлил», шул киңлекне урталайга ярып, диңгезне күбекләндереп алга омтыла. Безне бөтен яклап төтен сыман шәмәхә горизонт урап алган. Без биниһая зур сәгать циферблаты уртасында торабыз сыман. Мин бу циферблатның кабарынкы диңгез күкрәгендә һаман акрын-акрын күчә баруын ачык күрәм — без һаман серле Босфорга якынаябыз. Әллә тынгылыкның сәбәбе дә шушы тыелгысыз хәрәкәттәме икән?

* * *

Скипер аша берничә тапкыр белдерү тапшырдылар:

— Мангайдагы иллюминаторларны капларга!

Теплоход вакыт-вакыт озын, хәвефле гудоклар бирә. Тизлек нык киметелде. Хикмәт нәрсәдә икәнен белмәк булып, мин каютадан чыгам. Әһә, дингезне томан баскан икән! Капитан әйтмешли, гади сөт кенә түгел, ә куертылган сөт бу. Прожектор нурлары куе томанга килеп терәләләр дә, аны ун метрдан арыга тишә алмыйча, сүнеп калалар. Кораб утлары томанда кызыл һәм яшел төсләргә кереп ялтырый. Хәтта астагы су да күренми, аны бары тик дулкыннарның саңгырау чапылдауларыннан гына чамалап була.

Вахтенный бик зур игътибар белән алга карап бара. Ачык иллюминатордан штурманның картага иелеп, тагын бер мәртәбә маршрутны тикшерүе күренә. Капитан, борын эченнән генә нәрсәдер көйләп, күперчек өстендә әрле-бирле йөри. Вакыт-вакыт ул, маңгае белән радарның резина баранкасына бөтен йөзе белән текәлеп, алдагы юлны карый яки, исәпләүләрне үзе тикшерү өчен, штурман янына кереп чыга. Ул томан таралганга кадәр шушында булачак.

## Босфор бугазы




«Босфор бугазының буе 15 миль тирәсе (бугазга керү-чыгу юллары белән 25 миль). Иң киң урыны 4 миль, иң тар урыны — 4 кабельт [1]. Тирәнлеге — 20—100 метр. Агым тизлеге Кара дингез ягыннан 4 узел. Бугаз биек һәм текә яр эчендәге борылмалы елганы хәтерләтә».

*Лоциядән* [2]

Босфорны төнлә үтеп китәргә тиеш идек, ләкин томан коточкыч куе булганга, капитан бу кара төндә бугазга керергә җөрьәт итмәде. Без төрек ярларына якын гына урында якорь салдык. Иртән бер чит ил корабының төнлә ялган Босфорга әләгүен (Босфорга бик нык охшаган кечкенә генә бугазчык) һәм ныклап кына комга утыруын белдек. Бу мәсьәлә

---

[1] Миль — 1852 метр, 1 кабельт — мильнең уннан бер өлеше, ягъни 185,2 метр.

[2] Лоция — диңгезчеләр өчен чыгарыла торган белешмә.

буенча хәтта капитан белән баш ярдәмче арасында кечкенә генә бәхәс тә булып алды. Баш ярдәмче бәхетсезлеккә очраган корабка ярдәмгә барырга тәкъдим итте. Ләкин капитан кул гына селтәде дә: «Ә ул сине чакырдымы соң? — диде,— син «сос»ны ишеттеңме, яисә бәлага очрау сигналын күрдеңме? Ни пычагыма дип мин аңа үзем ялынып йөрергә тиеш соң әле? Бәлки аңа комда утыру ошыйдыр? Бәлки ул моны тирә-як белән соклану өчен махсус рәвештә эшләгәндер?»

Баш ярдәмче бер елмаеп куйды да башка дәшмәде. Чыннан да, чит ил корабы, радиостанциясе яхшы эшләүгә дә карамастан, беркемне дә ярдәмгә чакырмаган иде. Ничек тә булса үз көчем белән чыгармын да валютаны саклап калырмын дип уйлаган, күрәсең. Без якорьларны күтәрдек тә Босфорга табан юнәлдек.

Менә ул озын ылыслы кырым наратлары белән капланган кыялы ярлар — Төркия ярлары. Европа ягындагы уң як ярда Румели маягының биек ак манарасы һәм каралып беткән зур-зур таш коймалар, стена буйлап тезелеп киткән күзәтү тишекләре... Хәрабәләрдән арырак, тау итәгенә, ниндидер авылның ак, сары, алсу өйләре сибелеп утырган. Азия ягындагы сул як ярда Анадолу маягы күренеп тора һәм кыяларда ниндидер кара-кучкыл сызыклар күзгә чагыла. Мин бинокльдән карыйм. Ул сызыклар бетон дотларның туптан ату өчен ясалган ярыклары икән ләбаса! Әнә, нәкъ безгә табан төбәлгән тупның юан көпшәләренә кадәр күренеп тора. Менә сиңа иркә, зәңгәр Босфор!

Карантин хезмәте күрсәтүчеләр һәм яр буе властьлары вәкилләре, безнең корабка кереп, документларны тикшергәннән соң, бортка лоцман күтәрелә. Өстенә әйбәт йон костюм кигән, зур корсаклы һәм пеләш бу төрек лоцманы [1], рулевой рубкасына кереп, кычкырмыйча гына русча командалар бирә башлый.

— Сулгарак!

— Бераз алгарак!

— Шулай дәвам итәргә!

— Акрын! Тагын да акрынрак!

Капитан аның командаларын кычкырып, ачык итеп кабатлап бара һәм «Җәлил» акрын-акрын бугазга керә башлый. Уң ягыбызда — Европа, сул ягыбызда — Азия. Без ике континентны аерып торган сызыктан барабыз. Томан акрынлап тарала башлый. Тарак тешләре сыман тау түбәләре артыннан ярым-түгәрәк комлы яр шикелле сары кояш күренә һәм Босфор суы эчтән яктыртылган шикелле зәңгәрләнә башлый. Нарат, мирта, чәчәк аткан олеандра агачлары үсеп утырган матур ярлар; чүлмәк түбәле, киң террасалы кечкенә генә чиста өйләр; очлары буынтыклы манаралар; тасмадай сузылып киткән зәңгәрсу шоссе; шоссе буйлап тавыш-тынсыз гына төрле төстәге машиналар һәм автофургоннар шуышып бара. Төтен сыман зәңгәр бу иртәдә суда яшькелт-соры стена шәүләләре чагылып кала. Аларның күбесе инде Византия чорыннан ук шушы ярда басып торалар икән.

Босфор бездәге Кама яки Агыйдел шикелле елгалардан киң түгел һәм бик борылмалы. Капитанга да, рулевойга да игътибарлы булырга кирәк. Шуның өстенә Босфорда шактый көчле агым да бар. Зур кораблар билгеле бер тәртип белән акрын гына йөзәләр, ваграк баржалар, катерлар, моторлы көймәләр теләсә кайдан, теләсә кайсы якка мыж килеп йөреп тора, кайберләре хәтта безнең корабның борын астыннан ук үтеп китә.

Бугазга эчкәрерәк кергән саен яр буендагы корылмалар күбәя бара. Хәзер инде бер-берсенә терәп салынган йортлар су читеннән алып бөтен тау бите буйлап таралганнар. Байларның үзенчәлекле көнчыгыш архитектурасына нигезләнеп салынган гөмбәзле һәм террасалы мәрмәр вил-

[1] Лоцман — корабларны таныш булмаган тар урыннардан үткәрүче чит ил диңгезчесе.

алары, ерактан караганда умарта кәрәзенә охшаган, пыяла һәм бетонан заманча итеп эшләнгән биналар күренеп кала. Бер якта ике катлы аять зур күпер сыман нәрсә — борынгы Византия суүткәргече калды. Җакламый инде таш корылмалар һәм урамнар яшеллекне бөтенләй ысрыклап чыгаралар. Бусы инде ике миллион ярымнан артык халкы улган Истамбул — Европа һәм Азия кушылган урындагы иң зур шәһәрләрнең берсе.

Назыйм Хикмәт шигырьләре буенча миңа ифрат таныш булган тар әм кәкре урамнар, озын-озын таш стеналар һәм коймалар, кофеханәләр, р буе тулы товар саклый торган каралтылар, кечкенә-кечкенә базарлар... Өч-дүрт йорт аша — бер мәчет... Никадәр күп алар монда! Белешмәләрдә Босфор ярлары буенда биш йөздән артык манара бар дип язаар. Ләкин биек яр өстендәге атаклы Ая-Суфия мәчетенең гаять җиңел ары гөмбәзләре һәм гүзәл манаралары боларның барысыннан да аерып тора. Император Юстиниан заманнарында ук салынган һәм инде ненә үндүрт гасыр буе гүзәллеген саклап килгән бу мәчет турында миңа үпме укырга һәм ишетергә туры килгән иде! Ниһаять, аңа ерактан гына улса да күз салырга җай килде.

Ая-Суфиядан соң ук тагын да мәһабәтрәк, бинниһая зур соры бина — Солтан Әхмәт мәчете күренә. Аның алты манарасы, тоткалары белән скә каратып җиргә кадалган алтын хәнҗәр сыман ялтырап, күккә ашан. Бинокль аша аның тирәсендә кайнашучы экскурсия автобуслары, уристлар төркеме күренә. Без иске шәһәрне урап алган ярым җимерек репость стеналарын үтеп китәбез һәм иске Солтан сарае турына килеп итабыз. Ул гаять нык итеп өелгән ике рәт таш койма белән урап алынан. Диңгезчеләрнең сөйләвенә караганда, солтан гаремына керергә елаучыларнең котын алып, элек бу таш коймалар арасында ач юлбарысар чабып йөри торган булган.

Яр буенда — кармаклар тоткан кара-кучкыл тәнле, ялана яклы малайар... Тар басмалар буйлап җилкәләренә капчыклар күтәргән ябык аудәле йөкчеләр йөгерә... Яр буйлап тезелеп киткән бихисап ашханәләрдән кыздырылган кофе исе килә.

Без берәзга гына тукталып, төрек лоцманын төшереп калдырабыз әм юлыбызны дәвам итәбез.

* * *


Җир шарындагы иң кечкенә, иң җылы һәм иң тыныч диңгез — Мәрәр диңгезе буйлап барабыз. Ике якта да урманнар һәм куаклыклар елән капланган тәбәнәк тау тезмәләре. Диңгез буена сөзәкләнеп төшкән рларда эшкәртелгән кырлар, бакчалар, виноград түтәлләре.

Диңгез әллә ни зур булмаса да, тиздән ярлар тәмам күздән югалаар. Яшькелт иркә дулкыннар, наян көчекләр сыман йомшак кына итеп орабка килеп төртеләләр һәм борт тупас итеп кире бәреп җибәргәч, пкаләгәндәй артка чигенәләр. Диңгез өстенең куе яшел киңлегендә апк акчарлаклар уйный. Алар кинәт диңгез өстенә төшеп суга утыралар, ынтлар һуштан яздырган вак балыкларны эләктереп янадан һавага үтәреләләр. Двигательнең тигез гүләвенә күнеккән кебек, акчарлаклар- ның майламаган ишкәк чөедәй шыгырдавык авазларына да күнегәсең. Алардан башка диңгез күренеше ничектер тулы булмас, җансызланыр кебек.

Безгә каршы кар кебек ак пассажир теплоходы йөзеп килә. Аның палубасы купшы киенгән кешеләр белән тулган. Киндер кисәге тарттып ясалган җиңел урындыкларда эре сөякле, какча йөзле карчыклар йөзеп утыра. Бассейнда кояшта янган тәнле кешеләр чыпырдаша. Җил безгә өзек-өзек итеп бию көе тавышы алып килә.

Гомумән монда хәрәкәт шактый зур. Күз күреме кадәр җирдә һәркайсы төтен бөркеп торучы өч-дүрт моржа күренеп тора. Диңгез өстендә бик күп балыкчы көймәләре кайнаша.

# Бетмәс-төкәнмәс зәңгәрлек



Эгей диңгезен кичәбез. Тәнне, җанны изрәткеч төн. Бераз гына тешләнгән түгәрәк лимон телеме сыман ай яныннан үтә күренмәле каурый болытлар йөгереп үтәләр. Саргылт, күгелҗем-шәмәхә төсләр белән ялтыраган дулкыннар зур пыяла кисәгеннән ватып алынган кебек. Алар бертуктаусыз безнең корабның ян-якларын ышкыйлар. Ике якта вак-вак утраулар очраштыргалый. Аларда үсеп утырган агачлар кап-кара булып күренәләр. Биниһая зур җанварларның азау тешләренә охшап күк аксыллыгы белән каймаланган чем-кара таш кыялар ялтырап кала.

Мин, тоз белән кытыршыланып беткән култыксага тотынып, палубада басып торам. Битемне грек ярларыннан искән йомшак җилгә куеп, койрык артыннан ак күбекләр белән кайнап чыккан дулкыннарның эреп һәм каралып югалуларын күзәтәм. Аннары штурман рубкасына керәм.

Монда, имән такталардан ясалган озын өстәл астындагы кечкенә агач әрҗәләрдә, җир шарындагы бөтен диңгез һәм океаннарның карталары саклана. Алар язгы күк йөзе кебек зәңгәрләр, циркульләр белән төрткә-төртке булып тишкәләнгәннәр. Аларда энә кебек итеп очланган карандаш белән безнең корабның барыр юлы сызылган.

Карталарның почмакларында төрле озынлыктагы дүрт почмаклы «роза тажлары» — шушы тирәдә хөкем сөргән җилләрнең шартлы сурәтләре. Стена буйлап сузылган киштәләрдә энциклопедия томнары шикелле авыр-авыр китаплар — яр буйлары турында белешмәләр; диңгездә йөрү таблицалары; ел саен чыга торган диңгез астрономиясе басмалары; диңгез күтәрелешен билгеләүче, күктәге яктырткычларның биеклеген һәм азимутын күрсәтүче белешмәләр, диңгез атласлары һәм тагын әллә ниткән белешмәлекләр. Бу бихисап саннар кешеләргә диңгез сулышын, җилләр һәм давылларны, магнит бураннарын һәм офыкка һәрвакыт нәкъ үз вакытында гына күтәрелә торган йолдызларны таныргә ярдәм итә.

Почмакларда үтә күренмәле кәгазь төргәкләре, узган юл язылган тасмалар ята. Үтә төгәл хронометр ачык океанда безнең кайсы ноктада булуыбызны билгеләргә ярдәм итүче йолдыз вакытын саклый. Каралып

беткән бәрхет эчле агач капларда йолдызларның офыктагы биеклеген үлчи торган прибор — секстан һәм яшелләнеп беткән бронза каймалы йолдыз глобусы саклана.

* * *

Штурманнар да, механиклар да «сигез аша дүрт» сәгать вахтада торалар. (Ягъни дүрт сәгать эшлиләр, сигез сәгать ял итәләр, аннан тагын эшкә.) Иң авыры «эт» вахтасы — төнге 12 дән 4 кә кадәр. Бу вахтада икенче штурман эшли, ул капитанның икенче ярдәмчесе дә. Иртәнге 4 тән 8 гә кадәр булган вахтаны «король вахтасы» дип йөртәләр, чөнки ул тәүлекнең иң уңайлы вакытына туры килә. Монысын баш ярдәмче белән дүртенче штурман (ул көндезге дүрттән вахтага баса) бүлешәләр. Баш ярдәмчене монда кыскартып «старпом» дип йөртәләр. Кайберәүләр «чиф» та диләр. Монысы «чиф-мейт» — баш ярдәмче дигән инглиз сүзеннән килә булса кирәк. Кичке 8 дән төнге 12 гә кадәр һәм иртәнге 8 дән көндезге 12 гә кадәр булган вахта «сау бул, яшьлек» дип атала. Бусында өченче штурман эшли. Ул бөтен рейс буенча кино караудан да мәхрүм, башка культура чараларына да катнаша алмый. Чөнки бөтен чаралар гадәттә кичке тугызынчы яртыда башлана.

Капитан вахтада тормый һәм, әгәр барысы да тәртиптә булса, күпергенә сирәк күтәрелә. Аның каравы давыл, томан яки башка кыенлыклар килеп чыкса — ул рулевой рубкасыннан бөтенләй китми.

* * *

Бүген, капитан рөхсәте белән, беренче мәртәбә штурвалны үз кулыма алдым. Мин уйлаганча ук кыен түгел икән. Гирокомпасның әйләнеп тора торган картушкасына [1] карыйсың да штурвал тәгәрмәчен әйләндерәсең. Картушка уңга китсә — сулга таба борасың, сулга китсә — уңга таба. Минем янда, теләсә кайсы минутта ярдәмгә килергә әзер булып, рулевой Әхвәрҗаев басып тора. Ул кадәр кыенлыгы юк кебек, ләкин гаять зур игътибар, тәҗрибә, җитезлек һәм эчке бер тоем кирәк. Корабның теге яки бу якка бөтенләй кереп киткәнен көтеп торасы да юк, кораб борыла башлау белән штурвалны кире якка борып кына куясы. Шулай ук штурвалны артык нык әйләндермәскә дә тырышырга кирәк: курстан читкә китүләр никадәр аз булса — шул кадәр яхшырак. Соңыннан курсограф язмаларын караган идем, судноны мин алып барганда боргаланып беткән сызык — «яшен» килеп чыккан. Ә тәҗрибәле рулевой алып барганда бу сызыкта тайпылышлар аз гына беленерлек була. Мондый сызыкны диңгезчеләр «шнурлау» дип йөртәләр. Шунысы да бар, ачык диңгездә бер көе генә барганда рулевой штурвал янында сирәк була — корабны авторулевой алып бара.

* * *

Муса Җәлил турында беренче лекция-әңгәмә үткәрдем. Шагыйрьнең балачагы һәм комсомол елларындагы сугышчан яшьлеге турында сөйләдем. Диңгезчеләр игътибар белән тыңладылар һәм бик күп сорау-

---

[1] Картушка — гирокомпасның дөнья якларын күрсәтә торган шкаласы.

лар бирделәр. Күбесенчә Муса Җәлилнең гаиләсе белән кызыксынучылар — кайсы исән, кайда эшлиләр, кайда яшиләр. Сорауларның байтагы турыдан-туры Муса Җәлил иҗатына кагылмаса да, диңгезчеләрнең әдәбият белән кызыксынуларын, аны күзәтеп баруларын күрсәтә.

* * *

Бүген матрос Коля Кожинов белән чыгыр тәгәрмәчләренә сыланган пычракны чистарттык. Болай карап торырга юк кына эш кебек. Ныгытып куелган болтларны, сырлары бетмәсен өчен, иплэп кенә борып аласың, майлыйсың, әйбәтрәк майлансын өчен чыгыр тәгәрмәчләрен берничә тапкыр әйләндерәсең, артык майны чүпрәк белән сөртеп аласың да болтларны яңадан тыгызлап борып куясың. Ләкин югарыда эшләргә өйрәнмәгәнгә бераз баш әйләнүен, мачталарның әле уңга, әле сулга тирбәлеп баруын һәм күкрәгеңә бертуктаусыз көчле җил бәреп торуын искә алсаң, бик үк җиңел эш тә түгел бу.

* * *

Рейсның башлануы төрле җыелышлар белән билгеләп үтелә — партжыелыш, комсомол, профсоюз җыелышлары. Судно комитетына һәм санитария-көнкүреш комиссиясенә өстәмә сайлаулар булды. Политик мәгариф челтәре үз эшен башлап җибәрде. Ремонт һәм портта тору вакытында тукталып калган техник уку дәресләре яңартылды. Спикердан әледән-әле белдерүләр яңгырый: «Комсомол бюросы членнарына дүртенче штурман каютасына җыелырга!», «Стена газетасы редколлегиясе членнары 18 сәгать ноль-ноль минутта беренче ярдәмче каютасына җыелалар!»

— Кешеләр эш белән шөгыльләнергә тиешләр,— ди беренче ярдәмче Петр Ефимович Светов,— шул чакта гына аларның тормышлары кызык булачак, эч пошарга урын калмаячак.

* * *

Һәр корабта нинди дә булса җәнлек яки кош-корт була. Өч ел дәверендә «Муса Җәлил»дә төрле-төрле җәнлекләр асрап караганнар.

Башта сөйкемле, зирәк, ләкин бик тә тәрбиясез ике маймыл тотканнар. Әллә ниткән тәртипсезлекләр эшләү белән бергә, алар кәгазь сөймиторган булганнар. Кайда гына, нинди генә кәгазь кисәге күрмәсеннәр, аны шул минутта ук ерткалап ташлыйлар икән. Ә кайчакта аларга бик кирәкле кәгазьләр дә килеп эләккәләгән... Инде алар кермәсен дип каюталарның ишекләрен дә ябып йөреп караганнар, ләкин берәрсе ялгыш кына ишекне ачык калдырдымы, болар шул арада каютага керәләр дә, нинди кәгазь бар, барысын да ертып өяләр, җитмәсә өем өстенә кара түгеп китәләр икән. Аптырагач боларны бәйләп куярга уйлыйлар, ләкин тегеләр шундый тавыш күтәрәләр ки, хет колагыңа мамык тыгып йөр. Шуннан аларны ярга чыгарып калдырудан башка чара калмый.

Аннары корабка сирәк очрый торган Африка кәҗәсе алалар. Ләкин ул шул кадәр аңгыра һәм эчпошыргыч була ки, палуба пычратудан

ашка бер эш тә белми. Дингезче күнеленә монсы батмый да батмый иде.

Бервакыт ниндидер хезмәтләре өчен дингезчеләргә Һималай токымннан булган аю баласы бүләк итәләр. Дингезчеләр аны чит ил портарында кыенлык белән генә табыла торган сөт белән туйдыралар. Ләкин үсеп житә башлаганда гына аю баласы бәхетсезлеккә очрый. Ул акытта судно Куба ярларында тора. Куба йөкчеләре курыкмасын өчен, юны озын бау белән бәйләп куялар. Ул кайнар тропик кояшыннан качып шлюпканы каплаган киндер астына керә. Бераздан ул шлюпкадан чыып корабның икенче ягына бара һәм кинәт борттан ычкынып китә дә з бавына үзе асылынып кала. Дингезчеләр күргәндә ул инде үлгән ула.

Ләкин дингезчеләр барыннан да яратыбрак Бабетта дигән арыслан аласы турында сөйлиләр. Өч айлык ул арысланны капитан Африкадагы ер портта нәрсә беләндер алмашып алган. Ярты елдан соң Бабетта уксан килограммлы, арт аякларына басканда кеше биеклеге булган ын арыслан булып үсә. Аны бөтен команда ярата һәм рәхәтләнеп тәрия кыла. Фуфайка яки тыгыз киндердән тегелгән кием кияләр дә тегенең елән көрәшә башлыйлар. Бабетта гаҗәеп оста көрәшә: әле читкә сикерә, ле ничек тә булса җиргә егарга теләп, «дошманы» өстенә ташлана. Ләкин беркайчан да тырнаклары һәм тешләре белән шаярмый. Баштан ле аның белән теләсә никадәр көрәшәләр, ул үсеп җиткәч исә беркем дә ерничә минуттан ары түзә алмый башлый.

Чит ил портларында аны ябып тотарга туры килә. Бервакыт, «Җәлил» фрикадагы ниндидер бер портта торганда, кемдер әллә юри, әллә ялгыш абеттаны ирекkә чыгарган. Ә бу вакытта корабта җирле халык вәкилләре теплоход белән танышып йөриләр икән. Килгән кунаклардан берәү нәт ачы тавыш белән кычкырып җибәрә һәм киеме-ние белән суга керә. Аның артыннан башкалары да ташлана. Дингезчеләр шунда ына койрыгын селки-селки борт буйлап тыныч кына килгән Бабеттаны үреп алалар.

Индонезия ярларында икенче бер кызыклы хәл булып ала. Бабетта айлап кына кают-компаниягә кереп яткан була. Теплоход яңа гына яр ына килеп туктаган, тиздән порт властьлары керергә тиеш. Вахтадагы ингезче Бабеттаны алып чыгарга тели, ләкин арыслан тик ята бирә, ългын да селкетми. Дингезче моны швабра белән куркытмакчы була, Бабетта тегенә азау тешләрен күрсәтеп ырлап кына куя. Капитанны ыкырып китерергә мәҗбүр булалар. Гадәттә Бабетта капитанны башларга караганда күбрәк тыңлый торган була, ләкин бу юлы аны да ынларга теләми. Кают-компаниядә һәрвакыт һаваны сафландырып оралар, күрәсең, арысланның эссе һавага чыгасы килмәгәндер. Шуннан капитан усал гына итеп бер кычкырып куя да ике куллап тегенең ашына барып ябыша һәм ике-өч дингезче белән арысланны идәннән ытәрәләр. Бабетта аяклары җирдән аерылганны сизү белән тынычлана, ойрыгын бот арасына кыса һәм үзен караңгы бүлмәгә ябарга ирек бирә. Ләкин аны бүлмәгә кертеп җибәрүләре була, ул ачуланып бер почмактан икенче почмакка йөренә башлый.

Порттан властьлар килә, кирәкле кәгазьләр һәм таможня декларацияләре белән танышалар да гадәт буенча корабны тикшерә башлыйлар. Ирәк бит — вәкилләрнең берсе Бабетта бикләнгән бүлмә янына килә дә ишекне ачуны таләп итә. Капитан бүлмәдә арыслан булуын, житмәсә ның ачулы да чагы икәнлеген аңлата башлый. Теге ышанмыйча елмая ына: арыслан булса арыслан булыр, ә сез ачыгыз әле, янәсе. Үзе горур иләфәттә иптәшләренә караштырып ала — менә, янәсе, хәзер мин боларның яшерен эшләрен фаш итәм. Капитан янадан бүлмәне ачмаска киңәш итеп карый, ләкин теге һаман үзенекен итә. Шуннан капитан кулын селти

дә, ачкычны борып, ишекне аз гына ача. Шул мизгелдә үк коточкыч ырылдаудан тирә-як селкенеп куя һәм ишек ярыгыннан арысланның куш йодрык кадәр аягы күренә. Кунаклар, җил сыпырып алып киткәндәй, күз ачып йомганчы юк булалар. Капитан җилкәсе белән ишекне тераптора һәм тегеләрне чакыра: «Кая киттегез? Сез бит карарга теләгән идегез?» Ә тегеләр ерактан кул гына селтиләр: ышанабыз, янәсе, тизрәк бикли күрегез.

Гомумән алганда Бабетта акыллы һәм тыныч холыклы була, беркайчан да үзенең көче белән масаймый. Ләкин ул ниндидер хайвани тоем белән үзеннән курыккан кешене шәйли белә. Корабта аннан курка һәм аны яратмый торган бер диңгезче була, Бабетта шуны шаяртырга ярата. Менә матрослар палубада эшлиләр, күгәргән урыннарны ялтыраталар, нәрсәдер буйыйлар. Бабетта мәче кебек тавыш-тынсыз гына атлап нәкъ теге диңгезченең артына килә дә, арт аякларына басып, тегенең иңенә башын куя. Диңгезче куркуыннан лып итеп идәнгә утыра. Иптәшләре шаркылдап көлешәләр, ләкин барыннан да бигрәк Бабетта канәгать. Әлеге диңгезче аннан һәрвакыт качарга тырыша, палуба буйлап үткәндә берничә мәртәбә як-ягына карана. Ә Бабетта баулар өеме артына кача да тыныч кына ята бирә. Ун кеше үтсен — мыегын да селкетми. Теге куркак күренде исә сикереп тә чыга, имән күсәк кебек тәпие белән тегенең йомшак җиренә берне кундыра да.

Диңгезче никадәр тырышыбрак качса, Бабетта аны шулкадәр остарак аулый.

Бервакыт теге диңгезче юкка чыга. Төшке ашка да килми, төштән соң эшкә дә чыкмый, кичке ашта да күренми. Каютасында да, эш урынында да — беркайда да юк теге. Кешеләр инде борчыла ук башлыйлар. Шунда берәү Бабеттаның инде берничә сәгать буе борындагы трюм ишеге төбендә тыныч кына ятуына игътибар итә. Ишек янына килсәләр, тегеннән хәлсез тавыш ишетәләр: «Зинһар, коткарыгыз!» Диңгезче ни өчендер трюмга төшкән икән дә, аннан чыкканда каршында тешләрен ыржайткан Бабеттаны күреп кире кереп киткән. Шулай итеп куркак матрос ярты көн буе трюмда утырырга мәҗбүр булган.

Ниһаять, диңгезчеләр Бабетта белән дә аерылышырга мәҗбүр булалар. Юк, зыян иткәннән түгел. Бөтен диңгезчеләр дә аны яраталар һәм аңа тәмам өйрәнеп беткән булалар. Ләкин Бабеттага көн саен ике кило ярым чи ит кирәк була башлый. Башта капитан портларда үз акчасына ит сатып ала торган була, башкалар да кулдан килгәнчә ярдәм итәләр. Ләкин үсә барган саен арысланны туйдыру кыенлаша бара. Чит илләрдә итне валютага сатып алырга туры килә башлагач, Бабеттаны, япон балаларына бүләк итеп, зур булмаган бер порт шәһәренең зоопаркында калдыралар. Совет диңгезчеләренең бу дусларча мөнәсәбәте турында байтак кына япон газеталары язып чыга, хәтта арысланның рәсемнәрен телевидение аша тапшыралар. Соңыннан да җәлилчеләр, Япониягә килгәч, берничә тапкыр Бабетта янына баралар. Башта әле ул үзенең иске дусларын таный. Диңгезчеләрнең курыкмыйча читлеккә кереп аны иркәләүләрен һәм колакларын кашуларын күреп читлек янына халык җыела. Ләкин Бабетта рәшәткә артында үзенең элекке киң күңеллелеген тиз онытa һәм үзе янына беркемне дә кертми башлый.

Хәзер корабта бернинди токымсыз-нисез, гап-гади бер урам эте Чарлик һәм кают-кампания белән ашханәдәге зур аквариумнардагы алтын балыклар гына калган.

* * *

Капитан миңа торган саен ныграк ошый төшә. Диңгезчеләр аны хөрмәтләп «Оста» дип йөртәләр. Ул 1933 елгы, мондый зур судноның

капитаны булу өчен чагыштырмача яшь кеше. Уртача гәүдәле, бераз гына сирәкләнә башлаган аксыл чәчләрен шома итеп артка тарап йөри. Ачык коңгырт күзләрендә бераз шаянлык бар. Беренче караштан ук пөхтәлеге һәм төгәллеге күзгә ташлана. Роман Александрович беркайчан да кают-кампаниягә шапшак киенеп кермәс, хәтта ачык диңгездә дә көнгә ике мәртәбә кырынып. Аның үз-үзен тотышыннан ук хәрби пөхтәлеге аңкып тора. Диңгездә йөрү буенча югары белем алгач, Роман Александрович башта берничә ел хәрби торпеда катеры командиры булып йөзгән. Мин аңа карыйм да, эчтән генә: «Сугышларда нәкъ менә шушындый яшь офицерлар зур батырлыклар эшлидер инде»,— дип уйлап куям.

Шуның өстенә ул бик укымышлы кеше, аның белән теләсә нинди темага, шул исәптән әдәбият турында да, кызыклы әңгәмә куертып була. Үз-үзен тотышындагы эчке бер нәфислеге бу кешенең нечкә зәвыклы булуын һәм балачактан ук әйбәт тәрбия алган икәнлеген әйтеп тора. Мин моңа баштан ук игътибар иткән идем, ләкин аның шактый танылган рәссам гаиләсендә үсүен күптән түгел генә белдем.

Югары белем бирә торган диңгез училищесына аны балачакның романтик хыяллары алып килә. Дөрес, ул хыяллары беренче мәртәбә диңгезгә чыккан көнне үк челпәрәмә килеп ватыла. Ләкин аларга алмашка тәҗрибә, белем һәм диңгез эшенә аңлы мәхәббәт килә.

Бөек кешеләрдән берәү, кешенең балаларга һәм җанварларга карата булган мөнәсәбәтеннән аның чын асылын белеп була, дигән фикер әйткән. Монда балалар юк, ә җанварларны Роман Александрович җаны-тәне белән ярата. Суднода яшәп киткән җәнлекләрнең барысын да Роман Александрович тырышлыгы нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Бервакыт мин кают-кампаниягә төшеп, Роман Александровичның аквариумнар чистартуын һәм балыкларны үзе каравын күргәч, гаҗәпләнеп калдым. Соңыннан миңа бу аквариумнарның тарихын сөйләделәр.

Бер диңгезче Японíядә алтын балыклар йөзеп йөргән кечкенә генә аквариум сатып ала. Ләкин бит балыкларны һәрвакыт карап торырга кирәк, ә диңгезче бу эштән бик тиз туя. Шуннан аның балыкларын Роман Александрович үзе карый башлый. Ашата, суларын алыштырып тора. Озакламый балыклар үрчиләр һәм капитан аларга берничә бүлекле зуррак аквариум ясый. Бераздан тагын бер аквариум юнәтә. Хәзер монда шаһзадәләр шикелле ашыкмыйча гына кыймылдаучы челтәркойрыклар, кабарынкы торба күзле чем-кара «телескоп»лар, алтын акча кебек ялтырап торган карплар, көмеш сыман сызыклы житез скалярияләр, нәфис кызыл укйөрткечләр йөзеп йөри. Роман Александрович аларның һәркайсы турында сәгатьләр буе сөйли ала. Ул аларга озак-озак карап торырга ярата, һәркайсының холык-фигылен, кайсы балыкны кайсысы янына җибәрергә мөмкин икәнне белә, үзе генә белгән билгеләр аша кайсы балыкның кайчан үрчиячәген чамалый һәм булачак әнкәләрне махсус пыяла савытка, «тудыру йорты»на күчерә.

* * *

Кичә гомуми җыелышта беренче кварталда эшләгән эшкә йомгак ясалды. Экипажда эшләр шәп бара. Планнан тыш өч йөз тоннага якын йөк ташылган. Бу — алай ук зур сан түгел, ләкин, капитан әйтмешли, билгеле бер чикләрдән һәм кагыйдәләрдән өскә сикерең булмый. Әлбәттә, корабка күбрәк тә йөк төяп була, ләкин мондый «арттырып» үтәүнең азагы күңелсезлек белән тәмамланырга мөмкин. Йөз тонна артык йөк

алып бөтен корабны куркыныч астына куюың бар. Төп экономия йөзү һәм тик тору вакытын кыскарту исәбенә ясала. Өч ай эчендә безнең кораб 136 сәгать йөзү, 504 сәгать тик тору вакытын янга калдырган. Ә экономиянең һәр сәгате — берничә йөз сум дәүләт акчасын саклау, корабның әйләнеп кайтуын тизләтү, тагын йөк ташырга вакыт калдыру дигән сүз. Монда барысы да диңгезчеләрнең тырышлыгыннан тора — двигательнең тигез һәм туктаусыз эшләве; иң кыска юл сайлау; җилләрне, агымнарны, су күтәрелешләрен исәпкә алу, давыллар белән очрашудан мөмкин кадәр качып, корабны оста алып бара белү һәм, ниһаять, тәүлек буе төяү яки бушату өчен капитанның порт властьлары белән сөйләшә белүе һ. б. Беренче кварталда планнан тыш алынган табышның гомуми суммасы 85 мең сум тәшкил итә. Ә коллективның еллык йөкләмәләрендә 81,5 мең алырга дип язылган булган. Югарыдагы уңышны исәпкә алып, еллык йөкләмәләрне яңадан карарга һәм яңа, күтәренкерәк йөкләмәләр алырга карар чыгарылды.

Җыелыштан соң мин капитан белән сөйләшеп утырдым. Капитанның фикере буенча, әгәр күбрәк инициатива, кыюлык күрсәтсәң һәм пароходчылыкта үз кадрларына ныграк ышансалар, табышны артыграк та алып булыр иде.

— Югыйсә бит бездә еш кына ничек килеп чыга,— ди капитан,— бер илнең портында йөкне бушатасың. Һәм кинәт безнең өчен бик файдалы эш килеп чыга. Тиз генә радио аша Одесса белән бәйләнешкә керәсең. Анда үз чиратында Мәскәүгә шалтыраталар. Килешүләр, киңәшмәләр башлана. Бер сүз белән әйткәндә, җавап килеп җиткәнче, файдалы эшеңне житезрәк берәр капитан синең борының астыннан эләктереп тә китә. Шуның аркасында без күпме югалтабыз!

* * *

Мин башта, диңгезчеләр мине язучы буларак ничек кабул итәрләр икән, дип борчылган идем. Барысы да үзләре белән язучы чыгачагын беләләр иде. Мин үзем дә язучы икәнемне яшереп ниндидер башка кабыкка төренергә теләмәдем.

Ләкин икеләнүләрем бушка булды — барысы да миңа әйбәт мөгамәлә күрсәттеләр, кирәгенчә генә хөрмәт иттеләр, шул ук вакытта үз дәрәҗәләрен дә онытмадылар. Баштагы мәлдә күпләр миңа кызыксынып карыйлар иде — ни дисәң дә «тере язучыны» беренче мәртәбә күрәләр бит. Бераздан күнектеләр, һәм хәзер мин үземне бу коллективның тигез хокуклы кешесе итеп тоям. Редколлегия эшендә катнашам, радиогазетаның бер санын чыгардым, политуку үткәрдем.

Корабта үзләре каләм тибрәтүчеләр өчәү булып чыкты. Алар бер-бер артлы кадерле дәфтәрләрен тотып минем янга килделәр. Һәрберсе бу турыда минем беркемгә дә әйтмәвемне үтенде. Шигырьләре уртача — диңгез, давыллар, дәһшәтле өермәләр һәм сөйгән кызның ике маяк кебек янып торучы күзләре турында. Гаҗәп, ләкин кыршылып беткән әдәби калыпларның тәэсире диңгезчеләрне урап алган көндәлек мохиттан көчлерәк икән. Күрәсең, язучылык эшендә иң кыены сиңа кадәр язылганнарны тәмам онытып, дөньяны үз күзләрең белән күрә белүдәдер. Мин егетләргә моны турыдан-туры әйттем, һәм алар миңа үпкәләмәделәр булса кирәк.

Кичләрен миңнән еш кына атаклы язучылар турында сорашалар. Бу сораштырулар кайчакта тулы бер «укучылар конференциясенә» әверелеп китә. Диңгезчеләр: «Менә сезгә нәрсә турында язарга кирәк», дип конкрет

тәкъдимнәр дә әйтәләр. Безнең укучыларның язучыга үзенең вәкаләтле вәкил итеп каравы инде күптән билгеле. Ул аннан күңел хушландырырлык язмалар гына түгел, ә турыдан-туры тормышка мөрәҗәгать итеп, шул тормышны үзгәртергә ярдәм итәрлек әсәрләр көтә. Сәяхәт барышында мин моны аеруча ачык сиздем. Бу урында югарыда телгә алынган «конференция»ләрдә әйтелгән кайбер фикерләрне китереп узасым килә (әлбәттә, мин аларны соңыннан, үз каютама кергәч язып куйдым).

— Диңгез турында күп язалар. Ләкин иң күңелне төшергәне шул — кайбер язучы үзе яза торган мохитны начар белә. Болай карап торырга кечкенә генә булып тоелган төгәлсезлек күрәсең дә бөтен ышанычың җимерелә. Бөтенләй җан бизеп китә, укыйсы ук килми башлый. Менә әле күптән түгел генә безнең «Моряк» газетасында язганнар иде: имеш, бер судноның брашпилен яңадан төзәткәннәр дә судноның тизлеген 0,1 узелга арттырганнар.

— Кит аннан, алай язмаслар инде,— дип каршы төшә икенчесе.

— Ничек язмасыннар,— дип кызып китә теге.— Үз күзләрем белән укыдым бит. Я, ярый, ә без: «Судно тизлеген 0,5 узелга арттырырбыз», дигән йөкләмәләрне аз укыйбызмыни? Мескен корабның төзелүенә инде йөз ел үткән, димәк, инде аның тизлеге ел саен кими генә барырга тиеш иде, ә шулай да ел саен яңа йөкләмәләрне кабул иткәндә тизлекне тагы ярты узелга арттырабыз дип язалар. Кайчакта ачу килеп кулга каләм аласың да чутлап карыйсың һәм шаккатасың: әнекәйгенәм, мескен кораб космик тизлек белән йөзә булып чыга. Андый кораб белән диңгездә очрашу да куркыныч, бәреп кенә китәр, син түгел, үзе дә күрми калыр. Ләкин соңыннан аны туган яклардан ерак бер диңгездә күрәсең дә: «Аллага шөкер»,— дип куясың. Космик тизлек белән йөзәргә тиешле корабыбыз вак дулкыннарны чапылдата-чапылдата акрын гына кыймылдый һәм халыкара суднолар йөрешенә берни белән дә янамый... Кәгазь белән тормыш арасындагы аерма менә шуннан килеп чыга да инде...

— Ничек итеп чебеннән фил ясаулары турында язсагыз иде сез. Менә мин сезгә бер мисал китерәм. Егетләр алдарга ирек бирмәсләр. Моннан берничә ел элек безнең бер судно эчке резервлар хисабына күбрәк йөк ташырга, дип, кыйммәтле башлангыч белән чыкты. Һәм, чыннан да, болар кинәт берничә йөз тоннага артыграк ташый башладылар. Бу турыда бик күп газеталар язды. Ә моның сәбәбе бик гади булып чыкты. Сугыш вакытында бу судно бомбалар һәм башка сугыш кирәк-яраклары ташыган икән. Шул чакта судноның трюмнарына һәм палубаларына зур тимер терәткечләр ябыштырган булганнар. Сугыштан соң байтак еллар үткәч берсенең башына уй төшә бит. «Егетләр, бу тимер терәүләрне кисеп атсак, без күбрәк йөк ташый алыр идек ич»,— ди бу. Моны рационализатор тәкъдиме дип күтәреп алалар, бөтен пароходчылыкка шаулыйлар. Хәтерегездәме, ул чакта бөтен корабта диярлек, нәрсәне кисеп ташларга була икән дип эзләнеп йөрделәр. Мөмкин булса бөтен бер корпусны металломга озаткан булырлар иде. Шулай итеп, теге терәүләрне кисеп ташларга тәкъдим итүчегә премия бирәләр. Планны арттырып үтәгән өчен капитанга һәм бөтен экипажга премия өләшәләр... Ә бит, төптән уйлап карасаң, аларны премияләр биреп мактарга түгел, бәлки судка бирергә кирәк иде. Ни шайтаныма алар ничәмә еллар буе шул терәүләрне сөйрәп йөрткәннәр? Һәр адымда шуларга абынып, шуларны җиде бабалары белән сүгеп йөргәннәр, ә кисеп ташларга башлары җитмәгән.

— Эш баш җитмәүдә түгел, югарыдан күрсәтмә көткәннәр алар...

— Менә-менә, бу турыда да язарга кирәк.

# Сүрия кояшы астында



Сүрия ярларына килеп җитәбез. Мин, түземсезләнеп, бинокльдән яр буйларын карап барам. Диңгез зәңгәрлеге, ак күбекле дулкын тезмәләре белән киселеп, кызгылт-сары балчыклы текә ярга килеп терәлә. Саргылт-яшел тау итәкләрендә, кыялар һәм чәнечкеле күгән куаклары арасында кәҗә көтүләре йөри. Күгелҗем зәйтүн урманнары өстендә кабарынкы болытлар өере күренә.

Ә ташлы чүл өстендә кинәт кенә зур-зур ак чәчәкләр сыман булып башта ут көлтәсе күтәрелә, аннары пәри өермәсе кебек кара төтен баганасы пәйда була. Шуннан соң саңгырау гөрелте ишетелә.

— Хәрби маневрлар бара,— ди капитан, кискен генә.— Безне кисәтеп куйдылар...

«Инҗил»дә тасвирланган бу борынгы чүл хәзер Якын көнчыгыш кризисы мәйданына әверелде. Монда хәрби хәл игълан ителү сәбәпле, Латакия портына көн яктысында гына һәм махсус билгеләнгән өч миль киңлегендәге коридордан гына керергә рөхсәт ителә. Әнә бөкре Рас-Зыярәт борыны, дулкын тоткарлагыч һәм зур пирс [1] күренде. Алар артында биек, соры элеватор бинасы калкып тора. Яр буена товар саклый торган каралтылар, биниһая зур нефть чаннары тезелгән.

Шәһәр үзе дә күренә башлады. Бу — без тукталган беренче чит ил порты. Тау буенча тезелеп киткән ике-өч катлы таш өйләр бер-берсенә терәлеп үк утырганнар. Алар яссы түбәле сыерчык ояларын хәтерләтә. Түбәләрдә һәм балконнарда киптерергә эленгән керләр җилферди. Эссе кояштан качып, гөмбәзле биек тәрәзәләр агач япмалар белән капланган. Күккә эсселектән төссезләнеп калган мәчетләрнең ялтыравык гөмбәзләре һәм бизәкле манаралары сузылган.

Портта безне берничә совет корабы каршы ала. Безгә ин якын торган «Машук»тан безне сәламләп кул болгыйлар. Безнең корабның вахтадан бушаган диңгезчеләре барысы да палубага чыктылар һәм, тегеләргә җавап итеп, кул болгый башладылар. Барыбыз да шатланабыз, әйтерсең лә, үзебезнекеләрне еллар буе күрмәгәнбез. Кайберәүләр үзләренең таныш-белешләрен дә күреп алдылар. Уңайлы очрактан файдаланып, «Машук»лылар артыннан өйләребезгә хат язып җибәрергә мөмкин булачак.

---

[1] Пирс — диңгезгә кертеп салынган таш яки бетон дамба.

Порт әллә ни зур түгел. Бер дистә чамасы зур-зур кораб тирәсендә җилкәнле борынгы көймәләр дә бар. Аларның койрыклары кырт киселгән, ә очлы борыннары өскә күтәрелеп тора. Бу көймәләрне күргәч, кинәт дингезче Синдбад заманнары искә төшеп куя. Безнең кораблардагы йөкне һәм авыл хуҗалыгы машиналарын шулай ук безнең илдә эшләнгән көчле порт краннары бушата. Ә җилкәнле көймәләрдәге капчыкларны ябык, кара-кучкыл тәнле, нәзек балтырлы йөкчеләр ташый. Алар күбесе җилкәләренә төшеп торган яулыкларын тар кара тасма белән баш түбәләренә бәйләп куйганнар.

Капитанның беренче ярдәмчесе ярга чыгучыларның исемлеген төзи, өченче штурман кемгә күпме валюта тиешлекне исәпли, ә капитан үзе яр буе властьларын һәм карантин хезмәте күрсәтүчеләрне каршы алырга әзерләнә. Тиздән без борынгы Сүрия җиренә аяк басачакбыз.

* * *

Безнең кораб су астына артык тирән кереп торганга, ул причалга ук бара алмый. Арканнарны судагы тукталыш мичкәләренә генә бәйлиләр. Таможня кәгазьләре тикшерелеп беткәч, безне алырга яр буеннан катер килде. Катерның механигы — киң җилкәле, каратут йөзле гарәп — гаҗәпсенеп безнең суднога карап торды. Без траптан төшә башлагач, ул түзмәде, судно бортына язылган эре латин хәрефләренә бармагын төртеп: «Му-са Җә-лил» дип кычкырып куйды. Без, әйе, дип баш селкибез. «Кем ул Муса? — дип сорый бездән механик, инглиз телен вата-вата,— мөселманмы?» Мин көчемнән килгәнчә аңлатырга тотындым, Муса Җәлил — татар шагыйре, герой, фашистлар белән көрәштә һәлак булган, дим. Механик, мине тыңлап бетергәч: «Кем ул татар?» — дип сорый. Мин тагын аңлата башладым, татарлар — Советлар Союзындагы төрки халыкларның берсе, Җәлил үзенең шигырьләрен татар телендә язган, дим. Төрки дигән сүзне ишеткәч, механик җанланып китте: «О, төрки, беләм, беләм, мин бер румын төркинен белә идем»,— ди. Сүзләрен раслау өчен, ул безгә төрекчә сәлам бирә. Мин аңа татарча җавап кайтарам һәм үземнең дә төрки икәнемне әйтәм. Механик ышанмыйчарак мине баштанаяк күздән кичерә: «Сез Россия мөселманымы? Ә «Коръән»не беләсезме?» дип сорый. Мин «Коръән»нең башлангыч сурәсеннән кайчандыр әбием өйрәткән бер өзекне әйтәм. Механик күккә ашардай булып шатлана. Шуннан ул штурвалын бөтенләй ташлап, кулларын чәбәкли-чәбәкли, нәрсәдер сөйли башлый. Мин, әлбәттә, аның сөйләвеннән берни дә аңламыйм, каршы очраган баржаларның берәрсенә барып бәрелмәсәк кенә ярар иде, дип куркып торам. Ә механик үзенең яңа хәбәрен юлда очраган катерларның рулевойларына ирештерергә теләп, якягына: «Мин рус мөселманы утыртып барам!» — дип кычкыра.

Бераздан без аның белән сөйләшеп утырдык. Ул төрекчә сөйли, мин татарча җавап бирәм. Аңлашылмаган урыннарда инглиз һәм гарәп сүзләре кыстырып җибәрәбез. Механик миңа үзенең Гали исемле икәнен, портта инде егерме еллар чамасы эшләвен, хатынының сигез бала белән өйдә утыруын сөйләде. Мин аңа, сигез бала күбрәк түгел микән, дигәч, ул кискен итеп баш кына селтәде — һич юк, янәсе. Шунда ук ул миңа мисаллар да китерә башлады: аның бер иптәшенең тугыз баласы бар икән, ә икенче бер дустының — ун. Аның сүзләренә караганда, сигез бала ул гомумән күп түгел икән, һәм Гали миңа шукланып күз кыса — әле ул тагын кимендә бер яки ике бала булыр дип өметләнә, янәсе. «Безнең бәхетебез һәм киләчәгебез балаларда түгелмени?!» — дип, фәлсәфи рәвештә сүзен тәмамлый ул. Мин, әлбәттә, аның бу сүзләренә каршы килмим. Дөрес, бераздан аның һәр баласы башлангыч белем белән генә чикләнгәнлеге, малайлары унике-унөч яшьтән эшли башлаулары ачык-

ланды. Ләкин Гали боларны гадәти күренеш дип исәпли, ахры, чөнки ул хәзерге тормышын элеккегә караганда күп мәртәбәләр яхшы дип сөйләде.

* * *

Чит-ят илдә биш-алты көн эчендә нәрсәне генә күреп һәм аңлап өлгерә аласың?! Шулай да илнең гомуми сулышын тоеп була. Чөнки син монда бөркү турист автобусында кысылып, экскурсовод кая кушса, шунда башыңны борып йөрмисең. Шәһәрнең кайсы почмагына барырга теләсәң дә — ирек. Урамнарда кәҗә һәм сарык көтүләрен куганны карап йөрисең, мәзиннең озын итеп азан әйткәнен тыңлыйсың, ашханәләргә һәм кечкенә кибетләргә кереп чыгасың, кешеләр белән сөйләшәсең.

Яр буйлап сузылган киң асфальт юлның ике ягында горур пальмалар киң яфракларын кыштырдатып утыра. Соры таштан өеп ясалган озын коймалар артында таныш булмаган ниндидер куаклар шау чәчәккә күмелгән. Эре, ачык шәмәхә төстәге ул чәчәкләр баш әйләндергеч хуш ис тарата. Яр буендагы олеандра чәчәкләре алсу болытлар шикелле кабарып тора. Көнчыгыш стиле белән төзелгән затлы виллаларның, мәрмәр өйләрнең, мәһабәт банклар һәм дәүләт биналарының коймаларыннан һәрберсе чәй тәлинкәсе кадәр ак, аксыл сары, алсу төстәге купшы роза чәчәкләре асылынып тора.

Шунысы кызык, яр буе урамыннан борылып эчкә кергәч, яшеллек кинәт юкка чыкты. Тар, кәкре, түшәлгән ташлары ашалып беткән кечкенә урамнар башланды. Кая карама — соры таш, бары тик анда-санда гына коңгырт-кара яфраклы чормавык үләннәр күренә. Кайбер ишек алларында ачык яшел төстәге ялгыз инҗир агачлары үсеп утыра.

Урамның күләгәле ягындагы тротуарларда үкчәләренә җиткән киң ак чапаннан гарәп картлары утыра. Алар башларындагы шакмаклы яулыкларын дөя йонынннан бәйләнгән ике кат тасма белән бәйләп куйганнар. Кайберсенең кулында дисбе, күбесе башларын күкрәкләренә салып йоклыйлар. Шунда ук учма-учма йоны коелган ишәкләр күләгәгә башларын тыгып йокымсырый. Уяу гарәпләр кызыксынып безне күзәтәләр. Ләкин алар башларын бормыйча, безне күзләре белән генә озатып калалар. Урамга сибелеп йокымсыраучы бу кавемне уятудан курыккандай, без ирексездән тавышларыбызны акрынайтабыз.

Каршыбызга баштанаяк карага киенгән бер хатын килә. Битенә ул кара челтәр каплаган. Бер кулы белән башындагы зур төенчекне тоткан, икенчесе белән өч-дүрт яшьләрдәге бер малайны җитәкләгән. Итәгенә исә кара чәчле, кара күзле биш-алты яшьлек кыз ябышып килә. Урамнарда хатын-кызлар аз һәм барысы да диярлек битләрен япма белән каплаган. «Кара!» — дип янбашыма төртә бер дингезче. Борылып карасам, урамның теге ягыннан яшь кенә бер кызый нәзакәтле генә атлап бара. Өстендә кайтарма ак якалы кара костюм, аягында кадак үкчәле туфли, йөзендә ярым үтә күренмәле капрон тукыма. «Яраклашкан!» — дип көләләр дингезчеләр.

Ике-өч квартал үткәч, без шәһәрнең сәүдә өлешенә килеп чыгабыз. Кинәт этеш-төртеш, шау-шу, ыгы-зыгы арасында калабыз. Урамның ике ягына тезелеп киткән исәпсез-хисапсыз вак-вак кибетләрдәге сатучылар бар тавышларына акыра-акыра, кулларын болгый-болгый үз әйберләрен сатып алырга чакыралар. Кока-кола һәм эфлисун суы сатып йөрүче малайлар узган-барганның җиненнән эләктерердәй булып товарларын тәкъдим итәләр. Кофе сатучы, җиз чәшкәләрен шалтырата-шалтырата, кешеләрнең игътибарын үзенә җәлеп итәргә тырыша. Аның арбасына кофе тегермәне көйләнгән һәм шунда ук, хуш ис таратып, кофе кайнап утыра.

Монда егерменче гасыр яңалыклары белән мөселман урта гасырының язмалеге гаҗәпкә калдыра. Менә тар тыкрыктан, чем-кара буяуларын һәм никельләрен ялтыратып, һавага бензин исе бөркеп, Америкада эшләнгән зиннәтле җиңел машина килеп чыкты да кинәт туктап калды. Велосипед тәгәрмәчле агач арбага җигелгән ишәк юлга аркылы килеп туктаган икән. Автомобиль җан-фәрманга кычкырта. Стена буендагы күләгәдә аякларын бөкләп утыручы гарәпләр бер-берсенә карашып алалар да тирән бер канәгатьлек белән елмаеп куялар.

Яртылаш буш ашханә ишеге төбендә аякларын бөкләп, рәхәтләнеп күзләрен йомган килеш хурхур тартучылар утыра. Аларның алҗыган ябык йөзләре ачлыктан хәлсезләнгән кешене хәтерләтә. Ашханә хуҗасы өстәлләрдәге чүп-чарны идәнгә себереп төшерә һәм ашханәдәгеләрне игътибар белән күзәтеп тора. Ул муенына япон транзисторы аскан, аннан сагышлы көнчыгыш моңы агыла.

Адым саен мәчет. Кая таба гына карасаң да, күз алдында ике-өч манара. Менә бер мәчетнең ачык ишегеннән тышкы якка намаз укыган тавыш ишетелә. Берничә кеше, дөнья мәшәкатьләрен онытып, идәнгә җәелгән кыйммәтле келәмгә маңгайларын бәрә-бәрә дога кылалар. Ишек алды түрендә ак чалмалы, озын чапанлы кешеләр йөри. Ирексездән үзеңне «Мең дә бер кичә» әкиятләрендәге кебек хис итәсең. Ләкин манара кәрнизенә көчле репродуктор беркетелгән. Кичке намаз житкәч, мәзин тар баскычлардан әйләнә-әйләнә манарага үрмәләмәс, магнитофон төймәсенә басу да җитә.

Өйләрнең беренче катлары кибетләрдән генә тора диярлек. Кагыйдә буларак ишекләр дә, витриналар да, язулар да юк. Алар урынына күтәреп куела торган тимер капкачлар гына — кибетләр турыдан-туры урамнан башланып китә.

Кибетләр никадәр күп булса да, сатып алучыларны бармак белән генә санарлык. Кайбер кибетчеләр, безнең Россиядән икәнлегебезне каяндыр танып, үзләре белгән барлы-юклы рус сүзләрен тезәргә тотындылар:

— Москва, спутник — карашо! Гагарин карашо! Амэрикэн плехо! Кер, кер! Сатып алмасаң — бушлай карарга кер!

Ә кибеткә керсәң, хуҗа шулкадәр дустанә елмаеп һәм баш иеп синең тирәдә бөтерелә башлый, үзенең бөтен товарын һичбер иренмичә күрсәтә — нәрсә дә булса сатып алмыйча чыгып китү оят кебек тоела. Сатулашырга дисәң инде, монда аны булдыралар. Хуҗа күзен дә йоммыйча әйбернең ике бәясен сорый, аннан акрынлап төшә башлый һәм моны ул бары тик сиңа чиксез хөрмәт йөзеннән генә, үзенә зыян китереп эшләгән итеп күрсәтә. Без кибеттә сатулашырга өйрәнмәгән, һәм әгәр берәр диңгезче товар бәясен кыйммәтсенеп кибеттән чыгып китә башласа, хуҗа аңа үпкәли үк башлый. Ул: «Кирәкме соң? Кирәк булса чыгып китәргә ашыкма, сатулаш...» — дип арттан кычкырып кала.

Арырак җиләк-җимеш һәм яшелчә рәтләре китә. Сәкеләрдә һәм арбаларда яңа гына агачыннан өзелгән, әле яфраклары да шиңеп өлгермәгән лимоннар, кызгылт-сары әфлисуннар, төрле төстәге һәм төрле эрелектәге алмалар. Киптерелгән, каклаган, уылган яки яңа гына сабагыннан өзелгән инҗирләр һәм хөрмәләр, алычалар, зур-зур бәйләмнәрдә тимгел-тимгел яшел бананнар, кузылар, өрекләр, бадамнар.

Тау ягыннан искән җил ком һәм тузан алып килә, урамдагы кәгазьләрне һәм чүп-чарны өскә күтәрә. Зур калай чүп савытларында җыен калдык-постык череп ята, тирә-якка ишәк тизәгеннән ачы ис тарала.

Менә чүлмәк рәте китте. Бөтен товар күз алдында — кара тышлы ялтыравык коштабаклар, мискиләр, чүлмәкләр, борынгы грек савытларына охшаш нәзек тамаклы озын балчык савытлар. Киндер чатыр астында күзләрен йомып бер карт утыра. Ул озын ак чапан өстеннән иске җилән кигән һәм башына ак яулык бәйләгән. Без үтеп киткәндә ул торып

баса да, сул кулын йөрәге турына куеп баш ия һәм яңадан үз урынына утырып, күзләрен йома.

Ике адым да үтмибез, тагын шундый ук чүлмәкләр кибете янына килеп чыгабыз. Сатучысы да нәкъ баягысына охшаган — күз кабаклары җилсенгән, зур борынлы, салмак хәрәкәтле гарәп. Арырак киткәч тагын шундый чүлмәкче очрый, аннары тагын. Ләкин берсе янында да сатып алучы күренми.

Аз гына арырак хөрмә белән кабартма һәм мондагыларның иң яраткан ашы — кыздырган саранча саталар.

Искелектән кыршылып беткән соры таш стеналар һәм эссе, аксылзәңгәр күк фонында болар барысы да гаять дәрәҗәдә чуар күренәләр.

* * *

Шәрә стеналы кечкенә контора. Эчкә узу белән гади итеп ясалган иске язу өстәле һәм биш-алты тәбәнәк урындык күзгә ташлана. Тәрәзә аша бер тасма гына булып Урта диңгезнең ачык зәңгәрлеге күренә. Корабыбызга беркетелгән вәкил — шипшандлерда[1] кабул итү мәҗлесендә утырабыз. Хуҗаның ярдәмчесе төрекчә куе итеп ясалган кофе тәкъдим итә, рюмкаларга брэнди сала. Өстенә кара йон костюм кигән, зур гәүдәле, урта яшьләрдәге җитди кыяфәтле шипшандлер безне Америка сигарасы белән сыйлый һәм нык, сары тешләрен күрсәтеп елмая. Зур борыны астында бер чеметем генә кара мыегы тырпаеп тора һәм зәйтүн төсле йөзе майланып тирли, ләкин ул галстугын да бушатып куймый. Аның юан, йонлач бармаклары алтын балдаклар белән бизәлгән, кар кебек ак җиң очларында алтын кашлы зур каптырмалар.

Баш ярдәмче аның белән корабка яшелчәләр, җиләк-җимешләр, төче су һ. б. алу турында сөйләшеп бетергәч, шипшандлер безнең Сүриядә алган беренче тәэсирләребез турында сораша. Бөтен диңгезчеләр дә, сөйләшеп куйган шикелле, миңа таба борылалар һәм хуҗага минем язучы һәм журналист икәнлегемне әйтәләр. Мин, инглизчә сүзләрне кыенлык белән генә сайлап, беренче көннәрне нәрсәләр күрүем һәм нәрсәләр тоюым турында аңлатам.

Шипшандлер итагатьле генә итеп, күзләрен ярым йомып, бүлдермичә тыңлый, шулай да мин, аның йөзенә карап, сөйләгәннәремнең аңа ошамавын сизеп торам. Һәм шулай булып чыга да, мин авызымны ябуга, ул зур гына кайнар нотык сөйләп ташлый. Һәр сүзен кулларының кискен хәрәкәте белән ныгыта бара.

— Экзотика, әлбәттә, кызык инде,— ди ул.— Ләкин туристлар өчен кызык булып күренгән нәрсәләр безнең өчен бер дә кызык түгел. Менә сез бит япмаларын күргәнсез, ләкин инде безнең эшли яки укый торган алдынгы хатын-кызларыбыз битләрен япмыйлар. Һәм без бу искелек калдыгын тәмам бетергәнче көрәшәчәкбез. Әйе, безнең ирләребез башларына яулык бәйләп йөриләр. Ләкин бит бу, кайбер көнбатыш эшлеклеләре әйткәнчә, урта гасырлардан килгән искелек калдыгы түгел. Бу безнең һава шартларыбыз белән бәйләп каралырга тиешле үзенчәлек. Сез базар этеш-төртешләрен һәм андагы чуарлыкны да күргәнсез. Ә сез Сүриянең Якын Көнчыгышның йөрәге икәнлеген һәм, аннан да бигрәк, аның кешелек дөньясы чәчәк аткан беренче бишек икәнлеген беләсезме? Безнең культурабыз борынгы Эллада яки Римга караганда алдан чәчәк аткан булганын беләсезме? Көнбатышта безнең берничә гасырлар буе артка калуыбыз һәм торгынлык кичерүебез турында язалар. Мин сезнең аларга иярмәвегезне телим. Безнең илебез 400 ел төрек басып алучылары

---

[1] Шипшандлер — корабларны азык-төлек, су, запчасть һәм башка кирәк-ярак әйберләр белән тәэмин итүче агент.

кулы астында интеккән, аннан соң Француз колониясе булып торган. Безнең халык әле нибары 1945 елда гына бәйсезлек яулап алды. Үзегез дә аңлыйсыздыр, бу бик аз вакыт. Һәм 1963 елның 8 мартыннан, ягъни хөкүмәт башына Баас[1] партиясенең сул канаты килгәч кенә, илне прогресска һәм чәчәк атуга алып баручы демократик реформалар ясалды...

Бу кешенең милли тойгыларына кагылуым өчен мин уңайсызланып китәм һәм дингезчеләр дә миңа чәнчеп карыйлар. Шулай да безнең кечкенә мәҗлесебез матур тәмамлана. Шипшандлер безне җилкәләребездән дусларча кагып озатып кала, киң итеп елмая һәм тагын килергә чакыра.

Бу кечкенә генә сөйләшү миңа шактый нәрсәне аңларга ярдәм итте. Әйе, тулы бер ил турында беренче тәэсирләр нәтиҗәсендә генә хөкем йөртергә ярамый. Сүрия гарәп республикасы хәзер зур үзгәрешләр алдында тора. Ул, Якын Көнчыгышта беренче ил булып, капиталистик булмаган үсеш юлына басты. 1968 елдан башлап Сүрия халкы илнең нефть байлыкларын үз кулына алды һәм бөтен чит ил нефть компанияләрен юкка чыгарды. Шуның белән Сүрия халкы башка гарәп илләренә дә үрнәк күрсәтте. Көнбатыштагы финанс һәм промышленность магнатларының Сүриядәге уңышларны күреп борчылулары юкка гына түгел. Алар фикеренчә, Сүрия җир шарының бу почмагында чын мәгънәсендә империализмга янаучы реаль көч.

Хәзер дәүләт секторы бөтен авыр промышленность предприятиеләренең 85 процентын берләштерә. Илнең промышленностена салынган капиталның 77 проценты дәүләт контролендә. Милли кадрлар, укытучылар, врачлар, инженерлар хәзерләү буенча күп төрле чаралар үткәрелә.

Авыл хуҗалыгында китмәнгә һәм уракка алмашка тракторлар һәм өр-яңа авыл хуҗалыгы машиналары килә.

Сүрия халкы үзенең демократик юнәлештә үсешендә Советлар Союзы халыкларының дусларча ярдәменә таяна. Менә безнең бу килүебез дә шуның матур бер үрнәге булып тора: ике ил арасында төзелгән үзара экономик һәм техник ярдәмләшү буенча, без Латакиягә нефть промышленносте җиһазлары алып килдек.

Латакиядә без совет белгечләре, тимер юл төзелешендә эшләүче мәскәүлеләр белән дә очраштык. Алар безгә хәзер Сүриядә байтак кына совет белгечләре — инженерлар, геологлар, врачлар эшләве турында сөйләделәр. Бу белгечләр сүриялеләргә үз милли кадрларын үстерергә булышалар, табигый байлыкларны эзләүдә катнашалар, нефть-химия промышленносте предприятиеләре төзелешләрендә эшлиләр икән. Гаять кыен климатик шартларга да карамастан, совет белгечләре, һәрвакыттагыча, үзләрен әйбәт яктан гына күрсәтәләр.

* * *

Латакия Израиль чигеннән шактый ерак урнашкан, ләкин монда да киеренкелек сизелеп тора. Өй стеналарына, таш коймаларга, хөкүмәт учрежденнеләре янындагы махсус такталарга Израиль агрессорларына кискен каршылык күрсәтергә чакырып һәм Палестина патриотларына теләктәшлек белдереп язылган плакатлар ябыштырылган. Анда-санда хәрби патрульләр очраштыргалап куя. Яшел хәрби машиналар узып китә. Портта берничә хәрби корабль тора.

Кайсы гына гарәп белән сөйләшергә туры килмәсен, барысы да Израиль басып алучыларын гарәп җирләреннән куып чыгарырга әзер торуларын белдерәләр.

Бу көннәрдә без әлеге катер йөртүче Гали белән бөтенләй дуслашып киттек. Ул мине күрү белән ерактан ук елмая башлый, үзенең катерын

[1] Баас — Сүриядә идарә итүче партия.

җитез генә безнең кораб янына алып килә. Әгәр инде без аны көтмичә башка катерга утырып китсәк, үпкәли үк башлый. Ул миннән биграк та Совет илендәге тормыш турында һәм төрле милләт вәкилләренең үзара ярдәмләшеп яшәүләре турында сораша. Мәсәлән, Казанда эшли торган мәчет булуын һәм дин тотучы мөселманнарның анда йөрергә тулысынча хокуклары бар икәнен белгәч, ул гаҗәпкә кала. Ә өлкән буын мөселманнарның бик зур күпчелеге мәчеткә йөрмәүләрен, яшь буынның бөтенләй йөрмәвен һәм хатын-кызларның берсе дә битләрен япмыйча йөрүләрен белгәч, тагын да ныграк гаҗәпләнә. Россиядә медицина хезмәтләренең, белем алуның бушлай икәнен, студентларга дәүләт хисабыннан стипендия дә түләнүен сөйләгәндә, Гали әкият тыңлагандай соклана һәм бөтенләй үк ышанып та бетмичә тора.

Бу әңгәмәләр вакытында безнең янга йөкчеләр, шоферлар, портта эшләүче гарәпләр җыела. Гали миңа аларның сорауларын тәрҗемә итә, ә мин ничек тә булса аңлаешлырак һәм гадирәк итеп җавап бирергә тырышам. Мин сөйләгәннәрнең тәрҗемәсен тыңлагач, гарәпләр җөпләп баш селкиләр, нәрсә турындадыр кызу-кызу сөйләшеп алалар. Аннары яңадан сорау бирә башлыйлар.

Халыкара хәлләргә бәя биргәндә төрле кешенең төрлечәрәк фикер йөртүе сизелә. Ләкин кем белән генә очрашып сөйләшергә туры килмәсен, бер мәсьәләдә барысы да бер фикердә — һәркем совет кешеләренә һәм безнең илгә карата дуслык мөнәсәбәтләрен яклый. «Советлар Союзы — гарәп халыкларының дусты!» — дигән сүзләрне бик еш ишетергә туры килде. Хәтта порт сакчылары да, совет диңгезчеләрен күргәч, дустанә елмаялар һәм безне, рөхсәт кәгазьләребезне карамыйча гына, уздырып җибәрәләр. Китап кибетләрендә без гарәп телендә басылган Ленин хезмәтләрен күрдек. Ленин рәсеме төшерелгән значокларны аеруча яратып алалар. Кайберәүләр аларны күкрәкләренә кадыйлар, ә кайберләре кадерләп төрәләр дә кесәләренә салып куялар. Ленин идеяләренең яктысы борынгы Сүрия җиренә дә килеп җитүен күрү — күңелдә горурлык һәм шатлык хисе уята.

*Дәвамы бар*

**Әмир Нәҗип,**
филология фәннәре докторы

# УРТАК ХӘЗИНӘ

Хәзерге төрки телләрнең узганын эзлекле рәвештә төгәл өйрәнү, шул исәптән язма истәлекләрнең лингвистик хосусиятьләрен ачыклау филология фәнебездә иң катлаулы мәсьәләләрдән санала. Бу — чыннан да шулай күп көч, этрафлы белем сорый торган өлкә. Мәсәлән, иң элек, бер дәвердә иҗат ителгән язма истәлекләрне барларга, аларны чагыштырып тикшерергә һәм шуннан чыгып фәнни нигездә классификацияләргә кирәк. Моннан соң, алар туган чорларга караган мөһим фактларның һәммәсен дә истә тоткан килеш, тарихи, иҗтимагый-социаль, географик шартларны җентекләп өйрәнү таләп ителә. Аннары чиратта теге яки бу төбәктә яшәгән халыкларның этник составын ачыклау, шул халык яки кабиләнең күченеп йөрү фактларын күзәтү, шундый миграцияләр нәтиҗәсендә төрле урыннарда хасыйл булган яңа мәдәни мәркәзләрне билгеләү кебек зарури таләпләр тора. Ниһаять, мондый үзәкләр арасында барган әдәби-мәдәни мөнәсәбәтләрне, шундый аралашулардан туган нәтиҗәләрне[1] ачыкларга һәм тагы башка күп кенә катлаулы сорауларга җавап табарга кирәк. Әгәр бу мәсьәләләрне тиешле дәрәҗәдә хәл итмичә торып, теге яки бу язма истәлекне бер селтәнүдә үк хәзерге төрки халыкларның берәрсенә турыдан-туры нисбәт итә башласалар (кызганычка каршы, бездә моның мисаллары шактый), тупас хаталар һәм фәннилектән ерак тора торган зарарлы нәтиҗәләрдән котылып булмаячак. Мәгәр язма истәлекләрнең милли җирлеген билгеләү дә бик мөһим мәсьәлә, чөнки бу лингвистика өчен генә түгел, бәлки төрки телле язма әдәбиятларның тарихын дөрес яктырту өчен дә зарури.

* * *

Урта гасырларга карагач төрки язма истәлекләренең һәммәсе дә диярлек *катнаш* тел белән язылган. Кайберләренең нигезендә *уйгур* теле ята; икенчеләре исә, тулаем уйгурча булганы хәлдә, *карлук-чигел* теленең йогынтысы астында барлыкка килгән. Бераз соңрак иҗат ителгән әсәрләрдә *уйгурча* тел-нигезгә *угыз-төрекмән* яисә *кыпчак* телләренең тәэсире көчәя башлавын күрәбез. Тагы да соңрак, ягъни XIII — XIV йөзләрдә, *уйгурча* тел-нигез интенсив рәвештә кысрыклана башлый һәм аның урынын *угыз-төрекмән* яисә *кыпчак* телләре яулап ала. Шулай итеп, нигезен *угыз-төрекмән* яки *кыпчак* телләренең берсе тәшкил иткән бөтенләй диярлек башка сыйфатлы яңа катнаш телләр барлыкка килә. Хәер, *уйгур*, дөресрәге, *уйгур-карлук* теле дә бөтенләй эзсез югалмый; мисалга элгәрге әдәби традицияләрнең йогынтысы сыйфатында телдә сакланып калган уйгурча лексик-грамматик элементларны күрсәтеп булыр иде. Төрки телләр тарихында зур этапны тәшкил иткән мондый процесс XIV гасырга — катнаш *уйгур-угыз-кыпчак* телләре нигезен-

[1] Әйтик, төрле-төрле этник даирәләрдән чыккан галимнәр, язучы һәм шагыйрьләрнең күченеп йөрүләре, икенче бер илләргә барып иҗат итүләре, менә шулар нәтиҗәсендә бер җирле шивә нигезендә формалашкан әдәби телгә икенче шивәләрнең тәэсир ясавы һ. б.

дә күп санлы әдәби әсәрләр тудырылган чорга карый. Соңга таба милли әдәби телләр булып калыплашкан үзбәк, татар, әзербайҗан, төрекмән һәм тагы башка әдәби телләрнең тарихлары да шушы дәвердән үк башлана, чөнки аларның барсы да әле генә аталган катнаш нигезле язма телдән аерымланып чыга.

Урта Азия һәм Идел буе язма истәлекләренең тел хосусыятләрен тикшергән чакта, бездә боларга карахани яисә турыдан-туры уйгур әдәби телләренең көчле йогынтысы ясаган булуын әйтеп узу гадәткә кереп киткән. Әмма, моннан тыш, шул телләр белән бер үк вакытта — параллель рәвештә диярлек яшәгән һәм алар белән азмы-күпме эчке мөнәсәбәттә була килгән угыз-төрекмән тел традицияләрен дә онытып җибәрмәскә кирәк иде. Чөнки бу угыз-төрекмән тел традициясе кайбер төрки әдәбиятлар тарихында аерата зур роль уйнаган.

Урта Азия халыкларының язма истәлекләрен җентекләп тикшергән тюркологлардан мәрхүм А. К. Боровков та, мәсәлән, көнчыгыш төрки (ягъни карахани) әдәби теле белән бергә Урта Азиядә борынгы угыз-төрекмән әдәби тел традицияләренең дә яшәп килгән булуын исбатлап (дөрес, мин бу очракта «борынгы» дигән билгеләмә белән артык мавыкмас идем — Ә. Н.), бу угыз-төрекмән теленең XI — XIV йөзләрдә үк киң таралган булуын әйтә. Чөнки, ди ул, шул дәверләрдә үк әлеге карахани, угыз-төрекмән һәм иске үзбәк әдәби телләре өчен һәрберсенә хас диалекталь җирлекләр аерымланып чыккан була[1]. Галимнең әйтүенә караганда, күп санлы язма истәлекләр иҗат ителгән угыз-төрекмән теленең диалекталь нигезе оешуда Түбән Сыр-Дәрьяда яшәүче җирле кабиләләр төп рольне уйнаганнар. һәм бу угыз-төрекмән әдәби теле XII—XIV йөзләрдә Хорәзм җирлегендә формалашкан[2].

Минем фикеремчә, угыз-төрекмән шивәсе тәүбаштан ук әдәби теленең нигезен тәшкил иткән, һәм бу хәл, тарихи күзлектән караганда, борынгы дәвергә түгел, бәлки урта гасырларга туры килә[3]. Кыскасы, XII йөздә Түбән Сыр-Дәрьяда формалашкан бу тел тиз вакыт эчендә камилләшеп өлгерә һәм соңрак үз тәэсирен Төньяк Хорәзм белән Түбән Иделгә хәтле җәелдерә. Ә Алтын Урда дәверендә исә ул элекке уйгур телен тагы да интенсиврак рәвештә кысрыклый.

Менә шул дәверләрдән башлап, югарыда атап күрсәткән әдәби традицияләр төрле даирәләрдәге төрле авторларның иҗатларында төрлечә чагылыш табалар. Мәсәлән, кайбер әдипләрнең әсәрләре нигезендә уйгур әдәби тел традицияләре ятып, угыз-кыпчак теле тышкы тәэсир дәрәҗәсендә генә йогынты ясаган булса, икенчеләрендә, киресенчә, кыпчак-угыз әдәби традициясе тел нигезен тәшкил иткән. Монда, әлбәттә, әсәрләрнең нинди этник даирәдә язылган булулары да зур роль уйнаган. Әйтик, гел төрекмәннәр яшәгән Түбән Сыр-Дәрья, Төньяк Хорәзмдә иҗат ителгән хезмәтләрдә угыз элементлары билгән мәйдан киңәйгәннән киңәя барган; ә кыпчаклар күбрәк булган Түбән Иделдә исә, киресенчә, угыз элементлары кысрыкланып, яңа әдәби тел кыпчак шивәсе исәбенә баеган. Дөрес, элегрәк хөкем сөргән уйгур-карахани әдәби теленең тәэсире дә бөтенләй юкка чыкмый. Моңа ике фактор сәбәп булган. Беренчедән, бу — элекке традициягә ташлама ясауның бер нәтиҗәсе булса, икенчедән, Алтын Урда дәүләтендә хезмәт иткән күп санлы уйгур бахчилары да[4] җирле әдәби телгә азмы-күпме тәэсир ясаганнар. Шул ук вакытта уйгур әдәби тел традициясе XII—XIV гасырларда бары Урта Азиядә генә хөкем сөрә алуын, ә Түбән Сыр-Дәрья, Хорәзм һәм Түбән Иделдә, әле генә әйтелгәнчә, беренче урынга кыпчак-угыз теле чыккан булуын тагы бер кат искәртеп узарга кирәк.

XV йөздә, ягъни тимурилар хөкем сөргән чорда, менә шундый төрле традицияләрнең кушылуы нәтиҗәсендә Урта Азиядә бөтенләй икенче, яңа сыйфатлы әдәби тел барлыкка килә, һәм ул тел Миргалишир Нәваи заманында үзенең иң югары ноктасына ирешә. Бу инде соңрак шартлы рә-

---

[1] А. К. Боровков. Лексика среднеазиатского тефсира XII—XIII вв. Мәскәү. 1943. 10, 13 битләр.

[2] Шунда ук, 20, 23 битләр.

[3] «Борынгы» дигән төшенчәне сак кулланмау бигрәк тә татар филологиясе белемендә нык сизелә. Мәсәлән, татарча хезмәтләрдә «Йосыф китабы» да, Утыз Имәни әсәрләре дә бер уңайдан «борынгы» категориясенә кертеләләр. Күренә ки, сүз гыйльми атама булудан бигрәк, гадәти көнкүрештәге мәгънәсеннән аерылып житми. Нәтиҗәдә, буталчыклык кына килеп чыга.

[4] Бахчи — эш кәгазьләре алып баручы, секретарь.

вештә чыгытәй, ә безнең көннәрдә исә иске үзбәк теле дип атала торган мәгълүм әдәби тел иде. Нәкъ менә шушы дәвердә, хәтта аннан соңрак та, элекке Алтын Урданың төньяк өлкәләре булган хәзерге Татарстан белән Башкортстан территорияләрендә әллә ни үзгәрмичә үк әлеге кыпчак-угыз тел традициясе яшәвен дәвам иттерә. Хәтта хәзерге татар әдәби теле формалашып җиткәннән соң да ул, азмы-күпме яңарган хәлдә, икенче әдәби тел сыйфатында яшәүдән туктамый (моның мисалларын түбәндә күрербез).

Урта гасырларга караган төркичә катнаш әдәби телләр системасында Кырым татарлары теле үзенә күрә бер аерым урын биләп тора. Бу телнең нигезендә дә XIV йөздә Түбән Идел һәм Хорәзмдә формалашкан кыпчак-угыз теле ята. Һәм элекке кыпчакларның нәселе булган кырымлыларның әдәби теле аерымланып чыгуда көнбатыш кыпчакларның шивәсе аерата зур роль уйнаган. Шуңа күрә әлеге телдә кыпчак элементлары Түбән Сыр-Дәрьяда калыплашкан угыз-кыпчак әдәби теленә караганда да күбрәк очрый. Бу — урта гасырларда шулай иде. Соңра исә аның үсешенә госманлы төркисе көчле йогынты ясый башлый

Хәзер инде угыз-төрекмән тел традициясе тарихына килсәк, аның тәэсире хәтта безнең гасыр башындагы күренекле татар шагыйрьләре һәм язучыларының әсәрләрендә дә нык сизелә. Дөрес, аларның кайберләре иҗатында угыз элементлары соңгы дәвер төрек (госманлы) теленең тәэсире буларак та кулланылган. Тик күпчелек очракта мондый хәл элекке әдәби традициянең тәэсире иде. Шулай итеп, хәтта хәзерге татар әдәби теле формалашып җиткәч тә әлеге катнаш кыпчак-угыз теле икенче әдәби тел — дини-дидактик, тарихи-педагогик әсәрләрнең теле булып хезмәт итүдән туктамый. Шуңа күрә дә теге яки бу истәлекнең телен тикшергән вакытта кайбер төрки телләр узган шушы катлаулы юлны, бик буталган тарихи шартларны бер дә истән чыгармаска кирәк.

Әгәр төрле дәверләрдә иҗат ителгән катнаш телле төрки истәлекләрнең тел үзенчәлекләрен, аларның милли җирлеген билгеләгән чакта югарыда күрсәтелгән таләпләргә җавап бирелмәсә, бик тиз ялгышырга мөмкин. Бер халык вәкиле тарафыннан иҗат ителгән әдәби әсәрне икенче бер халыкка тагып кую бик ихтимал. Менә шуның өчен дә теге яки бу истәлекнең телен гомуми характерлау әллә ни кыен булмаса да, аның кайда һәм кайсы төрки халык вәкиле тарафыннан язылган булуын ачыклау шактый четерекле мәсьәлә.

Гадәттә, Казан белән Оренбург, Акмулла белән Троицк яки шул тирәләрдәге берәр авылда яшәгән һәм беркайчан да Урта Азия шәһәрләрендә булмаган кешенең әсәрләре турында фикер йөрткәндә, аларның телен чыгытайча дип билгеләп килделәр. Чынлыкта исә бу XIII—XIV гасырларда — чыгытай теленә кадәр үк хөкем сөргән урта гасыр әдәби традицияләренең табигый дәвам итүе иде. Кайбер мисалларга да мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

1880 елда Казанда нәшер ителгән «Кисекбаш» (авторы Гали) әсәрен алыйк:

Гали әйтүр, йа Рәсүл, барысарым,
Башыма нә йазмышын күрисәрем.[1]

**Ягъни:**

Гали әйтте: я пәйгамбәр, барырмын.
Башыма ни язылгандыр, күрермен.

«Барысарым» кебек форманы без XIV йөз истәлеге «Мәхәббәтнамә» һәм аннан башка, мәгәр шул дәвергә караган угызча (төрекчә, азербәйҗанча) әсәрләрдә дә очратабыз. Шул ук истәлектә ызгайлар (озатырлар), азак (аяк), казгу (кайгы) һ. б. борынгы угыз формаларын табабыз.

1900 елда Казанда басылган «Кыйссаи ике былбыл» китабында түбәндәге архаик формаларны һәм саф угызча элементларны күрәбез: бер кем ирсә (кемдер), айды (әйтте), вирде (бирде), улган (булган), мәкам дутар (мәкам тотар—яшәр) һәм башкалар.

«Гыйбрәт-намә» китабында исә (1903 елда басылган) архаизмнар һәм саф угызча элементлар тагы да күп очрый: кидисәр (китәр, китәчәк), килисәр (килер, киләчәк), тулыйсар (тулар, тулачак), үлисәр (үләр, үләчәк), дуст санма (дус дип белмә), дүн-күн (төн-көн), кеми мәҗнүн, кеми услу (кеме тиле, кеме аңлы) һ. б. Кыскасы, бу әсәрдә бик нык архаиклашкан сүзләр дә, саф угызча элементлар да күп кулланылган.

1803 елда Санкт-Петербургта, «татарча» дип, татарлар өчен чыгарылган медицина китабыннан түбәндәге үрнәкләрне алырга мөмкин: бу замана тикрү (бу

[1] Мисаллар хәзерге татар графикасы һәм орфоэпиясе нигезендә бирелә.

заманга чаклы), һич кандан (һич кайдан), кәндүләре (үзләре), ушандаг (шундый) һ. б. Ә «Китабы мостатаб»та (Казан, 1845 ел) мондый фактлар бар: мәглүм ула (мәгълүм булсын), кыйаматә дикин (кыяматкә кадәр), диргүзсә (тергезсә), дөрлү (төрле) һ. б. Архаизмнар шулай ук «Тәкый гаҗәп» (Казан, 1912 ел) китабында да шактый: дөнйа ичрә мәнмен тәйү күксен киргәй (бу дөньяда мин генә дип күкрәгеен киерер), уганым (тәңрем), изим (тәңрем), камуг җанлар (барлык җаннар), чыгубән (чыгып), тәмуг сары (тәмугка таба) һ. б.

Менә шундый иске сүзләр, угыз элементлары 1806, 1845, 1846 һәм башка елларда Казанда татарлар өчен бастырылып чыгарылган миссионер китапларында да әллә никадәр. Аларда да һәр адым саен: ичрәсендә (эчендә), кәндүсендә (үзендә), һәп адәмләр (барлык кешеләр), канда (кайда) һәм башка шулар кебек мисалларны очратабыз.

Саф *уйгурча* һәм борынгы *угызча* элементларны мәгълүм «Шура» журналында, мәсәлән, аның 1910 елгы саннарында басылган татар авторларының шигырьләрендә дә табарга мөмкин...

Узган гасырның икенче яртысында һәм революциягә кадәр Үзбәкстан шәһәрләреннән Ташкент, Сәмәрканд һәм Бохараларда литография ысулы белән нәшер ителгән китапларда исә икенчерәк картинаны күзәтәбез: үзбәк язучылары узган гасырда ук үз телләрен архаизмнар һәм угыз-төрекмән элементларыннан арындырып өлгерәләр. Ә менә татарлар арасында тудырылган тарихи-педагогик һәм дини-дидактик әсәрләренең теленә килгәндә исә, алар, югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, шактый архаик катламнарны саклап калганнар. Элекке *уйгур-карлук* традициясе тәэсирен нык татыган, соңрак *угыз* элементлары белән дә шактый ашланган бу архаик язма телнен тарихы, кайберәүләр уйлаганча, *чыгытайчага* түгел, бәлки аннан да элгәррәк калыплашкан *Алтын Урда дәвере әдәби теленә* барып тоташа. Мәсьәләнең бу ягын һич тә онытырга ярамый. Тюрколог А. Н. Кононов үзенең бер рецензиясендә[1] дөрес күрсәткәнчә, чыгытай теле формалашуда элгәре караханилар дәүләтенең теле белән бергә Җучи улусының әдәби теле дә база булып хезмәт иткән[2]. Соңрак исә бу тел, ягъни чыгытай теле, Урта Азиядә хөкем сөргән уңай шартлар аркасында архаизмнардан арына һәм иске үзбәк әдәби теле дигән бай традицияле әдәби телгә әверелә. Шул ук вакытта ул гарәп, фарсы алынмалары исәбенә дә нык байый. Нәваи дәверендә ул, әйткәнебезчә, үзенең иң югары ноктасына ирешә. Кыскасы, иске татар телен һичвакытта да чыгытай теленең бер ярчыгы дип карарга ярамый: үз традицияләре белән ул тирәнгәрәк, элгәререк дәверләргә, борынгырак чыганакларга барып тоташа.

Дөрес, Алтын Урда дәүләтенең язма әдәби теле шома юлдан гына бармый. Хәтта ул Түбән Сыр-Дәрья, Харәзм кебек мәдәни үзәкләрне югалткач, аннары мәмлүкләр Мисыры кебек яңа төрки культура учаклары белән булган тыгыз мөнәсәбәтләрен өзгәч, элекке интенсив үсүеннән туктый, алга таба сүнә баруга йөз тота. Әкрен-әкренләп дөньяви нәфис әдәбиятны катып калган архаик телле дини мистик, тарихи, дөресрәге, мифик-суфизм әсәрләр кысрыклап чыгара.

Шушы әйтелгәннәрдән күренә ки, XIV гасыр безнең культурабыз, әдәбиятыбыз тарихында катлаулы һәм узганны аңлау өчен иң мөһим дәверләрнең берсен тәшкил иткән икән. Әйе, бары шуннан соң гына төрле төбәкләрдә яңа язма әдәби телләрнең нигезләре салына башлый, ә болары үсә-килә хәзерге дәвер милли төрки телләргә тоташа.

Менә шуның өчен дә язма истәлекләрнең телен тикшереп билгеләгән, аларның текстларын бастырып чыгарган чакта тел-лингвистик фактлары өстенә гражданнар тарихын, әсәр иҗат ителгән тарихи-географик шартларны да тиешле дәрәҗәдә өйрәнмичә, ачыкламыйча, ниһаять, берише истәлекләрне үзара чагыштырып карамыйча торып, аларны теге яки бу халыкның гына бабаларына нисбәт итеп, бер милли җирлеккә генә кайтарып калдырырга омтылу бер дә акланмый. Шуңа күрә күп санлы истәлекләрне тиешле эзлеклелек белән тикшереп, аларның текстларын да сыйфатлы итеп бастырып чыгарганчыга, менә шундый бай база нигезендә аларны үзара чагыштырып һәм гомумиләштереп тикшерә алганчыга кадәр, безнеңчә, мондый

[1] А. М. Щербакның «Иске үзбәк теленең грамматикасы» исемле хезмәтенә (М., 1962) язылган рецензия — «Общественные науки» журналы. Ташкент. 1963 ел. 8 сан, 65 бит.

[2] «Җучи улусы» дип гомумән Алтын Урдага да, аның көнчыгыш өлешенә дә әйтәләр. Биредә соңгы төшенчә күз алдында тотыла.

милли күзлектән генә чыгып билгеләмә бирүләр белән мавыкмыйча торырга, бәлки угыз-кыпчак теле һ. б. шулар кебек нейтраль, мәгәр фәнни объектив атамалардан активрак файдалану хәерлерәк булыр.

Дөрес, соңгы вакытларда бу юнәлештә дә кайбер омтылышлар юк түгел. Мәсәлән, Н. А. Баскаков үзенең «Төрки телләрне өйрәнүгә кереш» исемле хезмәтенең төзәтелгән икенче басмасында шундый нейтраль атамаларны куллану юлына күчкән.

Моннан тыш, әдәби истәлекләрнең теленә карата алар барлыкка килгән территорияләрнең исемнәрен дә файдаланып булыр иде. Әйтик, Хорәзминең «Мәхәббәтнамә» исемле поэмасын, күренекле рус тюркологлары билгеләгәнчә, Алтын Урда төркисендә язылган әсәр дип атарга да мөмкин. Чөнки болай иткәндә бу истәлекнең Алтын Урда дәүләте составына кергән Түбән Сыр-Дәрьядан язылган булуы да онытылмаячак. Ә лингвистик күзлектән караганда, аны кыпчак-угыз телендә язылган дип билгеләргә мөмкин. Котыбның «Хөсрәү вә Ширин» китабын да шулай ук Алтын Урда төркисе, яисә уйгур традицияләренең көчле тәэсирен татыган угыз-кыпчак телендә дип, аны төрки телләренең 3 - группасына (ягъни «аяк» урынына «азак» дип сөйләүче шивәләр группасына) кертергә кирәк. Әхмәт Ясәвинең «Хикмәтләре» исә Сыр-Дәрья әсәре булып, кыпчак-угыз теленең j — группасына («з» урынына «й» авазын актив куллана торган шивәләр төркемәнә) нисбәт ителергә тиеш. Сәйф Сараиның «Гөлстан»ы да кыпчак-угыз яисә Алтын Урда-Мисыр төркисе дип атала алыр иде.

«Алтын урда төркисе» дигән төшенчәдән файдаланганда мин хәзерге төрки халыклардан төрекмән, казакъ, татар, үзбәк, башкорт, нугай һ. б. бабалары әлеге дәүләт составына кергән җирләрдә яшәгән булуларын күз алдында тотам. Димәк, шул халык-кабиләләрдән чыккан галимнәр, язучылар, шагыйрьләрнең һәммәсе дә диярлек ул дәүләттәге мәдәни хәрәкәткә, әдәби процесска, язма телнең үсеп баюына актив рәвештә катнашканнар. Шуңа күрә дә мин бу дәүләт территориясендә һәм мәмлүкләр Мисырында иҗат ителгән әсәрләрне төрки халыкларның күпчелеге (нугай, төрекмән, казакъ, үзбәк, татар, башкорт һ. б.) өчен уртак мирас дип исәплим.

# ҖӘҮҺӘРЛӘР САНДЫГЫ

Соңгы елларда татар халык иҗатын өйрәнү өлкәсендә сизелерлек уңышлар яуланды. Моны, барыннан да элек, фольклор әсәрләренең чын фәнни нигезләрдә төзелгән калын-калын җыентыклары дөньяга чыгуы күрсәтеп тора. Әкият, бәет, мәзәк, җыр, мәкаль кебек жанрлар буенча мәйданга килгән шундый хезмәтләр фәнни даирәләрдә дә, киң катлау укучылар тарафыннан да лаеклы рәвештә югары бәяләнделәр.

Ләкин бездә әле шушы вакытка кадәр халык поэзиясенең бик үзенчәлекле төрләреннән берсе булган табышмакларның башка фольклор томнары белән янәшә куярлык җыентыгы төзелгәне юк иде. Ниһаять, күптән түгел мондый җыентык та дөнья күрде.[1] Татар халык иҗатындагы табышмаклар байлыгын шактый тулы гәүдәләндергән бу китапны күренекле язучы һәм галим Нәкый ага Исәнбәт хәзерләгән. Аның тарафыннан ук «Татар табышмаклары турында» исемле тирән эчтәлекле кереш мәкалә язылган, күп кенә әсәрләргә төрле характердагы фәнни аңлатмалар бирелгән.

Җыентыкка кертелгән табышмакларның саны 4 меңнән артып китә. Бу азмы яки күпме? Мондый бер чагыштыру ясарга мөмкин. Бер-ике ел элек СССР Фәннәр Академиясенең рус әдәбияты институты (Пушкин йорты) тарафыннан чыгарылган «Загадки» җыентыгында биш мең ярым табышмак тупланган иде. Күрәсез, бу житди академик басмадан Нәкый Исәнбәт төзегән җыентык үзенең күләме буенча күпкә калышмый. Алай гына да түгел, төзүче үз кулында җыелган барлык табышмакларның биш мең чамасы булуын әйтә (93 бит). Инде афористик жанр әсәрләрен җыю әкиятләр яки җырлар язып алу кебек үрчемле булмавын да исәпкә кертсәк, бу саннар артында күпме хезмәт, никадәр тырышлык торганлыгын аңлау читен булмас. Китапка кергән әсәрләрнең иң зур күпчелеге Нәкый аганың үзе тарафыннан озак еллар дәвамында халык арасында йөреп бөртекләп җыйналган.

Билгеле, татар табышмакларын җыю һәм бастыру белән шөгыльләнүчеләр Исәнбәткә кадәр дә булган. Әле 1842 елда ук Оренбургтагы Неплюев хәрби училищесының татар теле укытучысы Мартиньян Иванов үзенең «Татарская хрестоматия» дәреслегендә, башка төр фольклор әсәрләре белән бергә, 34 табышмак та бастыра. Узган гасырның икенче яртысында Г. Балинт, В. Витевский, М. Салихов, Т. Яхин, К. Насыйри, Н. Катанов кебек галимнәр һәм мәгърифәтчеләр татар халкының телен, этнографиясен, тарихын өйрәнү яки балалар өчен уку китаплары төзү кебек максатларда табышмакларга да мөрәҗәгать итәләр. Егерменче йөз башында исә Г. Арсланов һәм Х. Бәдигыйның махсус табышмак җыентыклары дөньяга чыга.

Ләкин Исәнбәткә кадәр булган бу хезмәтләрдәге табышмаклар сан ягыннан күп түгел һәм еш кына бер-берләрен кабатлыйлар. Әгәр кабатланмый торганнарын гына исәпләсәң, аларның гомуми саны 500 чамасы белән чикләнә. «Исәнбәткә кадәр» дигәндә без әле аның 1941 елда чыккан «Табышмаклар» җыентыгын күздә тотабыз. Анда барысы 1468 табышмак урнаштырылып, шулардан меңгә якыны ул вакытта матбугатта беренче мәртәбә күренгән иде. Инде яңа җыентыгындагыларын кушып исәпләсәк, Н. Исәнбәт тарафыннан фәнни әйләнешкә кертелгән табышмакларның 3 меңнән артып киткәнен күрербез. Бу — галимнең табышмак жанрын өйрәнү һәм популярлаштыру өлкәсендәге эшчәнлегенең беренче әһәмиятле өлеше. Шуңа естәп, Н. Исәнбәтнең үз җыентыгына, беренче

[1] Татар халык табышмаклары. Җыючысы һәм төзүчесе Нәкый Исәнбәт. Казан. 1970 ел.

чиратта, халыкның олы шигъри талантын, аның искиткеч тапкырлыгын, үткенләгән, зирәклеген чагылдырган чын сәнгать әсәрләрен сайлап алырга омтылуын әйтергә кирәк. Безнең халык әкиятләрендә еш очрый торган тылсымлы сандык образы бар. Әкият герое ул сандыкны ачып җибәрсә, аның эче алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән, асыл ташлар белән тулып-тулы булып чыга. Шуның шикелле, «Татар халык табышмаклары» җыентыгын кулына алган һәр кеше аның эчендә чын халык иҗаты җәүһәрләрен табачак.

Табышмакларны китап рәвешендә укучыларга тәкъдим иткәнгә кадәр, аларны билгеле бер тәртип-системага салырга кирәк. Моның берничә төрле ысулы бар. Шулардан киң катлау укучылара исәпләнгән җыентык өчен иң кулае, һичшиксез, тематик яктан төркемләү. Н. Исәнбәт шулай эшләгән дә. Табышмакларны ул «Табигать дөньясы һәм аны эшкәртү», «Кеше, аның әгъзалары; өй-йорт тоту; кием-салым, савыт-саба; аш-су; аларны әзерләү», «Ил-көн иту; белем-һөнәр; юл-сәфәр; алыш-биреш; тел-музыка; уку-язу; һөнәр-техника; сугыш кораллары», «Дингә, руханиларга бәйләнешлеләр һәм төрлеләр» дип исемләнгән дүрт бүлеккә аерып чыга. Бу бүлекләр үз эчләрендә ваграк төркемнәргә аерылалар һ. б. Шушы рәвешчә җентекләп ясалган классификация татар табышмакларының тематик байлыгын күз алдына тулы хәлдә китереп бастыра. Икенче яктан, укучы үзен кызыксындырган әйбер турындагы табышмакны меңләгән әсәр арасыннан җиңел генә эзләп таба ала.

Дөрес, Н. Исәнбәт үз җыентыгында, тематик ысулдан читкә чыгып, «Борынгы табышмаклар» дигән бүлек тә бирә. Аңлашылганча, ул анда теге яки бу билгеләре буенча шактый борынгы заманнарныкы дип исәпләргә мөмкин булган әсәрләрне туплый. Мондый бүлекнең фәнни әһәмияте искиткеч зур. Бер яктан, ул жанрның үз тарихын, аның электәге иҗтимагый ролен һәм сәнгатьчә үзенчәлекләрен, икенче яктан, халыкның борынгы тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, йола-ысулларын өйрәнү өчен житди чыганак булып тора.

Табышмаклар тематика һәм эчтәлек ягыннан гына түгел, бәлки төзелешләре, формалары буенча да төрләргә бүленәләр. Татар фольклористикасында, гадәттә, дүрт төр күрсәтелә иде: метафорик табышмаклар, сорау табышмаклар, арифметик табышмаклар һәм әкият табышмаклар. Н. Исәнбәт бу классификациягә кайбер әһәмиятле өстәмәләр, төгәллекләр кертә. Мәсәлән, ул татар халык иҗатында да «әйтешле табышмаклар» булганын күрсәтә һәм аларның кызыклы гына үрнәкләрен китерә. Сорау өлеше дә, җавабы да тезмә рәвештә иҗат ителеп, көйләп башкарыла торган мондый әсәрләр борынгы заман төрки поэзиясендә бик еш очраган. «Мондый тоткарсыз рәвештә җыр чыгарып әйтүче илһами (импровизатор) шагыйрьләр урта йөзләрдә Идел — Җаекта күп булганнар. Алар арасында шигырь әйтешү, ярыш уздыру йолалары булган. Бу ярышта тезмә табышмаклар әйтеп каршы якны гаҗиз итүләр дә аз булмаган», — дип яза галим (67 бит). Бу факт татар табышмакларының тарихын һәм үсү юлын ачыклауда зур әһәмияткә ия.

Гадәттә «сорау табышмаклар» исеме астында йөртелүче әсәрләрне Н. Исәнбәт «Башваткыч җорлык белән сорау һәм аңа тапкыр җаваплар», «Туганлыкны төпчүләр», «Тоек (каламбур), сүз уйнату, шарадалар» кебек ваграк төрләргә аера. «Әкият табышмаклар» белән бергә, үзенең җыентыгында ул «мәзәк табышмаклар» да китерә. Һич арттырусыз әйтергә мөмкин: татар табышмакларына эчтәлек-тематика ягыннан һәм шулай ук төзелешләренә карап шундый төпле фәнни классификация ясавы белән Н. Исәнбәт безнең фольклористикабызның көн тәртибендә торган мөһим бер эшне башкарып чыккан.

Халык иҗаты әсәрләрен фәнни җыентыклар итеп бастыруның кайбер мәҗбүри (һәм, әйтергә кирәк, безнең татар фольклористикасы тарафыннан да шактый үзләштерелгән) принциплары бар. Җөмләдән берсе — текстларга искәрмә-аңлатмалар бирү. Н. Исәнбәтнең моңа кадәр дөнья күргән җыентыклары да бу яктан үрнәк булырлык дәрәҗәдә аерылып торалар иде. Шушы күркәм сыйфат «Татар халык табышмаклары» өчен дә хас. Андагы күп кенә әсәрләргә киң эрудицияле галим тарафыннан бирелгән аңлатмалар җыентыкның һәм фәнни, һәм практик әһәмиятен нык арттыралар.

Аңлатмалар үзләре берничә төрле характерда. Беренче чиратта, Н. Исәнбәт табышмакларның кайда язып алынуларын күрсәтә, укучыларны аларның «географиясе» белән таныштыра. Аерым әсәрләрне ул борынгы кулъязмалардан яки басма китаплардан эзләп тапкан. Андыйларга бирелгән искәрмәләр аеруча кызыклы һәм әһәмиятле. Әйтик, бүген дә телдә йөри торган «Үзе көя, үзгәләрне яктырта» (Чырак), «Үзгә-

ләрне ертәр, үзе ялангач калыр» (Энә) кебек табышмаклар 1310 елда Алтын Урдада язылган «Рәбгузи»дә дә теркәлеп калганнар икән.

Н. Исәнбәт табышмакларның бер ишеләрен М. Иванов, Г. Балинт, М. Салихов, К. Насыйри, Т. Яхин, Г. Арсланов, Х. Бәдигый кебек авторларның хезмәтләреннән дә алган булуын искәртә бара. Тик шунсын да әйтик, аерым урыннарда ул бу принципны сакламый. Җыентыкта укучыларга матбугат аша әле электән үк таныш булган табышмакларның шул басма чыганаклары искә алынмау очраклары да күренгәли. Сүз дә юк, ул әсәрләр төзүченең үз җыйналмасында да бардыр. Әмма, фәнни объективлык өчен, аларның беренче чыганакларын да күрсәтү кирәк иде.

Җыентыктагы байтак табышмакларның башка халыклар, бигрәк тә төрки халыклар иҗатындагы параллельләре китерелгән. Фольклор әсәрләрен, аеруча аларның борынгы төрләрен шушы рәвешчә чагыштыру, һичшиксез, Н. Исәнбәтнең үз сүзләре белән әйтсәк, «төрки халыкларның тел һәм авыз иҗатлары үсешендә үзара тарихи һәм мәдәни тыгыз мөнәсәбәтләре, бер-берсенә алмаш тәэсир итешүләре хакында сүз алып барырга» мөмкинлек тудыра.

Табышмак — халык иҗатының бик борынгы төрләреннән берсе. Фактик материаллар күрсәткәнчә, жанрның эчтәлеге элек-электән үк халыкның тормыш-көнкүреше, төгәлрәк әйткәндә, шул көнкүрештәге конкрет әйберләр: йорт-җир, кием-салым, аш-су һ. б., шулай ук халыкның борынгы ышанулары, йолалары, гореф-гадәтләре белән тыгыз бәйләнештә булган. Табигый ки, заманалар үткән саен элекке ышанулар акрынлап онытылган, иске көнкүреш әйберләре кулланылыштан чыга барган. Әмма алар белән бәйләнгән борынгы табышмакларның кайберләре, чын камиллеккә ирешкән сәнгать әсәрләре буларак, безнең көннәргә килеп җитә алганнар. Аерым әсәрләрнең хәзергәчә сакланып калуларына борынгы язма чыганаклар да ярдәм иткән. Әлбәттә, бу әүвәлге заман табышмаклары еш кына бүгенге укучы өчен аңлашылып та бетмиләр. Мондый очракларда Н. Исәнбәт үзенең укучылары кулына барлык серләргә үтеп керә ала торган хикмәтле ачкыч тоттыра. Ул биргән аңлатмаларның тирәнлегенә, илһами бер хыял белән өретелгән булуына сокланмыйча мөмкин түгел.

Бохараның былбылы,
Багы Ирәмнең гөле,
Ай-һай аның йөрмеше,
Таш капкага кермеше.

Дөресен әйтик, «былбыл», «гөл» кебек шигърияте сүзләрдән торган шушы табышмакта сүз... тычкан хакында барадыр дип без башыбызга да китерә алмас идек. Инде җавапны китаптан карап белгән тәкъдирдә дә, бу «идән асты кошының» ни өчен шундый гүзәл һәм көяз зат итеп сурәтләнүенең серенә төшенмәс идек. Ләкин безгә китап битенә карап авыз ачып утырырга туры килми. Чөнки табышмакның астында ук аңа аңлатма бирелгән. «Гарәпләрнең исламга кадәрге борынгы легендалары буенча, Гарәбстанда кадим заманнарда Шәддад бине Гад дигән бер бик бай патша булган. Янәсе, ул теге дөньяда оҗмах булыр дигәнгә каршы аны бу дөньяда төземәкче булган. Ирәм багы дигән искиткеч бакчалар, гаҗәеп сарайлар, энҗе-мәрҗәннәр белән тулы зиннәтле шәһәр салдырып, аны тышкы дөньядан беркем дә үтеп кермәслек бик калын биек таш коймалар, чуен капкалар белән уратып алдырган. Ләкин Шәддад җәннәте дигән бу бәхетләләр шәһәренә, астан җирне казып, тычканнар үтеп кергәннәр һәм, бик тиз арада бихисап үрчеп, шәһәрнең бар зиннәтен кимереп, диварларны екканнар, имеш. Тычкан турындагы бу татар табышмагының нәкъ шул борынгы легенда аша тычканны шигъри тасвирлавы белән халык теленә кереп саклануы кызыклы», — дип яза Исәнбәт үзенең бу аңлатмасында (494 бит).

Менә йолдызлар турында «Без, без, без идек, без унике кыз идек...» дип башланган мәгълүм табышмак. Ул «Кап та коп» уенында такмак буларак та әйтелә. Аны, беренче карашка, шаян, йөгерек сүзләр тезмәсе дип кенә кабул итәргә мөмкин. Әмма, тирәнгәрәк китеп карасаң, монда да бер хикмәт бар икән. Безнең халыкта борында күктә унике татар кызы 12 йолдыз булып мәңге яшәүгә ирешкәннәр, дигән ышану булган.

Озынгарак китсә дә, тагын бер мисал: «Ишек артында алтын таяк». Җавабы «кияү» диелгән. Ярый, кияү «алтын таяк» дип сурәтләүгә лаек та булсын ди. Ләкин ни өчен ул **ишек артында!** Чөнки элек кыз катына килгән кияүне юри, күрмәгәнгә салышып, тышта тоту йоласы яшәгән. Шушы юл белән кияүнең үпкәчәнлеген бетерергә, аны сабырлыкка өйрәтергә теләгәннәр.

Әлегә кадәр без «Татар халык табышмаклары» авторының җыючы һәм төзүче буларак башкарган эшләрен күздән кичердек.

Болардан тыш, алда әйткәнебезчә, хезмәтнең шактый күләмле теоретик өлеше дә бар. Җыентыкка бирелгән кереш мәкаләсендә Н. Исәнбәт жанрның тарихын һәм теориясен ачыклаучы җитди проблемалар куя, табышмакларның килеп чыгуын, аларның үсешен, җәмгыять тормышындагы ролен, тематикасын һәм эчтәлеген, шигъри үзенчәлекләрен җентекләп тикшерә. Ул шулай ук табышмаклар белән язма әдәбиятның үзара йогынтысы, аларның халыктан халыкка күчүчәнлекләре, башка фольклор төрләре белән бәйләнеше кебек мәсьәләләргә дә туктала.

Табышмакларның килеп чыгуын, аларның борынгы функциясен ачыклаганда галим, тарихи материаллар булмауга карамастан, үзенең фикерләрен, фараз кылуларын мөмкин кадәр дәлилле итәргә омтыла. Көчле микроскоп астына куеп карагандай, жанрның «йомак» дигән элекке атамасында гына да әллә никадәр мәгънә, хикмәт эзләп таба. Татар телендә **йом** тамырыннан **йомша, йомшарту, йомыш** сүзләре бар. **Йомыш кушу** — эш кушу, кушып эшләтү. Шуннан ясалган **йом, йомша** сүзләре бик борынгы им-том, ырым итүче шаманнарның табигатькә тәэсир итү, андагы «ия»ләрне буйсындыру, йомшарту, йомышка кушу процессындагы ырым, сихер, магия дигәнне аңлаткан. Жанрның «йомак» дигән исеме нәк шул **йом** тамырыннан килеп чыккан, дип гөман кыла Н. Исәнбәт (10 бит).

Әлбәттә, ул борынгы «йомак»ны бүгенге табышмаклар белән тәңгәл итеп күз алдына китерергә ярамый. Бу йомак (яки «юмак») башта «ырым-тылсым, мифик риваятьләр һәм аларның ритмик башкарылышы белән бергә катнаш, иң борынгы синкретизм хәлендә булган» (12 бит). Шаманизм заманнары үткәннән соң «халык иҗатындагы борынгы синкретизм таркалган, **юмак**ның ырымы ырымга, җыры җырга, әкияте әкияткә бүленгән кебек, табышмак аннан бүленеп «башка чыккан» (20 бит).

Татар табышмакларының килеп чыгуы һәм борынгы җәмгыятьтәге роле турындагы бу карашлар безнең фольклористикада бөтенләй диярлек тикшерелмәгән гаять катлаулы проблеманы чишү юлында җитди адым дип бәяләнергә лаеклы. Ләкин шуның белән бергә без Н. Исәнбәт мәкаләсендәге бер момент белән бөтенләй үк килешеп бетмәс идек. Мәсьәлә түбәндәгедән гыйбарәт. Совет фольклористикасында «табышмак жанрының башлангычы элекке **яшерен тел** яки **табу сүзләр** белән бәйләнгән» дигән гипотеза яшәп килә. Нәкый ага бу гипотезаны тулысынча кире кага.

Фәнни әдәбиятта **табу сүзләр** исеме белән теге яки бу шартларда әйтергә ярамый дип санала торган сүзләрне атыйлар. Алар иҗтимагый үсешнең түбән баскычында торучы кабилә телләрендә аеруча күп очрый. Борынгы җәмгыять тормышында җитди роль уйнаган бу күренешнең нигезендә дә нәкъ Н. Исәнбәт телгә алып үткән мифологик ышанулар, табигатьне җанлы итеп тану (анимизм) ята. Аерым күренешләрне һәм әйберләрне үз исемнәре белән әйтүне тыю, аларны **алмаш исемнәр** белән атап йөртү шулай ук электә сүзнең сихер, тылсым көченә ышануга бәйләнгән була. Мондый алмаш исемнәр кеше өчен хәвефле затны сүз ярдәмендә юашландыру, зарарсызландыру максатын күздә тотып сайланалар. Әйтик, еланга «камчы» дигән алмаш исеме белән эндәшсәң, имеш, ул **камчы шикелле** тыныч кына ятарга тиеш икән. Үз вакытында халык мондый ышануларга зур әһәмият биргән, аларны хәтта кагыйдә төсендә афористик формага да салган. (Мәсәлән: «Җылан дисәң җылата, камчы дисәң тик ята», «Җылан дисәң җылышып килә, корт дисәң корый» һ. б.)

Билгеле, табышмак жанрының генезисын яшерен телгә бәйләүне артык туры сызыклы итеп аңларга кирәкми. Төп хикмәт алар арасында кайбер уртаклыклар, охшашлыклар булуда. Яшерен тел дә, табышмак та әйберне үз исеме белән атамыйча, аны алмаштыралар, кагыйдә буларак, аның сурәтен ясыйлар. Бу сурәт ясау һәр икесендә дә бер үк чаралар ярдәмендә эшләнә. Шуның өстенә, яшерен тел белән табышмакның функцияләрендә зур якынлык бар. Бу соңгысы Н. Исәнбәтнең үз мәкаләсендә дә раслап үтелә.

«Тагын да борынга китсәк, **тел яшерү** анда күбрәк ыру-кабиләләрнең үзара мөнәсәбәт тотышу, ил-яу булышуларында бербересенең «кылын тартып карау» өчен практик чара итеп йөртелгән. Феодаллык һәм соңгы дәверләргә килсәк, тел яшерү анда үзара илче-яучы йөртүләрдә, дипломатия һәм шымчылыкта, хәрби эшләрдә иҗтимагый йомыш үти һәм сәяси роль уйный» (21 бит).

«Әкиятләрдә һәм кайбер сәхнә әсәрләрендә без табышмакларның элек патша сарайларында илчеләр яки халык вәкилләр

ре авызыннан әйтелүен еш күрәбез. Алар дәүләтләр арасында килешү яки сугышу алдыннан бер-берсенең чамасын белү — җәясен тартып карау, сынашу, чүмәкләшү кебек хәлиткеч урыннарда әйтелә итеп күрсәтеләләр. Менә шуннан табышмакларның дәүләт-идарә эшләрендә сәяси роле дә була башлавы аңлашыла» (29 бит).

Бу өзекләр, берсе яшерен тел, икенчесе табышмак турында сөйләсәләр дә, бердәй эчтәлекле булу гына түгел, бәлки бер үк сүзләрдән һәм әйләнмәләрдән торалар диярлек.

Җыйнап әйткәндә, табышмакларның генезисы бик катлаулы проблема. Аңа турыдан-туры кагылучы фактик материаллар булмау сәбәпле, монда «ике икең дүрт» шикелле бәхәссез хакыйкатьләр белән эш итәргә туры килми. Тик шунысы ачык: бу жанр борынгы анимизм дәверләрендә үк барлыкка килеп, кешенең табигать белән көрәшендә серле, тылсымлы бер чара сыйфатында файдаланылган. Безгә калса, яшерен телдәге шартлы атамалар белән Нәкый ага телгә ала торган сихри сүзләр арасында кытай стенасы юк шикелле. Әлбәттә, аның гипотезасы бөтенлеге, эзлеклелеге, фәнни зирәклеге һәм мөмкин булган дәрәҗәдәге дәлиллелеге ягыннан моңа кадәр гомуми төстәрәк әйтелә килгән карашлардан күп өстен тора. Галимнең халык иҗатындагы иң борынгы синкретизмны гәүдәләндерүче йомак турындагы фикерләре кызыклы гына фәнни табыш булырга охшый.

Мәҗүсилек заманнары узып, элекке йомак составыннан аерылып чыкканнан соң, табышмак мөстәкыйль жанр буларак үсә башлый. Табигый ки, аның баштагы ырымчылык-сихерчелек әһәмияте акрынлап юкка чыга. Ләкин ул әле шунда ук хәзердәге кебек күңел ачу, юаныч чарасы булып китми. Бу ике арада жанр тарихының чичәнлек сәнгате белән бәйләнгән бик кызыклы бер сәхифәсе бар. Н. Исәнбәт мәкаләсе безгә бу сәхифә белән якыннанрак танышу мөмкинлеге ача.

Патшалык-дәүләтләр оеша башлагач, табышмак «борынгы культ әйбере булудан бигрәк хикмәт ачкычы итеп тә карала башлый... Элек ул мәҗүси руханилар, ырымчы шаманнар репертуары булса, хәзер аны ил-көн сүзе, җәмәгать фикере, аның тормыш репертуары итү башлана... Шул заманнардан алып аны чыгарып әйтүгә шаманнар түгел, бәлки халык шагыйрьләре, җыручы (җырау)лар, чичәннәр һәм соңрак күчмә халыкларда акыннар катнашалар» (29—30 битләр).

Табышмак шулай хикмәтле әйбер итеп каралгач, аны әйтеп кешенең акылын, тормыш тәҗрибәсен сынау үзенә күрә бер йола булып әверелә. Табышмак әйтешү белән бәйле йолалар турында сүз алып барганда, Н. Исәнбәт гаҗәп кызыклы, әлегә безнең фольклористикада мәгълүм булмаган бер факт хакында хәбәр итә. Башка кайбер халыклардагы кебек, элеккерәк заманда бездә дә авылларда табышмак әйтү өчен үзенә махсус мәҗлесләр уздыру йоласы булган. Ул Болгар—Казанда ел башы дип саналган нәүрүз (март) аенда май чабу[1] вакытларында, нардуган кичәләренең берсендә ясалган. Табышмакны гадәттә олы кешеләр әйтеп, яшьләр чишә булганнар. Җавапны табуда кыенсынган очракларда йола буенча кайбер юнәлткеч сораулар бирергә рөхсәт ителгән. («Нәрсә затыннан?», «Нәрсә җенесеннән?» һ. б.)

Өлкәннәр тарафыннан яшьләрне шушы рәвештә табышмак ярдәмендә сынау-өйрәтү кайчандыр жанрның җитди тәрбияви роль уйнавын тагын бер кат раслый.

Кыска гына рецензиядә без Н. Исәнбәт хезмәтендә күтәрелгән проблемаларның барсына да аерым-аерым туктала алмадык. Кереш мәкалә, фәнни тирәнлеге өстенә, бик җанлы тел белән, мавыктыргыч итеп язылган. Китапны кулына алган һәр кеше аны үзе зур кызыксыну һәм канәгатьләнү белән укыр дип уйлыйбыз.

Инде барлык сөйләгәннәргә бер генә җөмлә белән йомгак ясап куйыйк. Үзенең бу хезмәте белән Нәкый Исәнбәт халык иҗатының төп жанрларыннан берсе булган табышмакларны җыю, бастыру һәм фәнни яктан өйрәнү эшен яңа бер баскычка күтәрде.

**ХУҖИ МӘХМҮТОВ.**

---

[1] Май чабу — элекке Болгар — Казан календаренча, ел башы марттан башланып, аның хөрмәтенә чаналарга төяләп, нәүрүз әйтеп чапканнар... Русларда бу — масленица дип атала. *(Н. Исәнбәт искәрмәсе.)*

# ӘСӘРДӘН ӘСӘРГӘ ҮСӘ БАРА...



Соңгы еллардагы татар театрлары репертуарында драматург Сәет Шәкүров пьесалары шактый зур урын алып кила. Ул профессиональ театрларыбыз сәхнәләрендә уңыш белән барган унлап пьеса язган автор. Аның Минзәлә һәм Оренбург театрларында уйналган «Тормыш бусагасында», «Зөһрә йолдыз», «Уракчы кыз», «Ана», «Мәхәббәт газабы» спектакльләре татар тамашачыларына яхшы таныш. Сәет Шәкүров кыен һәм катлаулы драма жанры өлкәсендә актив эшли. Аның иҗади осталыгы әсәрдән әсәргә үсә бара. Әйтик, аның 1969 елда Татар дәүләт академия театры сәхнәсенә куелган «Туган туфрак» исемле яңа әсәре тамашачылар тарафыннан аеруча җылы кабул ителде. С. Шәкүровның күп кенә пьесалары журналларда, китапларда басылып чыкты, кайбер әсәрләре конкурсларда премияләр алуга лаек булды. Бу ел аның тагын бер пьесалар җыентыгы басылып чыгачак.

С. Шәкүров пьесалары заманыбызның актуаль проблемаларын, замандашларыбызның уңай образларын чагылдыруга багышланган.

Үзе дә тәҗрибәле актер һәм театрда күп еллар эшләгән кеше буларак, С. Шәкүров театр табигатен яхшы белә, аның әсәрләре театраль һәм сәхнәгә куяр өчен җайлы итеп язылган. Шунлыктан аның әсәрләрен уйнарга артистлар да бик теләп алыналар.

С. Шәкүров пьесалары халык театрлары һәм үзешчән театрлар репертуарында да зур урын алып тора. Аның «Уракчы кыз» исемле пьесасы белән Бөтенсоюз смотрында катнашып, 1967 елны Әтнә халык театры лауреат исемен алуга лаек булды һәм аңа беренче дәрәҗәле диплом бирелде.

Драматург С. Шәкүровның бүгенге драматургиябез мәсьәләләренә кагылышлы мәкаләләр белән матбугатта чыгыш ясавын да әйтеп үтәсем килә.

Минә шуларны искә алып, мин Сәет Шәкүровны СССР язучылар союзына член итеп алынырга лаеклы дип саныйм.

— БАЯН ГЫЙЗЗӘТ.

# ШАТЛАНЫП ТӘКЪДИМ ИТӘМ

Талантлы, зур өметләр баглата торган прозаик буларак, Мөсәгыйт Хәбибуллин иптәшне СССР язучылар союзына членлыкка шатланып тәкъдим итәм.

М. Хәбибуллинның башта «Казан утлары» журналында басылган, аннары Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып чыккан «Унсигезенче яз» исемле повестен



язучылар һәм республикабыз җәмәгатьчелеге хуплап каршы алды.

М. Хәбибуллин дөньяны күп күргән, тормышны бик яхшы белә торган, хезмәтнең шофердан башлап инженерга кадәр булган барлык баскычларын үткән кеше.

Тыйнаклык, кызыксынучанлык һәм үз осталыгын арттыру өстендә туктаусыз эшләү — аңа хас сыйфатлар.

Менә шулар миңа иптәш Хәбибуллинны шактый перспективалы язучы дип исәпләргә мөмкинлек бирә.

АТИЛЛА РАСИХ.

# ХӘЕРЛЕ ЮЛ ТЕЛИМ



Шагыйрә, хат язып, миннән рекомендация сораган... Күптән үк әйткәнем бар, рәхим итегез, бик теләп язам.

Клара Булатованың ике җыентыгын һәм соңгы вакытларда «Казан утлары» белән «Азат хатын» журналларында күренгән шигырьләрен укып чыктым. Шулардан туган тәэсир мондый: Булатова — иҗат иясе. Аның үз дөньясы, тормышны үзенчә кабул итүе, үз җыры бар. Аның ике җыентыгындагы 62 шигыре бу фикерне бик рәхәтләнеп раслый ала. Шулар арасыннан шагыйрәнең «Язлар алда», «Син инженер», «Алтынчы класстагылар», «Кечке этюд», «Булмый алмашып», «Сугыштан соң беренче җәй...», «Мин зур үскәч», «Син үлгәнсең, имеш», «Ялгыз каен», «Табигатьтә...» исемле шигырьләре тагын да көчлерәк, матуррак һәм тирән хис белән язылганнар. Булатованың иҗаты елдан-ел киңәя, алга атлый барганлыгы, бер урында таптанмавы күренеп тора. Хәзер ул йөз бетереп тормыш мәйданына кереп китте. Аның киң полотнолы әсәрләр иҗат итүен бик ышанып көтәргә була. Моның өчен шагыйрәнең бөтен мөмкинлекләре һәм, барыннан да бигрәк, талант көче бар.

Хәерле юл телим шагыйрәгә.

ШӘЙХИ МАННУР.

# ӘНВӘР ДАВЫДОВ ЭЗЕ БУЙЛАП...

Рөстәм Мингалимов Әнвәр Давыдов эзе буйлап килә. Ул элекке Камышлы районының Йолдыз авылыннан.

Әтисе 1941 елда Бөек Ватан сугышында югала. Рөстәм башта Йолдызда укый, аннары Бөгелмә авыл хуҗалыгы училищесын тәмамлый, Казагыстанга китә, тракторда,



комбайнда эшли. Ташкентта экскаватор заводында хезмәт итә. 1962—67 елларда Казан университетының тарих-филология факультетында укый.

Поэзиягә ул бер генә яктан түгел, төрле яклардан килә... Давыдов эзе буйлап... юлларның ташып чыгуында, интонацион яңгыраштa кайчакта Давыдовка хас ниндидер бер иркенлек сизелә. Бер яктан башланып киткән юлны киңәйтә төшүчеләр, дәвам иттерүче икенче бераүләр була бит тарихта...

Мингалимовның «Эзләр» исемле беренче җыентыгы бар. Юка, ләкин образга, фикергә бай.

Кешене онытып, гомуми шау-шулар белән мавыгу заманы үтте поэзиядә. Бик нык уйлану, фикерләү чоры килде, үз авылына гына бикләнеп, шуннан гына торып бәяләүче түгел, зур дөньяны үзенеке итеп санаучы, аңа үзен хуҗа итеп санаучы, шул поэзиядән дөнья белән сөйләшүче яшь поэзия килде. Мингалимовның «Эзләр»ендә әнә шул масштабны күрәм мин. Шагыйрьне вак нәрсәдә түгел, зурда, заманны зур итеп ача белүендә эзләргә кирәк. «Табыш» шигырендә безнең әнкәләрнең сугыш елларында эзләгән зелпе тамырлары да безгә күп нәрсә турында сөйли.

...Бераздан
Шул арка,
Машина баллоны шикелле,
Бөгелгән
Зур зелпе куагын
Суырып чыгарды төбеннән.

Шул ноктада бүген буровой вышка туктый, нефть бәреп чыга. Нефть-резина... Ефәк, капрон... Барысы да әнкәләренең кайчандыр зелпедән сыдырылып беткән кулларыннан башланып китә...

Мингалимов — шагыйрь, таләпчән шагыйрь. Ул поэзиядә җиңел юлны яратмый. Аның кайбер шигырьләренең авырлыгын эзләнүнең авырлыгы итеп карыйм мин. Гомумән, минем үзем өчен эзләнү күп вакыт төп нәрсәгә әйләнә. Кешенең үлгәннән соң да әле эч көнлек эше кала, диләр. Ә миңа менә шагыйрь үлгәннән соң да әле өч көн буена эзләнеп газапланыр шикелле тоела.

Рөстәм Мингалимовның иҗатына карата 1967 елның декабрендә үткәрелгән семинарда ук инде шагыйрьләр бик җылы сүзләр әйттеләр. Мин үз исемемнән һәм шул иптәшләр исеменнән аны Язучылар союзына тәкъдим итәм.

СИБГАТ ХӘКИМ.

**Фаил Шәфигуллин**

# ДИАЛОГЛАР

## ХӨКЕМ



Яле, Галиулла, җыелыш алдыннан җавап бир. Эшкә исереп килмисеңме икенче?

— Килмим.

— Сүз бирәсеңме?

— Бирәм.

— Юк, болай булмый, Галиулла... Әйдә, бөтен шартын китереп... Кабатла минем арттан... Кичә, унбишенче майда...

— Әгәр дә рөхсәт итсәгез, мин, узган җыелыштагы кебек, үз сүзләрем белән генә әйтер идем...

— Нәрсә? Узган җыелышта сүз бирдеңмени син?

— Бирдем.

— Сүзеңдә тора алмадыңмы?

— Тора алмадым.

— Ни әйтсәң дә, син коллектив алдында, Галиулла. Оят түгелме азрак?

— Азрак оят.

— Оят шул менә... Я, ярар, гаебеңне тануың өчен рәхмәт. Инде син хәзер менә мондый сорауга җавап бир... Узган җыелышта ничек сүз бирдең — телдәнме, әллә язма рәвештәме?

— Телдән.

— Аңлашылды. Ә хәзер язма рәвештә бир... Менә кәгазь, менә каләм... Монда барысы да үзебезнекеләр. Кил, оялма.

— Оялмыйм мин.

— Нишләп торасың алайса?.. Кил, яз.

— Язуым начар минем.

— Үзем язып бирсәм, кул куярсыңмы?

— Куярмын.

— Алдамассыңмы?

— Алдамам.

— Кара аны, Галиулла!.. Коллектив алдында торасың.

# ИДЕЯ

*Телефоннан*



Әйе, завком председателе тыңлый. Кем сөйләшә минем белән?

— Слесарь Әхмәтшин.

— Ә, Әхмәтшинмыни? Исәнме-саумы, Әхмәтшин?.. Ни эш бетерәсең?

— Өйләндем әле менә...

— Кит аннан?! Тәбрик итәм, Әхмәтшин, чын күңелдән тәбрик итәм.

— Карале, иптәш завком! Миңа фатир тиештер бит инде?

— Нәүбәтең ничәнче соң синең?

— Нәүбәт дип, өйләнгәч тә тулай торакта яшәмәм тагын... Нигә тынып калдың?

— Башка бер идея килде әле.

— Нинди идея?

— Минем дә фатир юк бит, Әхмәтшин... Әллә тәвәккәлләп өйләнеп җибәрергә микән?..

# АНЕКДОТ ҺӘВӘСКӘРЕ



Габдрахман абый, менә шушы язуга печать басып җибәрсәнә.

— Һем, язуга? Нинди язу соң ул? Печать басып дисеңме? Печать басу дигәннән бер заманны шулай...

— Габдрахман абый, безнең теге иске самосвал күл басуында буксовать итә калды, шуны сөйрәп кайтырга трактор җибәрмәссез микән дип килгән идек.

— Трактор дисезме, егетләр, ярый, була ул. Утырыгыз, арыгансыз, тартып җибәрегез. Менә миндә высший сорты бар, үзебезнең Казан фабрикгында эшләнгән, мәйтәм, ни генә эшләмиләр хәзер безнең Казанда...

— Габдрахман абый, ә соң трактор?..

— Ватылып бетмәгән булсалар, обязательно җибәрәм, трактор бит ул, ни, тоже капризный машина. Әле менә сез әйткәч, искә килеп төште, точно хәтерләмим: утызынчы елларда микән, мөгаен, соңрактыр.

— Гафу ит, Габдрахман, сүзеңне бүлдердем, теге каһәр суккан үгез бүген тагын көтүдән кайтмады.

— Һи, сыер көтүе дә кайттымыни инде, мин бит, егетләр, ачы таңнан чыгып киткән кеше, китим. Мәфтуха апагызның токмачы куера торгандыр. Йомышларыгыз булса, әнә, ярдәмчегә мөрәҗәгать итегез...

# КЫШКЫ ИРТӘДӘ

Әбәтегез тәмле булсын, Бәдернисаттәй.

— Бергә булсын... И, кара, танымый да торам, Фагыйлә малае икән... Нихәл, нишләп йөрисең?

— Әни оеткыга бер-ике кашык катык бирсен әле дигән ие.

— Катыгым юк шул, акыллым...

— ?!

— Кар һаман явамы?

— Төшкәли.

— Анаң эшкә бармадымыни?

— Юк... Мунча ягабыз.

— Жизнәңнәр кайтмыйдыр ич?

— Юк.

— Атаң терелдеме инде?

— Терелде.

— Эшләмидер әле?

— Юк.

— Һе, һе, шулай диген... Катыгым юк шул, акыллым... Ашарга утыр дисәм инде...

— Сал, булмаса, Бәдернисаттәй. Бик кыстагач, берәр тәлинкә ашармын.

## МӘСКӘҮДӘ ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Узган елның октябрь ахырларында Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре уздырылды. Башкала сәхнәләреннән ун көн буе Татарстан моңнары яңгырап торды, шәһәрнең иң зур клублары, концерт заллары татар артистлары, композиторлар һәм язучылар карамагында булды.

Бәйрәм көннәре СССРның халык артисты **Натан Рахлин** житәкчелегендәге симфоник оркестр концертлары белән башланып китте. Татарстан сәнгать осталарының концертлары да һәркайда зур уңыш белән барды. РСФСРның халык артистлары **А. Аббасов, В. Шәрипова, З. Хисмәтуллина**, РСФСРның атказанган артисты **Р. Садыйков**, Татарстанның халык артисты **И. Шакиров**, Татарстанның атказанган артистлары **Э. Җәләлетдинов, А. Арсланов**, скрипкачыларның халыкара конкурслар лауреатлары **З. Шахморзаева, Х. Әхмәтова**, Г. Тукай исемендәге филармониянең яшь жырчылары **З. Нурмөхәммәтов, Р. Сибгатуллина** һәм башкаларның чыгышларын мәскәүлеләр аеруча жылы каршыладылар.

Мәскәүдә уздырылган мәдәният көннәрендә язучылар да якыннан торып катнашты. 22 октябрьда Әдипләрнең үзәк йортында булып үткән әдәби-музыкаль кичә бу яктан аеруча характерлы. Кичәгә Татарстанның һәм Мәскәүнең күренекле шагыйрьләре, прозаиклары, сәнгать осталары һәм күп санлы тамашачылар килгән иде. Аны Ленин премиясе лауреаты, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе **Сергей Михалков** алып барды. **С. Хәким, М. Әмир, Ә. Исхак, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, И. Юзеев, Г. Зәйнашева, Х. Сарьян, Р. Кутуй, З. Маликов** үзләренең әсәрләрен укыдылар. Мәскәү әдипләреннән **Р. Моран, С. Липкин, Ю. Окунев, В. Ганиев, В. Синицын, В. Цыбин** татар язучыларының әсәрләрен тамашачыларга рус телендә житкерделәр. Шундый ук әдәби кичә Химкидагы культура йортында да үткәрелде. Кичәдә катнашкан язучылардан **Ә. Исхак, С. Хәким, Г. Ахунов, Ю. Белостоцкий, И. Юзеев, Р. Кутуй, Х. Сарьян** үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, укучыларның сорауларына җаваплар бирделәр.

Татарстан сәнгать осталарының йомгаклау концерты Чайковский исемендәге залда булды. Бөтенсоюз радиосы аша бөтен илгә яңгыраган бу концертта КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы членлыгына кандидат, Үзәк Комитет секретаре **П. Н. Демичев**, РСФСР Министрлар Советы председателе урынбасары **В. И. Кочемасов**, РСФСР Культура министры **Н. А. Кузнецов**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе **С. Г. Батыев**, КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре **М. Ф. Вәлиев**, төрле иҗат оешмаларының житәкчеләре катнашты.

Татар мәдәнияте көннәрендә Мәскәү тамашачылары безнең гади гармуннан симфоник оркестрга, авыл җырларыннан опералларга, симфонияләргә китергән иҗади юлларыбызны күрделәр. Татарстанның тормышка тирән мәхәббәт белән сугарылган үзенчәлекле һәм халыкчан сәнгате аларга зур ләззәт бирде. «Правда», «Советская Россия», «Литературная газета», «Литературная Россия» кебек үзәк газеталарда татар әдәбияты һәм сәнгате көннәренә багышланган мәкаләләр чыгып торды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Татарстан АССР Культура министры **Булат Миннулла улы Гыйззәтуллинга**, совет культурасын үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1970 ел 23 октябрь указы белән **РСФСРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

## ЛИВАН МАТБУГАТЫ ТУКАЙ ТУРЫНДА

Бейрутта чыга торган «Әл-голүм» журналы үзенең 1969 елгы октябрь санында күренекле татар шагыйре Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат юлына багышланган мәкалә баскан. Журналның 42—48 битләренә урнашкан ул мәкалә «Габдулла Тукай — хакыйкать һәм азатлык шагыйре» дип атала. Авторы — Мәскәү дәүләт университеты каршында аспирантура тәмамлаган әдәбият белгече **Җәлил Камалетдин**.

## «РОМАН-ГАЗЕТА» БИТЛӘРЕНДӘ «АК ЧӘЧӘКЛӘР» РОМАНЫ

«Роман-газета»ның 1970 елгы 21—22 саннарында, 2 200 000 данә тираж белән, күренекле татар совет язучысы **Габдрахман Әпсәләмовның** «Ак чәчәкләр» романы басылып чыкты. Әсәрне рус теленә танылган совет язучысы, «Ледолом» романының авторы **К. Горбунов** тәрҗемә иткән.

21 санга авторның иҗат юлына багышланган кереш мәкалә урнаштырылган. Ул әдәбият белгече һәм тәнкыйтьче **Т. Резвова** тарафыннан язылган.

## ТАТАР АРТИСТЛАРЫ ЧИТ ИЛДӘ

Совет артистларының бер группасы Һинд океаны ярларында урнашкан илләр буйлап гастрольләрдә йөреп кайтты. Бу

группада Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры артистлары **Ревдар Садыйков** һәм **Сания Хантимерова** да бар иде. Алар чит ил тамашачыларына татар халык биюләре «Әпипә», «Кияү биюе», Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетыннан адажио, Александр Ключаревның вальсын һәм классик биюләр күрсәттеләр.

## ЛАУРЕАТЛАРНЫ ХӨРМӘТЛӘҮ

Билгеле булганча, ВЛКСМ өлкә комитетының Муса Җәлил исемендәге премияләре 1970 елда Казан зур драма театры актеры **Юрий Федотовка** һәм шагыйрь **Равил Фәйзуллинга** бирелгән иде. 16 ноябрьдә Казан шәһәренең Актерлар йортында лауреатларны хөрмәтләү кичәсе уздырылды.

Кичәне, кыскача кереш сүз сөйләп, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты секретаре **И. Хәйруллин** ачты. ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре **А. Василец** **Р. Фәйзуллин** белән **Ю. Федотовка** лауреат значоклары һәм дипломнар тапшырды. Шагыйрь **С. Хәким**, Татарстан язучылар союзының җаваплы секретаре **Г. Ахунов**, В. Качалов исемендәге Зур драма театры артисты **В. Павлова**, ВЛКСМның Идел буе райкомы секретаре **Г. Масленникова** һәм башкалар лауреатларны чын күңелдән котладылар, аларга яңа иҗат уңышлары теләделәр.

Соңыннан республикабыз артистлары көче белән зур концерт бирелде.

## ЗАҺИДӘ БУРНАШЕВАГА 75 ЯШЬ

1970 елның 12 ноябренда әдәбият сөючеләр Татарстан дәүләт музеена күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм шагыйрә **Заһидә Бурнашевага** (Гыйффәт туташ) 75 яшь тулуга багышланган бәйрәм кичәсенә җыелдылар.

Кичәне, кыскача кереш сүз сөйләп, язучы **Афзал Шамов** ачты. Танылган балалар язучысы **Госман Бакиров** кичәдә катнашучыларны **Заһидә Бурнашеваның** бай тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеге белән таныштырды. Аннары юбилярга котлау хатлары һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды, аның исеменә килгән телеграммалар укылды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Октябрь — ноябрь айларында Татарстан язучылар союзы каршындагы иҗат секцияләренең отчет-сайлау җыелышлары булып узды. Алар шактый актив һәм оешкан төстә үттеләр. Җыелышларда татар әдәбиятындагы аерым жанрларның бүгенге торышына тулы анализ ясалды, язучылар коллективы алдында торган актуаль мәсьәләләр каралды.

* * *

Отчет-сайлау җыелышларын балалар әдәбияты секциясе башлап җибәрде. Секциянең 23 октябрьда уздырылган утырышында бюро председателе **М. Фәйзуллинаның** хисап докладын тыңланды. Аннан балалар әдәбиятына караган мәсьәләләр буенча җанлы сөйләшү башланып китте. Фикер алышуларда уннан артык кеше катнашты. Алар арасында ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты секретаре **И. Хәйруллин**, язучылардан **Г. Бакиров**, **Ә. Бикчәнтәева**, **Л. Ихсанова**, **Н. Гайсин**, **М. Шабаев**, **М. Мазунов**, **Р. Батуллин**, **Р. Мингалимов** һәм башкалар бар иде.

Җыелыш, **Р. Мингалимов**, **Ш. Галиев**, **Л. Ихсанова**, **Р. Батуллин** һәм **Х. Халиковлар** составында, бюроның яңа составын сайлады. Балалар әдәбияты секциясенең бюро председателе итеп **Р. Мингалимов** билгеләнде.

* * *

Проза секциясенең отчет-сайлау җыелышы 18 ноябрьда уздырылды. Бюро председателе **А. Гыйләҗев** җыелышта катнашучыларны 1970 елда дөнья күргән яңа әсәрләр белән таныштырды, прозаиклар алдында торган бурычларга тукталды. Доклад буенча фикер алышуларда **И. Гази**, **Ә. Еники**, **А. Расих**, **Г. Кашшаф**, **Н. Дәүли**, **Г. Ахунов**, **С. Сабиров**, **Х. Сарьян** һәм башкалар катнашты.

Проза секциясенең яңа составына биш кеше (**Б. Камалов**, **М. Мәһдиев**, **Х. Сарьян**, **Ф. Мансуров** һәм **М. Маликова**) кертелде. Председатель итеп **Б. Камалов** сайланды.

* * *

Тагын бер көннән тәнкыйть секциясенең отчет-сайлау җыелышы булды. Бюроның бер еллык эше белән **Р. Мостафин** таныштырды. Җыелышта **Г. Халит**, **Х. Хәйри**, **И. Гази**, **И. Нуруллин**, **А. Әхмәдуллин**, **Г. Ахунов** һәм башкалар чыгыш ясады. Җыелыш бюроның элекке составын тагын бер елга үзгәртми калдырды. Бюро председателе итеп кабат **Р. Мостафин** сайланды.

## КОНСЕРВАТОРИЯ АЧЫЛУГА 25 ЕЛ

Казан дәүләт консерваториясе эшли башлауга 25 ел тулды. Татар совет музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән һәм чирек гасыр вакыт эчендә дистәләрчә композиторлар тәрбияләп үстергән, күп санлы музыкантлар, җырчылар әзерләп чыгарган бу уку йортының олы бәйрәмен республикабыз җәмәгатьчелеге киң күләмдә билгеләп үтте. Газета-журнал битләрендә консерваториянең күп кырлы эшчәнлеген чагылдырган мәкаләләр басылды, шәһәребезнең концерт залларында, клубларда, культура сарайларында зур бәйрәм концертлары куелды.

* * *

Казан дәүләт консерваториясенең 25 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш 1970 елның 20 ноябрендә уздырылды. Консерваториянең актлар залында булып узган бу җыелышта партия, совет, комсомол хезмәткәрләре, мәдәният әһелләре һәм күп санлы музыка сөючеләр катнашты.

Консерваториянең оештырылуы, туганлаш республикалар, өлкәләр белән элемтәсе, халкыбызга күрсәткән зур хезмәтләре турында күренекле татар совет композиторы, СССРның халык артисты, Дәүләт премиясе лауреаты, профессор **Нәҗип Җиһанов** сөйләде. КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре **М. Вәлиев** КПСС өлкә комитеты, Татарстан АССР Верховный Советы һәм ТАССР Министрлар Советының котлавын тапшырды. Аннары консерватория исеменә килгән котлаулар, телеграммалар укылды, бүләкләр тапшырылды.

Ахырдан сәнгать осталары һәм студентлар көче белән зур концерт бирелде.

* * *

Татарстан Верховный Советы Президиумы, югары квалификацияле музыка кадрлары хәзерләүдәге һәм совет музыкасын пропагандалаудагы зур хезмәтләре өчен, Казан дәүләт консерваториясен **Почет грамотасы** белән бүләкләде.

* * *

Квалификацияле кадрлар хәзерләүдәге һәм совет музыкасын пропагандалаудагы хезмәтләре өчен, Казан дәүләт консерваториясенең җыр кафедрасы укытучысы **Валентина Андреевна Лазькога** һәм гомуми фортепьяно кафедрасы мөдире **Назнинә Газиз кызы Сабитовскаяга Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

Казан дәүләт консерваториясенең музыка тарихы һәм теориясе кафедрасы укытучысы **Галина Яковлевна Касаткина**, консерваториянең тынлы инструментлар кафедрасы мөдире **Шамил Гыйльметдин улы Низаметдинов** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының **Почет грамоталары** белән бүләкләнде.

## КЫЗЫКЛЫ КҮРГӘЗМӘ

Казан актерлар йортында «Театр сәхнәләрендә коммунист образлары» дигән темага фотокүргәзмә ачылды. Аны Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге оештырган. Күргәзмәгә «Муса Җәлил», «Давылга табан», «Умырзаялар», «Беренче атлы армия», «Шамил Усманов», «Баһадирлар» кебек спектакльләрдән фоторәсемнәр, программалар, афишалар куелган.

Партиябезнең XXIV съезды хөрмәтенә багышлап оештырылган бу күргәзмә съезд ачылган көннәргә кадәр эшләячәк.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры тамашачыларга **Нәкый ага Исәнбәтнең** «Әбүгалисина» исемле әсәре буенча эшләнгән яңа спектакль күрсәтә башлады. Пьесаны сәхнәгә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Прозат Исәнбәт** куйган, художнигы — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Энәс Тумашев**. Рольләрне Татарстанның халык артистлары **Ибраһим Гафуров** һәм **Гали Надрюков**, Татарстанның атказанган артисты **Габдулла Фәтхуллин**, артистлардан **Равил Шәрәфиев, Гөлсем Исәнгулова, Илдар Хәйруллин** һәм **Флера Хәмитовалар** башкара.

* * *

Минзәлә татар дәүләт драма театры **Гөлшат Зәйнашеваның** «Кем гүзәл?» исемле яңа комедиясен сәхнәгә чыгарды. Спектакльнең режиссеры Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай бүләге лауреаты **Сабир Өметбаев**. Пьесага музыканы **З. Гыйбадуллин** язган. Рольләрне театрның яшь **артистлары башкара.**

## ГАИЛӘ ТЕАТРЫ

Пермь өлкәсе Елпачиха культура йорты каршындагы драма коллективын хаклы рәвештә гаилә театры дип йөртәләр. Бу түгәрәктә катнашучы һәвәскәрләрнең иң зур күпчелеге (барлыгы 23 артист) коллектив җитәкчесе **Әмин Искәндәровның** үз кешеләре: уллары, кызлары, киленнәре, оныклары һәм туганнан туганнары.

**Әмин Искәндәровның** сәхнә эшчәнлеге моннан илле еллар элек башлана. Ул оештырган драма коллективы акрынлап үсә, ныгый бара. Берәздән бу үзешчән театрга Әминнең ун баласы катнашып китә. Торабара репертуарда төп урынны татар классиклары һәм совет драматургларының иң яхшы әсәрләре ала. Коллективның соңгы эше — Мирсәй Әмирнең «Гөлшаян» пьесасы. Бу спектакль белән «гаилә театры» үзенең илленче сезонын ача.


oooooooooooo


Сара САДЫЙКОВА
музыкасы

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА
сүзләре

# ҺӘЙКӘЛ ҖЫРЫ

*Бәет*






Мин егерме яшем тулган көнне
Үлеп калдым сугыш кырында.
Мине хәзер таштан ясадылар,
Һәйкәл итеп зур бер урамга.
Газиз әнкәм җылый, дәшмисең дип.
Мин бит солдат таштан коелган.
Яшь йөрәгем ят ил туфрагында,
Күптән җир куенына уелган.

Мин сөйләшмим, мин тик җырлыйм гына,
Көем минем йомшак җил генә.
Мин җырлармын, мәңге мин көйләрмен,
Имин булсын туган ил генә.
Имин булсын илем, диеп үлдем,
Мин егерме яшем тулганда.
Исмем яшәр җирдә туган илем,
Туган халкым исән булганда.

Иңбашымда бала, кулда кылыч,—
Басып торам һәйкәл булып мин.
Кылыч булмас иде кулларымда —
Сугыш дәһшәтләрен онытмыйм.
Бөек җиңү көнен күрә алмый,
Ут эчендә үлеп калдым мин.
Онытмыйсың, илем, бүген миңа
Таштан коеп һәйкәл салдың син!

*Хөрмәтле иптәшләр!*

«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә. Һәр айның 20 сенә кадәр сез алдагы айлар өчен журналга языла аласыз.

Безнең журналга бернинди чикләүсез һәм илебездәге теләсә кайсы элемтә бүлегендә язылырга мөмкин. Аңа язылу шартлары «Союзпечать»ләрдәге газета-журналлар каталогында күрсәтелгән. «Казан утлары» ул каталогка 73210 номерлы индекс белән теркәлгән.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210